# казан утлары

11.1996



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**11**

**(889)**

**1996**

КАЗАН


## *Бу санда*


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Л. ШАГЫЙРЬҖАН. «Игезәкләр» йолдызлыгыннан мин... *Шигырьләр* ... 3
С. ПОВАРИСОВ. Яшьлек иртәсе. *Роман* ... 9
Ә. ГАДЕЛ. Сезгә — шигырем шифасы. *Шигырьләр* ... 44
Р. ШӘРИПОВ. Моңлы җыр. *Шигырьләр* ... 48
З. ЗӘЙНУЛЛИН. Ат караклары. *Роман* ... 53
ИДЕЛБИКӘ. Триптих. *Шигырьләр* ... 119
Б. КАМАЛОВ. Кыска хикәяләр ... 127
Ф. НӘГЫЙМОВ. Кыңгырау. *Хикәя* ... 133

ШӘҺИДӘ МАКСУДОВАГА — 70 ЯШЬ

Р. НИЗАМИЕВ. Тынгысыз сабырлык ... 123
ГӨЛШӘҺИДӘ. Моңнарымда — җиде кыл. *Шигырьләр* ... 124

РӘСТӘМ КУТУЙГА — 60 ЯШЬ

М. ӘГЪЛӘМОВ. Кутуй — үзе бер дөнья ул ... 138
Р. КУТУЙ. Килеп чыгышым. *Шигырьләр* ... 140
Р. КУТУЙ. Ир кешеләр. *Хикәя* ... 143

ШАГЫЙРЬ АРХИВЫННАН

Р. ГАТАШ. Җыр белән тәләнгән әҗәт ... 149
Р. РӘКЫЙПОВ. Җыр кайтарам. *Шигырьләр* ... 149

САРА САДЫЙКОВАНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Онытылмас олуг зат. *(Г. Бәширов, Г. Зәйнашева, Х. Гайнуллин, Р. Харитонов, З. Сөнгатуллина, Л. Любовский, Р. Исмәгыйлев, Ә. Айдарская, Ә. Хөсәеновларның истәлекләре)* ... 153

СӘНГАТЬ

Ф. ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ. Меңнәр арасыннан бер йөз эш ... 173
И. ХӘЛИУЛЛИН. Игелекле талант ... 169

ЮМОР-САТИРА

М. САТТАРОВ. «Бергә-бер» уены. *Шигырьләр* ... 188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа С. ПОВАРИСОВА «Утро юности», начало романа З. ЗАЙНУЛЛИНА «Конокрады», рассказы Б. КАМАЛОВА и Ф. НАГИМОВА; стихи Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, А. АДЕЛЯ, Р. ШАРИПОВА, ИДЕЛБИКИ, Ш. МАКСУДОВОЙ.
«К 60-летию Р. Кутуя»: статья М. АГЛЯМОВА «Кутуй — это целый мир», стихи и рассказ Р. КУТУЯ.
«Из архива поэта»: стихи Р. РАКИПОВА.
«К 90-летию Сары Садыковой»: воспоминания Г. БАШИРОВА, Г. ЗАЙНАШЕВОЙ, Х. ГАЙНУЛЛИНА, Р. ХАРИТОНОВА, З. СУНГАТУЛЛИНОЙ, Л. ЛЮБОВСКОГО, Р. ИСМАГИЛОВА, А. АЙДАРСКОЙ, А. ХУСАИНОВА.
«Искусство»: статья Ф. АХМЕТОВОЙ-УРМАНЧЕ «Сто работ из тысячи» посвящена творчеству Баки Урманче и статья И. ХАЛИУЛЛИНА «Благотворный талант».
«Юмор-сатира»: стихи М. САТТАРОВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
«На наших обложках»: портрет Ибн Фадлана — работа художника Рушана Шамсутдинова; поэтесса Роза Кожевникова.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 12.09.96 ел. Басарга кул куелды 5.10.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 527. Заказ Е-460.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Лена Шагыйрьҗан

### «ИГЕЗӘКЛӘР» ЙОЛДЫЗЛЫГЫННАН МИН...

* * *

Ике игезәк яши минем җанда,
ике «мин» ул — гүя кушкаен.
Тик ашыкмый алар үтәргә бик
берсе — икенчесе кушканын...

Ник соң алар икесе ике төрле,
бер тамырдан булгач тоташкан?
Бу ике «мин» тыштан гына шулай
бер тамчы су кебек охшашкан...

Әйтерсең лә, Сиам игезәкләре —
үзе тоташ, үзе аерым...
Ник газаплый мине йолдызлыгым,
ике якка йолкып, каерып?..

Интегәләр, диләр, игезәкләрне,
аерылсалар берсе-берсеннән...
Табигатьнең бөтенлегендә дә
тоташ бәхет юк, дип күрсенәм...

Йолдызнамәләр дә раслап тора
«Игезәкләр»нең сәер булганын.
Үз-үзенә «сыңар» була бик еш
ялгызлары «парлы» дөньяның...

Ә йолдызлар Галәм китабына
алтын хәреф булып язылган.

Капма-каршы булып тоташулар
кылә, диләр алар,—асылдан...

Яшим Җирдә... Ул әйләнә тора
салмак кына Кояш тирәли.
Йолдыз үлчәүләрен тигезләргә
димәк, мин дә кирәктер әле...

*1994*

## Күңелдәге иске яралар

Ничә еллар инде тоташ яра,
Тоташ әрнү яна җаннарда.
Коеп-коеп яуган яңгырлар да,
Урап-урап яуган карлар да

Юа алмас кебек юшкыннарын,
Күмә алмас кебек эзләрен...
Табармын, дип, бәлки, шифа-сихәт,
Агымсулар җырын эзләдем:

Аккан сулар кебек сафланырга
Өйрәтчәле, моңлы инешем!
Тигезләче уйлар сикәлтәсен,
Көйгә салчы йөрәк тибешен!..

Дөньяда яз... Күкләр зәңгәр, аяз,
Таллар әнә яфрак яралар.
Тик нигә соң бертуктаусыз сыкрый
Күңелдәге иске яралар?..

Агымсулар сыман аккан моңнар
Дәваласа икән җаннарны,—
Төзәталмаса да яраларны,
Басып бераз сагыш-зарларны...

*1996*

## Синең өчен шигырь яздым бүген...

Минем өчен көндәлек бер шөгыль:
Синең өчен яздым яңа шигырь...
Син укысын өчен генә түгел,—
Син язмаган өчен яздым бүген.

Коргаксуын күреп җирнең шулай,
Түгеләдер болыт—яңгыр булып.
Синең өчен яздым. Үпкәләмә—
Һәр кеше дә тумый шагыйрь булып.

Минем җырдан күчсен йөрәгеңә
Канатланган сүзләр, кайнар моңнар.

Мохтаҗ булса җаны — аңлар, дидем,
Сизгер булса күңеле — димен, тыңлар...

Колак сал бер, әй, син көчле бәндә,
Синең өчен яздым мин аларны!
Исән-сау син, нык, сәламәт, таза,
Сөбханалла гына нервыларың...

Синдә — мускул ташкан...
Миндә — хисләр...
Кем җиткерер сиңа Сүзнең көчен? —
Шуңа күрә, утырдым да кичен,
Шигырь яздым тагын синең өчен...

*1994*

* * *

Ашкынса да күңел һәрчак
яңага, яңартуга,
Беркөн килеп иңнәреңә
ап-ак кош килеп куна.

Ап-ак кошмы, ап-ак кышмы,
кусаң да китми очып...
Ак аланда кем моңая,
ап-ак каенны кочып?..

Ни сөйли ул ак урманга,
җилләр зарын бүлдереп?
...Узып киткән язлар, җәйләр,
елатып та, көлдереп...

Һәм — җырлатып...
Бу дөньяда
яшәвеңне белдереп...
Ак урманда — кызыл миләш,
җиткән тәмам өлгереп...

*1993*

## Күзләр моңы

Ах, бу гомер чәчкәләре!..
Инде
әллә ничә төрле төскә кереп,
ничә тапкыр атты,
ничә шиңде...
Умырзаялардан көнләшимме?..
Елыйм мәллә утырып
түтәлләргә —
гыйбрәт булсын өчен бүтәннәргә?..
Күңелләрне сарды күзләр моңы,
җанда — җәйләр җылысының соңы...

Якынлашып килә карлы болыт —
соңгы гөл дә күмеләчәк сулып.
Тәүге мәхәббәт тә
боз өстендә
агып китте Утлы чәчәк булып...

*1995*

## Кызлар хәтере

...Булмаса, булмас, дидем,
Яшьлеккә үлчәп тегелгән
Җәйге күлмәгем кидем...
Йа, могҗиза! — күлмәк иске,
Ә мин яңардым кинәт!
Ятсынып куйдым үземнән,
Яшәреп киттем, димәк?..
Әллә инде җәйге төсләр
Онытылган, уңганмы?
Үземне үзем таныйм да,
Танымый да торам мин...
Чыгып ук йөгермәсәм дә,
Көзге алдында — өйдә
Боргаланып, сыргаланып,
Биедем иске көйгә...
Искә төште ерак җәйдә
Үзем тегеп кигәнем.
Бер егетнең гашыйк булып
Минем арттан йөргәне...
Кул изим инде барсына,
Басып көзге каршына...
Ник соң бүген таңнан күңелем
Әллә кая ашкына?..
Яшьлеккә үлчәп тегелгән
Иске күлмәгем белән
Яшәргән кук күренсәм дә,
Курачланганын күрәм:
Кыскарган да, тарайган да,
Утырган да кук бераз.
Кемгә бүләк итим сине,
Яшьлектән калган «мирас»?.
Син шаһите — яшьлегемдә
Мине сөйгән егетнең.
Хәзер күрсәм, үзем аңа
Гашыйк булыр кебекмен...
Көзге артында гына ул
Басып торадыр кебек...
Юк шул, томаннарга кереп,
Югалган инде эреп...

*1993*

## Сүрелү

Ераклаша инде яшьлек яры...
Сөзәкләнә текә кыялар.
Бер-бер артлы үткән айлар, көннәр
Ярсу ташкыннарны тыялар...

Алар миңа гүя әмер бирә,
Сүрел, сүн, ди — йөрмә тилереп.
Елларыңны синең хисапчылар
Санга сукмый,— янма тилмереп...

Яшен яшьнимени көзләр җиткәч?..
Давыллар да тына,— тын инде.
Шаян җилләр кочагында биеп
Йөрер чакны югалттың инде...

Еллар, айлар, көннәр, әллә кемнәр,
Тыймагыз ла, зинһар, җанымны.
Бер сөярмен кебек әле янып,
Сөелермен — җуеп аңымны...

И, хыяллар! Эреп тараласыз,
И, хисләрем! — ялкауланасыз.
Их, учаклар, нигә ерагаеп,
Кызыктырып кына янасыз?..

Ияралмыйм инде житез җилгә,
Акрыная хәрәкәтләрем.
Ялга сусый арып беткән җаным,
Төнге тынлык — бар рәхәтләрем...

*1996*

## Йөрәкләр чылбыры яки шулай булса икән...

Без бер чылбыр булып береккәнбез,
Орынышып терсәк-терсәккә.
Зыңлап тора аның һәр буыны,
Еласак та, егылып, көлсәк тә...

Берәребез читтә ялгыз гына,
Яшерен генә үксеп ятса да,
Аваз сала шундук сизгер чылбыр —
Кем абынган, кемдер аксаган...

Йөгерә хәбәр буын арты буын,
Ашыгыч ярдәм булып ялганып.
Кайда хәтәр? Эзләп тап та, коткар! —
Дөресме ул?.. Әллә ялганмы!..

Зыңлап тора чылбыр... Өзелергә
Һич ярамый аңа, ярамый...
Кайсы йөрәк анда җәрәхәтле?
Кайсыбызның җаны яралы?!

Буын арты буын ашыга хәбәр,
Таңга хәтле йөри төн аша...
Бер-берсеннән кеше хәл сораша,
Чылбыр булып җаннар тоташа...

*1987*

## Көзге Казан

*Роза ханым Туфитуллловага*

Беренче кат күргәндәге сыман,
Яши-яши серләләнә бара,—
Язым белән җәем узган Казан,
Көзләремне каршы алган кала...

Әллә инде яңарамы кабат,
Әллә үзем яңараммы шулай?..
Юкса — күктә йөзә шул ук кояш,
Кабанында йөзә һаман шул ай...

Әй, Казаным, шигъри казан күк син,
Бертуктаусыз ташып-кайнап торган.
Җәең — гөлләр чиккән шигъри җәймә,
Кышың — шигъри юллар сырган юрган...

Яшьлек үткәчтен дә яңару бар.
Көзге яңгырлар да яңарталар.
Күңелдәге язгы кыңгыраулар
Көзге җырларымны яңгыраталар...

Яшьлегемнең дәртле Казанымы
Гүя миңа кире кайтып бара.
Язларыма шаһит булган шәһәр,
Көзләремә гашыйк булган кала...

*1995*



## Суфиян Поварисов

# ЯШЬЛЕК ИРТӘСЕ

РОМАН

* * *

Ул тузан-чаң, бер яхшылыкка тагылган мең төрле кара-куе болытны хәтерләтеп, алар артыннан авылны чыккач та һаман әле бик озак ияреп барды. Гыйрфан мулла атларын кара тиргә батканчы куды да куды. Әйтерсең, бөтен ачуын шулардан ала. Аның каны кайный, күңеле шаша, йөрәге парә-парә өзгәләнә иде. Алда, Ырымбурдан кайткач, янә зур көрәш-низаг булачак. Җиңәргә көче җитәрме? Мөбахис мәзин җыен ялагай, йомакай, бер мыскал онга адәм баласын сата торган имансызларны җыеп алды үз канаты астына. Инде хәзер аңа, Гыйрфан муллага таба борды ачу-агу сөңгесен. Соң бит, анда сугылып, монда бәрелеп, өтәләгән тавык кебек булып беткән иде. Алып килде шул өтәләгән тавыкны, ашатты-эчерде, кеше итте, юлга бастырды, адәм рәтенә керергә ярдәм итте. Биниһая шул ашка хәзер канлы-кара таш ата. Уф! Ничек җир йотмый шундыйларны? Әллә җир җирәнәме, югыйсә? Булыр да. Җирнең дә жаны бар аның. Бар, бар, бар... Ярый, аның үзенә пычагым да булмас. Хөрмәтулла жәл. Таланган чебеш хәлендә калган иде бит мескен. Шуннан... ир-егетлек көчен йодрыгына төйнәп, чебештән янә арысланга әверелеп килә иде. Тагы да борчак измәсе урынына изгәннәр. Инде хәзер измәдән адәм рәтенә күтәрелә алмас. Бусы Хөрмәтулланың соңгы изелүедер. Тфү!.. Фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килмәсен берүк.

Галимжан да шул хакта уйлап бара иде. Теге вакытта, Йосыф мәхдүм белән аларда булганда, нинди матур сүзләр сөйләгән иде Хөрмәтулла абзыйсы. Нәсел-нәсеп, ил-ватан, узган-булган гыйбрәтле хәлләр, киләчәк өчен өмет... Шуларны язарга кушты бит әле ул. Ә ничек язарга? Бу үзе зур тарих бит. Шул тарих дулкыннары эчендә — адәм балаларының авыр тормышы, даими хәрәкәте, киләчәк матурлык өчен жан атуы. Җәренгә, укып ялга кайткач, аның белән тагын да очрашыр иде, сүзләреннән күп фәһем алыр иде, читкә ыргытылганнарның йөрәк тибешен, жан әрнешен,

---

Ахыры. Башы 10 санда.

күңел сыкрануын тагын да ныграк аңлар иде. Тик... Хөрмәтулла абзыйсын яңадан күрә алмас инде ул. Барысы да бетте. Ватылды. Җимерелде. Чәнчелде. Челпәрәмә килде. Әтисе өйдә булса, бер җаен табып, яклар иде әле аны. Хәзер батырачаклар Хөрмәтулланы. Үлем түшәгенә ятарлык итеп тукмаганнардыр. Алар Ырымбурга барып җитмәс борын ук аның җан тәслим кылуы бар. Алты бала ятим калырмы? Мәликә түти нишләр! Мәдинә-Акчәчкә бик нечкә күңелле шикелле. Әтисе үлеме кайгысын күтәрә алырмы? Ул бит баш бала. Тормыш авырлыгы аның җилкәсенә нык төшәчәк. Калганнары (энеләре, сеңелләре) ниндиләр икән? Аларын да күрәсе килгән иде аның. Тик беркөн, Йосыф шәкерт белән барганда, өйдә булмадылар. Берәр җиргә уйнарга китеп барганнардыр, бәлкем. Кояшлы матур көндә бала-чаганы өйдә тотып буламы? Әллә ниләр сөйләде-сөйләде дә язарга кушты бит Хөрмәтулла абзыйсы. Ничек язарга? «Кыйссаи Йосыф», «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә»ләр кебек итепме? Ай-һай, һай, андый әсәрләр язу өчен бер генә түгел, биш пот тоз ашарга кирәктер ул. Андыйны Шакирҗан абыйсы сөйләгән... Теге ни... кем соң әле... Гаяз... Гаяз... Исхакый... Әйе... Гаяз Исхакый кебек пәйгамбәр җанлы бөек затлар гына булдыра аладыр ул. Их, Ырымбурга тизрәк барып җитәсе иде дә... шул Гаяз Исхакый әфәндене бер күрәсе иде...

Шакирҗан да бу минутта гамьсез күркәдәй кукраеп утырып бармый иде. Аның да йөрәге шул бер үк уй-кайгы утында янды. Нигә тормыш болай корылган? Ни өчен кешеләр бер-берсен ашый? Нишләп дөньяга ялган-нахак албасты канат җәя? Бусы — бер хәтәр кайгы. Икенчесе — шушы минутта әтисен кызгану. Ул әле атларны шартлап ярылыр дәрәҗәгә җиткән йөрәген басар өчен шулай куалый. Ул, гүя, авылда алган кара кайгы капчыгын төшереп калдыру, аның арттан иярмәвен теләп шулай шашына. Әтисенең гамьсезлекне, нахак бәлаләрне, имансызлыкны яратмаганын, җене сөймәгәнлеген белә ич ул. Тик... менә кирәгеннән артык ярсый бит әле. Котырган үгез белән бер. Тәгәрмәчләр җиргә тияр-тимәс әйләнә. Атлар күбеккә батты. Әллә акылыннан яздымы әтисе? Кызу канлы булса да, юлда чакта бу кадәр дә котырынганы юк иде ич аның. Болай чапса, йә атларның януы, йә тәгәрмәчләрнең кырылуы, йә кырын җирдә арбаның каплануы бар.

— Әткәй!.. Әткәй!.. Син арыдың, ял ит бераз, дилбегәне үзем тотыйм,— дип тә карады Шакирҗан.

Бу сүзләр әти кешене ярсытып кына җибәрде. Тавыкны йомырка өйрәтми, дип уйлады да, үзен сабантуйда чабыш аты өстендә утырган малайдай хис итеп, атларны алагаем куалый бирде. Бераздан нәкъ Шакирҗан уйлаганча килеп чыкты. Бер сөзәк урында, әллә нинди дүңгәләккә орынып, арба да капланды, атлар да тәгәрәп киттеләр. Дөньяның, гүя, асты-өскә килде...

## Алтынчы бүлек

*Бу дөньяга күзен ачкан мәлдә*
*Әверелер агу язмышка.*
*Ни ул шөһрәт — адәм үтерүме?*
*Йә үлүме? Ни дип кан куша?*

*Гомәр ХӘЙЯМ*

### I

Караңгы, авыр, кайгы-хәсрәтле язгы төн. Шәкертләр ястү намазын да кичтән рәтләп укымады. Моназарә-бәхәс тә бүген башка вакыттагыча уттай кызмады. Түлле тавышлар, мәдрәсә әчен җиме-

рердәй итеп, яңгырап тормады. Ни галәмәт? Кыш буе үпкәгә яткан кара тузан балалык-яшьлек ялкынына кургаш пәрдә блып сарылдымы? Яңаклары эчкә баткан саргылт йөзләрдә, хәлсез күзләрдә, алҗыган карашларда яшәү өмете чаткылары сүндеме? Язның көтелмәгән караңгы, шөкатьсез төне авырлыгы бастымы күңелләрен? Шуларның бөтенесе уптым илаһи сеңдердеме тирән вә татлы йокыга?

Галимҗан йокламады. Кичен, ахшам вакытында ук, карлы-бозлы яңгыр явып үтеп, җил, карасат-давыл купкан иде. Ул, адәм балаларын хөсетлек утында яндырырга шашынган Иблис шикелле, һаман әле котырына: бер караганда, коточкыч дию пәриедәй шыңшый, икенче мәл яраланган арысландай үкерә, йә ач бүре булып улый.

Йа, хода! Кем әйтмешли, хәерле каза булсын! Билхәер! Әмма ул давыл, гарасатлардан билхәерлек, изгелек көтү шайтаннан шәфкатьлелек өмет итү кебек кенәдер. Табигать ул кешеләр сыман. Аның җаны бар. Ач кеше ачучан, диләр. Ач кешенең ачуын китерсәң, Ходай күрсәтмәсен, ул инде җенләнә-шашына белә. Бәндәләрдәге шул сыйфатларны сизгән табигать йөрәге дә үрле-кырлы килә. Башта мәдрәсәдә дөнья корылышын әллә ничек томанлы итеп аңлаттылар. Җирне, имештер, үгез мөгезе күтәреп тора. Күп шәкерт моңа ышана. Бәгъзе берсе дөнья читен безне әйләндереп алган офык сызыклары белән чикли. Ә инде җәгърәфия өйрәнә башлаганнар иде, дөнья-галәмнең искиткеч серле, киң, зур икәнлегенә инандылар. Рәсәй акыл җитмәс дәрәҗәдә зур икән ләбаса. Аның янында Япония тузан бөртеге генә. Шул тузан бөртеге Порт-Артурны яулап алды. Бу бит черкинең филне җиңүе белән бер. Ай-һай, нык какшаган икән Рәсәй — нәкъ ярлы кешенең таралып төшәргә торган иске арбасы.

Бу арбаны төзәтергә кирәк, имеш. Тәгәрмәчләре тимердән булсын, янәсе. Башка илләр белән ярышка чыкканда, ул тәгәрмәчләр беркайчан да ватылырга тиеш түгел, ди. Моның өчен тәгәрмәче кырылырга торган патшаны тәхеттән тәгәрәтеп, аның урынына Йосыф пәйгамбәр ише җитмеш төрле һөнәре булган, адәм балаларына бәхет, мул тормыш китерердәй илаһи бөек затларны куярга кирәк икән. Шул җәһәттән җил-давыл, гарасат купты. Аны инкыйлаб дип атадылар. Инкыйлаб давылы иң әүвәл Мәскәү, Петербург, Казан кебек зур калаларда котырынды. Аннан Ырымбурга да килеп җитте. Урамнарда халык ташкыныургылды. Ул ташкынга яңалык эзләүче шәкертләр дулкыны да килеп кушылды. Галимҗан дулкын үзәгенә ыргылды. Ул үзәктә Шакирҗан да бар иде. .

Үзәкне эшче халкы тәшкил итә. Алар бер-берсенә тимер чылбыр белән бәйләнгән. Шул чылбыр комсыз, кеше җилкәсендә яшәүче капкорсакларның муенын буачак, янәсе. Бер уйласаң, бәхет дигәнең һич тә әллә кайда, Каф тау артында түгел икән ләбаса. Җәтмә белән балык сөзеп алган кебек, аны әлеге тимер чылбырлар белән кама да ал. Бәй, кемнең рәхәт яшисе килми кунакка килгән бу якты фани дөньяда? Эшчеләрнең гадәттән тыш авыр тормышын шәкертләр дә яхшы белә ич. Аларның күбесе җәйге көннәрдә шахтага, заводларга эшкә китә. Кыш укыр өчен акча әзерли... Тәүлегенә ундүрт-уналты сәгать, бәгъзе бервакыт аннан да күп эшләнеп, ач-ялангач, салкын баракларда иза чиккән эшчеләрнең аяныч тормышын шәкертләр үз күзләре белән күрде. Тик әлеге чылбыр йомшак икән шул әле, юкәдән ишкән иске дилбегә шикелле генә. Ул дилбегә тиз өзелде. Тормыш тәгәрмәче коргаксыган булса да, патшаның халыкны буарга әзерләгән тимер чылбыры хәзергә каты икәнлек беленде.

Патша рәхимсез, кансыз, миһербансыз икән ләбаса. Петербургта, әнә, үзләренең житди таләпләрен аңлатырга барган эшче-туганнарны патша гаскәре кыра да сала. Халык каны урамда елга булып ага. Бу хәл башка шәһәрләрдә барлык эшчеләрнең йөрәген ярсыта. Канлы хәбәр чит илләргә дә яшен тизлегендә барып җитә. Жандармнар Ырымбурда чит ил

социаль-демократлары җибәргән язмаларны таба. Канга-кан, җангаҗан, ачуга-ачу, дигәндәй, бөтен җирне инкыйлаб дулкыннары чолгап ала. Дулкын Уфа заводларына да җәелә. Дулкынга солдатлар да, игенчеләр дә кушыла. Тик дулкын һаман-һаман инкыйлабчылар каны белән тирәнәя бара.

Шул дулкыннар арасында бәхет эзли-эзли ике мәртәбә нахак бәлагә юлыккан Хөрмәтулла да йөзеп йөри кебек тоелды Галимҗанга. Хөрмәтулла!.. Мөбахис йортына ут төрткән дип, аны тагын да борчак измәсе урынына изеп ташлаганнар. Суд-хөкем ясап, аны Себер җибәргәннәр. Шул кадәр изелүләрне тагын да күтәрә алды микән? Әле исән микән? Исән булса, әлбәттә, кеше бәхете, гаделлек өчен көрәшкә ул да күтәрелгәндер. «Көрәш кирәк», дигән сүзләрне кат-кат әйткән иде бит. Ә нинди көрәш? Ничек көрәшергә? Нинди сыйфатта? Галимҗан моны үзе дә аңлап бетерә алмый иде. Ул әле мәдрәсәдә уку-укытуыны яңарту, аңламаган гарәп сүзләрен ятлатудан арыну, динне генә түгел, тарих, җәгърәфия, әдәбият, математика, физика һәм башка фәнне укытырга кирәклек өчен көрәшә.

Ни белән чикләнер бу көрәш? Дөньяны инкыйлаб дәһшәте чолгап алды. Давыл. Гарасат. Кан коеш. Табигать йөрәге шуны күреп әрниме? Тышта җил-давыл шуңа котырынамы? Торыгыз, йоклап ятмагыз, күтәрелегез, ялкаулар, изелгәннәр мәңге бәхетсез, диме? Җил шуның өчен ач бала имчәк сорап акырган кебек елыймы?

Кешенең баш миендә ундүрт миллиард чамасы күзәнәк-нейрон бар, имеш. Алар да тормыштагы, табигатьтәге вакыйга-күренешләр, адәм балалары йөреше-кыланышы кеби, даими дулкынланып, чайкалышып торалар икән. Ул күзәнәкләрдә табигать, яшәеш, галәм-дөнья хәрәкәтманзаралары чагыла, ди. Димәк, кешенең йөрәге табигать йөрәге белән бәйле булган кебек, аларның миләрендәге әллә күпме миллиард нейроннар да бер-берсенә керешеп яши булып чыга.

Тормыш, яшәеш, фани дөнья манзаралары Галимҗанның колагына «яз», «яз», «яз» дип пышылдагандай. Аннан ул сүзләр колактан күңел түренә, йөрәк төпкеленә үтә, ми күзәнәкләре дулкынына үрмәли, уйландыра, ярсыта, яшәүне авырлаштыра. Ми күзәнәкләре дулкынына хәзер инкыйлабый-революцион көрәш турындагы меңмиллион бөрчекләрдән торган хис-тойгы, уй чаткылары килеп керде. Алар да ярсыта, үрле-кырлы китертә, күңелне шаштыра. Кешеләргә фәкать бәхет теләп, тышкы котсызлыгы белән күпләрне өркеткәнкуркыткан, әмма эчендә гәүһәр йөрткән, нахак бәлаләрдән изелептапталып та инсаниятчелек сыйфатын саклап кала алган Хөрмәтулла шикелле мең-миллионнар азатлыгы өчен көрәш мәйданына чыгарга иде. Мәдинә-Акчәчкә төсләләргә ничек бәхет китерергә? Аларны караңгы баздан, тормыш фаҗигасеннән нинди көчләр белән тартып чыгарырга? Уйлар! Уйлар!! Уйлар!!! Алар тыштагы давыл-гарасаттан ким ярсымый. Галимҗанның ми күзәнәкләрендә уй-хис дулкыннары кайнаша. Ул дулкыннар Галимҗанны төн буе йоклатмады. Ә таң алдыннан:

— Торыгыз!.. Иртәнге намазга!..— дигән түлле тавыш яңгырады.

Тик Галимҗан моны ишетмәде. Ул инде уй дулкынына түгел, йокы дулкынына чумган иде.

Бүлмәдәше Шәһит, әлеге түлле тавышка сикереп торып, тиз генә киенеп алды. Ашык-пошык, йөгерә-атлый, кабалана-кабалана барып, ничек җитте шулай тәһарәтен дә алып килде. Ә Галимҗан җәннәттәге кайгысыз хур егете сыман һаман йоклый иде әле. Шәһит аптырап китте. Ул бит Галимҗанның мондый мәнсезлеген беркайчан да күрмәде. Бөтен эшне йөзенә кызыллык китермәслек итеп башкара. Вакытында ята. Вакытында тора. Ни булган аңа бүген? Әллә авырып киткәнме?

— Галимҗан!.. Галимҗан!..
— Әү...
— Тор!.. Мин инде әллә кайчан тәһарәт алып килдем... Иртәнге намазга соңлыйсың бит...
Галимҗан шаяртуга күчте:
— Син бүген минем өчен дә укы әле, Хак Тәгалә...

Йосыф Казанга «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчкәч, Галимҗан бер бүлмәдә Шәһит белән яши башлады. Алар тиз дуслашты. Шәһит ятим бала икән. Әтисе дә юк, әнисе дә. Ул бай шәкертләргә самавыр куеп, аларның төрле вак-төяк эшләрен башкарып яши. Моның өчен аңа аз булса да акча бирәләр. Вакыт-вакыт калган ашлар да эләгә. Башта Галимҗан аның бу гадәтен килештереп бетермәде: түбәнсенү, кеше табан астын ялау була, янәсе. Шәһит моны башкачарак аңлый икән. Авыл мәктәбендә дә ул кешеләргә хезмәт итә-итә укыган. Бу — аның маңгаена язылган язмышы.

Аның фикеренчә, язмышлардан узмыш юк. Мәдрәсәдә дә язмыш аны көлеп-елмаеп, шатланып-чәбәкәй итеп түгел, тешләрен ырҗайтып, йодрык төйнәп каршы ала. Боларны ул Галимҗанга беренче чәй табынында ук сайрап салды. Мәзәк итеп, бер урында сүзләрен чигүләп-матурлап, икенче урында майлап-баллап, өченче урында чәнечкеләп-кылчыклап сөйләде. Аның көр күңелле булуы, сүзнең җаен-чамасын белүе, авыр хәлен җиңеләйтеп, хәтта көлкеле итеп сөйләве ошады Галимҗанга. Ә инде бай шәкертләргә чәй кайнатуы, аш пешерүе, вак-төяк эшләрдә ярдәм итүенә ул аз гына да түбәнсенми. Моны да язмышка бәйли. Ходай шулай кушкан, ди.

— Мин бит урламыйм, Галимҗан, кешеләргә хезмәт итәм; моны шәригать тә, инсаният тә яклый,— дигән иде ул.

Шәһитнең нур сибеп торган моңлы күз карашлары, ягымлы сөйләшүе, матур елмаюы, чибәр йөзе, сөйкемлелеге һәркем тарафыннан яратырлык сыйфатлар иде. Аларны ул беркайчан да югалтмады. Кешеләргә карата булган ярату хисләре аны һаман-һаман олы йөрәкле итеп күрсәтте.

Дөрес, аның кайбер гадәтләрен Галимҗан яратып та бетермәде: бай шәкертләргә тамак өчен вак-төяк хезмәт итү бервакыт аны артык вакламасмы, ир-егетләрдә була торган горурлыкны чүпләмәсме? Шуларны уйлап, акча белән дә, ашау ягыннан да ярдәм итәргә тырышты. Ләкин андый чакта Шәһитнең матур, көләч йөзе кинәт үзгәреп китә, моңсуланып кала, күз карашлары мәзәкләнә, хәтта иреннәре калтырап куя. Моны ул хезмәт итми генә тамак өчен кешеләргә ымсынып кул сузып йөрүче теләнче эше дип исәпли иде.

Укуда ул Галимҗан дәрәҗәсендә үк булмаса да, һәрхәлдә алдынгы шәкертләр исемлегендә йөрде. Хәлфә соравына җавап биргәндә, бәгъзе бер йомшак бәдәнле шәкерт шикелле, аркасында чыбык чыжлаудан куркып, мескенләнеп-калтыранып тормады. Хәер, хәзер инде беләме, бәхәс вакытларында мантыйк әзлеклелеге күрсәтүе, акылы буенча алдынгы шәкертләрне генә түгел, мәдрәсә хуҗасы Вәли мулла, Заһидулла хәзрәт, Зарф хәлфәләрдән нык өстен торган Галимҗан бүлмәсендә яшәп, нишләп әле Шәһит шәкертләр койрыгында болгансын, ди.

«Шәһит» дип изге көрәшләрдә хаклык өчен җан тәслим кылган мөселман бәндәләренә әйтелә. Шәһитнең исеме җисеменә туры килә. Ул күңеле белән хак кеше. Шуңа күрә Галимҗан аны яратып, якын күреп, берникадәр шаяртып, «Хак Тәгалә» дип атады. Тик әле менә Галимҗанның «Хак Тәгалә» дип эндәшүе, иртәнге намаз алдыннан шаяртып маташуы ничектер сәер тоелды. Шулай да Шәһит моңа әллә ни игътибар итмәскә тырышты. Соңга калмас өчен, кабалана-кабалана, иртәнге намазга йөгерде. Ә инде Шәһит әйләнеп кайтканда, Галимҗан яңадан йокы чүлмәгенә чумган иде.

III

Ни гаҗәп? Нигә болай? Нишләп һаман тормый ул? Галимҗанның вакыт-вакыт авырып китүен белә Шәһит. Шуның өчен «Хөсәения» мәдрәсәсенә алмаганнар бит. Икенче ел укыганда абыйсы Шакирҗан, кем әйтмешли, теше-тырнагы белән тырышып караса да, максатка ирешә алмады. Сәламәтлеген тикшергән чакта Галимҗан тагын да нык ютәлләп җибәргән. Шулай да Галимҗанның моңа әллә ни исе китмәде. Кайда каралганмын, шунда агарыйм, дип Вәли мулланың шушы караңгы мәдрәсәсендә үзен агартырга булды. Ә инде сәламәтлеге начарая баруын беркемгә дә сиздермәскә, үзен гел-гелән «горур», күтәренке күңелле, вакыт-вакыт шаян табигатьле итеп күрсәтергә тырышты.

— Галимҗан!.. Галимҗан!.. Мин инде иртәнге намаздан кайттым, ә син һаман йоклыйсың, хәзрәт-фәлән килеп керсә, өстеңә мең төрле кара бәла ягачаклар; тор, дускай, болай ярамый, мәдрәсәнең низам-интизамын, эчке тәртибен онытмагансыңдыр бит.

— Юк, юк, Шәһит дускай, онытмадым. Ә намаз өчен борчылма. Мин аны түшәмдә укыдым.

— Шаяра торган вакыт түгел, Галимҗан!

— Ә мин чын әйтәм.

Дусты һаман-һаман төрткәләп торгач, хәтта чеметкәләп алгач, Галимҗан торып утырырга мәҗбүр булды. Шуннан ул бер строфа шигырь әйтте:

Бу дөньяга күзен ачкан мәлдә
Әверелер агу язмышка.
Ни ул шөһрәт — адәм үтерүме?
Йә үлүме? Ни дип кан куша?

Шәһит тәмам гаҗиз булды.

— Галимҗан!.. Син саташасың. Шигырь укып утырыр вакытмыни, валлаһи! Аңлыйм инде кичерешеңне. Әгәр Гомәр Хәйям әйткән агу язмышка әверелгән икән, аны төзәтеп буламы? Әгәр бүген адәм үтерү кем өчендер шөһрәт икән, Ырымбур урамнарында кан ага икән, ул кан елгасын гәүдәң белән генә буа алмассың бит.

— Ырымбур урамнарында гына түгел шул, Шәһит дускай, бөтен ил буенча. Син шуны бел: бу әле инкыйлаб каны диңгезенең чишмә башы гына. Ул каннар, аһ, күп булачак.

— Галимҗан!..

— Ярый, Хак Тәгалә, борчылма.

— Ник борчылыйм. Төне буе җил-давыл котырынды да, иртәнгә басылды бит әнә. Инкыйлаб гарасаты да шулай булыр.

— Син өстән-мөстән уйлыйсың, Шәһит дус!

— Ә син һәрнәрсәнең төбенә төшәргә тырышып бетерәсең үзеңне, авыруың турында да уйламыйсың. Сәламәтлек — кешенең көзгесе, дигән иде беркөн теге табиб.

— Сәламәтлекнең түре — йокы, Хак Тәгалә!

Шәһит кызып китте:

— Соң, шулай булгач, нигә бүген төне буе йокламадың? Үрле-кырлы килдең?

— Сәламәтлекне күз белән күрмиләр, колак белән ишетмиләр, тик җан-тән белән генә сизәләр.

— Соң, сиз алайса, җаның-тәнең белән той. Башыңда мең төрле хыял. Һәрберсе изге булсын. Авырулар кешене сазга батыра.

— Ә мин әле сазга йөз тотмыйм.

— Йолдызларгамы?

— Без — йолдыз балалары.

— Аһ! Тагын да хыял. — Шәһит кул селекте. Бәхәстә, сүз көрәшендә сине җиңеп булмас, дигәнне аңлата иде бу.

Аларның низаглашуын бүлмәләр арасында акыра-бакыра йөргән Зарф хәлфәнең казан төбе кырган тавышлар чыгарып чәрелдәве бүлде:

— Шәкертләр!.. Мәдрәсәгә Вәли мулла җәнаплары үзе килде. Аның сезгә әйтер сүзе бар.

* * *

Мондый вакытта шәкертләрне махсус бер зур бүлмәгә җыялар. Аның сәкесе бар. Мәдрәсә хуҗасы Вәли мулла, тамагын кыра-кыра, үзен Мөхәммәт пәйгамбәрдән дә өстен бер олы зат-шәхес санап, аның өчен махсус тәгаенләнеп куелган йомшак мендәргә менеп утыра. Аның кулына Зарф хәлфә сузылган еланны хәтерләтеп торган бер чыбык китереп тоттыра. Монысы инде аның «тәртип коралы» була. Сүз башлар алдыннан бу коралны уйнатып ала торган гадәте дә бар. Бу — аның үзен Алып батыр кебек гайрәтле итеп күрсәтергә маташу галәмәте. Мондый чакта шәкертләрнең күзе тоздай була. Бәгъзе берсе бүре алдында торган мескен сарыктай калтырана. Болары — куркаклар. Икенчеләре үзләрен төлкечә тотарга тырыша. Болары — хәйләкәрләр. «Ни рәвешле ярыйм сиңа, и Вәли әфәнде җәнаплары»,— дип уйлаганнар. Өченче бер төрлеләре аңа каты карый. Мондыйлары: «Урын кешене бизәми, кеше урынны бизи»,— дип хис иткәннәре. Астыртын караучылар да була. Алар — астан кисеп, өстән ямый торганнар. Астындагы мендәрен тартып алып аны как сәкегә утыртырга теләүчеләр.

Шул ук хәл бүген дә кабатланды. Шәкертләр җыелганда Вәли мулла ике кат йомшак мендәр өстендә кукраеп утыра иде инде. Чыбыкны чыжлатып алса да, шәкертләргә ул мөлаем карарга тырышты. Әллә нинди куркыныч заман килгәнне әллә белмиме ул? Белә. Бәгъзе шәкерт, аның уйлавынча, имансызлыкның чигенә чыкты. Бөтен бәла әлеге дә баягы шул инкыйлаб дулкыннарының ярсуында. Имансыз шәкертләр шайтан котыртуына тиз бирелә. Шундыйларның берсе Гыйрфан мулла улы мәхдүм Галимҗан Ибраһимов булып чыкты. Әтисе кем? Нәсел-нәсәбе кем? Ә менә балалары динсез, дәһри бер фөҗүр[1] булып чыкты. Аттан ала да туганы, кола да туганы шушыдыр инде, илаһым! Күпме ут йотты, җан атты Вәли мулла аны кеше итәр өчен. Мәдрәсәдән бер куылгач, бер юньсез кеше булса, аны монда яңадан эз дә бастырмас иде. Теге вакытта, «Котылдым бу дуңгыздан», дип уйлаган иде Вәли мулла. Әмма ләкин дә әтисе Гыйрфан мулла килеп ялынгач, сүзләре белән йөрәгенә сары май булып төшкәч, баласының киләчәктә «төзеләчәге» хакында ант иткәннән соң, янә укытырга ризалашты Вәли мулла. Ит яхшылык — көт явызлык, дигәне шушы икән. Тагын әллә нинди мең төрле таләпнамә язып килгән. Имеш, кадимгечә уку хәзерге шәкертләрне кызыксындырмый. Яңалык җилкәдән ала, янәсе. Барлык фәннәрне укытырга кирәк.

Әллә бу хакта Вәли мулла белмиме? Белә. Әллә баш ватмыймы? Вата. Башын ташка бәрердәй була бәгъзе бер вакыт. Бәрсәң, баш ватыла. Биреп кара син Зарф хәлфәгә ул теге ни... илләр өйрәнә торган фәнне... ягъни дә мәсәлән... җәгърәфияне... Үз авылының кай төбәктә икәнлеген белмәгән кибәк баш... Әлеге теге ни... Парт... парт... парт... ар... ар... ничек соң әле, каһәрең?.. Әйе, Пуртартурны тартып алып... Русия ярасына тоз сипкән җан... җан... Җапуниянең кайсы төштәрәк икәнлеген ничек чамалый алсын да... шәкертләргә аңы хәритәдән[2] ни рәвешле таптыра белсен. Хассиятсез бер кибәк баш бит ул. Тышкы яктан кояштай балкыган була. Эчендә, баш миендә мең пот аңгыралык касафәте.

---

[1] Фөҗүр — начар, әшәке эшләр эшләүче.

[2] Хәритә — карта.

Монысы бер булсын, ди, ягъни дә мәсәлән. Икенчесе шул: хәзер монда килүче хәлфә-мөгаллим юк. Имештер, Вәли мулланың мәдрәсәсе караңгы баз белән бер. Анысын да рас әйтәләр. Ләкин бит диварлары череп, туксан яшьлек карттай бәлтерәп торган ул мәдрәсәне күз ачып йомган арада алтын сарай итеп булмый. Моның өчен Алла кодрәте кирәк. Ә ул бәндәләрдә юк.

Янә азгын шайтан урынына кытыклап торган өченче бер куркыныч бар: Вәли мулла үзенең уй тубалында җил уйнаганны яхшы белә. Ә инде Зарф, Шәех, Хәмзә кебек хәлфәләр монда башка мәдрәсәдә артык калҗа булганга килде. Ярлының бура төбен мең кат себерсәң дә, бер уч он чыкмаган кебек, мәдрәсә таягы белән көн дә яткырып мең кәррә тукмасаң да, аларны инде хәзер адәм рәтле хәлфә-мөгаллим итеп булмый. Шулай да Вәли мулла өчен алар ифрат дәрәҗәдә кыйммәтле асылташлар: синең белән моназара кыла алмыйлар, табан астыңны яларга әзер торалар, мәдрәсә эчендәге кара тапны аслан урамга чыгармыйлар. Галимҗан кебекләр ул селәгәйләрнең авызын тиз томалый шул инде хәзер. Аларныкын бикләп, Вәли мулланың үзенекен капламакчы. Шул котырттты шәкертләрне. Хәзер алар оясына таяк тыгып болгаткан кырмыскалар урынына кайнаша. Бу низагның янә дә шулай котырынуы мөмкин түгел. Котылырга бу шайтан арбасыннан төшеп калган имансыздан. Моның өчен Зәһидулла хәзрәт, әлеге шул Зарф, Шәех, Хәмзә хәлфә-мөдәррисләр белән киңәшләшү булды. Алар әле, патшаның тән сакчыларына охшап, Вәли мулланың як-ягында утыралар.

Вәли мулла, үзенең шөһрәтен вә белдеклелеген күрсәтү өчен, иң әүвәл дөнья хәлләре турында берникадәр сафсата сатты. Япон сугышын искә алды хәтта. Борының сыймастай тишеккә башыңны тыгарга маташма, дигәндәй, киң дөньяга сәяхәт иткән булып, теленең капкынга эләккәнлеген сизми дә калды.

«Рәсәйдән биш мәртәбә зур Җәпүниә мәгърибдән сугыш башлап, Пуртартурны алды»... дигән иде, мулланың хатасын тиз аңлаган шәкертләр, кых-кых килеп, көлеп җибәрде. Вәли мулла, шау-шуны басар өчен, чыбыгын чыжылдатып алды да янә иҗтимагый-сәяси хәлләр дөньясына кереп китеп, соңгы вакытта булган инкыйлабый вакыйгаларны, кан коелу мәсьәләләрен телгә алды. Боларның халык бозылудан, динсез-дәһриләр арта барудан, күпләрнең Аллаһы Тәгаләне бар дип белмәүләреннән килүен әйтте. Баксаң, андый дәһриләр менә шушында, аның әйтүенчә, дин вә изгелек бакчасында тамыр җәя башлаганнар. Бусы инде, Ходай үзе сакласын, гөлбакчадагы шайтан таягы кеби. Шундыйларның бере, иң куркынычлысы — Гыйрфан мулла улы Галимҗан Ибраһимов. Вәли мулла тамак кыра-кыра, ашыкмыйча, җайлап-майлап кына, Галимҗан өстенә чиләкләп-чиләкләп пычрак су коярга тотынды. Имештер, Галимҗан башта мәгъсүмлек, сафлык, тырышлыкның гүзәл өлгеләрен күрсәтүче мәгърур шәкерт булган. Ә хәзер мәгыйшәтлек, нәҗеслек, аламалык юлына баскан. Аны, Галимҗанны, күп мәртәбәләр сыраханәдә күргәннәр. Сары сакаллы урыслар белән аракы эчеп, тәмәке тартып, кәнтәй Мәрүскәләр янына барып йөри, имеш. Дәхи дә адәм балаларын юлдан яздыра, йә котырта, кәфер итә торган китаплар укый икән. Шундый шайтан җанлылар күбәйсә, Ходай үзе сакласын, мәдрәсәне яшен сугуы ихтимал. Бүгенге Рәсәйдәге канкоеш Галимҗан кеби бозык канлы кешеләр аркасында. Аллаһы Тәгалә бәндәләргә авырлыкны шуның өчен сала. Хөрриятпәрвәр булам дип, бәйдән ычкынган эт шикелле, үз нәфесең өчен генә яшәү — Алла алдында зур гөнаһ эшләү.

Озак сөйләде Вәли мулла. Тәмләп, ләззәтләнеп, түгәрәк сакалын сыпыра-сыпыра, вакыт-вакыт кикерә-кикерә, тәмамән ышандырыйм дигән ният белән сөйләде.

— Әлхасыйл, шәкертләр, Гыйрфан мулла углы Галимҗан мәхдүмне без мәдрәсәдә моннан ары бер генә көн дә тота алмыйбыз, чүп үләнен вакытында юк итү хәерледер,— дип бетерде сүзен.

Шуннан соң сүз тынлыкка бирелде. Озак торды тынлык. Дәшмәде. Нәүмиз булып калдымы? Уйланырга мөмкинлек бирдеме? Адәм балаларының сабырлыгын авыр, караңгы, куркыныч мизгелдә сынап карыймы? Аларның яктылыкны күрмәүләренә хәйран калдымы? Шәкертләрнең бәгъзесе, аһ, бу шомлы таяк минем башыма төшә күрмәсен дип шүрләп утырганы, коелды да төште. Икенче бер төрлесе, Галимҗанга карата булган сүзләренең нахак икәнлеген аңлаганнары, Вәли мулланың бүлтәеп торган кызыл бит очларына барып ябыша язды. Өченчеләре, Вәли мулла сүзләренә ышанган аңгыра-җиңел акыллылары, әчтән генә Галимҗанның тетмәсен тетте: аның аркасында бөтен мәдрәсә йөзенә кара ягыла, янәсе.

Тынлык сабыр булды. Тынлык эндәшмәде. Тынлык сүзне дәхи дә Вәли мулланың үзенә бирде. Вәли мулла хәзер Галимҗанны мәдрәсәдән куу өчен язылган әмернамәне укырга тиеш иде. Ләкин Галимҗан моңа ирек куймады. Аягүрә басты да тынлыкка колак салды. Тынлык ашыкмаска, какшамаска, нык торырга, көрәшергә кушты.

Ашыкмады Галимҗан. Каушамады. Калтыранмады. Иң әүвәл Вәли муллага карап катты. Каты карады. Ул караштан Вәли мулланың әлеге ике бит очындагы кызыл бүлтәймәсе күгәреп катты, кулындагы чыбыгы төшеп китеп, күәс чиләге юанлыгы гәүдәсе калтыранып куйды. Шуннан Галимҗанның утлы карашы Заһидулла хәзрәтнең дә йөзен көйдерде, табан яларга яратучы хәлфәләрнең дә кашын җимерде. Аннан утлы караш ялкыны һәммә шәкертнең йөзен берәм-берәм ялмап алды. Куркак күзләр, агарып каткан йөзләр, салынып төшкән борыннар күрде Галимҗан. Әмма куплләрнең йөрәге үзенеке белән бергә типкәнлекне, каннары бердәй кайнашканлыкны, бер хис-тойгылар кичергәнлекне сизде Галимҗан. Шәһит тә, сикереп торып, Вәли муллага менә-менә ташланыр арысландай утыра. Шәһит яклылар Галимҗанның Вәли мулланы онталкан итәрдәй бик каты сүз әйтүеннән дә курыкмадылар. Анда, Галимҗанда, усаллык та җитәрлек ич. Шулай да көткәнчә килеп чыкмады. Тынлыктай тыныч иде Галимҗан. Ул Вәли муллага Япониянең мәгърибтә түгел, мәшрикъта икәнлеген әйтүне дә кирәк санамады. Карганы кырык мәртәбә сабынлап юсаң да агартып булмаган кебек, карт наданның миенә кырык көн буе ак нур өрсәң дә, аны барыбер аңлы итә алмассың.

Галимҗан үзен һаман шулай горурәнә тотып:

— Юк, кирәкми, укымагыз, мин, сез кумасагыз да, мәдрәсәгездән китәргә җыйналып беткән идем инде,— диде.

Вәли мулла иркен тын алып куйды. Бәй, Ходайның рәхмәте, бу авыр төен бик җиңел генә, бернинди низагсыз чишелә ләбаса. Әмма Галимҗанның соңгы сүзләре Вәли мулланың кап-корсагын чак шартлатмады.

— Карга оясына бөркет беркайчан да кунмаячак, кара базга кояш бервакытта да төшмәячәк,— диде дә тып-тын басып чыгып китте.

Галимҗанның хәзер киная белән, мәкаль-әйтемнәр кыстырып, үткен сөйләвен һәммәсе белә иде инде. Вакыт-вакыт ул надан башка аңлавы кыен булган чагыштырулар да куллана. Әмма бу кадим мәдрәсәсен карга оясына охшатуын дивана да аңларлык. Ә бөркетләр кем? Үземе? Йә булмаса шул «ирек-азатлык» дип җан аткан, селәгәй агызган әтрәк әләмнәрме? «Кара баз», имеш. Кояшы нәрсә? «Яктылык өчен көрәш» дип авыз ерталар. Үзләрен кояшка саныйлармы? Әллә-ләл, әллә-ләл, мәгыйшәтне, тормышны «ә» дигәнче кояш нуры белән коендырмак булалар. Тот капчыгыңны! Ю кара кулыңны мең кәррә сабынлап...

Галимҗан чыгып киткәч, кара болыт таралып, әнә шул якты кояш ялтырагандай тоелган иде. Ләкин аслан алай түгел икән. Уртага Шәһит чыгып басты. Мәдрәсәдә үз гомерен башкаларга хезмәт итеп үткәргән, аз сүзле, миһырбанлы, күндәм, мөлаем йөзле бу шәкерттән фәкать яклау сүзләре көткәннәр иде. Тик ул фикер тәртәсен бөтенләй башка якка борып җибәреп, суны Галимҗан тегермәненә коярга керешге:

— Сезнең әмернамәгез белән килешмим. Галимҗанның күп укуы дөрес. Аның хәзер белмәгәне юк. Ул һич тә кирәкмәгән китап укымады. Нигә сез сыраханәләрдә, кярханәләрдә, фәхеш итү йортларында йөргән, ун ел ми черетеп, әлепне таяк дип белмәгән, җәһаләт шәкертләрне кумыйсыз, ә? Нигә шәкертләр арасында үзен пәйгамбәр итеп күрсәтә алган Галимҗанга каныгасыз? Бу пычрак эшегез өчен мин сезнең өстән Уфага—әһле мәгарифка язачакмын. Ә хәзер, Галимҗан китсә, мин дә аннан калмаячакмын!..—дип, шуларга охшаш, дәхи дә әллә күпме куркыткыч сүзләр әйтеп, чыгып китте.

— Мин дә китәм...

— Мин дә...

— Галимҗаннан калмыйбыз...

— Нигә яшереп тәмәке тарткан Гыйсмәтне күрмисез?..

— Фәхешханә юлыннан кайтмаган Рәхмәй ал да гөл яши.

— Хәмер чөмергән чучка борын Шәйхисламны куарга кирәк.

— Оясын туздырабыз...

— Нәләт бу мәдрәсәгә...

— Ләгънәт...

Шундый сүзләр әйтә-әйтә, хәтта йодрыклар күрсәтә-күрсәтә, Шәһит артыннан егермеләп шәкерт чыгып китеп, Галимҗан бүлмәсенә кереп тулдылар. Аларның барысы да ярсу иде. Бәләкәй бүлмәдә аяк басар урын да калмады. Хәмит исемле шәкерт Галимҗан, Шәһит чыгып киткәч булган хәлләрне кыскача гына бәян итте дә:

— Барыбыз да мәдрәсәдән бүген үк китәбез,—диде.

Ләкин Галимҗан моңа каршы төште:

— Юк, дуслар, алай ярамый, мәдрәсәдә «Шәкертләр иттифакы» төзедек. Сез аны таркатырга тиеш түгелсез. Көрәшергә кирәк. Мин үз урыныма Шәһит Әхмәдиевне калдырам.

Шәһит аның сүзен бүлде:

— Юк, юк, Галимҗан, мин синең белән...

— Ярамый, Шәһит дус, очрашырбыз әле, хатлашып торырбыз.

— Ә син кая китмәкче буласың?

— Казанга. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә. Анда остазым Йосыф мөдәррис икән инде. Сәләтле иде ич ул. Соң, хатын укып күрсәткән идем бит инде, Шәһит.

Сүзгә төптән үк юан үскән калын тавышлы Хәмит кушылды:

— Галимҗан, мин гаҗиз булып калдым, нигә сиңа китәргә ярый да безгә юк, ә?

Галимҗан уратмый-чуратмый, гади генә итеп аңлатып бирде:

— Миңа калырга ярамый, туганнар! Күз алдында әмернамә язылган бит инде. Алар өчен иң куркынычлы кеше идем. Ә хәзер сезгә тимәячәкләр. Чөнки куркалар. Мәдрәсә шәкертсез калса, Вәли мулла армиясез генерал кебек булачак бит...

Аллаһы Тәгалә (Аңа данлау һәм хөрмәт булсын) көферләрне нык күзәткән вә үз рәсүленә-галәйһис сәламгә каршы көрәшүчеләр булуны искәрткән. Мөхәммәт пәйгамбәр (Аңа данлау һәм хөрмәт булсын) үзе урынына туганнан туган энесе Гали Ибне Әбуталипны калдырып кача. Аллаһы Тәгалә исә Мөхәммәтне үтерер өчен сагалаучыларга йокы җибәрә. Эзәрлекләүчеләр йокыдан арынып өйгә килеп керсәләр, Мөхәммәт урынына Әбуталипны күреп хәйран калалар.

Их, Мөхәммәт пәйгамбәр кебек булса икән Вәли мулла. Үзе урынына мәдрәсә башлыгы Заһидулла хәзрәтне калдырып, якасыннан алучыларны йоклатып, күзләрен сукырайтып бетерергә иде. Мәдрәсә хәзер рәсүл алдында калтыранып торган мәҗүс хәлендә калды. Укырга килүчеләр саны елдан-ел кими бара. Шәкертләр килсә, мәдрәсә бар. Шәкерт юк — мәдрәсә юк. Ачкүз Заһидулла хәзрәткә, Зарф кеби җебегән авызларга

ышанып шушы көнгә калдымы ул? Әллә үзенең ми казаны тишек булып чыктымы? Беркөн теге эт авыз Габдрахман сәүдәгәр:

— Япония җиһанның кай төшендәрәк? — дип сорады.

— Мәгърибтә, — дип җавап бирде ул.

Алдаганмы тирес бит, кеше алдында аны адәм көлкесенә калдырырга уйлаганмы, әллә үзе дә белмиме? Ул бит Җәпүниәне Рәсәйдән мең кат зуррак дигән иде. Монысын да аны сынар өчен көлеп әйткәнме хәшәрәт? Ни эшләде бу кешеләр? Нигә аннан каһкаһә белән көлә башладылар? Нигә Аlладан курыкмыйлар? Әллә Аллага ышанмый башладылармы? Алласы бармы бу яхшыдан туган яман Галимҗанның? Беләме ул үзе бу диннең чишмә башы кайда икәнлекне?

Галимҗан боларны белә иде инде. «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән хезмәтен язарга әзерләнә иде ул.

Һәр гыйлемнең, һәр фәннең, хәтта һәр хакыйкатьнең тамыры бар. Галимҗан бөтенесен дә әнә шул төбе-тамырыннан башлап өйрәнә. Үзлегеннән өйрәнә. Бервакыт мәдрәсәдә Коръәнне кем язу турында бәхәс купкан иде. Берсе дә әйтә алмагач, үзен бик белдекле санап, йөзенә менә мин сез җиһалләргә кем икәнлегемне күрсәтим әле, дигән төс чыгарып, Вәли мулла:

— Коръәнне Мөхәммәт пәйгамбәр язган, — диде чатнатып.

Галимҗан анда да Вәли мулланың ялган авызын каплады:

— Мөхәммәт пәйгамбәр укый-яза белмәгән бит.

Сукте дә китте Вәли мулла Галимҗанны:

— Ахмак... мин сине аңлы шәкерт дип йөрсәм... Кеше алдында әйтә күрмә бу сүзләреңне...

Бу хакта Галимҗан шәкертләргә аңлаткан иде инде. Коръәннең гасырлар буе халык күңеле иҗат иткән энҗе-гәүһәрдән торуы, анда ямәү рәвеше, әхлак кануннары тупланувы, сафлык-инсафлылык, намуслылык, кешелеклелек рухының югары дәрәҗәдә куелуы, һәр сүзенең күп мәгънә аңлатуы, асылташтай кыйммәтле булуы хакында бәйнә-бәйнә сөйләп биргән иде. Вәли мулланың шуны да белмәве шәкертләрне нык аптыратты. Шуннан соң Вәли мулла шәкертләр арасында артык буталып йөрмәүне мәслихәт күрде. Күп эшне мәдрәсә башлыгы Заһидулла хәзрәткә йөкләде. Хәзрәт исә төлкедәй койрык болгаучы булып чыкты. Күп очракта шәкертләр белән килешү җаен чамалады: «Әйе», «шулай», «ыһым», «менә тәрәкә» кебек ымлыклар, алмашлыклар, мөнәсәбәтлекләр әйтә-әйтә бер як кырыйга тайды.

Боларның һәммәсен биш бармагы кебек белә Вәли мулла. Үзенең һаман-һаман упкынга таба тәгәрәвен дә сизә. Әгәр җәренгә шәкертләр килмәсә, әһле мәгариф мәдрәсәнең ишеген алагаем кадаклап куячак. Бу Галимҗан дигән текә маңгайга кагыласы калмаган. Егермеләп шәкерт, анасыннан калышмаска тырышкан үрдәк балалары шикелле, аңа иярделәр бит. Әллә акның, караның кем ягында икәнлеген беләләрме шайтан алгырлары? Нинди замана килә соң әле? Егерменче йөз. Башы ук юньсезгә таба юл тотты. Ачлык. Сугыш. Атыш. Үтереш. Илаһым! Ни белән бетәр бу? Бер Ходайның үзенә генә мәгълүм.

Шундый тирән борчылу, хафалану, йончу уйлар давылы дулкынында кайтып керде Вәли мулла өенә. Үзе кебек үк юан, утар бияседәй симез, табак битле, кылыч борынлы, хәйләкәр елмаюлы остабикәсе Гыйззелбанат каршы алды аны. Башка вакытта, мулласы кайтып кергәч, инде карт биягә әйләнүенә карамастан, аның алдында куштанланып,боргаланып-сыргаланып торырга ярата иде ул. Ә бүген симез бәдәне аз гына да уйнакламады, песинекедәй соры күзләре елтырамады, кабарынкы куллары хәрәкәт итмәде. Чөнки мулласының сөмсере коелган, борыны салынган, күз карашларына кадәр мәзәкләнеп-сәерсенеп калган иде. Аңа якын бару да куркыныч. Менә-менә кеше йотарга әзерләнгән дию парисенә охшап тора иде.

* * *

Менә бервакыт Галимҗан, Шәһит бүлмәдә икесе генә калды. Аларның икесенә 38 яшь бит инде. Яшьлек дәртенең ташып, кайнап, ургылып торган чагы. Быел җәй йә казакълар арасына бала укытырга, йә Рәмиевләрнең алтын приискыларына эшкә китмәкчеләр иде. Бу хакта Казанга, Йосыф хәлфәгә дә хат язган иде. Ул һаман әле Галимҗанны үз янына чакыра. Анда Фатих Әмирхан, Галиәсгәр Камал, Шәриф Камал кебек каләм осталары булу турында язган. Йосыф абыйсы үзе дә берничә шигырь бастырган. Галимҗанда да язучылык бөресе барлыгын әйткән. Әгәр Казанга барса, ул бөре ачылып китәчәк тә чәчәк атачак, имеш. Ул бөренең барлыгын Галимҗан үзе дә сизә. Шигырьләр язып карый. Ләкин, Йосыф абыйсы өмет иткәнчә, ул бөре чәчәк булып балкымый, ниндидер чәнечкеле шайтан таягы булып килеп чыга. Аны ул бүлмәдәше Шәһиткә дә күрсәтми хәтта. Укып карый да, күңеленә ошамагач, ертып ыргыта, утка яга.

Галимҗан, үзен кая куярга белмичә, озак кына сүзсез басып торды. Шәһит белә гадәтен: мондый чакта аңа сүз әйтүнең бер файдасы да юк. Авыр мәсьәләне ул күбрәк үзе чишәргә ярата. Әле ул бер башын кая куярга белмәүдән гаҗиз. Хөрриятпәрвәр булу ягыннан Шакирҗан абыйсы аннан уздырып та җибәрде хәтта. «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләре үткән елда ук баш күтәрде. Яңача укыту кирәклек мәсьәләсен кузгаттылар. Әмма горур башлар шул күтәрелгән килеш калды. Башлар түбән иелмәде. Тик аларга түрәләр каты сукты. Утыз өч шәкертне мәдрәсәдән кудылар. Алар арасында Шакирҗан да бар иде. Әтисе Шакирҗаннан баш тартты. Шуннан Шакирҗан Орскига китеп, анда Әхмәт Исхакый мәдрәсәсендә укый башлады. Күпме генә хат язмасын, әтисе җавап бирмәде. Әнисе Хәсәнә абыстай гына бер хат күндергән иде. Ул әрни-әрни, сыкрана-сыкрана, өзгәләнеп язган. Хатка күз яшьләре тамган хәтта. Анда шундый сүзләр бар иде: «И балам! Күз нурым! Йөрәк парәм! Әтиең бик котырына, бик дулый, бик җенләнә. Нигә алай шәригать канунарына каршы киләсез? Үзегезнең нинди нәселдән икәнлегегезне әллә оныттыгызмы? Галимҗан кырысрак холыклы. Шулай да ул моны эшләмәде. Мондый башсызлыкны синнән аслан көтмәгән идек. Инде энең Галимҗан шундый ялгыш юлга баса күрмәсен берүк. Аннан минем якты көнем караңгы төнгә әйләнәчәк. Турыдан гына әйтмәсә дә, әтиең гел мине битәрли. Мин, имеш, сиңа дөрес тәрбия бирә алмаганмын. Әгәр Галимҗан да синең юлга басса, бу дөньяда яшәүнең бер кызыгы да калмаячак».

Бу хатны Шакирҗан Галимҗанга җибәргән иде. Аны укып чыккач, Галимҗан ни уйларга да белмәде. Шакирҗан абыйсының тел төбен аңлады ул. Аның юлын кабатламасын, янәсе. Ата-ана хакы бар бит.

Ата-ана! Алар хәтерен саклап яшәү кирәк тә бит. Ә ничек сакларга? Тормыш бөтенләй башкача яшәргә куша. Ата-ана әйткәнчә түгел. Әтисе үзе дә мәдрәсәне ташлап киткән бит. Авылга кайткан. Дөнья көтәргә. Адым саен «Алла» сүзен әйтеп, халык алдап яшәүче Мөбахис мәзин кебекләр белән бер сафта намаз укып йөрергә яратмый ул. Алла исеме аның канында, җанында, йөрәгендә. Алланы алдарга ярамый. Дин кешелексезлек, әдәпсезлек, миһырбансызлыклар белән килешә алмый. Шуны иман итеп алырга тиеш диндарлар.

Озак уйланды Галимҗан. Аның уйларын Фәсыйх мөдәррис килеп кереп бүлде. Бу әле күптән түгел килгән яңа мөдәррис. Троицк мәдрәсәсендә укыган. Шәкертләр аны тиз үз итте. Аны хәтта намускяр дип атадылар. Исеме дә җисеменә туры килеп тора. Фәсыйх — гарәп теленнән кергән сүз. Матур һәм килешле итеп сөйләүче дигән мәгънә аңлата. Сөйләме дә матур, холкы да күркәм, ак, чибәр кеше. Дөрес, әле ул түбән сыйныфларда сабак бирә. Шуңа күрә Галимҗанга аннан мәгълүмат алырга туры килмәде. Шулай да бәхәс-моназарә вакытларында фикер

алышалар иде. Бу мәдрәсәдә уку унике елга исәпләнгән. Кумасалар да, Галимҗан быел кайдадыр китәргә җыена иде инде. Чөнки җиде елда ул унике еллык кына түгел, әллә күпме белем алды. Әгәр Заһидулла хәзрәт аны «ярамаган» китаплар, урыс әдәбияты укыганы өчен даими рәвештә битәрләп торса, Фәсыйх мөдәррис, киресенчә, моның өчен Галимҗанны һәрвакыт мактап телгә алды. Чөнки Фәсыйх мөдәррис үзе дә әдәби әсәрләр укырга ярата икән. Тургенев, Толстой, Достоевский, Пушкин, Лермонтов әсәрләре буенча алар фикер алыша торган булып киттеләр. Урыс телен Галимҗан Солтанморатта учитель Сәетнең өч еллык школасында ук ару ыган өйрәнгән иде. Урыс әдәбиятын укый-укый ул һаман ачыла барды. Мәдрәсәдән әллә ни ерак тормаган бер урыс белән танышып алды хәтта. Шуның белән сөйләшә-сөйләшә телен чарлады. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Әбелкасыйм Фирдәүсенең «Шаһнамә»се, Каюм Насыйриның «Фәвакиһелҗөләса»сы... Кыскасы, кулына ни эләксә, шуны укыды Галимҗан. Фикер алышканда ул бәхәснең очын кешеләр язмышына, инсаниятлелек мәсьәләсенә китереп тери башлады. Мондый очракта теге яки бу сәбәпнең нигезен гомум яшәештән эзләде. Бер сөйләшкәндә безнең эрага чаклы ук яшәгән борынгы грек философы Аристотельнең: «Дәүләт кануны һәркем өстеннән хакимлек итәргә тиеш»,— дигән сүзләрен әйткән иде. Безнең эрага кадәр яшәгән грек философы Платон сүзләрен дә искә алды. Ул болай дигән: «Әгәр канунның көче булмаса һәм ул аерым шәхесләр кулында гына яшәсә, мин андый дәүләтнең тиздән фаҗигагә очраячагына ышанам».

Бу сүзләрне Галимҗан дәфтәренә язып куйган. Дәүләт кануннары кем өчен чыгарыла? Нигә алар үтәлми? Нигә ул кануннар аерым патшалар кулында гына яши? Ни өчен Хөрмәтулла кебек меңнәр, миллионнар нахактан рәнҗетелә? Ни өчен Мөбахис мәзин кебекләргә канун юк?

Мондый тирән уйланулар Галимҗан күңеленә 1905 елгы революция дулкыннары аша килеп керде. Бер теле кычытканда бу хакта Фәсыйх мөдәррискә дә әйткән иде ул. Фәсыйх мөдәррис, әдәби әсәрләрне күп укыса да, фәлсәфә белән шөгыльләнүче борынгы зур шәхесләрне белми иде. Үзенең һәм башкаларның бу мәдрәсәдә Галимҗаннан бик түбән торуларын аңлады ул.

Ничек кенә булмасын, Фәсыйх мөдәррисне кешелеклелеге, намуслылыгы, аңлылыгы өчен яратты ул. Яңа гасырның мәдрәсә тормышына да яңалыклар алып килә башлавына шатланды. Тик андыйлар диварлары черегән мондый мәдрәсәдә бик озак тормыйлар шул, китеп баралар. «Хөсәения»гә килгән Гаяз Исхакый да надан, җаһил мөгаллим-мөдәррисләр белән тынышса алмады. Галимҗан анда еш барды. Бер сөйләшкәндә әйтте Гаяз Исхакый:

— Сиңа язарга кирәк, Галимҗан туган,— диде.

Бу вакытта Гаяз Исхакыйның берничә әсәрен дә укыган иде инде ул.

Шушы ук фикерне аңа Фәсыйх мөдәррис тә әйтте:

— Фикерең дә зур, сөйләмең дә үткен, кеше язмышы турында да нык уйланасың, сиңа язарга кирәк, Галимҗан,— диде.

Әле дә ул шул фикерне әйтергә кергән. Моннан ике атна чамасы элек ниндидер йомыш белән Уфага киткән иде. Кайту белән, мәдрәсәдәге күңелсез хәбәрне ишетеп, Галимҗан янына аның кайгысын уртаклашырга кергән.

— Мин моны көткән идем, Галимҗан туган, ләкин син кайгырма, кит Казанга, анда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укырсың; остазың Йосыф мөдәррис тә анда бит, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал әфәнделәр белән аралашып яшәрсең, сиңа язарга кирәк,— диде.

Галимҗан тиз генә җавап бирмәде. Мәдрәсәдән куылуына кайгырмый түгел ул. Әтисе Шакирҗан абыйсыннан баш тартты. Шул ук язмыш, кайгы Галимҗан башына да төшәчәк. Һәр елны, җәйге ялга кайткач, уку мәсьәләләрен сораштырып, кызыксынып торды әтисе. Галимҗанның күп белүенә исе-акылы китә. Чыннан да, нәселдән бер пәйгамбәр чыкты

лабаса, дип уйлый. Бу фикерен Галимҗанның үзенә дә әйтте. Ә менә хәзер башлы пәйгамбәр түгел, башсыз пәйгамбәр булып чыкты. Әтисе сүгәчәк. Әнисе күз яше коячак. Алларына мәдрәсә бетерү турында шәһадәтнамә алып кайтып салса, түбәләре күккә тияр иде дә бит. Тик ул бәхет тәтемәде.

Язарга? Нәрсә язарга? Ничек итеп?

Фәсыйх мөдәррис чыгып киткәч, сүзне Шәһит башлады:

— Галимҗан, безнең йә казакълар арасына, йә Рәмиевларның алтын приискыларына барып эшләү нияте бар иде бит?

— Бу ният барып чыкмас шул инде хәзер, Шәһит дус!

— Ни өчен?

— Әткәйгә ярдәмче кирәк. Ул күп иген чәчә. Һәр җәйне нык эшләгәнне беләсең бит. Шакирҗан абый да өйдә юк. Әткәй аннан баш тартты.

— Әтиең мәдрәсәдән икенче мәртәбә куылганың өчен сине...

— Анысын да аңлыйм. Башта әйтмирәк торырга кирәк булыр. Белсә дә, әллә нишләп булмый. Бер давылланыр да туктар әле. Нигә хәкыйкатьтән качарга? Мин инде, Ходайга шөкер, унтугыз яшьлек егет.

## IV

Солтанморат авылы үз шатлыгын, үз кайгысын кичерә-кичерә, бер-бер артлы булып торган авыр дөнья мәшәкатьләрен җиңә-җиңә, кем әйтмешли, чыгырдан ычкынмаска тырышып, яши бирә. Елның дүрт фасылы, кунакка һич кичекми килгән тәртипле вә иҗтиһадлы кеше кебек, вакытында пәйда була да куя. Күңелләргә якты нур бөркеп, йөрәкләрне ярсытыр дәрәҗәдә сихерләп, сандугачлы яз килә. Аны чәчәкле җәй алыштыра. Аның артында — чуар көз. Шуннан соң кыш бабай җирне мамык кар юрганы белән каплый. Әмма соңгы елда дөнья бозылды. Әгәр Алланың бер ахмагы йә аягы, йә таягы белән күпме көч түгеп, җәфа-җофа чигә-чигә, сокланып туя алмаслык матур итеп өйгән кырмыска оясын бутаса, ул мескен изге җаннар күпме михнәт чигә, адәм балаларының шундый ерткыч, түбән җанлы, җаһил булулары өчен рәнҗи, аларга бәддога кыла. Кош-кортка, хәйваннарга, бөҗәкләргә рәхимсез нәҗес җаннар дөнья тулы шул әле. Кеше җәмгысен тапый, изә, сыта. Инде хәзер бер-берсен үтерешү кебек хурлык, гөнаһ юлына бастылар. Суешу. Кан коеш. Ерткычлык. Япон сугышы, инкыйлаб җилләре бөтен Руссияне айкап-байкап, котырына-котырына, шыңшый-шыңшый исте дә, елый-елый, ач бүредәй улап, Солтанморатка аһ орып килеп җитте. Авыл халкы әлеге кансыз хәшәрәтнең пычрак аягы белән туздырылган кырмыскалар шикелле, айкала-чайкала башлады. Берәүләр патша хезмәтенә китә. Икенчеләре «революция» дип җенләнә. Өченче бер төрлеләре байларга теш кайрый. Дөнья астына тәмуг уты ялкыны җибәргән зур казан урынына кайный. Яхшылыкка түгел бу. Түгел. Мең-миллион мәртәбә түгел. Илаһым! Кешеләрнең бер-берсен үтерешүеннән чәчрәгән кан дөнья йөзенә гөнаһлы кара тап булып ягыла. Гөнаһлы илдә бәндәләр имансызга әверелә. Имансыз ил күгәрә, чери, таркала. Ходаем, бу яңа гасыр шулай канга манчылып башланамы?

Әллә шуның тәэсиреме? Быел язы да дию пәриедәй котырынып, аждаһадай үкеренеп килде. Әле карлы-бозлы яңгыр ява, әле агачларны төбе-тамыры белән суырып алып ыргытырдай шашкын җил исә, әле яуган ырашкылар тау-тау булып өелә. Тик менә бүген генә елмаеп кояш чыкты, дөнья йөзенә нур сибелде. Кешеләр күңеле җылынып китте. Әлхәмде лилля, яхшылыкка булды бу!..

Иртән ихатада, абзар-курада, тегендә-монда ансын — алай, монысын — болай итеп, бүгенге дөнья турында уйланып йөргәннән соң өйгә кереп чишенгән иде Гыйрфан мулла, көтмәгәндә бүгенге ялтырап чыккан кояш кебек, улы Галимҗан кайтып керде. Илаһи бу киң дөньяга ике кояш берьюлы чыктымыни!

Мулла абзый быелгы язның шулай котсыз килү сәбәбен ачыкларга теләп, кулына ел фасылларының кәефе-холкы хакында теркәп барган язмаларын алырга уйлаган иде. Хәсәнә абыстайның шул инде: тавыклар гына түгел, бөтен дөнья күгәрченнәре чүпләп тә бетерә алмаслык үз эше — әле ул аш-су бүлмәсендә табак-савыт юу белән мәшгуль. Ата һәм ул башта бер-берсенә озак кына карашып торды. Галимҗанның карашы аңлаешсыз иде. Анда моңсулык та, кайгы да, берникадәр кайту шатлыгы да бар. Ул кулындагы төенчеген бер якка куеп, өстендәге җиләнен салып чөйгә элгәч, ата белән ул бер-берсенә янә карашып калды. Ата кешенең карашы каты һәм сынаучан иде. Мәгълүм инде: ул карашның төбендә, ачылып җитмәгән бөре кебек, кавышу шатлыгы чаткылары да яшеренгән. Ата кеше, шулай бераз карашып торгач, улын барып кочаклап алмакчы булды. Иллә мәгәр моны эшләмәде. Нин-дидер яшерен сихерле көч ашыкмаска, уйларга кушып, күлмәк итәгеннән торды. Бераздан ул:

— Нихәл, улым, исән-аман кайттыңмы, нигә чит кеше кебек түргә узмый торасың? — дип, ике кулын сузып килеп күреште.

— Исән-имин генә кайттым, әткәй, бөтен килеш, күреп торасың ич, барлык мөчәләрем төгәл, кителгән-мителгән җирем юк, — дип, Галимҗан салкын гына елмаеп куйды.

Ничек кенә булмасын, «барлык мөчәләрем төгәл», «кителгән-мителгән җирем юк» дип шаян сүзләр белән җавап бирүе ата күңелен җылытып җибәрде. Галимҗан һаман шулай шаярып сөйләшүчән. «Кителгән-мителгән җирем юк» дип әйтүе, димәк ки, камил акыл белән кайтканлыкны да аңлата. Ата кеше янә барып күреште дә аннан соң, әле миндә ирлек гайрәте йомшармаган дигәндәй, улының ике беләгеннән тотып селекте. Аннан аркасына чын аталарча сугып алган булды да:

— Әнкәсе, һәй, сиңа әйтәм, таш маңгаебыз кайтты бит, чык монда, ташла табак-савытларыңны, — дип кычкырды, шатлыклы, ярсулы тавыш белән.

— Мин бит табак-савыт юмыйм, атасы, сумса пешерәм, әллә ана күңеле бала кайтасын сизмиме, бүген төшемә үк кергән иде, — дип сөйләнә-сөйләнә чыкты да улының күкрәгенә барып капланды. Ана белән бала бер-берсенең кочакларында озак иркәләнештеләр. Хәсәнә абыстай җитеп беткән улын сабый чактагыдай кысып-кысып сөйде дә, калтыранып-йомшап, яшькә тыгылды. Бала алдында яшь күрсәтмәү — ана иманының бер фазыйләте, күркәм сыйфаты иде. Әмма ләкин бу юлы иманының бер як чите кителде. Күпме генә үзен кулга алырга, ярсыган күңелен басарга тырышмасын, буаны ерган көчле су кебек, йөрәк төпкеленнән үк килгән ачы яшьләр өзлексез агарга кереште. Бөгелеп-сыгылып, рәхәтләнеп, сабый бала шикелле үкседе ул. Гыйрфан мулланы тәрле сүзләр белән юатты:

— Йә, җитәр инде, анасы, нишләвең бу, гомергә булмаганны, син бит болай түгел идең, исән-имин кайткан лабаса, үзе әйткәнчә, бөтен мөчәсе — тән әгъзалары төп-төгәл, акылы камил...

Галимҗан әнисенең күз яшьләренә ялкын өстәмәскә, күңелен күтәрергә тырышып, шаян сүзләр кыстыра-кыстыра сөйләште:

— Әткәй дөрес әйтә, әнкәй, һәр яздагыча, үземдә булган барлык мөчәләремне быел да кире алып кайттым, юлда бересе дә төшеп калмады. Аллага шөкер. Дәхи дә шуны әйтим: егет кырына җиттем, акыл казаным зурайды, иманым артты, тирә-ягымда ырылдап йөргән шайтаннарны куар өчен Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән вә дә сезнең илаһилыктан алынган рухи һәм җисмәни көч-куәтем, гайрәтем бар.

«Шайтан» сүзе килеп кушылгач, ата кеше хәтта көлеп җибәрде.

Хәсәнә абыстай да елмаеп куйды. Дөрес, ул сүз гөлбакчасында үскән шайтан таягын хәтерләтте. Шаярып сөйләшкәндә Галимҗанның катыкаты сүзләр кыстыра торган гадәте бар шул. Ул бәгъзе берчак күңелгә кадак булып та кадала. Бу аның усаллыгы гына түгел, бер сүз белән күп

мәгънә аңлату галәмәте дә. Гыйрфан мулла үзе дә шулай лабаса: тормыш ямьсезләүче шайтаннарны җене сөйми.

Вакыт-вакыт аларны чәйнәп ыргытырдай була. Димәк, улы аңа охшап яшәү максатын куйган. Ә нишләп шулай булмаска тиеш әле? Аның каныннан, аның җаныннан, аның кабилиятеннән лабаса! Дөрес әйтә каһәрең: үз тирәсендә буталып йөргән барлык убырлы шайтаннарны капкынга эләктерәчәк бу таш маңгай.

Галимҗанның шаян сүзләре ананың күз яшьләрен дә корытты. Бу йомшауның шатлыктан иләнлегән дә аңлатырга тырышты ана. Чөнки Шакирҗан югалу кайгысы аның төн йокыларын качырды. Шундый хәл Галимҗан тарафыннан да эшләнә күрмәсен, Ходаем, дип үрсәләнде. Әгәр Галимҗан да шул юлга басса, Аллам сакласын, йөрәгем ярылыр, дип курыкты. Галимҗанны күрү шатлыгыннан түгелгән гәүһәр яшьләр алар.

— Сумсам хәзер өлгерә, атасы, син Галимҗан белән сөйләшә тор, озакламый чәй табыны әзерләрмен,— дип, тагын да аш-су бүлмәсенә кереп китте Хәсәнә абыстай.

* * *

Чәй табынында баште тынлык хөкем сөрде. Кайнар, тәмле, авызда эреп торган сумса ашап, бер-ике чынаяк чәй эчкәннән соң, сүз тезмәләре өстенлек алды. Ул башта изге күңелле кешеләрнең мөбарәк тәсбих төймәләрен берәмләп-берәмләп тартуын хәтерләтте. Тора-бара мөбарәк тәсбих өзелеп китте. Төймәләре чәй табынына чәчелде.

Сүзне ата кеше башлаган иде. Әлбәттә, йомшак кына, җай гына, аталык дәрәҗәсен саклаган кыяфәттә. Ул иң әүвәл «юньсезлеге» өчен Шакирҗаннан баш тартуын аңлатты. Аннан соң, җайлап-җайлап, Галимҗанның күңел кылларына чиртә башлады. Укулар ничек бара? Вәли мәдрәсәсе ни хәлдә? Вәли мулланың үз сәламәтлеге ничек? Шәкертләр арасына инкыйлаб шайтаннары кермиме? Тегесе-монысы, фәлән-фәсмәтән...

Галимҗан туры гына җавап бирмәде. Шаяртып маташты. Ул мәдрәсәдән куылу мәсьәләсенең җеп очын хәзергә яшереп торырга уйлаган иде: әтисен, әнисен борчыйсы килмәде. Әмма безне капчыкта яшереп тотып буламыни. Бервакыт тишеп чыга бит ул. Вәли мулла әтисенә хат язмый калмас. Чөнки алар дуслашып та киткән иде. Барган саен әтисе аңа зур бүләк-күчтәнәч бирә. Хат килсә, мәдрәсәдән ни өчен куылганлыкны тәсдыйк итсә, аңа, Галимҗанга, әтисе-әнисе алдында тагын да авыррак булачак: «ялганчы» дигән шелтә сагызы ябыштырачаклар маңгаена. Әйдә, уты-ялкыны бергә булсын. Куылуын ул башта туры гына әйтмәде. Әлеге әтисе соравына җавап биргәндә:

— Революция шайтаннары күбәйде, эткәй, мәдрәсәдә, мин шуларның берсе,— диде.

Ата кешенең күзләре маңгаена менде. Хәсәнә абыстай да калтыранып куйды. Сөйләшә-сөйләшә сүз шуңа барып җитте: Галимҗан мәдрәсәдән куылуын ачыктан-ачык әйтергә мәҗбүр булды. Һәр ат карагының «һөнәре» энә урлаудан башлана. Вак-төяк алдау кешене зур алдакчы булу «дәрәҗәсенә» җиткерә. Соңгы чиктә ул ике йөзле явызга әверелергә мөмкин. Боларны Галимҗан яхшы белә.

## V

Табигатьтә, яшәештә, кешеләр йөрәгендә, бөтен матди дөньяда, галәм киңлекләрендә — капма-каршылык. Көннәр бу арада тормышны, бәндәләрне, табигатьне яратмаудан мәңге эче пошып,

сыкранып, үрсәләнеп йөргән кара йөзле кешенең аһ оруы кебек булып торды. Аннан соң матур күңелле, олы йөрәкле, хис-тойгыларга бай кешенең елмаюын хәтерләтеп торган кояшлы аяз көннәр киләчәге табигый хәл. Килде. Ялтырап кояш чыкты. Җиһан әле якты-җылы нурлар эчендә изрәп ләззәтләнә. Ә йөрәкләрдә давыл, гарасат, томан.

Шул хакта уйлап ятты Галимҗан. Көне буе матур, җылы, кояшлы көн булды. Кояш офыкка якынлашканда кып-кызыл ут тәгәрмәчедәй булып янып торды. Офыкка килеп терәлгәч, ул алсу-кызгылт төскә әйләнде. Бу вакытта ул бит очына ал сөрткән көләч кызны хәтерләтте. Ә инде өске ягындагы сыек зәңгәрлек, гүя, сөрмә тартылган күз карашлары балкышы. Офыкта кояш моңаеп торды-торды да көне буе күк йөзендә исән-аман йөзүнең чигенә амин тотып, бәндәләр саулыгына дога кылып, матур төн үткәрергә фатихасын биреп, шифалы-йомшак нурлар калдырып баеды. Хәзер моңсу зәңгәр төн. Тынлык. Өскә кояш нурларыннан алып кергән йомшак юрган ябылган. Әмма эчтә давыл. Өермә. Зилзилә.

Галимҗан белән Габделхәким икенче катта йокларга булдылар. Галимҗан уң як стена буендагы караватка ятты, Габделхәким сул яктагысына. Габделхәким хәзер ун яшьтә инде. Сабакны башта әти-әнисеннән алды. Хәзер мәдрәсәдә һәйбәт кенә укый. Җәй көне, җае туры килгән саен, аның белемен Галимҗан да тикшереп кенә торды. Башта алар бераз сөйләшеп яттылар. Габделхәким шул ук әтисе-әнисе биргән сораулар белән йөдәтте. Нигә куганнар мәдрәсәдән? Хәзер кайда укыячак? Йә хәлфә, йә мулла, йә мәзин булырга хокукы бармы? Тегесе-монысы...

Галимҗан башта аны шаяртып маташты. Комсыз Мөбахис мәзинне беркем дә яратмый, ул шунын урынына кайткан, мәчеттә моңлы итеп азан әйтәчәк, имеш. Аның моңыннан бөтен авыл халкы сокланып ләззәтләнәчәк. Шуннан Галимҗан аны икенче бер төрле моңнар арасына алып кереп китте. Җыр моңы, дала моңы, йөрәк моңы турында сөйләде. Тик аларны Габделхәким тыңлап бетерә алмады. Тирән, татлы йокыга чумды. Андый йокы белән Галимҗанның да рәхәтләнәсе бик килгән иде. Ләкин уй чәнечкеләре йөрәген даими чәнчеп торды. Мәдрәсәдән куылганлыгын әйткәч, әтисенең күзләре котырган бүренекедәй ялт-йолт килде, тешләре озак кына шак-шок итеп торды, калын иреннәре тегермән ташы дырылдавын хәтерләтеп дерелдәде. Бу минутта аңа бер сүз әйтү дары мичкәсенә шырпы сызып ыргыту булыр иде. Шулай да Галимҗан сүзсез калмады.

— Әткәй! Дөреслекне якларга, иманга турылыклы булырга, алдашмаска син безне үзең өйрәттең бит; әнкәй дә шул рухта тәрбияләде,— диде.

Ата кешене бу сүзләр ярсытып кына җибәрде:

— Мәдрәсәдән куылу дөрес юлмы?

— Кайгырма, әткәй, югалмам.

— Ни эшләмәк буласың?

— Мәдрәсә бетмәгән бит.

— Һм... Кәккүк кебек, оя сайлап йөрмәк буласыңмы?

Сөйләшү шактый озакка сузылды. Галимҗан, әллә күпме вәгъдәләр биреп, әтисен юатырга тырышты. Ике улының да мәдрәсәдән куылу кайгысын күтәрү атага җиңел түгел. Моны аңлый Галимҗан. Тик бер яманлыкның яхшы ягы булуны аңлату кыен. Вәли мулланың кадим мәдрәсәсеннән куылу — яманлык. Аннан котылу, икенче мәдрәсәгә барып уку — яхшылык. Шул хакта да әйтте ул әтисенә. Әмма әтисе, комнан аркан ишеп булмый, дигәнне аңлатып, кулын гына селекте дә:

— Оят! Адәм арасында оят! Авыл халкы бот чабып көләчәк,— дип гайрәт чәчте.

Әнисе сүзсез генә торды. Ул эчтән кичерә. Эчендә кайгы уты икәнлекне Галимҗан белә. Аны кызгана. Шакирҗан өчен хәсрәтләнеп, ярты гомерен югалтканлыкны аңлый Галимҗан. Шуның өстенә икенче тетрәү. Бер ана йөрәге бит ул. Ул йөрәктә ана мәхәббәте, сафлык, садәлек, аклык

сакланырга тиеш. Ләкин балалар ул йөрәккә кара яга, ут сала. Әлбәттә, Галимҗан тынычландырыр яраткан, матур күңелле, олы йөрәкле анасын. Шундый уй-хисләр давылында йокыга талды ул.

Ата белән ана аскы каттагы сәкегә урын җәеп җайлаштылар. Гыйрфан мулла орчык урынына бөтерелеп-бөтерелеп ятты. Сизә остабикәсе: мулласының йөрәге яна, күңеле ярсый, үзен-үзе өзгәләп ташлау чигенә җитә.

Абыстай аны һаман шул элеккечә йомшак сүзләре белән юата:

— Мулла! Акылыңа кил! Ходайдан сабырлык сора! Әгәр ярсу йөрәгеңне баса алмасаң, иртән әллә нишләп ташлавың бар. Бу Галимҗанга кире тәэсир итәчәк. Аның әллә кая китеп югалуы мөмкин.

Остабикәсенең үгет-нәсихәтен аңлый мулла. Пырдымсызлыгын да таный. Шуның аркасында бәла-каза күрүен дә белә. Шакирҗанның кайтмавы да шуңа бәйләнгән. Теге вакытта җенләнеп китеп ат куу, бер сөзәк җирдә арба аву, атлар тәгәрәп китү... боларның барысы да пырдымсызлык сөземтәсе. Андагы этләнүләрне ходай дошманыңа күрсәтмәсен.

— Ярый, остабикә, син әйткәнчә булыр, кудым җанымны ярсыткан җеннәрне, иртәнге намазны бозык күңел белән каршыламыйк; иштә, ходай кушмаган эш булмас; Галимҗанны җиңү авыр хәзер, ул таш маңгай баш бирмәс байтал кебек, йоклыйк әйдә,— дип мулла абзый үзе үк остабикәсен тынычландырырга тырышты.

## VI

Кеше күңеле бәгъзе бер вакыт бөтен галәмне сыйдыра ала. Яки ул матди дөнья әйбер-җисемнәрен уч төбендә биетергә ярата. Биетеп-биетеп рәхәтләнгәч, учын йомарлый. Учында калганнарны, илаһилык мәрҗәнен ычкындырмаска тырышкан изге күңелле зат кебек, кысып тотарга тырыша. Әйтерсең, шунда аның бәхет орлыгы, киләчәк язмышы, гомер сукмагы.

Кондызлы күлнең текә яр башында уйга чумып, моңаеп, хис-тойгылар ташкынында газапланып утырган Галимҗанны да әле шундый кемсәләрнең берсенә охшатырга мөмкин. Бирегә еш килә ул. Эш юкта. Һәр форсаттан файдаланып. Җәй зур мәшәкатьләр белән үтеп китте. Һәр елдагыча иген игү, печән чабу, урак уру, ашлыкны келәткә салу кебек эшләр башкарылды. Галимҗан һәр көн басу хезмәтенең үзәгендә-күзендә булды. Болай рыядан гына түгел, ихлас күңелдән, ләззәтләнеп, ялкынланып, авыр кыр хезмәтенең үзенчә бер сәнгатен тоеп эшләде. Кичләрен Авыргазыга йөгерде, балыктай йөзеп, чумып-чумып, арыган-алҗыганлыгын елга дулкыннарына агызып җибәрде. Судан чыккач, үзен бөтенләй эшләмәгән, арымаган, җиңел сөякле кеше итеп тойды. Кыскасы, җисмәни һәм рухи яктан чыныкты. Үзен рәйхан мае белән сөртелеп җиңеләйгән кешедәй хис итте.

Бүген сентябрь уртасы. Хәзер үзенчә бер матурлык. Агач яфракларында мең төрле бизәк: яшел, яшькелт, ямь-яшел, сары, саргылт, сап-сары, кызгылт, соры-кызгылт, сары-кызгылт...— тагы да әллә нинди төсләр. Табигать яшелдән сарыга тиз генә күчәргә ашыкмый. Адәм балаларының күз явын төрле төстәге бизәкләрен күрсәтеп алмак була, күрәсең. Аннан инде ул бизәкләр тәмамән уңып бетә. Саргая. Корый. Көзге усал җилләр аларның язмышы белән нык шаяра: башта бөрәмләп-бөрәмләп, аннан куплап-куплап, ана имчәгенә ябышкан баладай үз ботагында иркәләнеп-эленеп торган яфракларны туздырырга, өзеп-өзеп ыргытырга тотына. Яфраклар, имчәктән аерылган бала кайгысын тоеп, яралдырып дөнья күрсәткән ботак-аналарыннан күз яшьләрен түгә-түгә аерылырга мәҗбүр булалар. Алар җиргә төшәлә. Аларны таптап-таптап үтәләр. Алар өстенә бервакыт кар катламы җәелә.

Ләкин моңа шактый вакыт бар әле. Хәзергә — сентябрь уртасы. Әмма көн җылы. Җәйдәге кебек. Ай башында да шулай булды. Җылылык җәйнекеннән әллә ни аерылмады. Тик моның кире ягы да бар икән. Сентябрь шулай булса, кешеләр сәламәтлегенә зыян кылә, имеш. Моны-сын Галимҗанның әтисе әйтте. Ул сынамышлар белән шөгыльләнә. Бөтенесен дә гамәл дәфтәренә яза бара. Андый көннәрнең серле-сихри кире йогынтысы, чыннан да, йомшак бәдәнле шәһәр халкының бәгъ-зеләрен бәлтерәтәдер, кан басымын күтәреп, әлсерәгән тавыктай йөрер-гә, йөрәк авыртуыннан зарланырга мәҗбүр итәдер. Авыл халкының бу хакта уйларга, йөрәк тотып җебеп утырырга, тышкы тәэсирләр белән гасабиләнергә аслан мөмкинияте юк. Аңа кыишлык азык әзерләп куярга кирәк. Шуның өстенә ул баланын, миләшен, гөлҗимешен, шомыртын, мәтрүшкәсен — тагы да әллә ни төрле җимешләре, шифалы үләннәрне җыеп куя. Ул җимешләрдән, ул үләннәрдән аңкыган хуш ис тәнеңә сарыла, танау тишекләреңне ярып кереп, бөтен эчке әгъза күзәнәкләренә сеңә. Менә сиңа шифа! Менә сиңа дару!! Менә сиңа сәламәтлек!!!

Кешеләр әле һаман су керә. Елга аларны көләч йөзе белән каршылый. Үз кочагына алып, дулкыннары белән иркәли. Елгага адәм баласы ашкынып, ярсып, йөгерә-йөгерә килә. Алар елганы ярата. Шуңа күрә елганың да бәндәләргә карата булган мәхәббәте ифрат зур. Ул кешеләр-не чыныктыра, сәламәтләндерә, матур күңелле итә.

Тик җәй белән чагыштырганда күк зәңгәрлегендә, көннең үз нурында үзгәрешләр дә юк түгел. Күк йөзенә сизелер-сизелмәслек кенә булып, күе-зәңгәр төс килеп кушылды. Өйләдән соң, кичкә таба ул аеруча нык埋 сизеләнә. Көн яктылыгына бәлләвер төс өстәлә. Шуның белән бергә, күк йөзенә дә, көн яктылыгына да көзге моңсулык нурлары сибелә.

Галимҗан әле шушы моңсулыкны күзәтә. Кондызлы күл яры башын-да зур гына бер таш бар. Ул утынлыктагы бүкәнне хәтерләтә. Өсте тип-тигез. Әйтерсең, Ходай Тәгалә аны кешеләр утырыр өчен махсус шулай эшләп куйган. Шунда утырып, Галимҗан озак-озак матурлыкка карап сокланa. Якында гына йодрык зурлыгы янә бер таш ята. Анысында җемелдәп торган вак-вак бөрчекләр бар. Ул бөрчекләр энҗе-мәрҗәнне, гәүһәрне хәтерләтә. Әллә чыннан да бу ташның эче тулы энҗе-мәрҗән-ме? Асылташ дигәннәре шушымы әллә? Әллә якут ташымы бу? Килеп утыру белән Галимҗан аны кулына ала. Шул энҗе-мәрҗәннәргә со-кланып, исе-акылы китеп карап тора. Кеше өчен табигать нинди генә гүзәллекләр ясамый, дип уйлый. Ул бүген дә шулай итте. Шул энҗе-мәрҗән, гәүһәр белән бизәлгән ташны кулына алып, озак кына илһам-ланып карап торгач, аны кире урынына куеп, күзен табигать гүзәллегенә ташлады. И табигать! Җанлы син! Олы йөрәкле син! Шагыйрь син! Илһам чыганагы син! Адәм балаларына аң-акыл, хис-тойгы, яшәү дәрте бирүче син!

Шундый татлы, тирән, серле, сихри уйлар дөньясында йөзә әле Галимҗанның күңеле. Ул иртәннән бирле табигать белән хушлашып йөрде. Авыргазы, Турсәгәле, Исәнбикә буйларында, Зәңгәр чишмә янында булды. Табигать, әйтерсең, аның сөйгән кызы. Ул шул кызны иркәләүче солтанат егет. Иртәгә ул Уфага китәчәк. «Галия» мәд-рәсәсенә. Менә ни өчен хушлаша табигать белән. Авыл табигатен ташлап китү яраткан-сөйгән ярдан аерылу белән бер икән. Ә менә моннан, Кондызлы күл ары башыннан, бөтенесе дә уч төбендәгедәй күренә. Шул ук Авыргазы белән Түрсәгәле елгаларының бер-берсе кочагына ташланган һәм үбешкән урын. Зәңгәр чишмә. Исәнбикә болыны. Тугайлар. Болыннар. Кырлар. Аларның һәрберсенең йөрәге бар кебек. Ул йөрәкләр бер-берсенә мәңге өзелмәс хәяти чылбыр белән тоташкан. Чылбырлар буйлап йөрәк каны ага. Йөрәк каны, йөрәк тамырлары аларны илаһи бер бөтен табигать җисеменә әвереләрдерә. Бу җисемнән гарьше көрсидәге кебек үзенчә бер яшәеш тәхете барлыкка килә.

Әле төш күптән авышып, кояшның баерга табан юл тоткан мәле. Кояшның йөзе ачык, тонык, ап-ак. Җәй көнендәге кебек эссе нурлары белән көйдерми. Шулай да җылы. Хәзер икенче төрлерәк нур: күзгә, моңсу, сабыр нур. Күк йөзе куе-зәңгәр. Ә җирдә кырлар, болыннар, тугайлар, елгалар, күлләр, гөлләр, чәчәкләр, җир рәйханнары, миләүшәләр, сөмбелләр, лаләләр... Әллә боларны ташлап китмәскәме? Әтисе кебек җир кешесе булып калыргамы? Өйлән. Дөнья көт. Җир сөр. Сукала. Тырмала. Чәч. Ур. Ат, сыер, сарык, кәҗә, каз, күркә, тавык асра. Әтисе гәрчә шушы эшләрне сөеп-яратып башкарса да, Галимҗанга алай кыланырга ирек бирми. Укырга, тәмамланган мәдрәсә белеме алырга куша. Галимҗан башта Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен сайлады. Йосыф хәлфә кулы аша үтсә, бик тә яхшы булыр иде. Ләкин тора-бара ул уеннан кире кайтты. Ул үз кендегенең шушы туган җир кендеге белән нык бәйләнгәнлеген сизде. Аны өзеп булмаячакны аңлады. Ул үзен каты холыклы, кырыс табигатьле, усал кешегә санап йөри иде. Сагыну хисе көчле икәнлеген аңлагач, бу уеннан берникадәр кире кайтты. Үзен йомшаклыкта гаепләде. Ләкин бусы да дөрес үк түгелдер. Сагыну олы йөрәкле, матур күңелле, хис-тойгы бай кешеләргә хас, имеш. Моны бер акыллы баш әйткән. Галимҗан аны кайдадыр укыган иде. Димәк ки, сагына белүгә катылыкның, йомшаклыкның кысылышы юк. Ә инде боз йөрәкләр, хис-тойгыдан мәхрүм мескеннәр, кешелексезләр сагына белми, ди. Уфа ерак ара түгел. Кайтыр да килер, кайтыр да килер. Сагыну ялкыннарын урманнар, күлләр, елгалар, гөл-чәчәкләр арасында балкып утырган туган авылының сөйкемле вә мөхтәрәм кешеләре арасына кайтып басар.

Шундый уйлардан соң ул табигатькә янә бер күз сала. Озак-озак моңаеп карап тора. Юк, бу моңаю гына түгел. Ярсу, хыяллану чигенә житү, уй-хисләренең иң тирән диңгезенә чуму бу. Шушы бай, моңсу, сихерле, шигъри табигать хозурландыра, шашындыра, җенләндерә аның күңелен. Бу сихерле табигать эчендә мең-миллион адәм балалары уйный, шаяра, матурлык белән ләззәтләнә кебек. Күңелдә ниндидер яңа, моңа чаклы булмаган хис-тойгы давылы купты. Ул давыл котыра, җенләнә, үрле-кырлы китерә.

Ул әле «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәясен ничегрәк итеп язу турында да хыяллана. Гаяз әфәнде Исхакый язарга кушты. Ул кешеләрне дүрт төргә бүлде. Беренчеләре — тормыш баскычының иң югары өлешендә торучылар. Болар ил, халык мәнфәгате белән яшәүче Йосыф пәйгамбәр кебекләр. Халыкка инсафлылык, әдәплелек, кешелеклелек дине булган ислам динен иңдерүче соңгы пәйгамбәр Мөхәммәт Галәйһиссәлам дә шуңа керә. Икенче төркем беренчеләрнең эш-гамәли тегермәне куласасына шифалы су коеп торырга тиеш, имеш. Яки алар ил, халык мәнфәгате дилбегәсен бергә тотарга хаклылар. Гаяз Исхакый әфәнде җәнаплары казакъ халкының бөек акыны Абайның бер шигырен дә әйткән иде. Галимҗан аны язып алды да соңыннан ятлады:

Ант итеп, антын бозган җаны корсын,
Кыска көндә кырык җиргә киртә куеп
Йөрүче хәйләкәрләр тагын корсын,
Бер атна йөз үзгәргән йөзе көйгер,
Үз-үзенә масайганның аты корсын.

Әйе, өченче төргә хәйләкәр кешеләрне керткән иде Гаяз әфәнде. Алар — әлеге беренче һәм икенчеләрнең кылган әмәлен үзенеке итеп күрсәтергә тырышучы кыл койрыклар. Дүртенче төрне ахмаклар тәшкил итә. Болар, Гаяз әфәнде әйткәнчә, хәйләкәр генә түгел, ә бәлки кешенең хәяти сукмагына аркылы сузылып ятарга маташучы аңгыра сарыклар. Бу дүртнең үз эчендә тагын мең-миллион төрлелекләр бар, ди. Гаяз Исхакый җәнаплары әйткәнчә, язучы әнә шул төрлелекләрне аң-акылы,

йөрәк хисе, күңел тойгысы белән сиземнәргә тиеш. Ә ничек сиземлисең? Бармы соң Русия җирендә беренче төргә керүчеләр? Николай патшамы? Юк инде. Аның үзен бәреп төшерергә кыҗрыйлар. Революция шуның өчен булды. Әмма ул ялкынланды да сүнде. Күмере, көле генә калды. Иллә мәгәр ул күмергә янә дә ут салып, кабыза-кабыза, дөрләтеп җибәрәчәкләр, имеш. Революция тагын да катырак, берәгәйлерәк, ялкынлырак балкыячак, янәсе. Патшаны тәхеттән бәреп төшерми торып, барыбер тынмаячаклар, ди. Нинди тәрәкъкыйпәрвәре булмаган патша ирәеп утырыр йомшак кәнәфиле алтын тәхеттә тагын да? Йосыф пәйгамбәр кебек хөрмәтле вә гыйззәтле була алырмы? Илгә, халыкка бәхет өләшерлек, аларны тәшвишкә салмаслык акылы, кодрәте булырмы? Язмыш ике төбәйле, диләр. Галимҗанның башында әле мең төбәйле уйлар, йөрәгендә кайнар хис-тойгылар кайнаша. Алар гавам халкы язмышына бәйле. Әтисе җирне дә дүрт төргә бүлеп карый. Бәлки, бөтен галәм якынча дүрт катламнан торадыр: күк тәхете, безнең кояш иле — галактикасы кояш белән җир арасы, җир үзе.

Шул хакта уйлап, мең мәртәбә баш вата-вата бөтен галәм киңлеген айкап чыккач, Галимҗанның күңеле янә җиргә — үз авылының изге туфрагына әйләнеп кайтты. Алланың нинди кашка тәкәсе керә беренче төргә? Авыл старостасы Тәхлисме? Юк. Ул — сатлык җан. Җаһил. Аның өчен арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит. Кеше язмышы, кеше бәхете, кеше киләчәге — аның өчен сукыр бер тиен. Андагы тәкъвасезлек галәмәтен шайтан да чүпләп бетерә алмас. Хөрмәтулла абзыйның фаҗигале үлеме — аның аркасында: «сарык буры» дигән нахак бәла тактылар. Сарык табылды. Мөбахис мәзиннең өенә ут төрткән дип, Себер җибәрделәр. Соңыннан ачыкланды: мәнсез остабикәсе абзар артына күмерле көл түккән булган; утлы күмерне җил очырып, коры салам арасына китереп салган. Монысы Ходай эшедер, бәлки. Чөнки харам мал бервакыт барыбер янарга тиеш. Мөбахис мәзин дөньясын яңадан тергезде. Менә дигән йорт салды. Ярый. Булсын. Яңа бер тарлык та юк. Хөрмәтулла абзый төрмәдән кайта. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, Мөбахис мәзиннең җирән кашкасы югала. Авылда янә «Хөрти урлаган» дигән хәбәр тарала. Бу юлы Мөбахис мәзин теге вакыттагы үчен җиренә җиткерү максатын куя. Сүзе аста калмасын, янәсе. Хөрмәтулла абзыйны тереләй күмәләр дә ташлыйлар. Галимҗан булса, моны эшләтмәс иде, билгеле. Ул инде ир корына җиткән егет кеше. Чәйнәшер иде. Тешләшер иде. Сүзе белән дә егар иде тегеләрне. Әтисе дә өйдә булмаган. Мондый вәхшилеккә ирек куймас иде. Көрәшер иде. Мөбахис мәзин үз табан астын ялаучы ярлыларны җыйган да хөкем чыгарганнар да куйганнар. Ике бозауга кибәк аерып бирә белмәгән надан, җаһил староста Тәхлис Мөбахис мәзиннең кубызына биегән. Бу бит — түбәнлек, имансызлык, хурлыкның иң пычрагы.

Бу гаделсезлекне, бу вәхшилекне, бу ерткычлыкны күтәрә алмый Мәликә түти. Акылдан яза. Кулына күсәк тотып килә дә Мөбахис мәзиннең тәрәзәләрен кыра. Шуннан унлап ир килеп, кулларын артка каерып бәйлиләр дә Нәҗметдин мәзиннең таш келәтенә китереп ябалар. Ул башта җан әчесе белән гел җырлап ята. Аннан тына. Өч көннән соң җан тәслим кыла. Баш бала Мәдинә-Акчәчкә хәзер ике энесе, өч сеңлесе өчен ана да, ата да булып калды.

Акчәчкә! Галимҗанның беренче мәхәббәте иң ул. Кайткан саен күрми калмады. Эч серен ачып салгач, Кендек әбисе Хәмдия абыстай аңлады Галимҗанның күңелен. Бервакыт шул караңгы базында очраштырып, үзе чыгып китте. Тик Галимҗанның мәхәббәтен кабул итмәде Мәдинә-Акчәчкә. Теге вакытта:

— Кырлык белән бодайны бергә кушмыйлар, Галимҗан абый,— дигән иде.

Димәк, ярлы баласы булганга, үзен кырлыкка саный; бай нәселдән чыккан Галимҗанны бодайга тиңли.

Бу юлы:

— Житен борчасы житен чәчәген харап итә бит ул, Галимҗан абый,— диде.

Димәк, ул Галимҗанны житен чәчәге дип исәпли, ә үзен шул чәчәкне харап итүче борчага охшата.

Кызның үткен телле, авыр табигатьле, шигъри күңелле, тәкәллефсез булуы Галимҗанның йөрәген янә мең кәррә ярсытып җибәрде. Акыл иярәренең мәхәббәт турында әйткән сүзләрен дә тугылады, кат-кат тәсдыйк итте ул. Мәхәббәтнең бай, ярлы баласы булуга нигезләнмәвен дә тәмамән аңлатырга тырышты. Мәхәббәтнең асылы күңел байлыгына бәйләнгән. Галимҗан шул иманга инанды. Мәдинә — бай күңелле кыз. Шул җиткән. Анынча, калганы тормыш көткәндә, майлы табада шуган коймак шикелле, үзеннән-үзе җайга салына. Мәхәббәт ул — бөек сафлык! Галимҗан Оренбургта чакта Галишер Нәваины укыганда аның бу хакта әйткән сүзләрен ятлап та алган иде. Шуларны җиткерде, кат-кат тәкърарлады ул Мәдинә-Акчәчкәгә:

> Гыйшыкка сафлык җан кебек кирәк,
> Чуар хисләрне сыйдырмый йөрәк.

Аларның икесендә ике тел иде: Мәдинә-Акчәчкә сүзләрне авылча «чәчә», Галимҗан зыялыларга хас назлы, йомшак, купшы лисан-тел белән эш итә. Шуның белән ялгышты да ул. «Гыйшыкка сафлык җан кебек кирәк», дигән сүзләрне Мәдинә-Акчәчкәнең йөрәге кабул итмәде. Чөнки ул үзен саф җан дип исәпләми. Әйтерсең, аның җанына ярлылык кере сеңгән. Җитмәсә, әтисенең төрле яклап «пычрануына» Мәдинә бик нык кыенсына иде. Нигә шундый керлелек белән ак нәселнең саф чәчәге булган Галимҗанны караларга? «Чуар хисләрне сыйдыра алмый» дигәне дә тетрәндерде Мәдинәне. Хисләре нинди Мәдинәнең? Чуармы? Кем белсен. Караңгы баз кебек өйдә яшәгән ярлы кызының хисләре томанлыдыр инде ул.

Бу очрашу былтыр булган иде. Аларның икесенә утыз алты яшь иде бит инде. Мәхәббәт, яратышу, сөешү турында һич икеләнми, мөкиббәнә, эчкерсез сөйләшер вакыт. Шулай да Мәдинә-Акчәчкә кулын да тоттырмады, кочакларга да ирек куймады. Бу очракта да ул хис-тойгысын халык әйтеменә нигезләп:

— Галимҗан абый, соңгы сүзем шул: минем сыерчык оясына ялгыш килеп эләккән чыпчык буласым килми, моннан ары болай әдәпсез кыланмагыз, чакырмагыз, очрашулар файдасыз,— диде дә матур гына елмаеп чыгып китте. Бу Галимҗан өчен түбәнлек иде. Ул янды, көйде, үрсәләнде, йодрыгы белән маңгаен төйде. Актүти кайтканчы чыгып китмәде.

Актүти мәсьәләнең мәсләген тиз сизде.

— Ул сине җарата бит, балакаем, нык җарата, әллә шыны аңламыйсыңмы... Бакчи... кобараң очкан, төсең киткән, шылай җарамый бит инде... Ул җарлы кызы булганга кәмсенә...— дип Галимҗанны төрлечә юату ягын карады. Галимҗан исә:

— Юк, Актүти, ул мине яратмый,— диде дә, ачуын уч төбенә йомарлап, кырт кына чыгып китте.

Чынында исә Галимҗанга гашыйк иде Мәдинә. Аны беренче мәхәббәте дип исәпләде. Ләкин... Ләкин... ак күңелне каралыйсы килмәде Мәдинәнең.

Кешеләрне төрләргә бүлгәндә дә күңелгә әнә нинди уйлар килә икән. Югарыга әтисен дә куеп карады ул. Ләкин ул башлык түгел. Шуңа күрә ил, халык мәнфәгате белән яшәү ягыннан караганда, аны өстән аска таба икенче баскычка бастырырга мөмкиндер. Яхшы, иҗтиһатлы башлыкка ул җанын фида кылырга да әзер тора.

Өченче төркемгә Мөбахис мәзин кебек хәйләкәрләр керә. Дүртенчесенә — староста Тәхлис ишеләр. Ә менә Хөрмәтулла абзый сыманнарны кая куярга? Андыйлар, гәрчә үзләре кыерсытылган булсалар да,

башкаларга аслан яманлык теләми. Димәк ки, олы йөрәкле, матур күңелле, кешелекле булып чыгалар. Аларны икенче төркемнең бер күзәнәгенә «сылап куярга» мөмкиндер, бәлки.

Авылга Мөхәммәтгали исемле яңа ахун килде. Аны мактыйлар. Кешелекле, иҗтиһатлы, эзлекле, имеш. Әйдә, аны югары шүрлеккә мендерик. Белеме, акылы, шәфкатьлелеге белән авылга иман нуры чәчсен, бәндәләрнең рухын күтәрсен, Ходай Тәгалә кушканны гавам халкына түкми-чәчми җиткерсен. Амин!

Күңел сандыгына күп нәрсә җыелган икән. Аңа менә шушы күркәм табигатьнең аллы-гөлле чәчәкләр хуш исе сеңгән. Шушы гүзәллекнең энҗе-мәрҗәннәре, гәүһәрләре җыелган ул күңел сандыгына. Табигатьтән бар булган матурлык алынган. Ул булачак язучының йөрәк төпкеленәчә үтеп, бөтен әчке әгъзаларына таралган. Әллә нинди дә сихри көч аның колагына «яз», «яз», «яз» дип пышылдый; бу матурлык эченә генә сыеп бетмәс, аны башка урыннарда яшәгәннәргә каләмең белән сурәтләп-тасвирлап күрсәт, табигатьтән алганыңнан мең өлеш артыграк итеп сылулап-чибәрләп, тәҗәссемләп бир, ди. Ул инде табигать матурлыгы белән әсәрләнүче, хисләнүче, шашынучы хыялый зат кына түгел, тормышның әчесен-төчесен татучы, гаделсезлек, хаксызлык, юньсезлек өчен сыкранучы, Хөрмәтулла кебек миллионнарның язмышын үз йөрәгенә алучы шәхес булып та житлекте.— «Җазыгыз менә шуларны»,— дигән иде теге вакытта Хөрмәтулла абыйсы. Әле дә менә мең-мең юксыллар, ярлылар аның колагына: — Яз, яз, яз»,— дип пышылдыйлар сыман.— «Язам, язам, язам»,— дип ант итте Галимҗан. Менә шушында. Табигать кочагында. Гөлләр-чәчәкләр арасында. Туган туфрагында.

* * *

Озак утырды Галимҗан бүген Кондызлы күл яры башындагы бүкәнне хәтерләткән таш өстендә. Ул, әйтерсең, авылының бөтен табигать матурлыгын су урынына эчә, йота, бөтен әгъзаларына сеңдерә, чалбар кесәләренә тутыра, яңа мәдрәсәдә бер кышка җитәрлек хуш ис, болын һавасы, чәчәкләр шифасы алып китә. Ул бүген мәдрәсәдәгечә, шәкертчә киенмәде. Әнисе теккән кара чалбар, ак күлмәк киде. Күлмәкне чалбар эченә тыкмады, тышкы якта калдырып, билен әнисе ясап биргән бармак юанлыгы гына ефәк билбау белән буып куйды. Аның ике очы да биленең уң ягына туры килеп, шунын берсе озынрак калдырылды. Ул оч чачаклы-чачаклы булып,бер сөям чамасы аска төшерелеп, асылынып тора. Очында төрле бизәкле җепләр. Ул чачаклы мәкне дә, чачаклы канәферне дә хәтерләтә. Күлмәге төз якалы. Изүе ачык. Сул як яка төз тора. Уң яктагысы өчпочмак шәкелендә кайтарылып төшкән. Җәй буе үскән кара чәчләр аны ифрат сөйкемле, нык, гайрәтле егет итеп күрсәтә. Чәч үстерүне башта әтисе дә, әнисе дә килештермәде.

— Улым, мөселман кешегә бер дә муафыйк түгел бит әле болай төксем булып йөрү,— диде беркөн әтисе.

Әнисе аның сүзләрен куәтләде:

— Әйе, әтиең дөрес әйтә, улым, озын чәчтән иман качар, ди.

Галимҗан берникадәр шаяртып, шул ук вакытта чын хакыйкатьчә җавап бирде:

— Иманым чәчемдә түгел, әткәй, әнкәй, йөрәгемдә, аның белән беркайчан да сату итмәячәкмен, борчылмагыз.

Галимҗанны бөгү авыр икәнлекне әтисе дә, әнисе дә яхшы белә. Аңа теге яки бу мәсьәләне тәфсилләп аңлатырга тырышу — ут чыкмаганга чаң кагу. Шуңа күрә бу хакта башкача сүз куертып маташмадылар. Дәхи дә шунсы мәгълүм: Троицкида да, Ырынбурда да, Казанда да шәкертләрнең чәч үстерә башлавы турындагы аяклы хәбәрләр йөри. Моназәрә — бәхәс, сүз көрәше, фикер мантыйгы буенча теләсә кемне егып сала

торган Галимҗан ни эшләп әле шундый яңалыкның койрыгында өстерәләргә тиеш? Яңалык ул ташны тишеп үскән үлән белән бер. Аны аслан туктатып булмый. Такыр баш Галимҗан бер төсле иде. Чәчле Галимҗанга бөтенләй икенче мәһабәт сыйфат керде. Матураеп, гаҗәп күркәмләнеп, карап туйгысыз егет булып китте. Бу килеш Галимҗан үзен мәдрәсәдәге чапан яки җилән кысасы эчендә йомылган ирексез кеше итеп тоймый. Бу кием аны ирекле итә, үзенчә яшәргә илһамландыра, инде чын егет булып җиткәнлекне ышандыра. Хакыйкатьтән, шулайдыр. Әтисе, әнисе аны бүген сөйкемле күз карашлары белән озатып калды. Әнисе хәтта урамга чыкты:

— Галимҗан улым, бик озак йөрергә тырышма, иртәгә сәфәр чыгасы бит, аннан ары сөйләшеп тә утырырбыз; күпме генә карасам да сиңа, күзләрем һаман туймады әле,— диде.

Галимҗан һаман шаяртып маташты:

— Ярар, әнкәй, озак йөрмәм; кайткач, каршыңда төп кебек утырырмын да ике сәгать селкенмәм, тәгъзим кылырмын, ә син мине күз нурларың белән иркәләрсең.

Хәсәнә абыстай елмаеп куйды:

— Әниеңнең ике сәгать буе сиңа тилмереп карап торырга вакыты бардыр шул, әле юлга кирәк-яракларны да әзерләп куя алмадым.

— Бернәрсә дә кирәкми, әнкәй! Үзеңне-үзең бетермә. Борчылма. Ял ит. Беләм инде: бәлеш, сумса, коймак, чәкчәк... Төн йокламаячаксың. Кояш зурлыгы бер бодай икмәге булса, шул җиткән миңа...

Галимҗан артык ашыкмый, ләкин җитез-җитез атлап, китеп барды. Гәүдәсе төз. Адымы нык. Башы югары. Кул хәрәкәтләренә кадәр ипле, чамалы, бәгъзе бер кылтым егетнеке шикелле кылдый-былдый килми. Хәсәнә абыстай күз нурларын җылы агым итеп, элеккедән мең кәррә артык сөеп-назлап карап, аналарда гына була торган бөек хис-тойгы белән, улы күмелгәнче аңа бәхетле-сәгадәтле киләчәк теләп торды. Шакирҗанын исенә төшереп, балавыз да сыгып алды.

Менә бервакыт мулласының лап-лоп атлап килгәне шәйләнде. Ул тиз генә күз яшьләрен сөртте дә ихатага керде. Елаганын сиздермәскә тырышып, яулык очы белән битен каплады да мулласыннан ерагаерга тырышты. Сәбәпсез Сәми дә сәндерәгә менми, дигәндәй, сиздә мулла абзый яулык белән капланган битнең сәбәбен.

— Син тагын да йомшаргансың, остабикә,— диде мулласы.

Хәсәнә абыстай, моны йөрәге кушмаса да, алдашырга мәҗбүр булды:

— Юк, юк, мулла, еламадым мин, күземә чүп керде...

Галимҗан боларын белми. Ә инде әнисенең күзләре талганчы озатып карап калуын белә. Шактый киткәч, бер әйләнеп караса, әнисе һаман капка төбендә моңаеп басып тора иде әле. Ана! Бала өчен йөрәген ярып бирергә әзер тора ул. Ананың бөтен гомере «бала» дип үтә. Ул үзе өчен рәхәт тормыш та теләми. Фәкать баласы өчен яхшы булсын. Йокысыз төннәр. Бөтен кайгыны үз йөрәгенә алу. Бала аркасында михнәт чигүләр. Нинди яхшылык күрсәтергә мондый бөек анага? Ана-алиһәгә? Фәрештә-анага? Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлап кулга шәһадәтнамә алгач, алар Галимҗанның йә мөдәррис, йө мулла, йә ахун булуын телиләр. Әнисен, әтисен шуның белән канәгатьләндерергәме? Язмыш җилләре аны әллә кайларга, әллә нинди ят җирләргә алып китеп диңкетмәсме? Кайда егылырыңны белсәң, шунда салам түшәп куяр идең, диләр бит. Тормыш бабай аслан әйтми ул кай төштә башыңа чукмар белән тондырасын. Ә инде әсәр язарга теләк барлыкны әйтсәң, янә гауга, низаг, зил-зилә котырачак. «Нигә кирәк ул лыгырдыкнамә, синдә бит пәйгамбәрләр башы, андый вак-төяк шөгыль шалапайлар өчен хас»,— диячәк әтисе.

Шул уйларны да, тәсбих төймәләре шикелле итеп, башыннан кичерде Галимҗан. Тирә-ягына янә бер каранып алды. Таш бүкән яныннан ук чабылмаган озын үлән мәйданы сузылып китә. Үләннәр арасында төрле-

төрле чәчкәләр. Аларның бәгъзе берләре, гәрчә җәйге кебек җылы булса да, көз сулышына бирелеп, зәгыйфьләнгәннәр. Кайсыберләре әле горур чибәр кызны хәтерләтеп балкып утыра. Таҗлары төбәтәй зурлык булганнары да бар. Әллә яңадан чәчәк аттылармы? Булыр да. Шундый үзенчәлекле көз бит бу: алмагачлар, чияләр икенче мәртәбә чәчәк атты. Картлар моны төрлечә аңлата: берәүләр яхшылыкка юрый, икенчеләр — яманлыкка. Галимҗанның әтисе моны уңай күренеш әдип исәпли. Урыс-япон сугышы, инкыйлабка бәйле рәвештә халыкка искиткеч авырлык килде. Яхшылык белән яманлык, аязлы-болытлы көн кебек, алмашынып торучан. Шул яманлык артыннан Аллаһу Тәгалә бәндәләргә матур көз бүләк итте, янәсе. Бирсен Ходай! Шулай булсын! Табигать матурлыгы белән назлану, ләззәтләнү, хозурлану кешене олы йөрәкле итә.

Үлән мәйданы бик озынга сузылмый. Аннан кара урман башлана. Анда җиләк, гөлҗимеш, шомырт, миләш, балан үсә. Аның эченә кереп китсәң, син үзеңне оҗмах-җәннәткә сират күперсез генә килеп эләккән кешедәй хис итәсең.

Чү! Кем җырлый? Урман эчендә көмеш моң агыла. Мең сандугач моңы бергә килеп кушылган диярсең. Галимҗан аягүрә басты. Урманга карап йөгерергә уйлады. Ләкин тыелды. Йөгерсә, ул моң өзелер, киселер, югалыр кебек тоелды. Хәтта тын алырга да курыкты. Әйтерсең, тыны белән җылы һава дулкыныдай агылып торган моңны каплый. Галимҗанның алдыннан гына әллә күпме ак күбәләк очып китте. Алар уйный, шатлана, көн матурлыгына куана. Гомерләре бигрәк кыска шул. Нибары бер көн. Изге әрвахларның җаны күбәләк булып җиргә кайта, дигән сүз дә бар. Моның өчен аларга фәкать бер көн вакыт бирелгән, имеш. Кайта да, бала булса, ата-анасын, абый-апа, эне-сеңелләрен, туган туфрагын, авылын күреп китә. Күбәләкләр уйнаклашып, очынып, назланып очтылар-очтылар да гөлләргә, чәчәкләргә, үләннәргә тезелешеп кундылар. Алар да әлеге урман ягыннан килгән моңга әсәрләнделәр шикелле. Очмый, селкенми, канатларын салындырып, шул моң эченә йотылдылар. Бераз шулай тын гына торгач, янә һавага күтәрелделәр. Икесе урман ягына таба җилпенеп очып китте. Кем белә, алары Хөрмәтулла абзый белән Мәликә түти җаннарыдыр, бәлки. Җырлаган кызның Мәдинә-Акчәчкә икәнлеген аңлады Галимҗан. Хөрмәтулла абзый белән Мәликә түтинең җан иясе булган ике күбәләк Мәдинә-Акчәчкәнең моң эченә барып керәчәк. Чү! Галимҗанның ике беләгенә ике ак күбәләк килеп кунды. Мөгаен, карап туймаслык бу якты дөнья белән бик иртә хушлашкан сеңелләре Фәрдәнә белән Нәфисәнең җан гәүһәрләредер алар. Галимҗан нишләргә дә белми аптырап тик торды. Каушады. Йомшады. Әсәрләнде. Бик авыр вакытларда да, ишелеп-ишелеп кайгы-хәсрәт килгәндә дә, дөреслек өчен кешеләр белән якалашканда да болай җебеми торган иде бит ул. Әле менә коелды да төште. Күбәләкләрнең икесен дә алып сөясе, иркәлисе, назлыйсы килде. Ләкин курыкты. Саксыз кыланып, имгәтеп ташлавы бар. Кул белән кагылсаң, алар очып китәчәкләр. Моны Галимҗан теләми. Озак-озак шулай иркәләнеп, назланып, хозурланып торсыннар әле абыйсының беләгендә кунаклап. Ә урман эчендәге моң агыла да агыла. Теге вакытта, Кендек әбисе өендә җырлаганда, Мәдинә-Акчәчкәнең тавышы, гәрчә бик моңлы булса да, бала-чаганыкы кебек кенә иде әле. Ә хәзер инде ул җиткән кыз. Тавышы көр. Моңы тирән. Йөрәгеңне кисә. Үзәгеңне өзә. Күңелеңне телгәли.

Нәкъ шушы урында Галимҗанның сандугач сайраганын тыңлап торганы бар. Ул гел бер моң белән генә сайрамый. Бер моң белән бераз сайрагач, кешеләр күңелен икенчесе белән хисләндерим дигәндәй, башкасына күчә. Алар бик күп. Сансыз. Чамасыз. Бихисап. Мәдинә-Акчәчкәнеке дә шулай икән. Моңнарны ул алыштырып кына тора. Берсендә шушы гүзәл табигатьнең кешеләр йөрәгенә матур тойгылар салуы, күңелләрен күбәләктәй канатландыруы, хис-тойгылар дөньясында ләззәтләндерүе булса, икенчесендә әтисе-әнисе язмышы өчен өзгәләнү,

өченчесендә авыр тормышка каргыш яудыру кебек моңнар сибелә. Бу моңнарны күбәләкләр, үләннәр, гөлләр, чәчәкләр, бөтен урман тыңлый. Шул моңнар шаукымында Җир белән Күк үбешеп ала төсле. Баерга юл тоткан Кояш та аптырап туктап калды шикелле. Ул, гүя, хәзер ашыкмый, моңлы кызны калдырып китәсе килми.

Галимҗан һаман шулай бер килеш басып торды да торды. Барыргамы янына? Барса, билгеле, ул җырламаячак, моң киселәчәк. Ә инде аның киселүен теләми Галимҗан. Бармаса, иртәгә Мәдинә-Акчәчәкне күрми сәфәр чыгачак. Аның хәзер авылга башка сукмак белән кайтып китүе дә бар бит әле. Юк, барырга. Янына барырга! Рәхәтләнеп, эч серен бушатканчы, күңел булганчы, йөрәкне-йөрәккә кушып бер сөйләшергә. Моннан да уңай вакыт-урын мәңге-мәңге табылачак түгел. Урман. Табигать кочагы. Чәчәкләр. Гөлләр. Алар икәү генә. Яшьлек тилелеге белән ярсыган, шашкан, гасабиләнгән йөрәкнең давыл-ташкыннарын мәхәббәт шифасы белән басарга кирәк. Иртәгә юлга...

Галимҗан башта акрын гына атлады. Теге ике күбәләк тә бара аның белән. Әмма... Әмма... Шәп-шәп атлап китим дисә,— әллә аны сөешүдә җиңү казану тәмамән ярсыттымы,— аяк астындагы бер түмгәккә абынды да егылды. Шулай да ул озак ятмады. Ата сeләүсен тизлеге белән дәррәү сикереп торып, өстен каккалап алды. Каударлыгы, мәхәббәт алдында сөмсез кемсә шикелле кылануы өчен эчтән генә үзен сүгеп-битәрләп тә куйды. Ә теге ике күбәләк — әрвах сеңелләренең җан иярләре — очып киткәннәр иде инде. Ярый, егылганда сытылмаганнар. Моның өчен шат Галимҗан. Әнә, алар әле һаман уйнаклап-уйнаклап очалар. Әйләнеп-тулганып очтылар-очтылар да авылга таба юл тоттылар. Димәк, Фәрдәнә белән Нәфисә җаны туган йортына китте. Анда бакчадагы канәфер куакларына, алмагач ботакларына кунып шатланачаклар. Әтисе, әнисе чыкса ихатага, карап куаначаклар, җилкәләренә барып кунарлар, бәлки. Бер җай табып, ачык ишектән өйгә үтүләре дә мөмкин. Анда — ахшам-сафа гөле, рәйхан гөле, сөмбел гөле... Шуларның чәчәкләренә кунып рәхәтләнәчәкләр. Хушыгыз ике күбәләк — ике җан иясе! Кайта торыгыз. Мин дә озакламам. Туган йортта очрашырбыз! Тизрәк очыгыз! Тизрәк!! Тизрәк!!!

Күбәләкләрне күздән югалганчы карап торды Галимҗан. Аннан соң тирән хис-тойгылар, күңел тетрәнү, йөрәк ярсу аны урман ягына — мәхәббәте-бәхете янына ашыктырды. Ләкин аңа анда барырга туры килмәде. Чөнки йөрәгенең парәсе Мәдинә-Акчәчкә үзе монда таба атлый иде инде. Ул инде хәзер җырламый. Ике кулында — ике төенчек-капчык. Алары аның җимештер инде. Йә балан, йә миләш-фәләндер.

Каккан казыктай басып тик торды Галимҗан. Нишләргә дә белмәде. Ә Мәдинә-Акчәчкә, яшьлек ярсуларымны түкми-чәчми сиңа тапшырам дигәндәй, туп-туры аңа таба килә. Бераздан Галимҗан да, бәхет сандугачын тизрәк эләктерергә чамалап, ашыга-ашыга атлап китте. Менә очрашты алар. Мәдинә-Акчәчкәнең ике кулбашында ике ак күбәләк иде. Әкияттәге сыман бу. Серле дөньяның мәңге ачылмас серләре диярсең. Бу, гүя, оҗмах-җәннәтнең үзе. Ике ак күбәләк Галимҗанга да кунды. Мәдинә-Акчәчкәнең дә кулбашларында тын гына иркәләнеп утыралар. Болар инде, мөгаен, әтисе-әнисенең җан иярләре. Мәдинә-Акчәчкә ашыкмый, җай гына, бик акрын атлап килде. Шул әрвах-күбәләкләрнең очып китүеннән курыккандыр, бәлки. Килеп туктагач, иплән кенә, тәнен-бәдәнен төз тоткан хәлдә, ике төенчеген сак кына җиргә куйды. Аның берсе тузган-ямаулы капчык иде. Аны ул аркылы-торкылы чабата киндерәсе белән бәйләгән. Таралып төшүдән түгел. Икенчесе ашъяулык булса кирәк. Анда күп итеп балан төрелгән. Ашъяулык та шактый иске; ямаулы, тормыш авырлыгы төсен сиздереп тора. Ул дүрт почмагын бергә китереп төйнәп куелган. Шул төйнәлгән җирдә буш калган урыннан кызарып пешкән баланнар җемелдәп күренеп тора.

Алар кул бирешеп күреште. Нәкъ шул вакыт әлеге ике күбәләк очып китте. Авыл ягына. Болар икесе дә алар күздән язганчы карап тордылар. Аннан бер-берсенә карашып, катып калдылар. Мәдинә-Акчәчкәнең киемендә берникадәр үзгәреш тә бар. Ул кышкы көннәрдә Галимҗанның әнисе янына килеп, аннан тегүгә, чигүгә өйрәнгән икән. Шуннан кул белән кешеләргә күлмәк тегеп бирә башлаган. Монысы инде энә белән кое казу кебек. Шулай да күлмәкләрне бик ипле, килешле, матур тегә икән. Галимҗанның әнисе белә кул белән күлмәк тегүнең авырлыгын. Кызгана моны. Шуннан аны аяклы машинада тегәргә өйрәтә. Көндезләрен килеп, бер көн эчендә бер күлмәк тегеп китә. Чигүгә дә тиз өйрәнә Мәдинә-Акчәчкә. Кияүгә китәсе кызлар сөлге-тастымал, кулъяулык, ашъяулык кебекләрне аннан чиктерә башлады. Шуның белән шөһрәт казанды ул авылда. «Алтын куллы Мәдинә» дигән даны бар хәзер. Хәсәнә абыстай аны укыргаязарга да өйрәтте. Моңа да ул тиз төшенде. Чөнки һәр эшкә ихлас, мөкиббән, йөрәге белән бирелеп керешә. Дөрес, җәй көне, Галимҗан мәдрәсәдән кайткач, аларның өендә бик буталып йөрмәскә тырыша. Галимҗанның күзенә чалынудан курка. Шулай да беркөн очраштылар. Чигүгә кызыл җебе беткән икән, Хәсәнә абыстайдан шуны сорап килгән. Галимҗан берүзе генә иде. Моны белгәч, кыз тиз генә чыгып китү ягын карады. Тик Галимҗан ирек куймады. Кулыннан алды да:

— Мин бүре түгел, Мәдинә-Акчәчкә, ашамам әле үзеңне, әйдә үт,— дип, аны кәнәфигә китереп утыртты.

— Сез мине нигә «Акчәчкә» дисез, Галимҗан абый, бу миннән көлүегезме?

— Мин, Акчәчкә, кешедән көлмим, андый гадәтем юк, кеше бөек ул!

— Шайтан таягын акчәчкә итеп буламы?

— Син алай түбәнсенмә, Мәдинә-Акчәчкә! Әнкәй сине нык мактый. Белмәгән эше юк, акылы да алтын, кулы да алтын, ди.

— И... Хәсәнә абыстай бит ул кешенең яхшы ягын гына күрә, яманында эше юк; үзенең күңеле матур булганга шулайдыр инде; кайда инде ул безгә алтын булу, бакыры да житкән.

— Син тиз генә бакырга әйләнмә әле. Минем өчен Акчәчкә син. Ак чәчкәгә охшагансың.

— Сез, Галимҗан абый, матур сөйлисез. Андый тел бездә юк инде ул. Бездә агач тел, чәнечкеле тел.

— Ә мин чәнчеп сөйләүчеләрне дә яратам. Әгәр ул урынлы чәнчә белсә.

— Сез яхшы күңелле, Галимҗан абый! Әтиең дә, әниең дә шулай. Хәер, картлар әйтмешли, алма агачыннан ерак төгәрәми бит.

— Синең дә әтиең, әниең яхшы күңелле кешеләр, Мәдинә-Акчәчкә, аларны аңлый белергә кирәк.

— И... аңлыйсың ла ул, Галимҗан абый, аңлау белән генә булмый икән шул; әнә, әтинең өстенә күпме нахак пычрагы өйделәр, житмәсә, имгәтеп ташладылар.

— Килер бер көн, Мәдинә-Акчәчкә, кешеләр арасында яхшы мөнәсәбәт булыр, алар бер-берсен рәнҗетмәс, аңлашып яшәрләр.

Мәдинә елмаеп куйды:

— Кызыл кар яугачмы, Галимҗан абый?

— Кызыл кар яугач түгел, кызыл көчләр алып киләчәк андый тормышны.

— Мин аларны аңламыйм, Галимҗан абый!

— Кызыл көчләрме? Хәзер аңлатам. Ул болай...

Нәкъ шул мәлдә Хәсәнә абыстай кайтып керде. Боларның сүзләре, кинәт өзелгән җеп кебек, капылт туктап калды.

— Кунак бар икән ләбаса, ә мин күршегә кергән идем... Хәзер менә чәй эчәрбез,— дип елмайды Хәсәнә абыстай, керә-керешкә.

— И... нинди кунак ди инде ул, абыстай, еш киләм бит, әле менә кызыл җебем бетте дә...

— Кызыл җепме? Табарбыз, гөлкәем, табарбыз.

Хәсәнә абыстай Мәдинәне өске бүлмәгә алып менеп китте. Галимҗан ялгызы гына калды.

Бәйрәм ашы кара-каршы, дигәндәй, Мәдинә-Акчәчкә Хәсәнә абыстайның яхшылыкларын мең өлеш кире кайтару уе белән йөрде. Бер килгәндә «ә» дигәнче ике катның да идәннәрен ялтыратып юып чыга, икенче тапкыр керләрен чайкап бирә, өченчесендә янә нидер эшли. Яз көне бакчада түтәлләр казый. Аннан чүп үләннәрен утарга килә. Күзен урак урыша. Нинди генә хезмәткә тотынмасын, кем әйтмешли, эш аның кулында биеп тора. Менә шундый киленең булсын иде, карт көнемдә рәхәтләнеп кенә яшәр идем, дип уйлый Хәсәнә абыстай. Бервакыт бу фикерен Галимҗанга да әйтте ул.

— Бәй, әнкәй, сакла алай булгач Мәдинә-Акчәчәкне минем өчен, мәдрәсәне тәмамлап кайту белән туй ясарбыз,— диде Галимҗан, берчә шаяртып, берчә чынлык белән.— Ул минем беренче мәхәббәтем, моны Кендекәй дә белә, син дә сизенәсең булыр.

— Атаң авылда мәдрәсә ачарга хыяллана. Шунда мөдәррис булырсың. Мәдинә укырга-язарга тиз өйрәнде. Бик зирәк бит ул. Бергә яши башлагач, мәгълүматын үзең дә күтәрерсең, ул бөтен нәрсәгә тиз төшенә.

Бу сөйләшүдән соң Галимҗан әнисен кочаклап үбеп алды хәтта. Үз анасының олы йөрәкле булуын янә бер мәртәбә нык лап аңлады ул. Димәк, ул кешеләрне ярлыга, байга аермый. Ул күңел байлыгы, күңел ярлылыгы буенча эш итә; ярлы күңелле бай, бай күңелле ярлы булуны аңлый. Әтисе дә шулай лабаса. Димәк ки, Мәдинә-Акчәчәкне шушы өйнең нуры итүгә ул да каршы килмәячәк. Әтисе, әнисе капма-каршы холыклы булсалар да, дөньяга караш, күңел байлыгы, кеше йөрәген аңлау ягыннан бер-берсенә ике тамчы су кебек охшашлар икән. Алар, гүя, икесе бер җан сыйфатына әверелеп кәрәзләнгән. Шундый мәсләкле, иманлы, олы йөрәкле, бөтен авыл өчен мөхтәрәм вә хөрмәтле ата-ана кулында тәрбияләнүенә үтә канәгать Галимҗан. Дөрес, шау-шу, низаг, өермә, давыллар булгалап ала. Хәер, тормышта табак-савыт шалтырамый тормый, диләр. Шалтырауга ата-анасы түгел, күбрәк үзләре гаепле. Ата-ана өчен бала тәрбияләүнең никадәр авыр икәнлеген Галимҗан үзе дә нык лап аңлады инде хәзер. Соңгы «ахмаклыгы» да аларны аз йончытмады. Инде киләчәктә булмасын. «Галия» мәдрәсәсен алар йөзенә кара тап якмаслык итеп тәмамларга язсын! Амин! Быел бит әле ул киләчәк өчен искиткеч матур өметләр белән китә. Әнисе Мәдинә-Акчәчәкне килене итәргә җыена. Рәхмәт сөекле ана! Бөек ана! Фәрештә ана! Алиһә ана!

Менә аның күз алдында Мәдинә-Акчәчәк үзе басып тора. Зәңгәр ситсы күлмәк өстеннән ак алъяпкыч бәйләгән. Аягында читек. Артка чөеп бәйләгән ак яулыгы астыннан ике калын толым сузылып аркасына яткан. Ул толымнар алтын төсле елык-елык килеп тора. Тын алганда калку күкрәге дулкынлана. Моңа чаклы күзләренә тутырып караганы юк иде. Зәп-зәңгәр икән алар. Зәңгәр күк төсле. Тирән. Серле. Уйчаннар. Ике бит очы алмадай кызарып тора. Әллә бу кызыл сөртеп куштанланып та йөри башлаганмы, дип уйлаган иде башта Галимҗан. Юк, алай түгел икән. Ул кызыллык, бәлки, кояштандыр. Анда, бәлки, эчке йөрәк кайнарлыгы бәреп чыккандыр. Яшьлек дәрте кызыллыгыдыр. Әллә матур күрсәтер өчен төн фәрештәсе кызыл якканмы аның бит очларына? Андагы сизелер-сизелмәс сипкелләр энҗе җемелдәвен хәтерләтә. Аксыл йөзгә аларның барысы да бик килешле, урынлы, табигый кебек. Уң як бит очында, әлеге энҗе-сипкелләр арасында, зәңгәрсу миң бар. Анысы хас та кыйммәтле мәрҗән. Авызы уймак кебек кенә. Пешкән чиядәй кызарып янып торган сутлы иреннәр таш йөрәкне дә эретерлек. Бу иреннәр нишләп шулкадәр кызыл, әллә буяганмы, дигән уй килгән иде башта Галимҗанның күңеленә. Ләкин бу очракта да ул ялгышты. Ул

кызыл иреннәрне дә аңа табигать бүләк иткән икән. Моны ничек дип атарга? Урман кызы? Су кызы? Табигать кызы? Ә нишләп урманга бу кадәр матур киенеп килгән ул? Әллә Галимҗанның монда икәнлеген белгәнме? Барырга йөрәге кушканмы? Җимеш җыюы бер хәйлә генәме? Белмәссең. Аңламассың. Гаҗәп нәрсә. Ә бит үзе элекке кебек йөзен дә, карашын да яшерми. Зур зәңгәр күзләрен чекрәйтеп карап тик тора. Мин синеке, Галимҗан абый, курыкма, тартынма, кочакла, дигән кебек. Авызга кердәй булып тора. Бүген, әйтерсең, Ходай Тәгалә үзе очраштырды аларны.

Галимҗан аның мамыктай йомшак кулларыннан алды, аннан иплән кенә бөтен гәүдәсен үзенә таба тартты. Аннан кысып кочаклап, бит очларыннан чут-чут үбәргә кереште. Мәдинә-Акчәчкә ләм-мим бер сүз әйтми тик тора. Үз гомерендә беренче мәртәбә татыган бу ләззәттән ул, гүя, йомшарды, эреде, җебеде. Кыздан кояш нурлары белән аралашкан чәчәкләр исе, урман исе, дала исе килә иде. Галимҗан шул хуш исләр сихеренә йотылды. Мондый сөешү бәхетенең аңа да тәүге мәртәбә елмаюы бит әле. Нинди кадерле минутларны, Ходаем, нишләп әле сөлектәй егетне унтугыз яшенә хәтле шушындый татлы рәхәтлекләрдән мәхрүм итеп килдең? Дөньяда барыннан да өстен торган сөешү кебек мәңгелек, сихри бер бөек көч бар икән. Алар сөешүне озак кына дәвам итте. Ләкин берсе бер сүз әйтмәде. Хәзер инде аң-акыл да, уй да болар иркендә түгел. Тик хис-тойгы, ярсу, шашып сөешү генә хөкем сөрә. Мәдинә-Акчәчкә үзе үк таралып төшкәндәй булды. Йомшарды. Хис давылына күмелде. Аның өчен хәзер бөтен дөньясы сукыр бер тиен тора. Аның өчен сөешү кебек бөек ләззәт кенә бар. Ул үзе дә Галимҗанны кысып-кысып сөя, күзләреннән, маңгаеннан, бит очларыннан чут-чут үбә башлады. Аннан иреннәр очрашты. Монысы — иң кайнар үбешү. Мин — синеке, син — минеке, дигәнне тәмамән аңлата торганы. Йөрәкләр йөрәккә беректе. Кысыша торгач, алар, гүя, икесе бер-берсенең тән күзәнәкләренә керешеп, бер бөтен мәхәббәт илаһилыгына әверелделәр. Бервакыт, киселгән агачтай, кочаклашкан-үбешкән килеш җиргә ауганнарын үзләре дә сизми калды. Аннан алар берникадәр зәңгәр күккә карап яттылар. Сүз һаман юк. Фәкать ике яшь күңелне шашындырган, ярсыткан, җенләндергән кайнар хис-тойгылар давылы гына бар. Бераздан алар, яткан килеш кочаклашып, янә үбешергә керештеләр. Мәдинә-Акчәчкәнең иреннәрннән бал тәме, чәчәкләр хуш исе тәме килә. Алар янә кысышты. Икесе бер бөтенгә әверелде. Мәхәббәт йомгагы дияргә мөмкин моны. Сулып-шиңеп барган көзге чәчәкләр, яшел төсләрен җуеп, кибә башлаган озын үләннәр арасында барлыкка килгән яңа адәми чәчкә дип атарга да мөмкиндер, бәлки.

Бервакыт Мәдинә-Акчәчкә һушына килде. Ялт сикереп торды да өс-башын каккалады. Бөгәрләнгән күлмәген рәткә китерде. Яулыгын яхшылап бәйләде. Аннан соң, кинәт җендәй кыланып, сөешү хисләре исереклегеннән һаман айнымый яткан Галимҗанны кулыннан тотып җилтерәтеп торгызды. Алар арасында шундый сөйләшү булып алды:

— Галимҗан абый, сез мине алдап кына йөрисезме? Мыскыл итәргә уйлыйсызмы?

— Мин, сөеклем, урынсызга беркайчан да кешедән көлмим.

— Мине хатынлыкка алырга уйлыйсызмы?

— Әйе. Әнкәй дә мактый үзеңне.

— Әгәр алсаң, чәчем белән җир себерер идем.

— Алай түбәнсенмә, Акчәчкә.

— Мин бик усал бит, Галимҗан абый, бу яктан әткәйгә охшаганмын, түзәрсеңме?

— Син акыллы усал.

— Бу холкым белән Хәсәнә абыстайны хафага салмаммы?

— Әнкәй кешеләргә бәяне йөрәгенә карап бирә.

— Энеләремә, сеңелләремә ярдәм итәрсеңме соң?

— Мин бу хакта, син әйтмәсәң дә, уйланам.

— Син бик изге күңелле, Галимҗан абый!
— Тормыш чәчәгем булырсың, Мәдинә!
— Һи, син бит иртәгә китәсең.
— Киләсе җәйдә туй ясарбыз. Көт.
— Көтәрмен лә ул. Кайткач, алмасаң?
— Мин вәгъдәле кеше.
— Вәгъдә — иман?
— Әйе. Вәгъдә — иман!
— Галимҗан җаным!
— Әү!
— Озакка сузмыйк моны.
— Ничек алай?
— Син мине хәзер үк хатын ит.

Бу сүзләрне ишеткәч, Галимҗанның аркасыннан меңләгән кырмыскалар йөгерешеп үткәндәй булды. Аның исе-акылы китте. Йөзенә кара коелды. Ул арада Мәдинә, әллә нинди мәзәк-сәер тавышлар белән шаркылдап көлеп, чалкан ятты да тәүфикъсызланып, тәкатьсезләнеп, Галимҗанны янына чакырды:

— Кил, җаныем, курыкма, монда берәү дә юк бит. Алмасаң да, баламны сиңа такмам. Төсең итеп тотармын.

Галимҗанның җен ачуы чыкты. Кызып китте, Мәдинәне җилтерәтеп торгызды да:

— Исәр икәнсең,— диде.

— Ә син куркак. Бай балалары шулай җебегән була. Сез бит йомшак көпшәләр. Ха-ха-хау...

Бераз тырпаеп торгач, ат кешнәгән тавышлар чыгарып, ямьсез итеп көлде дә Мәдинә:

— Тот... тот... тота алмыйсың...— дип, тыр-тыр йөгереп китте.

Шулай итеп, бер мизгелдә барлыкка килгән олы мәхәббәт күз белән каш арасында кәмиткә әйләнде. Галимҗан йөгермәде аның артыннан. Мәдинәне кат-кат чакырып карады. Ләкин ул якын килмәде, тәкәбберлек күрсәтте. Менә бервакыт, әтисе тарафыннан рәнҗетелгән сабый бала шикелле, баскан урынында кычкырып елап җибәрде. Галимҗан аның акылы җиңеләйгәнлеген аңлады. Димәк, әтисе, әнисе кайгысы аны да бөккән. Йа, Хода! Ник син оҗмахтай бу матур җир йөзендә Мөбахис мәзин, Тәхлис кебек бәндәләр язмышы белән шаяручыларны яшәтәсең?

Галимҗан, куянны качтырудан куркып атлаган саклык белән, акрын гына атлап, Мәдинә янына барды:

— Мәдинә-Акчәчкә! Әйдә кайтыйк.
— Иртәгә туй ясарбызмы?
— Ясарбыз.

Мәдинә аның күкрәгенә башын куйды:

— Мин бит, Галимҗан абый, синең монда икәнлегеңне белеп килдем. Шуңа матур киенергә тырыштым. Әллә бу күлмәгем, бу алъяпкычым ошамыймы сиңа?

— Ошый, Мәдинә-Акчәчкә, син бик гүзәлсең; әйдә, кайтыйк.

— Юк, кайтмыйк, Галимҗан абый, куныйк шушында гына. Безне берәү дә күрмәс. Иртәгә никах укытырбыз.

Мәдинә сөйләде дә сөйләде. Сүзләрендә ул нык бутала, ялгыша башлады. Галимҗан кайтырга күпме генә кыстамасын, тыңламады, киреләнде.

— Мәдинәм! Акчәчкәм! Энеләрең, сеңелләрең көтәдер; алар ачтыр, әйдә, кайтыйк,— дигәч кенә берникадәр акылына килде. Бер төенчекне Мәдинә үзе алды, икенчесен — Галимҗан.

Юлда Галимҗан гел яхшылык турында гына сөйләргә, Мәдинәнең сорауларына нык уйлап җавап бирергә тырышты. Чөнки, тагын да акыл эзеннән язмасын өчен, аның күңелен даими күтәреп торырга кирәк иде.

* * *

Галимжан Мәдинәне юл буена гел юатып барды. Мәдинә исә йә елап җибәрә, йә шаркылдап көлә, йә Галимҗанга әллә нинди күңелсез сүзләр әйтә. Галимҗан аның өчен сүзләрнең гел матурларын сайларга тырышты. Яхшы сүз котырган бүрене дә тынычландыра, дигәнне ишеткәне бар иде аның. Чын икән. Аның шашынган вакытында бер яман сүз ычкындырсаң, ул тагын да мең өлеш җенләнеп китәргә мөмкин. «Син бик чибәр, Мәдинә-Акчәчкә»; «Энеләрең, сеңелләрең өчен кайгырма, аларны үзем карармын»; «Без бик матур яшәрбез», кебек сүзләрне әйтсә, Мәдинә тынычлана, моңсулана, тирән уйга чума.

Шулай парлашып, икесе ике төенчек тоткан хәлдә, авылга кайтып житеп, урам буйлап атладылар. Үзләренең өе яныннан үткәндә аларны Хәсәнә абыстай күреп калды. Икенде намазын укыгач, ул, Галимҗанның озак кайтмавына хафаланып, капка төбенә чыккан иде. Аларның парлашып үтеп китүләре Хәсәнә абыстайны тирән борчуга салды. И илаһым, әлгаязе биллаһу, бу нинди ахмаклык инде тагы да, и бу Галимҗанны, һаман балалыктан аерылмый, халык ни әйтер, көпә-көндез никахсыз житкән егет белән кыз урамда парлашып төенчек күтәреп йөрсеннәр, имеш, дип сыкранды. Кычкырыйм, чакырыйм дисә, алар шактый ераклашканнар иде инде.

Галимҗан Мәдинәне Актүтигә алып барды. Аларны Кендекәй якты йөз, күтәренке күңел белән каршылады. Шул ук вакытта аның чыраенда ник гаҗәпләнү чаткылары бар иде. Мәдинәнең үзен генә калдырып, Галимҗан Кендекәйне ишегалдына чыгарга ымлады. Чыккач, мәсьәләнең барын да сөйләп бирде.

— И... бигрәк миһербанлы булдың инде, балакаем, ничек түземлекләрең җитте монда алып килергә, бирәү булса, ташлар да китәр иде,— дип, Галимҗанның аркасыннан кат-кат сөеп куйды Актүти.

— Хәзер кайтып мин моны әнкәйгә әйтәм, ул монда килми калмас, Кендекәй, борчылма инде, Мәдинәгә авыр сүз әйтә күрмә.

— Әйтмәм, балакаем, әйтмәм. Кешеләргә болай мәрхәмәтле булганың өчен, Аллаһу Тәгалә үзеңә таудай бәхет, корычтай сәламәтлек, пәйгамбәрләрнекедәй акыл бирсен! Барыр юлларыңа фәрештәләр гөл сипсен! Намаз арты саен олы бәхет теләп дога кылырмын үзеңә. Мин бит синең икенче анаң. Кендекәйнең изге теләге кабул булмый калмый ул...

— Рәхмәт, Кендекәй, әйткәннәрең фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килсен; фатихаңны Ходай Тәгалә үзе кабул итсен дә аннан миңа кайтарсын,— дип чыгып китте Галимҗан.

Ул кайтып кергәндә әтисе белән әнисе аскы өйдә иде. Галимҗан бар булган хәлне түкми-чәчми сөйләп бирде. Мәдинәне әле Кендекәйдә калдыруын әйтте. Аннан соң:

— Әткәй, әнкәй, аларга ярдәм кирәк, безнең мөмкинлек бар бит, игеннәр дә быел, сөбханалла, каерылып уңды,— диде.

Әтисе улының бу сүзләренә матур җавап бирде:

— Әйе, улым, әлхәмде лилля, игеннәр быел Аллага шөкер!.. Дин кануннары буенча без икмәкнең кырыктан бер өлешен ятимнәргә, ярлыларга, Актүти кебек карт-корыга бирергә тиешбез. Тәңрем үзе шаһит, мин аны биш тапкырга арттырам. Яшь кенә көеңә кеше язмышы турында болай җитди уйлануың сине бик зурлый. Андый зат-шәхесләр бәхетле була. Иншаллаһ, Аллаһу Тәгалә моның өчен беркайчан да рәнҗетмәс үзеңне!

Хәсәнә абыстай да сүзсез калмады:

— Әйе, әтиең дөрес әйтә, балам, яхшылык җирдә ятмый, ул адәм баласының үзенә кире кайта. Мин инде аларга болай да кулдан килгәнчә ярдәм итеп торам. Әле менә Мәдинәгә ак күлмәгемне, читегемне, алъяпкычымны биргән идем. Ул үзе дә бит бик ярдәмчел. Быел, үзең беләсең ич, арты урагыбызны Мәдинә урды. Җен кебек эшли бит ул. Җен кебек.

Тик бәхеткәйләре генә булмады. Бәхеткәйләре генә. Нигә шулайдыр инде. Үтә әчкерсез, гөнаһсыз, матур күңелле кешеләр иде бит, югыйсә. И Аллам! И Ходаем!

Остабикәсенең сүзләрен мулла абзый дәвам итте:

— Әйе, бигрәк уңган кыз иде бит. Тик... син, Галимҗан улым, борчылма, тыныч күңел белән кит, без монда күз-колак булып торырбыз, киемен дә юнәтербез, ашлыклата да ярдәм итәрбез; Ходайга шөкер, буралар быел аркылып тулды, бодай, арыш, тары... Аларны ач итмәбез, әтиләре, әниләре дә миңа күп файда итте; авыр туфраклары җиңел булсын! Кем уйлаган аларның гомере шулай күңелсез өзелер дип. Кем уйлаган. И бәндәләр, бәндәләр! Нигә болай котырыналар икән? Бер дә юннелеккә түгел бу. Бервакыт Ходай Тәгалә моның өчен аларны утлы табага бастырачак бит. Мондый әшәкелек бөтен илне какшата ул. Бөтен илне. Әгәр дә мондый яманлыклар дәвам итсә, Ходаем үзе сакласын, киләчәктә илебез бик мөшкел хәлгә төшәчәк бит. Мөшкел хәлгә. Гөнаһлы ил озак яшәми. Чүп баскан бакчага әверелә ул.

Шулай итеп, үзе дә сизмәстән, сүз иярә сүз чыгып, киләчәк дөньясына, халык, ил язмышы мәсьәләсенә, инсаниятлелек тойгыларына кереп китте мулла абзый.

— Син, атасы, әллә кайда, гарьше көрсидә, чүпләнгән бакча эчендә йөрмә әле, аяк астындагыны, борын төбендәгене күр,— диде, мулласының сүзен бүлеп Хәсәнә абыстай.

— Нәрсә бар борын төбендә?

— Һм... и бу ирләрне... Әллә Мәдинә язмышы борчымыймы сине?

— Соң, остабикә, шуңа ут йотып утырабыз бит.

— Харап икән берәүләр: ут йота. Ә кем су сибәр?

— Менә тагы... иманлы авыздан яман сүз... Сиңа ни булды бүген?

— Сезнең гамьсезлек аркасында килеп чыга шундый күңелсез хәлләр. Йокымсырыйсыз.

— Менә тагы...

Әнисенең сүзләрен Галимҗан куәтләде:

— Әнкәй дөрес әйтә, әткәй: начарлыкка каршы көрәшә белмибез.

— Аллаһу Тәгалә иртәме-соңмы залимнарга, җаһилләргә, юньсезләргә үз хөкемен чыгармый калмый ул, балам!

— Алла хөкемен көтеп ятарга кирәкми, әткәй!

— Чү! Аллага тел тидермә. Иманыңнан язарсың.

— Имансыз кеше буш тубал ул, әткәй. Ә минем буш тубал буласым килми. Иманым үзем белән. Алласыз кеше дә буш капчык. Минем буш капчык та буласым килми. Аллам үзем белән. Йөрәгемдә, күңелемдә. Зиһенемдә. Минем өчен кайгырмагыз. Дингә ышанган булып, Алла исеменнән яманлык кылучылар борчый мине. Әгәр бу юл белән китсәк, киләчәктә Алланың да, мулланың да, диннең дә кадере калмаячак.

— Мин монысын аңлыйм, улым, дөрес әйтәсең, әмма ләкин...

Галимҗан әтисенең сүзен бүлде:

— Әткәй! Менә хәзер мин синең үз иманыңны тикшерәм. Тыңлап тор. Әнкәй син дә тыңла. «Әмәнтү билләһи үә мәлләә икәтиһи үә күтүбиһи үә рүсүлиһи үәл-йәүмил. Әхири үәл-кадәри хәйриһи үә шәрраһи мәнәл-лаһи тәгалә үәл-бәген бәгдәл-мәүти». Аңладыңмы, әткәй?

— Аңладым.

— Алайса, үз телебезгә тәрҗемә ит, мәгънәсен әйт.

— Коръән тәрҗемә ителми.

Галимҗан көлеп җибәрде:

— Тыңлагыз, әткәй, әнкәй: «Иманым Аллаһы Тәгаләгә вә дәхи. Аның фәрештәләренә, вә дәхи Аның китапларына, вә дәхи Аның пәйгамбәрләренә, вә дәхи ахирәт көненә, вә дәхи тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән булуына, вә дәхи үлгәннән соң янә терелүгә». Менә, әткәй, иманны ничек аңларга кирәк. Коръән теле гаҗәп серле, шигъри, мәгънәле. Ә сез аның мәгънәсен белмисез. Бу сезнең динне,

Алланы, Ходайны алдавыгыз түгелмени? Әмма ләкин, син уйлаганча, әткәй, дөньяны надан муллалар белән генә алып барып булмый. Галәм зур, серле, баш җитмәслек чиксез. Аны халыкка аңлату өчен диндарның тарих, җәгърәфия, физика, математика, һәндәсә-геометрия, мантыйк, тел, әдәбият фәннәрен белүе мотлак. Чөнки киләчәктә дарелфөнүн яки университет тәмамлаган акыллы башлар күп булачак. Мин үзем дә шундый изге максат белән яшим. Күп китаплар язачакмын. Халкыбызның тарихы, тел, әдәбият, сәнгать, психология, педагогика, методика...— Мине барысы да кызыксындыра. Ул «Сарыф», «Нәху», «Әнмүзәҗ»ләр искерде, әткәй! Яңаларын мин язачакмын. Алла боерса!

Ата, ана бер-берсенә карашып алды. Менә кем икән безнең улыбыз, дигәнне аңлата иде ул карашлар. Галимҗан дәвам итте:

— Әткәй! Син күп нәрсәне аңлап бетермисең. Синеңчә, Шакирҗан абый юлдан язган, имансыз, алласыз. Бер дә алай түгел. Рәнҗетмә аны. Хат яз. Эрет ике арадагы бозны. Шакирҗан абый матур күңелле, йомшак табигатьле, ул менә дигән мөгаллим-укытучы булачак.

Бу сүзләрдән соң Галимҗан ата-ана алдында янә тау дәүмәллеге булып үсеп китте. Хөрмәтуллалар язмышы өчен янып-көеп йөрүе, хәзер кызы Мәдинәгә җанын ярып бирергә әзер торуы, Шакирҗан абыйсының йөрәк-күңелен шулай тирән аңлавы, кешелеклелек, гомум кешелеклек тойгылары белән яшәве, аң-акылының бәяләп бетергесез камил булуы ата-ана күңелен күк тәхетенә хәтле күтәрде. Гыйрфан мулланың Уфада да мәгълүматлы дуслары юк түгел. Алар үзләрен әллә кемгә санап, зур куеп сөйләшә. Менә шуларны улы Галимҗан белән моназарә кылдырасы иде. Үзләренең йомшак җирләрен тиз сизәрләр иде. Масайган мәнсезләр. Шул: пәйгамбәрләр башы бар монда. Пәйгамбәрләр башы!

— Ярар, улым, ниятең изге, карашың киң, акылың алтын, пәйгамбәр башы бар үзеңдә...

— Пәйгамбәр булу өчен, әткәй, хәзер бөтенләй башка баш кирәк.

Бәхәснең озакка сузылачагын сизеп, Хәсәнә абыстай аларның сүзен бүлде:

— Йә, җитте инде, атасы, сүзне җилем урынына сузуда бер файда да юк; акыллы тыңлар, юләр такылдар, дигәнне дә онытма, иртәгә юлга чыгасы, шуңа әзерләнегез; мин Актүтиләргә барып кайтыйм әле. Хәер дә бирәсем бар иде.

* * *

Хәсәнә абыстай зур бер бодай икмәге, чәй-шикәр, май-фәлән алып, Хәмдия абыстайларга китте. Ул барып кергәндә, Кендекәй белән Мәдинә ару гына сөйләшеп утыралар иде. Идәндә әлеге ике төенчек ята. Хәсәнә абыстай исәнлек-саулык сорашкач, Актүтигә хәер бирде, иртәгә Галимҗанның сәфәр чыгачагын әйтте. Шуннан алар тиешлесен әчтән генә укып, дога кылдылар. Бу изге эшкә Мәдинә дә катнашты. Тик... «Галимҗан» дигән сүз генә аны тетрәндереп җибәрде. Хәтта сорау бирергә мәҗбүр итте:

— Галимҗан кайчан кайтыр, Хәсәнә абыстай?

— Киләсе язда, акыллым, Аллаһу боерса!

— Ә иртәгә безнең туй булмыймыни?

— Туймы? Ярый, балам, уйлашырбыз. Борчылма. Әйдә, үзегезгә барыйк.

Хәсәнә абыстай, «Киттек» дигәнне аңлатып ым какты да Актүтигә күз ташлады. Бер төенчекне алып, чыгып та китте. Икенче төенчекне Актүти күтәрде. Мәдинә нишләптер аңа әллә ни игътибар итмәде. Актүти төенчегенең бер урынына ябышып, гамьсез генә атлый бирде.

Мәдинәнең Җәмилә исемле бер сеңлесе — унбиштә, Хәдимә исемлесе — унөч яшьтә, Сәлимәсе унбердә инде хәзер. Тугыз яшьлек

Мөхәммәтҗан, җиде яшьлек Газизҗан...— барысы да өйдә иде. Килеп керү белән, чөйдә эленеп торган ашъяулыкны алып, аны сәкегә җәеп, Хәсәнә абыстай әлеге кабарып пешкән зур бодай икмәген телемләп ташлады. Бер савытка салып, маен да куйды табынга. Моны күреп, балаларның күзләре тоздай булды. Моның чынлыгына ышанмый тордылар хәтта. Ә Мәдинә, берни булмагандай, көлеп карап торды да энеләрен, сеңелләрен сөяргә тотынды. Мәгәр андый-мондый сүз ычкындырмады. Акылына килде, шәй, дип уйлады Хәсәнә абыстай. Аңа ашыгырга кирәк иде. Галимҗанны юлга әзерлисе бар. Шуңа күрә исәнләшеп чыгып китте. Актүти дә аннан калмады.

— Мин монда куна калам, Хәсәнә абыстай, хафаланма берүк, берни дә булмас, Аллаһу боерса, тыныч күңелең белән кит,— диде дә Актүти кире өйгә кереп китте.

## VII

Кызарып кояш чыкканда, сәфәрчеләр юлга әзер иде инде. Хәсәнә абыстай төне буе диярлек юньләп керфек какмады. Башка вакыттагы кебек юлга ашамлык әзерләде: ит кыздырды, бәлеш, сумса, коймак, чәкчәк пешерде. Гыйрфан мулла да черем итеп кенә алды. Юлга чыгасы булса аның тынычсызлану гадәте яшь чагыннан ук килә. Бүген бигрәк тә җаны түзмәс булды? Чөнки Уфада танышлары да күп. Шуларның берсенә — Габдрахман хаҗиларга керәчәк ул. Күчтәнәчләрне Хәсәнә остабикәсенең иң югары сыйфатлы итеп әзерләячәген яхшы белә. Бу яктан күңеле тыныч. Алмачуарны тимер арбага җигеп барырга уйлады ул. Уфа Ырынбур кебек ерак түгел, 70—80 чакрым чамасы, бер көнлек юл. Тарантас җигеп кенә дә җилдерергә булыр иде. Шулай да, кем әйтмешли, чамага — чанасы, чанага — чамасы туры килми. Фырт егеттәй кылануда фәтва юк. Ходай эшен кем белә: ул әле бәлки сине Уфада ике-өч көн кунарга кушар. Тегендә-монда борын төртеп, базарына-мазарына барып печән, солы эзләп, ух-пух килеп йөрүне җене сөйми Гыйрфан мулланың. Ярый, бардың да, ди. Солтанморат болыннарында үскән туклыклы печән,— моны ул ант итеп әйтә ала,— ихластыр менә, бөтен тирә-якта гына түгел, җир йөзендә юктыр. Солтанморат бит ул! Ходай Тәгалә аңа оҗмах бакчасының бер як читен кисеп биргән. Мөбахис-Төбахис, Тәслих-Мәслих ише бәндәләрнең җилкәсен кимерүчеләр, Хәмәтдин-Мәмәтдин шикелле ялкаулар булсалар да, уптым илаһи алганда, аның кешеләре иҗтиһатлы, гаять хезмәт сөючән. Аллаһы Тәгалә бу авыл кемсәләренә шуңа күрә биргәндер оҗмахтай җирне. Аның кара бәрхеттәй кабарып торган туфрагында бүртеп үскән туклыклы солысы да,— монысы өчен дә ул кулына икмәк тотып ант итә ала,— бер җирдә юк; хәтта ки, көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Алмачуар бик назлы, нәзберек. Ул әле теләсә кемнең, ни җитте кешенең солысын, печәнен ашамый да, суын да эчми. Аңа, тәмле тамакка, оҗмахтагы кәүсәр күле суы тәме килеп торганы гына кирәк. Солтанмораттагы Зәңгәр чишмә суы кебек. Шуңа күрә үзенең Исәнбикә болыныннан чапкан чәчкә печәнен дә тимер арбага мул төяп, солысын да, арыш икмәген дә (Алмачуар-тәмле тамак аны да бик яратып ашый) күп алып, кичтән хәстәрләп бетерә алмаганнарын иртәнге намаздан соң җиренә җиткереп куйды. Юлга ул Кояш-бабай җир йөзенә сөйкемле карашларын ташлаганда, күңелләргә моң, йөрәкләргә дәрт, бөтен бәдәнеңә куәт бирердәй нурлар сипкәндә чыгып китәргә ярата. Бүген дә шулай итте. Иртәнге намаз укылган. Чәй эчелгән. Ат җигелгән. Йөрәк кагып, ярсып тора. Күңелләр шат. Атны Галимҗан белән бергә җиктеләр. Ата кеше гел сөйләнеп эшләде:

— Пәйгамбәр улымны, башлы, зиһенле улымны Уфага «һә» дигәнче илтеп куям. Ә таңы нинди, көне нинди, нәкъ пәйгамбәр туган таң төсле.


Карачы: бөтен офык кызарып янып тора. Сәфәр алдыннан Ходай безгә шундый матур таң бүләк итте. Пәйгамбәрләр таңы! Пәйгамбәрләр таңы! Сиңа да, улым, Ташмаңгаем, дәверебезнең пәйгамбәре булырга насыйп итсен.

Капка ачык. Алар печән төягәннән соң алда үзләре өчен калдырылган махсус урынга менеп җайлаштылар. Галимҗан — сул якта, әтисе — уңда. Дилбегәне үзе алмакчы булган иде Галимҗан, ләкин әтисе ирек куймады. Бу картлач һаман әле безнең көчкә, ныклап ат тота алуыбызга да ышанып бетми, күрәсең, дип уйлап, җиңелчә генә елмаеп куйды Галимҗан. Әнисе әллә ничә мәртәбә кысып-кысып сөйгән иде инде. Арбага менеп утыргач, йөгереп килеп, янә иркәләргә тотынды. Мулласы:

— Йә җитте инде, әнкәсе, әллә кайда, җәһәннәмгә китми ләбаса, Уфа ерак җир түгел, үзебез дә барып торырбыз, ул да кайтыр да килер, йә, кит инде, кузгалабыз, тәгәрмәчкә уралуың бар,— дигәч кенә, Хәсәнә абыстай аерылырга мәҗбүр булды. Дилбегәне аз гына, сак кына кагу белән, Алмачуар тожрылу ягын шайләде. Аның, пырдымсызның, башын чайкый-чайкый, дулап-дулап китүе дә бар. Шуны уйлап, дилбегәне нык тартып тотарга, Алмачуарга җендәй ярсып чабарга ирек куймаска тырышты мулла абзый. Әмма капканы чыгу белән ул алды да китте. Берәр җиргә орып, тончыктыруы да бар бит әле аның. Гыйрфан мулла тешләрен кыса-кыса дилбегәне урап-урап тотып, авызлыгын нык каергач кына, Алмачуар, хуҗасының көчле кулын тоеп, ахмакларча артык шашынмаска булды.

Хәсәнә абыстай алга төшереп бәйләгән яулык очы белән күз яшьләрен сөртеп, алар күмелгәнче моңаеп карап торды. Күмелгәч, кереп, янә бер мәртәбә утырып дога кылды. Исән-аман барып җитүләрен, мулласының исән-сау әйләнеп кайтуын теләде. И, ходаем, балаларга, барлык бәндәләргә бәхет бир, бозыклыклардан сакла, илдә тынычлык булсын, дип амин тотты.

*Беренче китап тәмам.*





# Әхмәт Гадел

## СЕЗГӘ — ШИГЫРЕМ ШИФАСЫ

* * *

Бу шигырьләр сиңа шатлык
Алып килсә — мең рәхмәт:
Сиңа булсын уй вә сагыш,
Татлы хыял һәм ләззәт!..

Көнемне төнгә ялгадым,
Өметне — хыялларга...
И укучым, юк ялганым,
Бизәдем мин сурәтләрне
Иң садә буяуларга.

Сиңа шигырем шифасы
Булсын — гамьнәр галәме:
Сиңа җанымның җылысы,
Ихлас йөрәк сәламе!

### Ни әйтерсең, Иделем?

Җәй айлары бәйрәм сыман:
Таң ата да кич җитә...
Гомеркәй — җәйдән дә кыска,
Бигрәк сиздерми үтә...

Якты язым әле гөлдә,
Уйда — күрәм көземне...

Күбәләк гомередәй тоям
Мин тормышта үземне.

Йә чиллә, йә туфан-тузан,
Иминме күгем, җирем?
Агым суга карап торам:
Ни әйтерсең, Иделем?!

Яфраклар кошлар артыннан
Очмакчы — талпыналар:
Кошларның канаты каурый,
Җил канатында — алар!
Иделгә талпыналар...

## Кадерле гомер

Ташыган суда,
Боз-салкын суда
Һәм алкын суда
Тирбәлгән саллар —
Кайларга ага,
Кайларга китә,
Кайларга җитә
Бәйләнгән саллар?!

Дулкынлы суда
Теләкләр китә,
Хыяллар китә,
Агалар салдай...
Болытлар уза,
Сагышлар уза,
Йөрәкләр туза....
Теләкләр — балдай...

Аһ, татлы гомер!
Аһ, баллы гомер!
Аһ, затлы гомер,
Ал-гөлле гомер!
Кайларга, салдай,
Син, татлы балдай
Агасың, гомер?!
Барасың, гомер?!

Син — һәркемгә бер,
Кадерле гомер!

## Әбү ирек![1]

Урламагыз минем җанымны! —
Үз Ватаным — сөйгән ярымны!

[1] Әбү ирек — ирек улы, абрек, ирек өчен көрәшүче.

Мине тапкан газиз әнкәмне!
Җимешемне — балам-балымны!

Урламагыз минем җанымны! —
Киләчәгем — торыннарымны![1]

Энә, хәнҗәр, сөнге, ук белән
Кадамагыз минем тәнемә!
Урламагыз минем җанымны!

...Җил. Кар. Буран. Салкын. Өшеткеч.

Кемдә хәят? Шунда — кемдә көч! —
Корыч табан кигән танкта,
Кара портфель тоткан «халык»та...
Очакларның канат астында...

Урламагыз минем җанымны! —
Калсын миңа җаным — Ватаным! —
Шулай дип, ул югалтты аңын...

Җир белән күк тоташкан иде.
Таулардан ташлар ташкан иде.
Күктән яуды бомба. Авыллар
Гүя күккә, аһ, ашкан иде...

Нигә кирәк сезгә бу ташлар?!
Җир җитмиме, бәлале башлар?!

Урламагыз минем җанымны —
Алтынга тиң гөл-Ватанымны!!!

## Без бәхетле идек...

Без бәхетле идек, заман!

Бәхетсезләр илендә
белми, күрми яшәдек без
хак җирне дә, күген дә...

Без бәхетле идек, заман!
Без шат идек, саф идек.
Сызлансак, качып еладык,
еласы чакта көлдек.
Бездәй сабый-нарасыйны
тагын кайдан табасың?!
Ничә гасыр кояш дидек
күршеләрнең табасын!

Нигә болай салкын дигәч,
орышмадык болытны.
«Кояш бөтен дөньяны да
ул бертигез җылытмый?»
Җылытмый?! Бу хаксызлыкны
инде ничек аңласы?!
Илне баскан күршебездәй,
без дә Хакның баласы!...
Без дә!
Без дә!..
Кинәт күзләр
Ачылдымы дөньяга?!
...Хәзер инде сак бул, заман,
Алдап җанны кыйнама!

[1] Торын — оның.

## Әманәт

Ерак-ерак илдә, тауларда
Йөри егет «дошман» ауларга.
Көтмәгәндә ядрә тиде дә
Сузып салды аны җиренә...

Кабат тора алмасын сизеп,
Сафташына болай ди егет:

— Җан дускаем, өйгә исән кайтсаң,
Юлың төшсә безнең авылга,
Чишмә суы алып иңнәренә,
Бер гүзәл кыз чыгар алдыңа.

Ул елмаеп тәкъдим итәр суын,
Бәллүр суын алып эч син, юын...
Һәм рәнҗетмә, туган, кызны... какма...
Җайлап кына сөйлә минем хакта...
Синең өчен ул кыз чит түгел,
Кыз кардәшем — сиңа чын сеңел.

Ерак-ерак илдә, тауларга
Барды егет «дошман» ауларга.
Тиде аңа дошман ядрәсе лә:
Сузып салды аны газиз җиргә.
Кабат тора алмаслыгын белеп,
Юлдашыннан бик үтенде егет:
— Җан дускаем, илгә исән кайтсаң,
Эзләп тап син минем өемне,
Ак яулыктан, ак алъяпкыч япкан
Капка алдында кем? — дисеңме?
Ул әнием булыр. Зурлап күреш,
Аннан инде сөйләш, хәлен белеш...
Әйт син аңа миннән кайнар сәлам.
Исән диген... тауда... фәлән-фәлән...
Газиз әнкәм минем куансын...
Исән дип ул тәмам инансын...

Ерак-ерак илдә, тауларга...
Барды егет «дошман» ауларга...
Көтмәгәндә тапты аны ядрә,
Екты, сузып салды туган җиргә...
Кабат тора алмаслыгын сизеп,
Сафташыннан бик үтенде егет:
— Исән кайтсаң әгәр туган илгә,
Юлың төшсә әгәр безнең өйгә:
Каракүлдән «татар бүрек» кигән
Агай булыр, гүя корыч имән...
Торыр уйчан — капка алдында...
Әтием ул. Сөйлә барын да:
Бу мәхшәрдә ничек сугышканны,
Кирәкмәскә ничек түктек канны,
Мәнфәгатен яклап яманның —
Комсызлардан комсыз Иванның...
Үлеп ятканымны эсседә...—
Сөйлә барсын чын ир кешегә!



# Рәниф Шәрипов

## Моңлы җыр

1

Әкрен җилдә, дулкын-дулкын,
Чайкалды арыш кырлары.
Өзелеп-өзелеп, зәңгәр күктә
Тургай моңлы җыр җырлады.

Камышлыктан күк йөзенә
Очып чыкты кыр үрдәге.
Ә бытбылдык, кача-кача,
Болында мине үртәде.

Табигатьнең бишегеннән
Җиргә төшкән мин бер кунак.
Кайвакытта миннән зыян —
Ялгыш сынган ялгыз куак...

2

Арыш кырларына басып,
Бер балыксыз инеш буйлап,
Авылсыз авыл баласы —
Кайтып киләм, ниләр уйлап?

Сулар акты... Төннәр якты,
Утта яна күз карасы,—
Адым саен, адым саен
Төзәлмәслек Җир ярасы!

Кырлар һаман дулкын-дулкын,
Бу — балачак арышы бит!
Бер карасам — туган җир күк,
Бер карасам — барысы чит.

3

Кырга чыгып ниләр эзлим?
Юлга чыгып кая барам?
Юлда тәгәрмәчләр шавы,
Кырлар авазларга саран.

Балачакта күккә очкан
Кыр үрдәге кайтмый бүтән.
Бер суга, бер күккә карыйм,
Канат каккан тавыш көтәм.

Кайда син, шаян бытбылдык?
Исәнме син? Бармы җирдә?
Үле тынлык... Тик тын гына
Арыш кыры шаулый җилдә.

* * *

Көйләде ул, җырлады ул,
Сәер авазлар чыгарды.
Кыпчак далалары буйлап
Болгар шәһәренә барды.

Яу артыннан яулар килгән...
Кемнең кемнән бу баласы?
Хәтердән очып үттеме
Үткәннәрнең бер авазы?

Карыйм аңа бергә кушып
Борынгы белән бүгенне.
Җырлый белми күпләр җырлый,
Җыр тамыры шул түгелме?

...Сиздe җырның көйсезлеген,
Әйтте шуннан миңа дәшеп:
«Җыр түгел бу, көй түгел бу,
Моңлану бу энекәшем...»

## Урам эте

Ах, бу урам этләренең
Җан көйдергеч карашы!
Түзә алмый сызлый башлый
Китек күңел ярасы.

Карый мескен, ышанмыйча,
Таяк атканны көтеп.
Өмет өзгән кешелектән
Хуҗасыз урам эте.

Карама, син, үпкә белән,
Үз кайгым да минем күп.
Кит! Карама! Үз-үземә
Хуҗасыз мин, синең күк.

Зарланма язмышка, дускай,
Була төрле хуҗалар.

Чылбырын чәйнәп елаган
Йорт этләре җирдә бар...

## Дөнья серләре

Син үрелеп кара дөнья серләренә —
Акыл гына Җитми, билләһи.
Бер кагылып кына үтсәң хәтта,
Йә юләр син инде, йә даһи.

«Акыл!» диеп кемдер күкрәк кага...
Мыштым гына көлә Табигать,—
Тыпырчына, имеш, бер күзәнәк...
Мең йозакта Хак сүз, Хакыйкать!

Бу серләргә кулын сузып янган
Хакыйкатьтә даһи сабыйлар —
Ахирәттә тиздән юкка чыккан
Барысы да алар Шагыйрьләр.

Бер үрелеп кара Тарих серләренә,
Талпына да утта кем яна?
Түрәсеме, шагыйреме илне
Данлы итә фани дөньяда?

## Бирәм дигән колына...

Болай гына бала тапкан, имеш...
Бирсен сиңа Ходай сабырлык.
Бу илаһи гөнаһ бәхет өчен,
Тормыш өчен кылган батырлык.

Юлың изге. Кайберәүләр бизде.
Кулда — бәхет. Тәндә мең сихәт.
Ни булса да, синең исем — Ана!
Юк моннан да олы хакыйкать.

«Җилдән» түгел, зинадан да түгел,
Бозык сүзләр — бозык дөньядан.
Тол булса да, кол буласы килми,
Ул Ходайдан бәхет сораган.

Мендәрләрен кочып елаганның
Бала имезергә хакы бар.
Язык диеп утка салсалар да,
Җир әйләнә, үсә сабыйлар.

Хак Тәгалә — Хак Табигать үзе,
Хөкем итә бары ул гына.
Ә син, сабый, тирбәл бишегеңдә,
Үсеп җит тә Кеше бул гына!

## Дүртьюллыклар

* * *

Тирә-якта һава шундый тынчу,
Тынсыз калып җиргә ятырлык.
Бу заманда чәчәк булып шыту—
Тиңсез, ләкин соңгы батырлык.

* * *

Җырларымны—күңел гөлләремне
Сибеп киләм туган кырларга.
Кыраулардан күңел саргайганчы,
Эх, җырларга иде, җырларга...

* * *

Нинди сүзләр белән бизәсәң дә
Исемемнең якын-тирәсен,
Ярдәм-киңәш эзләп авыр чакта
Иң беренче миңа киләсең.

* * *

Вак усаллык колы булмам һич тә,
Вөҗдан яза хөкем сүземне:
Мин кичердем сине, тик беркайчан
Гафу итмәм инде үземне.

* * *

Ахырын һәм башын белми кыйблаларның,
Сәбәбен һәм яшен белми дөньяларның,
Әкрен генә Вакыт буйлап агып барыш,
Ә күңелдә Галәм кебек чиксез сагыш...

* * *

Заман бае, «эшлекле» бу надан адәм,
Чолгау чолгап, алтын башмак кияр иде.
«Марста да тереклек бар»,—дип әйтсәләр,
«Тик шул гына җитми безгә»,—дияр иде.

* * *

Мәхәббәтне туздыргансың, инде кире китерәсең,
Исәп-хисап таләп итеп, истәлекләр җимерәсең.
Беренчедән, әрәм иттем бит мин сиңа күпме көчем,
Икенчедән, вак акчам юк, өлешеңне бирер өчен.

* * *

Бу дөньяда шигырьдән дә күп нәрсә бар?
Тема була кайчак шактый чүп нәрсәләр.
Йөздән бере калыр иде микән, әгәр
«Һәр шигырең ташка чокып яз»,—дисәләр...

* * *

Хатын шаулый: «Бәхетләләр генералда кияүдә...»
Түзмәде шулвакыт ире, болай диде:
«Мин генерал булыр адәм булсам әгәр,
Сине алып шушы көнгә калмас идем!»

* * *

Чын җырчылар белән бер рәттә ул,
Моңлы ташкын — бу көй агышы.
Бик тырышып ул да җырлый кебек,
Якын килсәң чыкмый тавышы.

* * *

Ана — ана инде гомерлеккә,
Балам, ди ул көн дә, балам, ди.
Ә баласы: «Ун сум алган идең,
Кайтармыйсың, әнкәй, һаман»,— ди...

* * *

Ни булса да, якты дөнья көчсезлектән
Кан-яшь түгәр өчен генә төзелмәгән.
Ачы язмыш кара тартма түгел әле,
Чебен булма — бер файдасыз безелдәгән.

* * *

Китап уку йокы белән алышынган
Ялган сәнгать төссезлеге агышыннан...
Йокы туйгач киерелеп торып басу берни түгел.
Уяныр мы ләкин җаны? Талпыныр мы моңлы күңел?

## чәчмә әсәрләр



**Зәки Зәйнуллин**

# АТ КАРАКЛАРЫ

РОМАН

Ат тояклары, арба машина тәгәрмәчләре изгән көзге пычрак юлларны туңдырып кар төшәргә айдан артык вакыт бар иде әле. Табигать мул уңыш биреп арыган кырларын ял иттереп, уҗымнарын яшәртеп, кышкылыкка әзерләнеп суыклар көтә.

Тау астында аккан елганың ике ягы буйлап утырган зур татар авылының су агышы белән түбән ягында җәелеп яткан тугайларда мал-туар курпы уртлап, колхозның ихаталанмаган печән кибәннәрен кимереп, кышкылыкка май җыя. Тугайларда, инде көтү кергәнлектән, төрле зурлыктагы, төрле төстәге сыер, башмак тана кәҗә-сарык маллары күп булып өере-өере белән йөриләр. Көндезләрен сирәк-мирәк кенә күренгән җиңел аяклы, сыбызгы борынлы малай-шалай, кайчакта бөкреләре чыккан, бер якка янтайган карт-коры үзләренең хайваннарын барлап, аларны күреп кайтып китәләр. Озакламый хуҗасының үткен пычагы астына керәсен аңгыра башларына кертә белмәгән сарыклар, агач башларына менеп-төшеп дигәндәй йөрегән әрсез, сакаллы кәҗәләр, тугай буендагы иркенлекләрдә соңгы көннәрен, атналарын яшиләр.

Авылдан ике чакрым тирәсе җирдә, бер ягы текә генә тауга барып терәлгән елга буйлап сузылган яшел тугай аланлыгы ята. Бу урын — атлар тугае. Алар йөрегән җирне күп ашарга яраткан юан корсаклы сыерлар, барысыннан да алда йөгерүче азгын кәҗәләр, өерләре белән вакыт-вакыт дәррәү куптарылып чабып алучы сарыклар өнәп бетермиләр. Аларга, күрәсең, атларның чинашып бер-берсе белән тибешүләре, тешләшүләре ошамыйдыр инде. Сугышу, тибешү, тешләшү, чинашу көзләрен атлар өчен бик тә табигый һәм кирәк эш. Артларын сикертеп, ике арт аякны берьюлы селтәп, алар сугышкан кебек иттереп кыйланалар гына. Тояктагы дагалар һавада ялтырап китә, тик бер-берсенең сырт-ларына тигән чаклары булмый диярлек. Күп тә үтми, бер-берсе белән «тибешкән» атлар, башларын инде дуска әйләнгәннең аркасына салып, аркадагы ыңгырчак ята торган җирләрен тешалмаш кашышалар. Алар инде аерылмаслык ахириләр. Тагын аз гына вакыт үтми, шул ук атлар

арт аякларына басып, ал аякларын һавада алмаш-тилмәш селтәп, инде тагын «сугыша» башлыйлар.

Күп ашап корсакларын тутырганнан соң күшәп, тыныч кына ятарга яраткан сыер ыруы, атлардан ераккарак китеп, үзләре өчен тынычрак урын эзли. Ә инде кәҗә-сарык, җәй буена шул мышнаучы, зур корсаклы сыерлар белән ялан-кырларда йөреп өйрәнгәнлектән, көзге тугайларда да алардан калмыйлар.

Тугайларда йөрегән атлар көр. Авыр эш башкаруны машина-тракторларга йөкләгәннән соң, колхозда атларның эше җиңеләйде һәм... баш саннары да нык кимеде. Сугыш башланганда, аталары сугышка киткән 10—11 яшьлек малайлар, укуларын ташлап, аталарыннан калган бахбайларны җигеп, үзләре дә колхоз эшенә җигелделәр. Укый алмыйча надан калып, бик иртә сырлап-сырлап сүгенергә өйрәнеп, малайчак елларын ат җигеп, «кара эштә» уздырдылар. Бүген инде аларның күбесе алтмышка якынлашып килә. Андыйлар — колхозда берничә дистә. Барлык колхозда гомерләре буена урлашып яшәгән тәҗрибәләрен, акылларын кулланып көн күрә алар. «Мудысы чыккан» атларны иткә «ыздавайт» итәргә тырышкан «калхуз начансвасына» алар бердәм булып каршы торалар. Һәр бригадта атларны асрау чараларын күреп киләләр. Чөнки алар ат җигеп эшкә чыкмасалар, тамакларына аш үтми, үтсә дә туймый, туйса да, дөньяның кызыгы юк. Колхоз эше дип машина-трактор тирәсендә йөрегәннәре бик аз аларның. Ул эшне күпчелеге белми һәм белергә дә теләми. Тик бер елны «Чижук» кушаматлы берсе әнә, дуамалланып китеп, киявенә ияреп (ат азгыны тайга иярә!) «Беларусь» тракторына укып маташкан иде. Укып чыкканнан соң, трактор өстенә кунаклагач, ярата иде Чижук, ат җигеп эшкә китеп барган элекке дуслары янынннан, тракторыннан кара төтен борхытып, аны тырылдатып акыртып, тегеләрнең атларын куркытып, өркетеп үтеп китәргә. Тик капарлануы бер җәйдән уза алмады. Кышын трактор ремонтына йөрергә «кәтигәрик рәвештә тәвәккәллек күрсәтеп» баш тартты. Колхоз идарәсенә чакыртып үгетләргә булашкан рәискә каршы торып тик үзенекен генә сукалады Чижук:

— Юк, энем, булмый! Җәйләрен ат исен иснәмичә эшләгәннән дип уйлыйм мин, кыш буена башым авыртты. Билләрем сызлый. Аннары күз алларыма җәҗе-мәҗе килеп тик тора. Төннәрен юньләп йоклаганым юк. Ялгыш кына онытылып, йоклаган кебегрәк була башласам, гелән генә кашка колыннар керә төшемә. Гомердә булган нәрсә түгел иде, биссуниса дигәннәре икән. Юк, энем, булмый миннән. Көчләмә мине...

Атлы арба белән колхоз эшендә йөрегәндә арба төбендә иген, печән-салам, утын һәм башкача дөнья «кирәк-яраклары» кайтканны ул рәискә сөйләп булашмады. «Хуҗаның башын андый вак-төяк нәстәләр белән тутырмау хәерлерәк»,— дип уйлады ул, үзенә кирәкне генә сөйләде. Ак керфекләре астыннан елмайган яшел күзләрен рәистән яшереп, ныклы, каршы әйтергә урын калдырмый торган тавыш белән сүзен бетереп куйды:

— Аннан соң ул тракторга менеп тә булмый инде хәзер. Аяк-кул шуңарга тотынудан пулный атказ иттеләр,— дип, рәискә агач көрәктәй зур кулларын күрсәтте ул.

Шул, 1983 елның кара пычрак көзендә, зур татар авылыннан елга агышының түбәнрәк ягында урнашкан тугайдан кышкы сугымга дип симертелеп йөрегән дүрт ат берьюлы югалды. Атларның хуҗалары кайсы колхозда, кайсысы төрле җирдә «кара эштә» йөрегән, гомере буе нужа бабай белән кочаклашып, аңардан аерыла алмыйча яшәгән кешеләр. Алар шул хайваннарның кайсысын кайдан, төрле таныш-белешлек, «знакумлык», «шабралык» белән арзанракка алган булганнар иде. Татар-башкортта «җылкы малы» дип йөретелгән ул атлар, төрлесе төрле авыр эштән арынып, инде ике айга якын бер эш тә башкармыйча тамак

туйдыру исәбе белән генә тугайларда, игеннәре җыйналып беткән, бетмәгән кырлар-яланнарда йөределәр. Югалган атларың өчесе зур «хахул» атлары. Алар авылдан унсигез чакрымда урнашкан, җирле башкортлар әйтмешли украиннар яшәгән Кушкул исемле авылдан өч яшьлек башмакларга алмаштырып алынган «бракуванный» колхоз атлары. Ул яклар өчен табигый күренеш: көз житә башласа, татар авылының берәр агае яисә бабае өч яшьлек танасын яисә үгезен, мөгезеннән бау салып арба артына тага да, тирә-яктагы урыс, украин, белорус авылларының берсенә юл тота. Урыс, украин авылларында аның атасыннан калган «знакумнары» бар, ә инде белорус авылында «шабрасы». Татарлар — Түрешле, башкортлар — Кушкүл, хохоллар Золотоножка дип аталган авылга. Хохолларга күбрәк йөриләр татарлар башмакны атка алмаштырырга. Чөнки хохол атлары гәүдәгә зурлар, иткә түгәрәкләр, тиз симерәләр. Ничәмә ничә еллар килгән «знакумлык» буенча арба артына башмагын бәйләгән татар «хахулга» килеп керә. Аны «Знакум» кулларын җәеп кочаклап каршы ала, атын тугарыша, ашарга куя, үзен «ызбасына» алып кереп китә.

Шул ук кичне кара-каршы утырып, бер-берсе белән аралаша-аралаша отып алган украин-татар җырларын әйттереп, туйганчы мәгәрич эчелә! Иртәгесен, колхоздан «Знакум» үзенә дип сатып алган «бракованый», зур гәүдәле «хахул аты», кичә генә агай килгән юл белән татар авылына таба арба артыннан юырта. Кичәге мөгәричтән, «знакумы» иртән юлга чыгар алдыннан «төзәттергән» башының авыртуы басыла башлаганга куанып, арбада аякларын салындырып утырган татар алыштырып алган малына карап, аңарга бәя биреп кайта. Агайның кесәсендә хахуллар авыл советыннан алган, ат сатарга ясалган документлар ята. Ә «знакум» хахулның сараена ябылып аерылып калган башмак татарча мөгерәп моңая, хуҗасын юксына. Аның кадерле әнисе ала сыер да, кәкере коерыклы дусты Алабае да юклар инде. Тик абзар диварының теге ягында ниндидер үтә дә сасы исле, моңарчы белмәгән ниндидер хайванның өзлексез мыркылдавы һәм гопыр-гопыр китереп, комсызланып ашаганы гына ишетелә. Хохол хуҗаның кәефе шәп. Православныйга суеп, итен ашарга ярамаган атны «знакомый гололобый татарин» бөтен бер зур башмак биреп, өстәү дә сорап тормастан, алып кайтып китте. Үзе килгән бит әле ул алмашырга! Ни әйтсәң дә, аңлап бетми торган татарин инде. Хохол, өстәүгә дип әзерләп, кесәсенә салып куйган ике йөзлекне каткан бармаклары белән сәрмәп елмая: «Хатынга әйтергәме, юкмы бирмәгәнне?»

Ә шул чакта хохоллар авылыннан үз авылына, авыз эченнән нәрсәдер көйләгән кебек иттереп моңая-моңая «Знакомый татарин» бик шәп кәефсафа белән, карап-карап алып, арба артына бәйләнгән, юырткан атның гәүдә торышын чамалый. Үзенең башында, Түрешле авылында, капкасы төбендә, чалбар кесәсендә нәрсәдер сәрмәнеп калган «знакумыныкына» караганда капма-каршы уйлар. «Хахул дисәң, хахул инде! Аңа чучка мае булса — дөньясы тигезләнгән! Тәмлерәк булсын өчен салоны, салолап ашый торган нәмәстә инде ул хахуллар. Хәзер башмакны калхузына биреп, чучкага алмаштырып ала инде ул. Йә, инде дөя хәтлек гәүдәле атны бер башмакка башма-баш алмаш инде, ә? Хет бер-ике йөз өстәү сорар иде. Юк, атаң башы! Җитмәсә мөгәричне дә үзе куйды бит әле. Теге төнлә туган гына булса да — кибет аракысы бер якта торсын! Хәер, җылкы тәмен каян белсен инде ул хахул... На-а малкай-й...

Югалган атларның дүртенчесе, озын аяклы, сылу, нечкә гәүдәле чаптар бия иде. Хуҗасы, ул бияне якындагы кала ипподромыннан, шунда ат карауны булып эшләгән, сугышта ятып калган әтисенең бертуган энесе Гарәфетдин абзасы аркылы алды сатып. Алды дигәч тә, ул сатып алу бушка алган кебек кенә булды инде. Ул кола биясе аңарга нибары ике йөз дә унике тәңкә дә, илле өч тиенгә генә төште. Чаптар бия биш ел чамасы ике эрзинкә көпчәкле җиңел арба өстерәп, ипподром юлларында беренчелекне алып, зур дан тоткан асыл хайван булган икән шул. Тик соңгы

елда нәрсәдәндер тыны кысыла торган булып киткән дә, стадион түгәрәген ике-өч тапкыр урауга, гыжлап тын ала башлап, йөгерүенең рәтечираты юк икән. Шунлыктан авыр йөк тартып эшләп өйрәнмәгән ул хайванны ипподромдагы ат комиссиясе караган да, башкача йөгерергә ярамый, дип, гамәлдән чыгарган һәм, шунда эшләгәннәргә сату өчен бик кыйммәт итмичә, бәясен дә тәгаенләп куйган. Атны шул сәгатендә үк конюх абзасы сатып алган да, энесенә хәбәр иткән: «Килеп ал, кышлык ит булды балаларга!»

Авыл тугаенда иркендә йөргән алты атның икесе югалмаган. Алары инде кечерәк гәүдәле, күп еллар буена колхозның төрле авыр эшләрен башкарып, шунда картаеп, төрле куллар аша үтеп ватылган, зур корсаклы башкорт атлары. Берсенең исеме — Хәфизә, икенчесенеке — Күгәрчен. Ул атларын, авыл халкы әйтмешли, бушка бирсәләр генә инде! Гәүдәләре бәләкәйлеге өстенә, үзләре карт, аяк-ботлары уалы һәм көч төшкәннән кәкре-бөкреләр. Күгәрченнең арт сул яны чыккан һәм ул атлаганда аксабрак та атлый җитмәсә...

Ат хуҗалары, алты кеше үзара сөйләшеп, һәр тәүлек, бер иртәдән икенче иртәгә кадәр, алмашлап, «чират саклап» атларны ике айга якын тугайда барлап, карап йөрделәр. Иртән ике кеше тугайга төшеп атларны табып, исән-имин икәнлекләрен тикшереп, үзара «дижур здавайт» итәләр. Атлар югаласы төнгә каршы кичне ат хуҗаларының берсе Чижук Хәйдәр, су агымы белән тугай буйлап күрше башкорт авылы Мәксет ягына төшеп киткән алты атны, тышауларын алмыйча гына, кире, авыл ягына куып алып кайтты. Тугайның авыл яныннан ук башланган җиренә китереп куйды атларны. Аннан соң үзенең зур гәүдәле Кара биясен кожан кесәсеннән чыгарып, эре тоз сибелеп чүпрәккә төргән арыш ипие белән сыйлады. Бәрхет иреннәре белән кымтып, ипи кисәкләреннән тәм табып ашаган биясенең ялыннан берничә тигәнәк алып ташлады. Аннан соң, еллар буе авыр эштән кәкрәеп каткан бармаклары белән биянең ялын тарагандай итеп, кылларын аралады. Атның муены яныннан тиресеннән, алгы аягына кадәр бер-бер артлы йөгереп өч дулкын үтте. Хайванның тамагы тук һәм күңеле хуҗасыныкы кебек көр иде. Хәйдәр исә тук куанычын, иреннәрен ерып килеп чыккан елмаюын яшерә алмады. Кесәсеннән кабы белән «Прима» сигаретын чыгарып, берсен алып капты да кабызып җибәрде. Эчке бер канәгатьлек белән үз алдына сөйләнеп куйды:

— Казылык шәп тә булыр, күп тә булыр быел...

Икенче көнне алар Бугаз Зарифы белән икәүләшеп елганың ике ягында җәелеп яткан, урыны-урыны белән таллар үскән тугайлыкларны аркылы-буй йөреп чыктылар. Байтак вакыт эзләсәләр дә, атлар күренмәде. Суның сул ягындагы калкулыкка күтәрелеп, тирә-якны күздән кичерделәр. Тик атлар өстән караганда да күренмәде. Калкулыктан төшеп, тагын байтак йөрегәч, куе әрәмәлек эчендә саесканнар кытырдаганга барып, тал куаклары эчендәге, курән арасыннан чылтырап агып яткан салкын чишмә янында Хәфизә белән Күгәрченне таптылар. Икесе дә, муеннарына салган арканнар белән тал куакларына бәйләп куелган иде. Күпме генә эзләсәләр дә, башка атлар күренмәде. Зариф, Күчәрченгә атланып, кабаланып авылга кайтып китте. Телевизордан караклар, бандитлар турында карарга яраткан Чижук кабаланмый гына атлар бәйләнгән тал куакларының тирә-ягын карап чыкты. Аның, атларның кая табан киткәннәрен, аларның эзләрен табасы килгән иде. Тик күпме генә йөресә дә, ачык кына иттереп әйтерлек эзләр таба алмады. Сыер һәм ат тизәкләре генә тирә-якта күренгәли иде...

Шул юктан юк булып, дүрт ат суга төшкән кебек булдылар. Алар табылмады. Ат хуҗалары тирә-яктагы ялан-кырларны, урман-чокырларны, тугайлыкларны, су буйларын, тау араларын, якындагы, ерактагы төрле милләт халыклары яшәгән авылларны барлап, карап, тикшереп чыктылар. Кая гына барсалар да, һәрбер каршы очраган, юлда туры

килгән бәндәләрдән атлары турында сораштылар. Тик атларны күрдем дигән кеше очрамады.

Шул юктан юк булып дүрт ат табылмады. «Аптыраган үрдәк, арты белән күлгә чумган»,— дигәндәй, атлар юкка чыкканга өч көн тулып дүртенчегә киткәндә, ат хуҗалары, нәрсә эшләргә инде, дигән сорауга җавап таба алмыйча, милиция йортына юнәлделәр. Үзләре белән бер чамада үскән милицияләрнең хуҗасы Хәмитов Исмәгыйль, аларның мыңгыр-мыңгыр килеп сөйләп болашканнарын тыңлап та бетермичә, туктатты:

— Туктагыз, тукта! Тукта-а-агы-ыз-зз! Сезнең ул азгын атларыгыз колхозның менә кай җиренә менеп утырдылар инде.

Хәмитов үзенең симез җилкәсенә сырты кабартма кебек күпереп торган кулы белән шапылдатып берничә мәртәбә сугып алды.

— Үзегез эзләгез! Ул дүрт аяклы дармоедларыгызның тәүге тапкыр югалулары түгел. Монда утырсам да, белеп, күреп торам мин.— Ул диварда эленеп торган Дзержинский сурәтенә карап алды.— Авылда нәрсә булган-булмаганын вич белеп торырга укытылган, өйрәтелгән кеше мин. Чекистлар, диләр безне. Мин сезгә ул нәстәләрегез өчен зурдан китереп штраф салырга дип йөридер идем әле. Так-то вот. Колхоз игеннәрен бозган өчен дә, җирен таптаган өчен дә...

Ат хуҗалары, кирәктәй зур кулларын кая куярга да белмичә, яшелле-сарылы тавышлар чыгарып акрын гына гөрләшеп алдылар:

— Калхузныкы дип кенә алай өздермә. Без дә калхузныкылар. Ничә-мә ничә еллар...

— Ы-ы-ы! Туганда ук калхуз милке булып туган бит без...

— Югалды дип инде, бер-ике көн юк булып торгаладылар инде. Шул бөтенесе...

— Таптыйлар дип инде. Барыбыз да җир өстеннән йөрибез...

— Йу-уу-ук! Моңарчы югалганнары булмады-ы...

Хәмитов өстәлгә уң кулы белән шапылдатып сукты да, сүзне кыска тотты:

— Барыгыз, бар! Кем әйтмешли, алдыгыздан артыгыз матур! Чыгып китегез моннан. Үзегез эзләгез атларыгызны. Так-то вот! Барыгыз!

Милиция идарәсенең биек баскычыннан төшкәндә Чижук Хәйдәр зарлангандай итте:

— Ничекләр итеп эредән җибәрә, әй. Чикист имеш! Беренче сыйныф-ка бергә кергән иек. Шунда теге иң тәүдә яза торган әлеп кебек таякны көянтә кебек кәкре иттереп язае ул. Мин язып бирәем. Бергә балтырган шулпасы эчеп үскән малай димәссең үзен. Үзегез эзләгез, имеш! Ул милисия безгә ни пычагыма кирәк инде, атларны да эзләргә ярамагач!

Башкалар эндәшмәде.

Шул көннән соң атна үткәч, Хәмитов, өстәле каршында басып торган, күбесен төрле төстәге сакал-мыек басып беткән авылдашларына сүзсез азрак карап торгач, авыр иттереп сулап куйды.

—Түрешледә булдыгызмы?—диде ул, сүз юктан сүз булсын дигәндәй.

— Булдык. Юк атлар анда. Хахуллар би-ик ышанычлылар. Аларда шигебез юк безнең.

Хәмитов өстәл тартмасын ачып берничә бит ак кәгазь алып, алдында басып торганнарга сузды:

— Атларыгызның кайчан югалганнарын күрсәтеп, минем исемгә гариза языгыз. Һәркайсыгыз үзенең атының төсен, особый приметаларын, каян сатып алдыгыз — барысын да языгыз. Иң өскә, уң почмакка үзегезнең йорт адресын, фамилиягезне куегыз. Үз малыгызны карый белмисез дә, бәласе — милициягә. Кая дүртенчегез?

Ирләр бер-берсенә карашып алдылар да, җавапсыз калдылар. Хәмитов сагая биреп, соравын кабатлады:

— Кая дүртенчегез дип сорыйм бит. Нигә дәшмисез?

— Сухадулга китте кичәгенәк.
— Нәрсә бар аңарга анда? Атын эзләргәме?
— Хатыны шул якныкы бит аның. Кем белсен инде... Бәлки эзләргәдер...

Бу өчәү Хәмитовтан нәрсәдер яшерәләр иде бугай, ул шуны сизеп алды.

— Монда кермичә нигә китте ул анда? Ә? Әйтегез тизрәк, минем сезнең белән тел чарлап торырга вакытым юк.

Азрак таптанып торгач, берсе телгә килде:

— Ай, бик беләсең килә икән, әйтербез, нигә әйтмәскә ди инде тагын. Шул Сухадулда Әким исемле бер күрәзәче чуаш карты бар икән. Шунда китте.

— Һы! Чуаш күрәзәчесеннән эзләтәсезмени инде?

— Ничарадан-бичара инде. Син бит безне кире борып чыгардың, үзегез эзләгез атларыгызны, дип. Син эзләтергә теләмәгәч, җибәрдек инде. Ул Әким би-ик белеп әйтә, ди...

— Ала-ай...

Хәмитов алдында таптанган ирләргә азрак көлемсерәп карады:

— Атларыгызны эзләргә сез, милиция белән параллель, чуаш күрәзәчесен дә җигәргә чамалыйсызмыни инде?

— Син, Хәмитов туган, алай диебрәк сөйләшеп безне бугазлама инде. Теге көнне үзең безне борып чыгаргач, ничарага-бичара дигәндәй булып эшләгән эш иде инде. Хатыннар да тынгы бирмиләр — ашаган аш түгел, йоклаган йокы түгел. Көн-төн кычкырыш та талаш, талаш та кычкырыш өйдә. Дөньяның яме китте гүпчим. Азмы-күпме әҗерен бирер идек, буш итмәс идек, анысы...

— Син, Чижук нәрсә сөйләгәнеңне азрак уйлабрак әйт! Әййе! Монда бит син взятка тәкъдим итәсең миңа.

— Сездән гафу үтенәм, иптәш Хәмитов! Гафу! Аптыраганнан әллә нәрсәләр биреп бетәргә әзер инде без. Әйтергә генә дә ансат түгел бит. Ат хәтле ат югалсын әле. Берәү генә түгел, дүртәү бит. Дүртәү. Бик тә асыллар иде бит хайванкайлар. Аннан соң, берьюлы дүрт ат югалу, сезгә дә дәрәҗә китермәс бит инде.

— Ярар, буш сүз белән вакыт уздырмыйк. Әйдә, гаризалар язгыгыз үз кулларыгыз белән.

Хәмитов ирләргә шариклы каләмнәр таратты да, урындыклар биреп, өстәл тирәли утыртты. Бик зур тырышлык күрсәтеп яза башлаганнарның берсе, кузгалгандай итте:

— Энем, иптәш Исмәгыйль! Минем бетермәгән ике генә сыйныф белем бит. Сугыш башланып эти фронтка чыгып киткәч, уку кайгылары бетте бит бездә. Язу-сызу тирәсе минем өчен үзең беләсең...

— Әйдә, мин әйтеп торам, җайлап кына булса да яз инде. Минем үз кулларыгыздан яздырасы килгән иде. Белмәгәннәрегез Гаяз абзыйга иярегез, минем әйткәнне тыңлап. Тик үзегезнең исем, фамилиягезне куегыз. Иң өскә уңгарак, фәлән район начальнигы Хәмитов Исмәгыйльгә диегез. Шуннан соң үзегезнең йорт адресын язгач, фәләнефтән диегез. Аннан соң яңа юлдан, битнең уртасына баш хәреф белән «Гариза» дип куегыз. Аннан соң инде тагын яңа юлдан зур хәреф белән...

— Туктап тор әле, Исмәгыйль, чак кына. Безне бик алай куалама инде син. Бу бит сиңа урман кисү белән печән чабу түгел. Язу-сызу, диләр моны. Аркадан артка бөрчек-бөрчек тир ага башлады. Гомере буена язу-сызуда утырганнарга Ходай үзе түземлек бирсен инде...

Шул юктан юк булып, суга батып юкка чыккан кебек дүрт ат хәбәрсез югалдылар. Ат хуҗалары үзләре дә, подполковник Хәмитов җитәкчелеге «иптәш милиционерлар» төркеме дә айга якын тирә-як авылларны, якындагы дүрт каланы, күрше районнарны, урман-кырларны, тау араларын, чокыр-чакырларны бетереп эзләсәләр дә, атларны таба алмадылар. Атларны күргән яисә һич югы алар турында ишеткән кешеләр табылмады...

Күзгә кара пычрак юлларны туңдырып, тәүге суыклар килде. Алар артыннан бик озак та көттермичә, барлык тирә-якны ап-ак кар белән каплап, озын кыш килеп җитте. Кар төшеп, чана юллары салынгач, авыл кешеләренең күңеленә, әллә кайда калган еллардан килгән кебек, кара шом курку сала башлады. Яше, карты дертләп куйды: ат караклары!

* * *

Ат караклары!

Ул сүзләрнең каян килеп чыкканын, иң башлап кем әйткәнен, беренче булып кем ишеткәнен белерлек түгел. Ул ике сүз әле авыл гайбәте генә кебек булып, шуышкан елан кебек өйдән-өйгә, урамнан-урамга тарала башлады. Төрле имеш-мимешләр белән арттырылып, симереп, колактан-колакка «сер иттереп кенә» сөйләнеп, урамнан-урамга, кибеттән-кибеткә, су алган колонкалар янына, аннан соң инде авылдан-авылга таралып, ныгып, кала юлына да чыгып китте.

— Аларны берәү күргән, ди. Тик караңгыда кемнәр икәнен, ничәүләр икәнен генә чамалый алмаган. Икәүдән күбрәк иде дип әйтә, ди...

— Аларның берсен таныган, ди ул. Тик курка, ди әйтергә. Баш берәү генә бит, шунлыктан бик тә кадерле дип әйтә, ди...

— Шул атлар югалган төндә, теге мытыес тавыннан Кәҗә тавына менгән җирдә, күккә каршы якта Мәксетнең бер башкорты күргән, ди, дүрт атны алып китеп барганнарын. Икесен ике кеше менгән, ди, ике атны җитәкләгәннәр, дип әйтә, ди. Ярты төн узганые дип әйтә, ди.

Урамнар тутырып йөргән имеш-мимешләр арасында, җимертеп дөнья көтеп йөргәннәрдән, картаеп аерылып, инде намаз гына диеп мәчет юлында гына йөрегән ике бабайның сөйләшкәннәре әһәмияткә ия булмыйча читтәрәк торып калды.

Берничә ел инде йортыннан чыкмыйча тик мәчеткә генә, җомга намазына, барып-кайтып йөрегән Шөшле Хәлиулла бабай ястү намазыннан соң, ике ягына да сәламнәрен тапшыргач, урыныннан җайлап кына торып, намазлыгын җыеп киштәгә элеп куйды. Аннан соң, укына-укына алгы якка чыкты. Гәҗит караштырып утырган, инде алтмышны куган улына эндәште:

— Син, Мәхмүт улым, иртәгә мине Түбән очка, Хөснулла кордаш янына төшереп куй әле. Атың белән. Иртәгә тугызлар тирәсендә. Өйләгәрәк алып кайтырсың йортка. Күрешмәгәнгә ел тулып үтте. Ныклап утырып сөйләшмәгәнгә ике ел бардыр инде.

— Мәчеттә очрашканыгыз юкмыни?

— Юк шул. Камун бит ул. Заманында, үзе кисмәсә дә, мәчет манараларын кистереп йөреде бит. Өендә генә укый намазын, Алладан ярлыкагыл кылуын үтенеп. Алып бар мине, улым.

— Алып барырмын, ния алып бармаска ди. Тик каралып китмәсәң юлда, диюем генә.

— Нинди каралып китү ди инде тагын. Юкны сөйлисең. Минем никрут булып каралганга инде алтмыш елдан артып китте. Син югыең әле анда. Шаярып сөйләшергә ниятең булса, аз гына башны алдан эшләтергә өйрәнергә вакыт инде сиңа. Инде бит алтмышны узган ирсең, Ходай бәндәсе...

— Ярар, ярар, синеңчә булсын. Иртән үк әзерлекләр уздырып, тәһәрәт-намазларыңны башкарып куй. Алып барырмын, алып кайтарып куярмын, Алла боерса.

«Алла боерса»ны ныграк, кычкырыбрак та әйтте.

Атасының йөзе яктырып китте.

— Менә шулай иттерепләр сөйләш син атаң белән. «Алла» диген, намаз диген. Инде сиңа да мәчеткә, җомга намазына йөри башларга вакыт. Сиңа да килеп җитте картлык көннәре. Аллага мең шөкер, сугыш күрмәдең...

Икенче көнне ике кордаш келәт алдындагы юан имән бүрәнә өстендә сөйләшеп байтак утырдылар. Йорт эшләре белән ишек алдында йөрешкән хатын-кыз, бала-чага күренсә, шпионнардан сакланган кебек, алар сөйләшүләрен туктатып, дәшмичә утырдылар. Тик барыбер тулысынча сакланып бетә алмадылар. Авылда барлык яңалыкларны, гайбәтләрне, имеш-мимешләрне иң беренчеләрдән булып белергә яратучы, йорт хуҗасы Хөснулла картның килене, картлар утырган җиргә якын абзар эченә яшеренеп, тегеләрнең сөйләшкәннәрен азрак тыңлап тора алган. Шуларны кичен, йокларга яткач, иренә сөйләгән бу.

— Теге, Югары очтан үзен ат җиктереп китерттергән Хәлиулла бабай безнең әткәйгә әйтә: «Кордаш, ди, бу дүрт атның югалуы теге Гыйльван башкорт эшедер дип уйлыйм мин, ди. Шуңа каршы безнең әткәй кеткелдәп көлә. Ул Гыйльван башкортны, Әбрәнең атларын урлап тотылгач, урамда йөретеп, кыйнап үтерделәр бит инде, ди.

Шуннан, колакка каты диң инде син аларны. Минем абзар эчендә басып торганны сизенделәр, ахрысы, туктадылар беразга сөйләшүдән. Азрак утырдылар. Бу карт кешеләр би-ик кызык булалар икән алар. Икесе дә ишетеп бетермиләр, тотындылар мин сиңа әйтим, пышылдап сөйләшергә. Хет көл, хет ела инде, ишетеп кенә дә булмый бит, әй. Үзләре ничекләр ишетәдер бер-берсен.

— Йә, йә, шуннан?!

— Шуннанмы?

— Ыымы!

— Бетте дияргә ярый инде. Тагын берничә сүзләрен генә аерып ишетә алдым.

Йокы баса башлаган ире йокымсыраган тавыш белән сорый:

— Алары нинди сүзләр инде?

— Безнең әткәй әйтә: Рәвил карак сукмагы, ди. Шуннан куганнардыр атларны кире якка, казакъ ягына, ди. Аннан соң бик ишетелмәде. Аннан соң Якуб Чәршәмбе бер акырып җибәрсә, атлар артларына утыра торганнар иде, ди...

Иренең йокысы ачылып китте.

— Якуб Чәршәмбе ди-и?!

— Әййеме менә, валлаһи-билләһи...

— Мин малай чакта авылда шундый исемле бабай бар иде чыннан да. Әлеге кинотеатр бар бит?

— Әййе.

— Әнә шул урында Баһрам дигән бабай белән икесенең йортлары янәшә тора иде. Баһрам бабайның йорты калай түбәле, шәп йорт иде. Ә бу бабайның авылдагы иң хөрти йортларның берсе иде. Ике генә тәрәзәле, череп беткән салам башлы, юкагачтан ясалган өйалды...

Исенә төшереп яткач өстәде:

— Сакалы, мыегы бакыр төсле, үзе азрак, урысчалап әйтсәң, сутулый иде. Куе кашлары астыннан гына карап, кулларын артка куеп йөрер иде үзе. Авыл халкы нигәдер курка иде аңардан. Без — малайлар да, аның яныннан урап уза торган идек. Нигә шулай шүрләгәнбездер инде, бүген дә белмим.

— Әллә кайдагы, хан заманнарындагы кешеләрне беләсең инде син. Мин шуларның берсен бер белмим инде.

Ире, көлеп, хатынының артыннан шапылдатып сөйде:

— Соң, син белергә тагын. Мин солдатка киткәндә тездән түбән буйлы ак ыштан кигән, үсә алмыйча этләшкән бер маңка идең бит әле син.

— Кит, шушының! Бер сурьюзный сүзе булмас. Гелән генә шырдыйбырдый, мәгънәсез буш сүз. Син хет әллә нәрсә диген, безнең әткәй белән Шөшле бабай нәрсәдер беләләр ул урланган атлар хакында.

— Шулайдыр, әллә кая! Беләләрдер инде бик. Көне буена комган күтәреп йөреп, капка төбе саклап, нәрсә белергә мөмкин. И-и-эй, бу баш

дигәнең синдә. Аларның акылы хәзер бала-чага акылы кебек, керәле дә чыгалы инде. Син дә шулар сыңары. Колакларына кеше сөйләгән кереп калгандыр ялгышып. Йокла, иртәгә бәйрәм түгел. Йөремә анда, картларының нирвысында уйнап, алар сөйләшкән җирдә боталанып...

— Ки-ит, сөйләмә юкның югын! Нинди ниткән нирвы булсын ди аларда. Алар заманы нирвылы заманмыни ул. Менә нирвы бездә ул! Иртән тор дисәң нирвы. Аларның сабырлыгы җитәрлек. Нирвы-ы-ы, имеш.

Ире бушка сүз көрәштерүгә караганда, танавын мышнатып йокы симертүне кулайрак күрде...

* * *

Бу авыл — казакъ-башкорт далалары очрашкан урыннарга татарлар күченеп килеп утырганнан барлыкка килгән авылдыр. Явыз Иван Казанны алып, кала эчендәге татарларның ирләрен картларыннан алып бала-чагаларына кадәр кылычтан уздырып, барлык Казан ханлыгындагы мәчет-мәдрәсәләрне яндырып, туздырып бетереп, татарларны көчләп чукындырырга тотына. Шул чакта татарларның буйсынырга, урыс кул астына керергә теләмәгәннәре туган-үскән җирләрен ташлап чит якларга, урыс кулы җитмәслек төбәкләргә күченеп чыгып киткәннәр. Шул качып чыгып китүчеләр арасында кемнәр генә булмаган. Урыска баш иеп, каршылык күрсәтүдән туктап, урыннарында китмичә торып калганнарга караганда, чит-ят, таныш булмаган җирләргә чыгып киткән татарлар арасында күбесе тынгысыз эш сөючән, кыю йөрәкле, үз иреге өчен көрәшүче, үзенең телен, динен, милләтен яраткан кешеләр бик күп булганнар. Мәчет-мәхәлләсез калган ишаннар, муллалар, мәдрәсәләре яндырылган мөдәррисләр, хәлфәләр, Казан-Бохара араларын үзенең ишегалды кебек белгән, елан аягын кискән, бик күп телләр белгән ут сәүдәгәрләр, арбаларына күпсанлы балаларын тутырган, сабанын салган игенчеләр, малчылар, балта осталары, ташчылар, кирпеч сугучылар, күнчеләр, итекчеләр, тегүчеләр, палас сугарга маһир әбиләр, яшь кызлар, ат өстендә бөркет булган егетләр, акыл иясе картлар, пима басучылар һәм тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр. Шулар арасында һөнәрен бер кешегә дә сөйләми белә торган дәшмәс, аз сүзле татарлар да байтак булган. Болары инде урыс кайда гына очраса да, хәнҗәргә, кылычка, балтага тотына торган гайрәтле ирләр булганнар...

Киң далада барысына да урын җитәрлек табылган. Җир яралганнан бирле сабан-сука күрмәгән дала, тау-ташлы, урман-кырлы булган бу яклар. Кара туфракка да, урман-суга да, эче тулы ташка да бай урыннар күп булган бу якларда. Бу җирләр өчен борын-борыннан, бу җирләр безнеке дип, башкорт белән казакъ-кайсак арасында бик күп тартышлар, сугышлар, барымтага чабулар, кан коешлар бик күп һәм еш булган. Бигрәк тә карлар эреп, җир өсте ачылып, җәйләүләр яшәргәч, ике халык арасында мал йөретү өчен урын биләү максаты белән һәрчак тавышгауга чыккан., Шул тавышлардан туйган башкортлар. Коръәнле, сабанлы, муллалы, бодай онлы, кызыл маллы, үзләре мөселман татарлар, башкортлардан утырырга, авыл салырга җир сорагач, тегеләре озак уйлап та тормыйлар — ризалашалар.

— Һәз, татарзар, укымышлы, сәүдәле, игенле халыкһыз. Теге киң битле казахтар менән үзегез килешерһез. Без һезгә үзебеззең ерзәрзе бирәбез. Алардыкын түгел. Менә ошо ердәр һеззеке булырдар. Ултырығыз, үрсегез...

Үзе дә, казакъныкыннан да кысыграк күзле, аныкыннан да киңрәк битле Солтанморат башкорт камчысы белән офык ягына селти:

— ...шул яктар, Тәмиганга кадәр һеззең ердәр булыр. Казакъ-кайсактар беззең ата-бабаныкы булган ерзәргә каныгып яшәнеләр. Үлән шәп

был яктарда. Әйдә игелеген күрегез, хакын түләрһез инде, әййе. Башкорт ерзәрендә икәнегеззе бөтенләй онытып ебәрмәгез, дибез...

Шуның белән сөйләшүне беткәнгә санап, татарлар арасында гәүдәгә иң олпат, иң абруйлы, сәүдә өчен бик тә кирәкле күп телләр өйрәнгән, Бохара аша Кашгарга бара белүче, үткен зиһенле Юныс байга Солтанморат башкорт ике кулын биреп, килешү төзи. Барлык башкортлар исеменнән. Тиешле акчаны алтын-көмештән ала башкортлар.

Шул көннән алып татарлар, биек булмаса да, текә генә тау итәгендә алты урыннан бәреп чыгып яткан чишмә янына утар салып утыралар. Көн күрә башлыйлар. Игеннәре яхшы үсеп, сәүдәләре табышлар биреп, тагын килгән кешеләре күбәя барып, утарлары үскәннән-үсә, тәмам авылга әверелеп китә.

Тәүге еллары чирәм ертып, йортлар салып, каралтылар төзеп, юллар сузып, елгалар аша күперләр салып, мал үстереп уза. Берничә йорт салу белән, агачтан, бик зурдан купмыйча мәчет торгызалар, күзләреннән аккан яшьләренә ирек биреп, манара башына ярымай утыртып куялар. Мәчет янына кечкенә мәдрәсә дә салына. Манарадан әйтелгән азан тавышы каршы таудан кайтаваз булып әйләнеп кайтып, авыл өстенә ямь бирә, мөселманнар күңелендә киләчәккә өмет тудыра. Мәдрәсәдә дәрес башланган еллар унҗиденче гасыр азакларына тәңгәл килгән еллар була бу. Мәдрәсәләрдә дәресләр башланган чакларда иркен далаларны гизеп чыгып казакъ якларына барулар кайсы вакытта, кем белән телисең һәм ничек телисең — шулай булган. Урыс әле үзенең балта, сөңге тоткан күләгәсен кылганнары иркен итеп үсеп утырган далаларга тулысынча сала алмаган чагы булган. Аннан казакъ далаларын эзләп, ерак сәфәргә чыгасы да юк. Авылдан төньяктарак күренеп торган Кайраклы тавына барып җиткәч, тавык та атлап чыгарлык киңлектәге кечкенә Өршәк елгасын кичеп, икенче ярына күтәрелсәң, шул җирләр инде кыргыз-кайсак яклары була. Татарлар авыл салып утырган урыннан нибарысы унике чакрым чамасы гына.

Башкорт һәм кыргыз-кайсакның уртак диярлек урынына китереп салынган бу татар авылы, гомерләре буена чаптар ат, курай, кымыз яраткан башкорт өчен дә, дала киңлеген, шулай ук чаптар атлар, сунар, яңа суелган куй ите, башкорт кебек үк кымыз яратучы казакълар өчен башта бик сәер авыл булып тоелган. Чөнки, татарда, аларда булган сыйфатлар бик нык җитешмәгән, ә кайберләре бөтенләй булмаган да. Кайда барса да, китабын янсә күтәреп, янсә киндер җәймәгә төреп үзе белән озын-озак юлга да алып чыга торган татарга башкорты да, кыргыз-кайсагы да азрак җитешмәгәнрәккә караган кебек иттереп караганнар баштарак. Тик озын-озын кышкы буранлы кичләрдә, янган учак яктысында, тирмәләрдә, алачыкларда китапны көйләп-көйләп укый белгән татар галим-голәмәләренә алар исләре китеп, аннан соң инде, китаптан агылган сүзләрнең моңын аңлау дәрәҗәсенә җитә башлагач, сокланып карый башлаганнар. Еллар уза барган, һәм татар авылындагы мәдрәсәдә, түбәтәйле, догалы, намазлы, инсафлы, иманлы татар шәкертләре арасында, ялгышып килеп кергән кебек башкорт, казакъ-кыргыз, нугай малайлары да күренә башлаганнар. Шул шәкертләр, язгы сулар китеп, дала яшелләнә башлагач та, барысы да бердәм булып, дәррәү кузгалып, үзләрен кыш буена укыткан ишан-хәлфәләрен тыңламыйча кача-поса, ашыга-кабалана атларына атланып, җәйләүләренә китеп юкка чыкканнар. Мәдрәсәдән кара көзгә кадәр юк булганнар алар. Шулай булса да киткән чакларында, татар шәкертләреннән күргәнчә, ак чүпрәкләргә, киндергә төреп үзләре белән әкиятләр, хикәяләр, кыйссалар язылган китапларны алып кайтып киткәннәр. Җәйләүләрдә мәдрәсәдән кайткан әкият-хикәяләр сузып-сузып моңланып укыла башлагач, дала-кырлар киңлеге тагын да матурланып киңәеп киткәннәр. Шул еллардан башлап мәдрәсәле татар авылына башкорт, казакъ, кыргыз, нугай ягыннан мөнәсәбәтләр яхшыга таба үзгәрә башлаган. Яңа салынган, мәд-

рәсәле, мәчетле, ишанлы-хәлфә, шәкертле татар авылы янында җәйләүләрдә көн уздырган башкорт һәм кайсаклар арасында кычкырышызгышлар кимегәннән-кими, мөселманлык, дуслык, татулык көчәя бара.

Әмма башкорт белән кыргыз-кайсакларны икегә бүлеп, Иделдән алып Җаек елгасына кадәр урысларның Самара-Ырымбур сызыгы крепостьлары төзелә. Ырымбур каласы салына башлагач, башкорт җирләреннән борын-борыннан узган кәрван юлы Болгар-Бохара дугасы урысларның Уфадан Ырымбурга йөри торган төп юлына әйләнә. Ул юл мәдрәсә-мәчетле татар авылы аркылы да узган була. Уфа—Ырымбур тракты буйлап бик күп яңа татар авыллары калкып чыга. Бозаяз, Толбазы, Эстәрлетамак, Эстәрлебаш, Айдәрәле, Тәтер-Арслан Бүз Ат, Шарлык, Абдулла — болар шушы тракттагы иң зур татар авыллары. Барысы да мәчетле, иманлы, кечкенә генә булса да мәдрәсәле авыллар. Сәер булса да, Ырымбур трактында татар авылларының күбәюе, басып алу сәясәтен генә үткәргән урыс патшалары өчен файдага була. Чөнки әрсез, үткер, белемле татар мөселман сәүдәгәрләре тәре таккан урыс купецлары барырга курыккан әллә кайдагы мөселман җирләренә барып чыга белгәннәр. Алар өчен Бохара, Сәмәрканд, Хива якларына бару күрше авылга барып кайту чамасында исәпләнгән. «Бисмилла» белән «Ля иллаһы»ны укы да юлга чык. Мөселман ягы — юлың уң булыр, иншалла. Татар сәүдәгәрләренең иң үткерләре, мал артыннан куганнары Герат, Кандагар, Кишкар якларына ук барып чыкканнар. Берничәсе бергәләшеп юлга чыгып, унсигезенче гасыр башларына хәтта әкияти Һиндстанга да барып, зур табыш белән, исән-имин кайта алганнар. Берсе шунда — Мөхәммәт Дәмин дигән сәүдәгәр — бер көлке дә, үзе кызыклы да, һөнәр дисәң һөнәр түгел, бер шөгыльгә өйрәнеп кайткан. Башын түшәмгә каратып күтәрә, авызын зур иттереп ача, ансыз да озын муенын дөянекедәй иттереп тагын да килбәтсез итеп суза да, кулына алган чәйнекне өскә күтәреп, шуның борыныннан авызына ачы бал коя. Бер генә тапкыр да йотмыйча, шул чәйнектәге балны авызына агыза да бетерә. Һиндстанда шулай иттереп эчә беләләр икән. Ходай үзе беләдер инде, тик без инсафлы мөселманга кулай нәстә түгел.

Урыска татарның ерак мөселман илләренә барып сәүдә итүе бик тә кирәк булган. Үзе үтеп керә алмаган җирләрдән, киләчәккә басып керү өчен мәгълүмат җыйган урыс патшалары. Петр I нең васыятен исләрендә нык тотканнар урыс патшалары: алга, Һиндстанга кадәр! Һинд океанына! Сәүдә белән разведка кулга-кул тотынышып хәрәкәт иткәннәр. Казакъ ханы Вәлиханның улы Чоканхан да, Омск кадет корпусына укырга керүгә кадәр, уналты яше тулганчы, Эстәрлебаш мәдрәсәсендә дин дәресләре өйрәнеп, фарсы, гарәп, төрек телләрен казакъ теленнән дә әйбәтрәк өйрәнеп чыккан. Урыска хезмәт итеп, Хива, Кашгар якларында тирән разведка алып барган. Шунлыктан, үлеме дә үз үлеме булмаган, дигәнрәк фаразлар бар тарихта.

Татарлар килеп утырганчы ук бу як далаларда кеше күзеннән яшерелеп башкарыла торган борынгы бер кәсеп булган. Мөселман булсалар да, Аллага кирәк чакларында гына табына белгән башкорты да, кыргызкайсагы да, дин хупламаган ул кәсепне, мөселман булсалар да, ташламаганнар, аның белән иң гаярь, иң йөрәкле, иң җитез, башкисәр егетләре шөгыльләнгәннәр. Чөнки ул кәсеп чын ир-егетләр кәсебе саналган. Аның өчен курку белмәс йөрәк, уйлап эш йөретә белгән акыллы баш та кирәк булган. Андый егетләрнең исеме ат караклары булган. Ат буры түгел, ә ат карагы! Чөнки ат карагы нәрсә эләкте — шуны урлау белән шөгыльләнгәннәргә дәрәҗәсез кеше иттереп, түбәнсетеп караган. Ат карагы сарык, кәҗә буры белән беркайчан да уртак караклык кылмаган һәм аны уена да китермәгән.

Казакъ далалары белән эргәдәш яшәгән башкортларда да, дала баласы булган, җаен-кышын башыннан өч колаклы олы бүреген башыннан

салмаган казакъ-кайсакларда да, кыргызларда да кара яздан алып, кыш житкәнче, мал кышлауга кергәнче, бер-берсенең исәпсез-сансыз җылкы көтүләреннән унарлап, уңышлы чагында йөзләгән атлар куалап алып китү гадәти бер эш, зур егетлек саналган. Ничәмә-ничә гасырлар җир өчен, мул печәнле җәйләүләр өчен ызгыш-гаугалар туктамастан барсалар да, яз яхшы килеп, җәен үләннәр җәйләүләрдә әйбәт, куе һәм биек булып үссәләр, ул ике халык татулы, солыхлы һәм тыныч көннәр уздырган. Бер-берсе белән аралашканнар, кымыз эчкәннәр, башкорт кураен тыңлаганнар, казакъ акыннарының ярышып-ярышып сөйләгәннәрен-көйләгәннәрен тыңлаганнар. Тик андый тыныч заманалар бик озакка бармаган шул. Ырымбур каласына нигез салынып, унсигезенче гасырның башында урыслар Самар-Ырымбур сызыгында крепость-кальгалар сала башлагач, башкорт һәм казакълар арасында кычкырыш-ызгышлар, хәтта корал кулланып сугышулар бик нык көчәеп китә. Чөнки ак патша хөкүмәте башкорт белән дала казакъларын бер-берсенә оста дәрәҗәдә өстереп-котыртып, мәкерле сәясәт алып бара башлый. Ак патша кешеләре килгәнче, үлән житмәгәннән коры, яңгырсыз елларда гына җәйләүләр, су буйлары өчен тартышкан, ызгышса да уртак тел таба белгән ике халык, урыс коткысына бирелеп, бертуктаусыз сугыша торган ике дошманга әверелеп китә. Пүгәч патша фетнәсе бастырылгач, Әби патша җибәргән алдак кәгазьләргә ышанып, казакъ ханнары, бәкләре, ыру башлыклары, фетнәдә катнашкан, инде котылу эзләп казакъ якларына качкан фетнәче башкорт-татарның күпчелеген тотып, мал-мөлкәтен, хатыннарын, бала-чагаларын үзләренә коллыкка алып калып, Әби патша генераллары кулына тапшыралар. Генераллар да, үзләренең Әби патшаларын тыңлап, фетнәчеләрнең мал-мөлкәтен дә, хатын-балаларын да сорап тормыйлар. Казакълар үзләренең мәкерләре өчен йөз ел узарузмаста җәзаларын ала — урыс гаскәрләре аларның да җирләренә басып керә, үзләрен дә, башкорт, татар кебекләр иттереп, урыс коллары итәләр.

Фетнә бастырылганнан соң, Самар-Ырынбур хәрби сызыгын тагын көчлерәк иттереп ныгытуга Әби патша бик күп көч куя. Акчаны кызганмый. Ырымбур крепостен ныгытуның бер сәбәбе, Эстәрлетамак пристаненнан Агидел елгасының агышына каршы, Ырымбур каласына турыдан зур, киң, таш юл салу була. Чөнки Пүгәч фетнәсе вакытында Эстәрлетамак-Ырымбурны тоташтырган, тоташ татар авыллары утырган борынгы Болгар-Бохара юлы, шул ике арада тоташ Пүгәч яклы фетнәче татарлар кулында була. Бу юл Пүгәчнең атаклы полковнигы, татар Канзәфәр Усаев житәкчелек иткән татар-башкорт сугышчылары кулында була. Орск янында 1774 елның март аенда Әби патша гаскәрләре белән сугышта җиңелгәннән соң да, Пүгәч үзе шушы юл белән качып чыгып китеп, юкка чыга. Татар авыллары утырган фетнәле юлны уза алмыйча, Әби патшаның гаскәрләре сугышып байтак көннәрен заяга үткәрәләр. Шунлыктан, Пүгәч җиңелеп башы чабылганнан соң, Әби патша Эстәрлетамактан Ырымбурга туры юл салдырып, инде ул юл буйлап тик урыс авылларын гына утырта. Казакъ далалары чигенә табан каратып салынган юллар күбәйгәннән-күбәя баралар. Һәм күбесе таудан казып алган таш белән түшәлгән юллар булалар. Кеше хакына яшәп тәм тапкан Русиянең ак патшалары, мөселман халыклары яшәгән урта Азияне алу планнарын тормышка ашыра башлау өчен зур әзерлекләр башлый.

Самара—Ырымбур хәрби сызыгы салынып, ныгытыла башлагач, казакъ-кайсак якларыннан килгән малларны урыслар сызыкның бу ягына түләүсез чыгаруны туктаталар. Патша хөкүмәте, моңарчы далада күренмәгән талау тәртибе кертә: сатарга алып килгәнсең икән, хәрби сызыкны узганда, мал башыннан тиешле салымны түлә дә, әнә сезгә Оренбург каласы, әнә сезгә аның базарлары! Шунда тагын базар хакын түләргә тиешсез, шуннан соң тиеш бәясен алып, әйдә сату итегез... Тыштан караганда тәртип салынган, сату-алу эшләре гөрләп тора. Бар да ал да гөл, урыс карашы астында тынычлык, тәртип, сугышлар ике арада

туктатылган, сәүдә эшләре алга бара, халык тыныч көн күрә. Ак патшабызга, Русиягә дан шуның өчен! Афәрин!

Шулай иттереп күрсәтелсә дә, шулай булып тоелса да, тик урыс патшасы күзеннән, аның барлык нәрсәне күреп, белеп, тикшереп, үз кул астында тота белүеннән дә яшерелгән бер кәсеп, бер шөгыль килеп чыга.

Әле дала иркен, урыс крепостьлары салынмаган чакта, чит көтүдән аерып алып, куып үз ягыңа алып кайтып, үзеңнеке иткән бер өер җылкы малы әллә ни зур гөнаһлардан саналмаган. Көн дә иртән таң атып, кояш чыккан кебек инде. Далада күбесенчә ат урлаганнар. Чөнки сыер малын, сарык-куйларны көтүеннән аерып алганнан соң, яисә тоташ көтүе белән, зур тизлек белән йөгертеп ерак алып китеп булмый. Көтүчеләр салган һау-һуга, маллары урланган халык бик тиз күтәрелеп, атларга менеп, чукмарларын күтәреп арканнарын иярләренә бәйләп, бурларны куа чыгалар. Йөгерә алмаган сыер, сарык-куй көтүләре белән мәшгуль бурларны алар тиз куып җитә алганнар. Ә инде куып җитеп, эләктерсәләр, яисә сугышка китсә, шул куып җиткән урында күсәк, чукмарлар, очына курган теккән камчылар күпләрнең җанын кыйган. Шуңа күрә далада мал урлап кәсеп иткәннәргә урлашу өчен җылкы малыннан да кулае булмаган. Бердән атларны зур тавыш-гауга чыгармыйча зур тизлек белән куып алып китеп булса, икенчедән, атның базардагы хакы сыер бәясеннән дә ярыйсы гына югары һәм аны сатып алучылар һәрчак табыла торган. Ат игенчегә дә, сәүдәгәргә дә, мулла-мәзингә дә, байга да, губернаторга да кирәк. Хәтта, ат карагын тотарга хыялланган урядник, палисмистер халкына да кирәк тиз юыртучы, тиз чабучы атлар. Кара туфраклы, суга-урманга бай, Русия басып алган җирләргә күчеп килгән урыс, татар, украин, белорус, латыш, немец, эстон, чуаш крәстияннәре өчен яңа җирләргә чирәм күтәрергә, дөнья көтәргә, тирес-иген ташырга, кунакка йөрергә шулай ук ат кирәк. Атның нәрсәләр өчен кирәген санап та бетерерлек түгел. Кирәк, бик тә кирәк! Күп кирәк атлар. Ә ул кирәк атлар казакъ, кыргыз-кайсак далаларында бик тә күп санлы булып, эшсез-нисез тик май җыеп кына йөриләр икән бит. Татарлар далага якынлашып утыра башлагач та, чирәм күтәрергә ат күче кирәк. Ә инде ул тирәләрне урыс корал көче белән буйсындыргач, җир эшкәртү өчен ат тагын да күбрәк кирәк була башлаган. Далага урыс килгәннән соң, ат каракларының кәсебе хаҗәткә әйләнгән.

Оренбург крепосте салына башлагач та, ат караклары аны урап үтеп, казакълар ягына чыгып йөрергә өйрәнгәннәр. Тик шулай да дала тар булып, берничә тапкыр крепостьтан чыккан, яисә анда кайтып барган солдатлар, хәрби хезмәтче атлы казаклар белән очрашканнан соң, алардан бик үк шикләнми башлаганнар. Чөнки, Ырымбур-Самар сызыгында утырган эреле-ваклы крепостьларда хезмәт иткән, казакъ ягыннан урланып куылган мал өерен бик сирәк туктатканнар. Казакъ ягына мал кумасалар, йөк белән йөремәсәләр, аларны да туктатып тормаганнар. Ак патша хөкүмәтенең сәясәте шундый булган: сызыкның бу ягына казакъкайсак, кыргызларны урыслар гомум исем белән кыскача гына «кыргызлар» дип атаганнар, тикшерүсез, налог салмыйча кертмәскә, ә инде теге якка буш кул белән, атка атланып яисә җәяүләп кенә булса да чыкканнарны туктатмаска. Алар Русия файдасына «кәсеп итәләр». Үзе башкаларны талаган урыс патшасы, урлашып, талап Русиягә кергән малны фәкать хуплаган. «Талаган булса да, Русия йортына кайта бит!» Йөри бирсеннәр!

Бигрәк тә ат кәсебе белән татар, башкортлар йөрегән. Чөнки ул атлар арзанга төшә һәм ат базарларында сатыла. Русия базарларында! Ә инде ул атлар Русия ягына куылып кайткач, базарларда сатылгач, күбесе җигелеп җир эшендә кулланылалар. Русиянең икмәге күбәя, Русия баеый. Аннан соң, кирәк булса, хөкүмәт кешеләре, өстән кушу буенча, базарда сатылырга китерелеп бәйләнгән ул урланган атларны, патша кануннарына таянып, шул базарда ук тартып та алалган. Сатарга китергән кешесенә «качарга» мөмкинлек тудырып, билгеле. Тагын китерсен, табыш кирәк бит.

Казакъ ягыннан, зур тавыш-гауга күтәрмичә, акырып тавыш чыгармаска тырышып, урланган ат көтүен куып килгән ат каракларын хәрби сызыкта хезмәт иткән атлы казакълар һәрвакыт каршы алырга тырышканнар. Чөнки чит-ят күзләрдән качып-посып, урланган атларны зур тизлек белән куган «кәсепчеләр» хәрби сызыкны тизрәк үтәргә ашыкканнар. Сызыкны үтү белән үзләрен ат хуҗалары куып җитү хәвефеннән арынган алар. Ә инде узган чакта крепость казакъларына очрасалар, аларга тиешле әҗерен түлә дә, үз юлыңны бел. Кайтып җиту юлларында күсәк, чукмар күтәргән кыргыз-кайсак юк инде башкача. Юлың уң булсын, ат карагы! Без сине күрмәдек, син безне күрмәдең. Ә сызыкны үткән өчен түләү билгеле — ун атның берсен аерып калдырасың! Әгәр инде түлисең килмичә крепостьларне качып-посып ат көтүең белән сызыкның бу ягына узып керергә чамалыйсың икән, барлык атларыңнан да колак кагып, үзеңне аяк-кулыңа богау салып Ырымбур төрмәсенә озатачаклар. Ә аннан инде Себер юлы сиңа, синең богаулы аякларыңа. Кайтасыңмы аннан, юкмы — анысын инде бер Алла гына беләдер. Тик урыс уйлап чыгарган Себер, Акатуй, Нерчинск, Сахалин каторгаларында Алланың катнашы юк икәнен аннан котылып иленә кайта алган сирәк-мирәк кенә тере мөселман бәндәләре бик яхшы беләләр. Шунлыктан иң җайлысы — патша хезмәтендәге һәрвакыт хәмердән кызмача атлы казакка кирәген түлә дә, калган атларыңны теләсәң нәрсә эшләтеп куй.

Хәрби сызыкны узгач, ике төп эш кала. Берсе — хөкүмәт чиновниклары, үрядникләре күзенә урланган атларны күрсәтмәскә. Икенчесе — ничек тә булса ул атларны кыйммәтрәк хакка, тавыш-тынсыз гына сатып акчага әйләндерү...

Әллә кайчандагы, ике йөз еллардан да элегрәк булган ат караклары турындагы истәлекләр халык күңелендә, өзек җеп кисәкләре кебек булып, төрле имеш-мимешләрдә генә сакланып калганнар. Узган гасырдагы казакъ далаларына барып, өере-өере белән ат урлап куып алып китүләрнең истәлекләре, каты җирдә беленер-беленмәс кенә торып калган ат тоякларының эзләре кебек, унар, йөзәр еллар узу белән югала барып, халык күңелендә бик аз гына булып сакланганнар. Тик унтугызынчы елның азагында, аның сиксәненче, туксанынчы елларында булган хәлләр генә маҗаралы истәлекләр булып калган. Чөнки зур осталык белән тормышка ашырылган ат урлаулар, гади халык күзенә, колагына, ат караклары берәр ялгышлык эшләп, хөкүмәт кулына эләксәләр яисә авыл урамнарында кыйналып йөретелсәләр генә күренгәннәр, ишетелгәннәр. Ат каракларының күпчелек «эше» кара халык күзеннән ерак һәм билгесез булып, күренмичәрәк үтә торган булган.

Казакъ далалары урыслар тарафыннан басып алынып, андагы җирле халык диненнән, гореф-гадәтеннән мәхрүм ителә башлагач та, җылкы көтүләреннән атларны өерләре белән куып алып китеп урлаулар барыбер кимемәгән. Бу кәсеп Ырымбур тирәләрендә яшәгән татар, башкортларның беркадәр өлешенең «көн күрү кәсебенә» әверелеп, нәселдән-нәселгә атадан улына күчә торган булып киткән. Ат урлау җир эшкәртү, мал асрау кебек, бер һөнәргә әйләнгән. Революциягә кадәр үк һәм аннан соң да дистә еллар чамасы Идел буйларында ат урлау белән иң атаклы саналган Шәкүр каракка караганда да, Ырымбур якларында ат каракларының аңардан да зәһәррәкләре, остараклары булган. Шуларның берсе — Рәвил исемлесе — тумышы белән үк данлыклы ат карагы Ишморат улы булган. Инде иллегә якынлашып килгән Ишморат бер елны март бураннары басыла башлап, җир өстенә кыш буена буранлап, явып өелгән кар көртләре, язгы кояш астында күгелҗемләнеп, авырая башлаган чакларында, алты иптәше белән казакъ далаларына «ат кәсебенә» чыгып китә. Өстенә кыска каеры тунын киенеп, билен билбавы белән урап-урап буганнан соң, алтынчыга авырлы хатыны — кара-кучкыл битле Гыйльменисага ишектән чыгып китәр алдыннан соңгы сүзләрен әйтә:

— Мин әйткәнне колагыңа киртләп куй. Миңа үзем кебек башкисәр малай тап. Җитте сиңа бертуктаусыз елап-мәлҗеп торган кызлар китерү. Мин кайтканчы бала табып куйсаң, малай булса, исемен Рәвил куш. Әгәр инде тагын кыздан уздыра алмасаң, миннән башкача мәрхәмәт көтмә. Кыз тапсаң, кайту белән яшь бичә алам. Миңа малай кирәк. Үзем кебек ат карагы була торган малай!

Шул чыгып китүеннән Ишморат та, аның алты башкисәр кәсепчеләре дә суга төшкән кебек юкка чыгалар. Тик, елдан артык вакыт узгач кына, Ырымбурда, җәйге ат ярминкәсендә Ишморатның йөгерек, акбүз биясен күрше авыл башкортлары күреп таныганнар. Берничә башкорт җыйналып, бия бәйләнгән җиргә килгәннәр. Тик, биянең яңа хуҗасы, ут күзле, үтә дә елгыр казакъ егете башкортлар күз алдында биясенә сикереп менеп, юкка чыккан. Күп яшәгән, казакълар белән күп аралашкан, аларның гореф-гадәтләрен яхшы үзләштергән һәм ихтирам иткән Сурагол башкорт, Ырымбурдан акбүз бияне күреп кайткан авылдашларына әйткән:

— Казакълар юк иткәннәр Ишморатты. Казакъ егете шуны еткерергә Ырымбурга килгән... эһ-һем, эһһһем, ... ат кәсепләренә. Ишморатыгыззы бетердек дип, хәбәр иткән ул егет. Көтмәгез инде атаклы ат карагы Ишморатты. Беткән аның гаярь башы...

Ире киткәнгә өч ай узар-узмастан, Ишморатның хатыны, дөньяга елый белмәгән бер малайны китерә. Башы кавын кебек булып артка чыккан, озынча ябык кына ул бала биләвендә тавыш-тынсыз гына ята торган малай була. Асты юешләнсә дә, кәҗә бәтиенекенә охшатып «мкерт» дигән аваз гына чыгара, анда да еламый. Тагын дәшмичә ятуын белә. Еллар үтә-үтә, дөньялары хәерчелек белән дус булса да, ул күп сөйләшмәс, тирә-якка һәрчак каш астыннан гына, дәшмичә карап, зур игътибар белән тыңлый белә торган малай булып буй җиткерә ул. Үсә. Үсүе белән үзләренең урамнарында гына түгел, авылларында да «сугыш чукмары» дигән исем ала. Бәләкәйрәк чагында урамда «шаралы», «чебенле», «кәшәкәле» уйнаганда иптәш малайлары аңарга «сугыш чукмары», «кавын баш» дигән кушаматлар бирәләр. Еллар үтә-үтә аның тик «Кавынбаш» дигәне генә торып кала. Чыннан да, аның кырган зур башы, озынчарак кавын кебек, артка чыгып тора. Үскән чагында ук Рәвил башына түбәтәй киеп йөри алмый. Тормый аның башында түгәрәк түбәтәй! Үскән чагында угрылык ягыннан ул-бу сизелми. Унбиш яше тулып үткәч, уналты яше якынлашып килгәндә, февраль бураннары котырган бер төнне аларга чуен кебек кара, камыт аяклы, олпат гәүдәле бер башкорт кереп куна. Кичләтеп кенә исәнлек-иминлек теләп өйгә керә дә, чыгып чаналы атын тугарып, абзар эченә кертеп, солы печәнен салгач, Гыйльменисага бер бөтен зур сарык түшкәсен тоттыра.

— Арт санын пешер әле, сылу. Мин ятып торыйм, бик алҗыдым. Ит пешкәч уятырсың мине...— ди.

Пешкән сарыкның бер арт санын китереп табынга куйгач, башкорт ит ашап, бер самавыр чәй эчеп бетереп, зур толыбына төренә дә, идән уртасына ятып йоклый.

Иртән торып, әпен-төпен дога укыгандай итә дә кара башкорт, чәй эчәргә утыра. Утырган уңайга ук сырган чалбарының төпсез кесәсеннән чалгы пәкесен чыгара. Пәкенең сабы чаганнан булып, башы җиз белән уратылып алынган була. Пәкене башкорт хуҗа хатынына суза:

— Мә, һылу! Ошоның менән туракла әпәкәйзе...

Нужа басудан, күп һәм авыр эштән ватылып картайган хатын башкорт сузган пәкене күргәч, өнсез кала. Көч-хәл белән авызын ачып телгә килә:

— Бу бит...

— Шаулама, һылу, шаулама! Һуңгы тапкыр кәсепкә киткәндә иң якын дустым биреп киткәйне. Ходай насыйп итмәне башкаса күрешергә. Урыны оҗмахта булһын. Минем үземдең кайтканга ел гына тулды әле.

Менә кергәйнем һиңә, дустымдың кеме бар икән тием. Аллага шөкер, малай икән. Тик Ишморат кына күрә алманы...

Аны тыңлаган саен нужадан картайган хатынның тыны кысыла бара:

— Йу-ук, агай! Йу-ук! Рөхсәтем юк! Улымны бирмим. Яңа гына авыр эшне кулымнан алып, кул арасына керә башлады. Бирми-им!..

— Атаһы малае ла ул! Ысын ир-егет булган кеше, хатыннар һүзе менән йөремәясәк беркайсан да.

Барлык сөйләшүне тавыш-тынсыз зур дикъкать белән тыңлап утырган Рәвилгә генә мөрәҗәгать итеп, Морзагыл башкорт әйтә:

— Әйдә, кустым, мине озата бар азрак. Авыл осына кадәр. Атаең әйтеп калдырган васиятте һиңә еткерер вакыт етте...

Акшарланган мичкә аркасы белән сөялеп, яулык очы белән күз яшьләрен сөртә-сөртә елаган әнисенә карамаска тырышып, Рәвил Морзагыл башкортның толыбын күтәреп, аңарга ияреп чыгып китте. Алар чыкканда урамда каты буран иде. Әйтерсең лә Ходай Тәгалә буран чыгарып, Рәвилнең начар юлга баса башлаганын аның үзенә искәртеп, тыярга тырыша иде...

Карлар эреп бетеп, котырып аккан кар сулары ерак диңгезне эзләп агып киттеләр. Юллары төшеп, тирә-як табигать яшелләнә башлаган бер көнне ат карагы улы Рәвил авылдан башын алып чыгып китеп, юк булды. Авылларыннан унҗиде чакрымдагы Болаштан урыс куписы Роман картның абзарыннан нәсел айгыры юкка чыкты шул төнне. Дон ягыннан кайтартылган ул пләмә айгыры барлык тирә-якка данлыклы иде. Биләрен каплатырга алып килгән өчен ярыйсы гына хак түләтеп Роман купис үзенә файда ясый иде. Йозагы белән бикле булган ат абзары эчендә айгырның юкка чыкканын иртән күргәч, тирә-ягында койрыкларын болгап йөргән өч этен дә астырып, төнге каравылчысын куып чыгарган Роман. Ырымбур, Эстәрлетамак, Уфа үрәдникләрен, аларның хуҗаларын күпме генә сыйлап та, акчалата биреп караса да, айгыр табылмады, юкка чыкты...

Егет булып җитешеп кенә килгән Рәвил Морзагыл башкортның атлар урлап кәсеп иткән шайкасына барып керә. Ун ел тулар-тулмастан шайка атаманы, атасының җан дусты Кара Морзагыл еракта, казакъларның Тургай далалары дип йөртелгән якларда, ат куганда, җирле халык белән сугышып, һәлак була. Илле яшендә. Үзеннән дә зуррак гәүдәле, башына зур малахай бүрек кигән, билгә кадәр ялангач казакъ егете җитә аның башына. Олы күсәк белән сугудан башы урталай ярылып, чукмарлар белән сугышканнарның ат тояклары астына, кылган каплаган эссе җир өстенә тәгәрәп барып төшә Морзагыл башкорт. Казакълар белән сугышып, канга баткан Рәвил зур күсәге ярдәмендә сугышкан халык арасыннан Морзагылның үле гәүдәсе янына ыргыла. Атыннан төшмичә генә Морзагылның биш потлы авыр гәүдәсен җирдән күтәреп алып ияренә аркылы сала да, үзе уратып алган дүрт иптәше сагында, урланган атлар өерен ташлап, якындагы ерым эчендәге тар сукмакка ташлана.

Морзагылны җирләгәч, чаган саплы, зур, үткен пәке Рәвил кулына күчә. Шул көннән башлап Рәвил ат караклары шайкасының атаманы булып китә. Яшь дип тормыйлар, үлем белән бик еш очрашып, зур тәвәккәллек күрсәтеп кәсеп иткән, ат караклары аны бер каршылыксыз үзләренең атаманнары итеп таныйлар...

Яшь атаман ул җәйне, ат урлауны туктатып, ике зур оештыру эше үткәрә.

Ырымбур каласыннан көньякта ике йөз чакрымнан да арырак урнашкан күпчелеге татарлар яшәгән Тоз Күбә диган авыл тирәсеннән алып, урыс крепосте Ырымбурны уңда калдырып, Шарлык, Эстәрлебаш, Бояр урманы аша башкорт йомагуҗасына чыгып, аннан соң Кыргыз Миякә Бикколын, башкорт Каранын сулда, Шыңгак Күлне уңда калдырып, Самар ягына юл тоткан сукмак сала ул. Рәвил карак Совет хөкүмәтен

Ленин китереп чыгарып, Сталин аны нығытып куйганчы ук атаклы булган Ат Караклары Сукмагын салган. Ул Сукмак Урал тавының казакъ далаларына кереп таралып, Уфа яныннан үтеп, Урал тавының Урта Сырты буйлап килеп, Башкортстан аша узып, кискен борылыш ясап, Самар каласы янына кадәр барып җиткән. Сукмакның иң нык үзенчәлеге—ул бер генә елганы да кисеп чыкмаган һәм елның нинди генә вакыты булуга да карамастан, сыбайлы кеше шул сукмак буйлап үтә ала торган булган. Ат Караклары Сукмагы күбесенчә Урал тавының Урта Сырты аша узган. Сырт итәгендә чыгып яткан чишмәләр ике яклы—йә Җаек елгасы ягына, яисә Агыйделгә карап акканнар. Сукмак даладан башланып китеп, таш-кыялы, урман сулы таулар аша үтеп, зур юллардан читтә, бер генә авылга да кермичә ат каракларының ышанычлы йөри торган сукмагына әверелгән. Бу сукмак буйлап казакъ ягында урланган атлар өере зур тизлек белән куылганнар. Казакъ далаларын узып, Ырымбур артта калганчы туктау, ял итү булмаган. Арыган атларын яңага алмаштырып, җайдак менеп, ат караклары көнне-төнне белмәстән урланган атларны куганнар да куганнар. Арып егылганнары, Сукмактан алып ташланып, атлары өеренә күренмичә артларыннан ияргән бүре көтүенә азык булып калган.

Сукмакны җайга салган җәйне Рәвил иң ышанычлы дүрт егете белән даладан Самарга кадәр, аннан кире якка ике мәртәбә узган. Өченче мәртәбә даладан юл башлаганда иярләнгән, яңа гына өч яше тулып узган, Кара Кашка биясен иярдән азат иткән. Кара бия йөгереклеге өстенә хуҗасының аңардан нәрсә теләгәнен яхшы аңлаган бик тә акыллы хайван булган. Сукмак башланган җирдә, маңгаенда ак йолдызы булган Кара биясенең Рәвил иркәләп тамак астын кашыган да, дустына дәшкән кебек иркәләп әйткән:

— Сукмактан киттек, Кара биякәй. Өйгә кайту ягына!

Иркәләп, шапылдатып арт ягына суккан Рәвил Кара биясенең. Алмаштырган атына атланган да, тирә-яктагы далага шом салырдай иттереп ачы сызгыру белән һаваны ярып җибәргән. Кара бия хуҗасының теләген аңлап, үзе ике мәртәбә, дала ягыннан Самарга узган, әле яңа гына барлыкка килә башлаган Ат Караклары Сукмагы белән элдереп чыгып чапкан. Рәвил иптәшләре белән Кара биягә ияргән. Һәм бер генә урында да аның алдына чыкмаган. Сукмактан Самарга хәтле Рәвилне һәм аның дусларын ияртеп алып кайткан, Кара Кашка.

Самар ягына кайтып җиткәч, Ярулла дигән иптәше сораган Рәвилдән:

— Нәрсә дип таптыйбыз инде бу Сукмакны без җәй буена? Мин аңлап бетерә алмыйм бит әле, Рәвил.

— Кабаланма инде. Аңларсың озакламыйчарак. Аңларсың.

— Кайчан инде ул, озакламыйчак, дигәнең?

Кулындагы камчысы белән, акрын гына иттереп Рәвил Ярулланың күлмәкчән аркасына шаяртып суккан:

— Безнең кәсеп белән йөрегән егетләр, артык сорау бирергә тиеш түгелләр миңа. Ул безгә нәзер булып килә. Мин уйлап чыгарган нәстә түгел. Атаманның әйткәнен генә тыңлап эш итәргә өйрәнергә кирәк. Сорау бирү урынсыз. Аңладыңмы?

— Соң бит, беләсе килә.

— Вакыты җиткәч белерсең. Ә инде вакытыннан алда беләсе килгәннең башы икәү булырга тиеш...

Көлә белмәгән күзләре белән Ярулланың күзләренә карап бетереп куя:

— ...минеке кебек...

Шул сөйләшүдән соң ай үтәр үтмәстән Ярулла барысын да аңлый. Аңлау гына түгел, Рәвилнең чынлап та «Ике башлы» икәненә ныклап ышана.

Август азакларында, шул ук ышанычлы дүрт иптәшен алып, Яруллаlarны бишенче итеп өстәп, Рәвил казакъ далаларына чыып китә. Аның бу чыгуы Кара биянең «ат караклары кәсебенә яраганлыгын» тикшерү була. Иркен далада дүрт казакъ карамагында йөргән зур җылкы көтүен эзләп табалар алар. Көтүчеләр күзенә чалынмыйча гына көнозын аларның кайда, ничек иттереп атларны көткәннәрен өйрәнәләр. Куаклар белән капланган бер чокырдан. Караңгы төшеп, күз бәйләнгәч, Рәвил бер иптәше белән ат көтүе төн кунган җиргә китә. Атка менгән килеш, муенына аркан салган Кара бияне үзе белән җитәкләп алып китә. Ат көтүе ягына җайлап кына, атларны атлатып кына баралар. Барып җитәргә әле байтак ара булса да, көтүчеләрнең этләре боларны сизеп өрә башлаган көйгә үк, Кара Кашка биянең муеныннан арканны чишеп алып, Рәвил аның арт ягына камчысы белән акрын гына суга. Кара бия үзенең беренче «эшен» башлаганын белгәндәй урыныннан кузгалып ат көтүенә карап атлап китә дә берничә адым узгач, кешнәп юыртуга күчә.

— Ходайга тапшырдык! — ди Рәвил. Һәм атын борып, акрын гына атлатып караңгылыкка кереп югала.

Казакъларның ат көтүеннән еракта, агачлар белән капланган тирән чокыр эчендә ике көн, ике төн яшиләр «ат кәсепчеләре». Шул вакыт узгач, өченче көннең таңы атып яктыра башлаганда Рәвил ике иптәше белән куе кылган арасында ята. Ат көтүен әйдәп ярты чакрым ерактанрак узган көтүчеләргә күренмичә генә алар, дөбердәп чапкан атларны барлап карыйлар. Кысык күзле башкорт Байгужа дәшми генә камчы сабы белән Рәвилнең кабыргасына төртә. Рәвил аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңлаганын белдереп, кыска гына иттереп башын кагып куя. Алар икесе дә Кара бияне күреп алалар. Күрмәслек тә түгел шул. Кара бия ял-коерыкларын җелфердәтеп көтүнең иң алдыннан бара. Ә аның янында көтү башлыгы, кара яллы, кара койрыклы кызыл айгыр җилдертә. Ераклаша барган ат көтүен зур канәгатьлелек белән карап озата да Рәвил, куанычын яшереп тормыйча, янында яткан Байгужага пышылдый:

— Була бу, болай булгач, башкорт дус! Үзем дә оста икәнмен, әй!

— Шәп, Рәвил, шәп! — дип агач мөһерне сугып куя башкорт дусты.

Кайтуларына чокыр төбендә яккан учакта күп иттереп чиләктә ит пешерелгән. Төтене аз булсын өчен коры карама агачлардан гына яндырылган учак тирәләп утырган дусларына Рәвил үзенең уйлап чыгарган ат урлауның яңа ысулын сөйли:

— Без, моңарчы, ат көтүенә бәреп, көтүчеләр белән сугышып, яисә аларны йоклаган җирләрендә бәйләп, яисә үтереп, атларының бер өлешен көтүдән аерып алып, куып алып китә торган идек. Бик зур тәвәккәллек һәм курыкмыйча эш итәргә кирәк андый чакта. Бүген мин уйлаган хәйлә барып чыкса, бүген төнлә безнең эш җиңеләячәк...

Дәшми генә тыңлап утырган иптәшләрен күздән кичерә үзе. Барысы да утыз белән кырык арасындагы башкисәрләр. Рәвил артыннан, аңарга тулысынча ышанып, буйсынып утка да, суга да керә торган егетләр. Байгужа белән Сынтимер — башкорт егетләре. Бу икәүгә менергә ат, гыжылдатырга курай белән эчәргә кымыз булса, башка бернәрсә кирәк түгел. Башкортларга хас булган бик яхшы сыйфатлары бар — комсыз түгелләр. Аннан соң кешенеке күпме булса да аларның күзе кешенекенә кызып бармый. Ат урлауны алар, иң беренче чиратта, егетлек иттереп карыйлар. Агале-энеле Ибрай белән Биктимер — татар егетләре. Икесе дә — Кара Морзагылдан Рәвилгә калган «ат урлау белгечләре». Үзара да сирәк сөйләшә торган бик тә ышанычлы, тугрылыклы егетләр Рәвил өчен. Инде бишенчесе — Ярулла. Бик зур авырлык белән өйрәнеп килә «ат кәсебенә». Телен тыюы бик авыр аңарга. Күрәсең, нәселдән килә торган холыктыр инде ул — тел тыя белмәгәнлек, дип уйлап та куя Рәвил. Шул җитешсезлеге янында Ярулланың бик тә зур тәвәккәллеге дә бар. Бер генә очракта да югалып калмый. Рәвил кыска гына итеп аларны бу төндә нәрсә көткәнне аңлатты.

— Ярты төн җиткәч, ат көтүен кузгатып, бер урында уратып, түгәрәктә куып чаптырып кыздырабыз. Ныклап акырыгыз, камчылагыз. Инде атлар кызып, чабуга күчкәч, мин сызгырып җибәрермен. Кара бия кайту ягына чыгып ычкыначак. Көтү айгыры — Кара бия артыннан, Айгыр артыннан барлык көтү чабачак. Безнең төп эш, чапкан көтүдән үзебезгә җитәрлек атларны бүлеп алу. Миннән калмаска. Аерып алганны зур тизлек белән куарга. Кем куа алып киткәннәрне?

Ибрай энесен карап алды:

— Без икәүдер инде.

— Яхшы! — диде Рәвил. Калган өчегез минем янда, көтүчеләр белән сугышырга кала. Елмайгандай иттереп бите азрак кыйшайды:

— Мин уйлаган барып чыкса, арттан куалау кирәк тә булмас. Кара бияга ияргән көтү башлыгы айгыр алып китәчәк безнең табышны.

Хәзер бик нык иттереп ашагыз, алып килгән кымызны эчегез. Учакны җир белән күмеп сүндерегез. Сусыз сүндерегез. Су сибәргә кирәкмәгәнне беләсез инде. — Чажгылдап төтене чыга. Барыгыз да йокларга ятыгыз. Йокларга ятыр алдыннан атларыгызны эчерегез. Торгач бу туктаган урынны тәртипкә китерәбез, эзләрне югалтабыз да, Аллага тапшырып тотынырбыз...

Шул төннән алып, Ат Караклары Сукмагы эшли башлаган.

Кара бия төнен ат көтүенә килеп кергәч, казакъ көтүчеләре аны тотарга маташып карадылар. Тик Кара Кашка бия тоттырмады. Корык тоткан көтүче күпме генә якынлашырга тырышса да, Кара Кашка аны якын да җибәрмәде. Аркан ыргытып, аны Кара Кашканың муенына салырга булышканын да уңышсызлык каршы алды. Аркан һавада очкан арада, бия чапкан юнәлешен кискен үзгәртеп, тизлеген арттырды гына. Аркан һавада ысылдап очып, кылганнар өстенә барып төште. Бия тоттырмады. Аның елгырлыгына казакълар тел шартлатып карап тордылар.

— Ярар, йөреп торсын. Берничә көн йөреп өйрәнгәч, тотарбыз да карарбыз тамгаларын. Бик асылга охшаган хайванкай, — диде көтүчеләрнең иң өлкәне.

Кызыл айгыр исә яңа бияга барысына караганда да ныграк куанды бугай. Көтүдә булган барлык бияләрне ташлап, тик яңа бия янында гына бөтерелде. Тик бия аны бик үк үз итеп, якын җибәрмәде. Шулай ук тибенеп, тешләшеп, айгырның күңелен дә кайтармады. Биянең дә табигате егетләр сайлап, үзенә кирәген, ошаганын барлап, яныннан бик үк ерак җибәрмәгән вә һәм дә сайлануын һаман дәвам иткән җилбәзәк кыз кебегрәк иде, ахрысы. Айгыр үзенең гайрәтен дә, теләген дә яшермичә Кара Кашканы үзенеке итәргә ашкынды һәм шуны гына теләп биядән бер тотам да калышмыйча, көтүне каравын яртылаш онытып йөри башлады. Дәрте артканнан-артты Кызыл айгырның...

Төнлә белән җидәүләшеп акырып-бакырып елкы көтүен уралтып-уралтып чаптырып кыздыралар. Ырымбур ягыннан килгән ат каракларының тәвәккәллеге, кискенлеге, башсызлыгы хакында күп ишеткән казакълар аптыраганнарына курыкканнарын да кушып, ярдәм сорап сөрән сала-сала тирмәләренә сыпырталар. Атлар көтүе кызып, бер йомгак булып әйләнеп бер урында уралып кыза башлагач, Рәвил өзәнгеләренә баса биреп, казакъ даласына шом салып, бик тә көчле һәм әче иттереп сызгырып җибәрә. Шуны гына көткән Кара Кашка атлар өереннән аерылып килеп чыга да, зур тизлек белән чабып кайту ягына аткан уктай атыла. Елгыр биядән бер тотам калмыйча ияреп Кызыл айгыр да томырылып чаба башлый. Ат көтүе исә үзенең башлыгы булган Кызыл айгыр артыннан агыла...

Тәүлеккә якын туктамастан көтүдән аерып алган ат өерен дала буйлап килгән сукмак белән куалар кәсепчеләр. Куудан бигрәк, атларны Кара Кашка алып бара. Атлар артыннан ияргән Ибрай белән Биктимергә атларны әйдәп куарга эш тә калмый. Ике йөзгә якын елкы малы Кара

Кашка белән Кызыл айгыр артыннан чаба да чаба. Чапкан ат өереннән кырык-илле чакрымга артта калып, утызлап атны кугандай итеп, Рәвил белән бергә тагын өч иптәше баралар. Болары инде, казакълар артларыннан куа чыгып, куып җитә башласалар, урланган атларны ташлап качырга тиешләр. Ат хуҗалары куып җитеп караклар ташлап качкан атларын кире алып кайтып китәргә тиешләр.

Тик бу юлы аларны куып җитүче булмады...

Ырымбур-Самар сызыгын үткәч, Шарлыкка җитәрәк ике төркем бергә кушылды. Рәвил уйлап чыгарган «яңа ат урлау ысулы» ныклы булып тормышка ашты һәм әлеге ысулга «Кара кашка» дип исем дә бирелде...

Сигез көн узуга, атлар өере Самардан Идел буйлап су агышында, егерме чакрымнар тирәсе урнашкан урман аланында иде. Язын башланган ярминкәләр Чита якларына килеп җитә язган иде. Шунлыктан урланган атларны сату бик җиңелдән булмады. Тик Рәвил бу очракта да оештыра белү сәләтен күрсәтте. Ике көн иптәшләре яныннан юк булып торды да, сул колагына алтын алка таккан бер Дон казагын ияртеп кайтты. Казак алан тутырып йөргән, моңарчы ияр, камыт күрмәгән атларны күргәч, шатлыгыннан көлеп җибәрде. Түзмәде, сорады:

— Бу атлар кай тарафтан килеп чыктылар бу якларга?

— Алтай якларыннан,— диде Рәвил күзен дә йоммыйча.— Ике ай буена кудык. Ял иттерә-иттерә.

— Ял иткәннәре шикле инде. Бик зур юлны, зур тизлек белән үткәннәре күренеп тора. Ну, ярар, Алтай да булсын ди инде... Дон казагы шәп ат белгече булып чыкты.

— Оптом алам, хакына килешсәк,— диде ул күзләрен Кара Кашкадан ала алмыйча.— Ә бу бияне аерым сатып алам. Хакында тормам.

— Юк, знакум, бу бия сата торган мал түгел. Үземнеке.

— Кызганыч,— диде казак.

Рәвил сатулашып тормады, казак әйткән хакка атларны өере белән сатып та җибәрде. Иптәшләре арасыннан да нигә арзан диюче булмады. Чөнки житеп килгән көзгә карата урланган атларны сатып акчага әйләндерү ифрат та авыр булачагын барысы да аңлыйлар һәм шунлыктан атларның азрак арзанга булса да сатылуы белән килештеләр.

Сөйләшенгән буенча өч көн үткәч, атларны Идел яры буйлап илле чакрым су агышы белән куалап төшереп, алкалы казак кул астындагы хәрәкәт итүче Дон казакларына тапшырдылар. Атлар арзаннан китсәләр дә, саннары байтак булганнан акча да шактый тиде һәрберсенә. Бар да канәгать калып, куеннарына төргәге белән акча тутырып, Уфага кадәр бергә юл тоттылар. Уфадан соң һәркайсы, яз җитә башлау белән Рәвилдән киләчәк хәбәрне көтеп ятарга дип, үз авылларына таралыштылар...

Шул елдан соң ат урлаулар яңа ысулга күчте. Март бураннарында Рәвил шайкасы полиция-урядниклар күзеннән ерактагы тау арасындагы кечкенә авылга җыйнала. Кара Кашканы чанага тагып Рәвил килеп җитә. Барасы иптәшләре җыйналып беткәч, атларны тоткан сарайда тиз генә киңәшләшеп алалар да, парларга бүленеп, Ырымбур ягына юл тоталар. Җыелу урыны итеп Тозлы Күбәне сайлыйлар. Анда аларның бик яхшы абзалары — Чатан Таҗетдин бар. Җыйналып куна ятканнары да андыймондый шик тудырмый. Чөнки, чатан булса да, ике хатынлы, шулардан унике бала таптырган абзалары юлчылар куныш чыга торган зур аерым йорт тота. Кышкы буранлы юллардан туңып килеп кергән утыз олауны сыйдыра торган бик тә зур лапас кебегрәк эшләнгән абзары да бар. Йорт ышанычлы. Таҗетдин абзый яшәгән, ул тоткан юлчылар куна торган йорт-курада бервакытта да,бернәрсә дә югалганы, юлчыларга бәла-каза килгәне юк.

Май урталарында Самар каласында бик зур ярминкә була. Һәм шул ярминкәдә атларны берәмләп тә, унарлап та саталар. Әгәр инде патшага кирәк булса, Дон казаклары үзләренә дигән булып, атларны йөзәрләп тә алалар. Тик хәрби хезмәткә түзәрлек таза булсын да, яшерен чире,

житешмәгән җире булмасын. Шул Самар каласыннан башланган ярминкә бер каладан икенчесенә күченә-күчэнә август урталарына Байкал күленең теге ягындагы бүрәтләрнең Улан-Үде дигән калаларына барып җитә. Май урталарына Рәвил икенче елны йөз илледән артыграк атны куып алып кайта казакъ ягыннан. Алып кайта кайтуын, тик ике башкортның берсен далада бөтенләйгә калдырып китә. Ул егет Байгуҗа иде. Һай-һулап атлар өергәндә чапкан аты, йомран өненә басып, аягын кырт сындыра. Атының башы аркылы барып очкан Байгуҗа тупырдап чапкан күпсанлы ат тояклары астына эләгә дә, берничә секунд эчендә тапталып, ит белән сөякләр аралашкан, туфракка буталган кәлҗемәгә әйләнә. Тик аны карап торырга ат каракларының вакыты да булмый. Байгуҗаның якын дусты, камчылы уң кулы белән бит янындагы һаваны селтәп «Аллаһы әкбәр!» дип әйтеп кенә өлгерә. Бу инде аның дусты Байгуҗага чыккан соңгы ясины була.

Атларны алар Самар ярминкәсе ачылырга бер атна кала куып алып килделәр. Ярминкә ачылу белән атларны сатып акчага әйләндерү башланды. Ярминкә нихәтле генә зур һәм шәп булмасын, куып алып кайткан атларны бер Самар ярминкәсендә генә сатып бетереп булмый. Арзан хакка сатасы килми, тиешле бәясе өчен сатулаша башласаң, бердән, вакыт үтә, икенчедән, хөкүмәт сагында торганнарның күзенә чалынуың бар. Шунлыктан инде, Идел ярында утырган Самардан алып, Урал тауларының теге ягында утырган Шадринск каласына кадәр атларны, бер ярминкәдән икенчесенә куу башлана. Ул куу август башларына кадәр дәвам итеп, кәсепчеләргә табышны икеләтә арттыра. Вә ләкин атларны сатышырга тагын яңа кешеләр дә кушыла һәм аларга да өлеш чыгарырга туры килә. Тик шулай да атларны ярминкәдән ярминкәгә йөретеп сату ике яктан файдалы. Беренчедән, атларга хөкүмәт кешеләренең күзе төшеп өлгерми, чөнки аларның бер ярминкәгә кергән баш саннары аз була. Икенчедән, ваклап саткач, шул ярминкә тирәсендәге авылларда яшәгән, базар хәйләләрен белгән берничә кешегә ат сатарга кушсаң — бәясе дә ярыйсы гына килеп чыга.

Казанны урыслар яулап алганнан соң, аның атаклы Олы Базарын Нижний Новгородка күчереп Макарьево монастыре янында оештырганнар. Татарлар телендә Мәкәрҗә ярминкәсе дип аталып, Казанда булган Олы Базар дәрәҗәсенә җитә алмаса да, ул ярминкә дә бик зурлардан саналып йөри башлаган. Ел да язның соңгы аенда, җәй башында гөрләп уза торган шул Мәкәрҗә ярминкәсе ябылганнан соң, Казан, Сембер, Самар ярминкәләре узган. Аннан соң инде ярминкәләр Көнчыгышка табан күчәнә башлаганнар. Бөгелмә, Бәләбәй, Уфа, Эстәрлетамак, Ырынбур, Чиләбе, Екатеринбург, Курган, Шадринск — бар да ярминкәле калалар булганнар. Шул бер каладан икенчесенә күчеп барган ярминкәләргә ияреп ат караклары да, сату исәбе белән, урланган атларын куганнар. Шул ярминкәләргә ияреп, атлар күчерү өчен Рәвил карак тагын бер сукмак, монысы инде ботаклы имән агачы кебек тармаклы-тармаклы «Ярминкә сукмагы» салдырган. Шул тармаклы сукмаклардан күп төрле авылларда яшәгән Рәвилнең танышлары урланган атларны үзләренең авылларына алып кайтканнар. Моны эшләү болайрак башкарылган. Егерме-утыз баш ат, алдан сөйләшенгән көнгә, алдан билгеләнгән берәр урынга куып китерелгән. Шунда килеп алганнар Рәвилнең танышлары атларны. Һәм тиешле сатулашу белән сатканнан соң, Рәвилгә акчалата кайтарып биргәннәр. Саткан хакның уннан тугызы Рәвил каракка, уннан бере атны сатучыга. Ике як та бик риза моңа. Ат караклары сукмагы Кара Кашка ярдәмендә «эшли» башлаганнан соң, Рәвилнең зур осталыгы белән салынган «Ярминкә сукмагы» ат каракларына күп файда китергән. Тик, Ат Караклары Сукмагы, авыл, калаларны читләтеп, урап үтсә, Ярминкә сукмагы бормалы-бормалы булып бер авылдан икенче авылга сузылган. Таныш-белешләрдә тукталып, арыган атларны ял иттереп алырга мөмкинчелек биргән Ярминкә сукмагы. Башкортстан җирендә

утырган ярминкәле барлык авылларга килеп тортелә Ярминкә сукмагы. Дәүләкән, Дүртөйле, Кыргыз-Миякә, Чишмә, Кырмыскалы, Эстәрлебаш, Эстәрлетамак, Әкчүн, Шафран, Мәләүз, Тәтер Арслан — боларның барысына да Ярминкә сукмагы килеп керә. Килеп керә һәм Рәвил карак шайкасына ат сатканнан килгән табышны бик нык арттыра. Ярминкә Сукмагын уйлап чыгарып, аны салып хәрәкәт иттерә башлаудан да, атларны шуның ярдәмендә тиешле бәясенә сатуны оештыруда да Рәвил зур сәләт күрсәтеп, тиккә генә бала чактан алган «кушбаш» кушаматын йөретмәгәнен яхшы иттереп исбатлый. Шул Ярминкә сукмагының бер тармагы булган авылда, кимендә, аның бер ат караучысы һәм бер сатучысы була. Кайвакытта әлеге ике вазифаны бер генә кеше башкарган чаклар да булгалый. Анысы инде кешенең зиһененә, елгырлыгына карап була. Ул кешеләр Рәвилнең шайкасына кереп эш итсәләр дә, аңарга ияреп Казакъ далаларына ат урларга йөремиләр. Аларның эше — китергән атларны саклау һәм сату. Берничә ел буена салынып ат сату өчен эшләнгән Ярминкә Сукмагын Рәвил үзе һәлак булганчы да, Гражданнар сугышы үтеп, хөкүмәткә кеше башларын миллионлап өзеп ыргытудан да тартынмый торган мөртәтләр килеп утыргач та, ат караклары «бетеп», юллар тынып калгач та әле ат караклары белән бәйләнеше булган кешеләрдән башка белүче җаннар булмаган. Казакъ далаларына бармыйча гына да шайкага катнашы булганнарны Рәвил карак телләрен нык тыярга яхшы иттереп өйрәтә белгән:

— Телең озын булса, башың белән бергә кисәрмен. Әгәр инде чак кына озын кебегрәк булса, андый телнең дә нәрсәгә китергәнен беләсең, күрәсең килсә, Самарның зур базарында хәер сорашып көн күргән сыңар куллы Ярулладан сорагыз. Ул әйтер сиңа ни өчен кан йөткергәнен дә, ни өчен башын күтәрмичә кәкерәеп утырганын да. Яныннан хәер бирмичә үтмәгез — Ходай бәндәсе ул...

Яруллланы ат караклары барысы да беләләр. Белүен беләләр, тик якыннан аралашмыйлар. Ярулла белән күбесенчә Рәвил үзе генә аралаша, сөйләшә. Рәвил өчен Ярулла — Самардагы колак белән күз. Башка ат караклары белән Ярулла сөйләшми дә. Исәнме, исән! Бетте шуның белән. Күпчелек аның бу гадәтен Рәвилдән куркуы дип аңлый. Ат каракларының уйлавынча, тиктормас теле аркасында Ярулланың Рәвил алдында нинди-дер гаебе булган булырга охшаган. Рәвилне күрү белән Ярулла, аңарга ярарга тырышуын йөзенә чыгара да, ул гына иштерлек иттереп, зур авызын аның колагы янына якын китереп, Самар яңалыклары белән бергә, тик Рәвил генә белергә тиешле серләрне дә акрын гына тавыш белән сөйләп бирә. Шул Ярулла хәбәрләреннән соң Рәвил, башкача беркем белән сөйләшмәсә дә, Самар яңалыкларын, ат бәяләрен, Ярминкә сукмагының хәлләрен — барысын да белә. Кайсы чакларда, Ярулла белән сөйләшкәннән соң, Самарда да, башка урыннарда да ат сатуны туктата Рәвил. Шайкасын каладан чыгарып җибәреп, полиция, жандармнар күзеннән яшеренеп куя. Берничә көн үткәч, ярминкәне уратып алган мылтыклы солдатларның ничә икәнен санап, кылыч таккан урядникләрен барлап, эт кебек иснәнеп йөрегән филерларны исләрендә калдырып, баш-төс үзгәртеп ярминкәдә йөри Рәвил. Күзәтә, тыңлый, исендә калдыра, уйлана, төрле планнар кора «ике башы» белән. Ә полицейскийләр ат каракларын, аларның саткан атларын эзләп, ярминкәнең астын өскә китереп тикшереп йөриләр, тентиләр, иснәнәләр, актаралар. Буш китәселәре килми бит инде, документлары бик үк дөрес булмаган, яисә бөтенләй документсыз берничә атны алып чыгып китәләр ярминкәдән. Тик ул атлар арасында Рәвил карак шайкасы китергән атларның берсе дә булмый. Чөнки ярминкәдәге бүген булачак хәлне, полиция бүлекчәсендә эшләгән, Рәвил тарафыннан яхшы иттереп түләнгән кешеләр аңарга хәбәр итеп өлгергәннәр инде. Атларны кайсы ярминкәдә, кайвакытта чыгарып сатарга тик Рәвил үзе генә белә һәм беркайчан да ялгышмый. Атларны сатарга карар кылгач, ул читтә калмыйча алу-сатуның уртасында, ярминкә шавында була.

Ат каραклары Сукмагы Кара Кашка белән бергә яхшы табыш китерә башлый. Сукмак эшли башлап берничә ел узгач, зур өер атларны Самар ярминкәсенә куып алып килгәннәр алар. Тик юллары хәвефле, авыр булган бу юлы. Казакъ далаларында кул сугышында ике иптәшләре һәлак булган. Атларны куып алып кайтып Самар ярминкәсенә куарга әзерлек барган чакта, Рәвил эшне туктатып, атларны сатарга чыгармаска була. Ул көннәр буена кала трактирларында гомерен уздыра, җыен килде-китте кешеләр белән тел чарлый, юкны эзләп йөрегәндәй кылана. Зур акчага өмет итеп айдан артык ярдән юньләп төшмәгән ат караклары арасында Рәвилнең кала буйлап «эт эчереп» йөргәненнән ризасызлык туа башлый. «Үзе генә тота акчаны, ә безгә юк!» Тик атаманнарының кискен тәвәккәл холкын белгән каракларның күпчелеге ризасызлыгын тышка чыгармый, атаманга сиздерми. Шулай да, Рәвил белән байтак еллар «кәсептә» йөргән, утны-суны кичкән Дим буе башкорты берничә иптәшләре белән сөйләшеп сүз куешканнан соң, атаманга каршы баш күтәрә.

— Җилкәбездә күп татыдык без, сине Кушбаш. Җитте сиңа! Безнең өлешкә тиешле малкайларны бүлеп бир дә, без — үзебезгә, син — үзеңә! Вәссәлам шуның белән! Геләннәр син дигәнчә генә булмасын әле — без дә ир-егетләрнең төшеп калганнарыннан түгел. Безнеңчә дә булсын!

— Ялгышасың, Чынтимер дус!.. — ди Рәвил.

— Син ялгышасың куркып. Нәрсәдән куркасың син?! Ярминкә гөрләп сату итә, атларга арыслан хакы бирәләр бит. Болай булганы юк иде бер елны да. Ярминкә сүнә башлагач, аннан тагын ярты хакка сатаргамы безгә? Без башларны куя-куя, җаннарны казакъ далаларыннан әллә кайта, әллә юк дип алып барып тапкан маллар бит алар...

Рәвил, яшел күзләрен куе керфекләре астына яшергәләп, бер Чынтимергә, бер аның артында башын иебрәк басып торган Камчы Зарифуллага караштыргалап, икесен дә тагын үгетләп карый:

— Егетләр, тынычланыгыз, туктагыз! Сез бит акны карадан аера белмичә боталанган сарык бәрәннәре түгелсез. Атлар белән дә, ярминкәдә дә нәрсә эшләргә кирәклекне үзем генә беләм. Хәзергә безнең атлар өчен ярминкә ябык, аңлагыз шуны. Берничә көн көтик. Инде алай да барып чыкмаса, атларны куабыз кирегә, Уфа ягына...

Тик Чынтимер Рәвилнең сөйләвен тыңлаудан узган иде инде.

— Син, Кушбаш, татарлыгыңа аркаланып үзсүзләнәсең. Яхшылык белән бир безнең өлешне. Иртәгә без аларны ярминкәдә сатабыз да, кызыл утка[1] керәбез. Шәп марҗалар янына. Җитте синең сүз белән генә йөрү. Мин әйтәм бу сүзләрне, Ысынтимер дигән башкорт...

Рәвил исә Зарифуллага карап сорый:

— Синең уйлар ничегрәк, Камчы абзый?

— Мин Чынтимер белән.

— Ала-ай!

Азрак сүзсез генә, камчысы белән итек балтырына суккалап уйланып тора да Рәвил, артында басып торган биш иптәшләреннән сорый:

— Сез нәрсә дисез инде, егетләр?

Барысы өчен дә Чыгыр Бәхетгәрәй җавап бирә:

— Син ничек, без шулай, Рәвил. Алам дигәннең, авызы яман. Бир сораганнарын, тыгылсыннар.

Рәвил шул сүзләрне ишеткәч, Чынтимер сораганга булган ризалыгын белдерә:

— Ярар алайсак! Егетләр дә бирү ягында булгач, мин инде алардан узынып бернәрсә дә эшли алмыйм. Бәхетгәрәй абзый, тиешлесен бүлеп бир. Нәрсә теләсәләр, шуны эшләсеннәр. Бирегез дә, әзерлек күрегез. Калган хайваннар белән төнгелеккә моннан кузгалабыз. Бер ярминкәдә

---

[1] Кызыл ут — кергән ишек башында урам яктан кызыл ут янган уйнаш йорты.

ике бүре башына урын җитмәс, борынгы бабайлар әйтмешли. Кысырык булыр...

Кычкырышып, тавыш чыгармыйча, Чынтимер белән Бәхтегәрәй атларны бүлешәләр. Чынтимер белән Камчы Зарифулланың икесенә кырык ике ат бүленеп бирелә. Бүлешкәннән соң калган атларны кояш чыгышы ягына куалый башлаган, тугрылыклы булып калган иптәшләренең артыннан атларны Ат Караклары сукмагыннан кирегә куа башлаганнарын Рәвил азрак карап тора да, китәр алдыннан җирдә басып торган Чынтимернең аркасына, иярдә утырган хәлдә, камчысы белән шаяртып, акрын гына суга:

— Хуш, Чынтимеркә-әй! Ярминкә — уңсын, бае! Тик мин салган сукмакларны, минем дус-иптәшләрне, авылларын, кайда яшәгәннәрен оныт! Тар сукмакта миңа тап була күрмә берүк.

Шатлыгы күзләреннән агылган Чынтимер, бергәләшеп озын ат сукмакларын узган, күп тапкырлар бергәләшеп үлемгә каршы көрәшкән атаманы белән коры гына хушлаша:

— Куркытма мине, Кушбаш! Без салачак яңа сукмакларга ялгышып үзең килеп керә күрмә-ә...

Ике көн узгач, Самар ярминкәсендәге атлар базарында булган фаҗигане шунда булган халык берничә ел оныта алмыйча сөйли...

Унлап атны яхшы гына хакка сатып, зур, күн янчыгын шыгырдап торган акчалар белән тутыра башлаган башкорт Чынтимер белән Камчы Зарифулла янына биш полицейский иярткән капитан Никольский килеп туктый. Чынтимер белән Зарифулланың паспортларын, атларга тиешле ат паспортларын да күрсәтүләрен сорый. Кызып-кызып Чынтимер белән ат бәясен төшерергә тырышып сатулашкан өч кара чегән, полицейский офицерыннан читкәрәк, бәйдә торган атларның икенче ягына тайпылалар. Шулчак кайсы якка таю ягын чамалап, ялт-йолт тирә-ягына карана башлаган Чынтимернең курку белмәс күзләренә, ярминкә эчендәге ыгы-зыгыда кайнашкан кешеләр арасында Рәвилнең якын ярдәмчесе Бәхтегәрәйнең кызыл йөзе чагылып китә. Тәвәккәллектән йөрәге кысыла башлаган Чынтимернең кылыч борынына күкерт исе килеп бәрелә. Атлар ягына йөзен борып өлгерә алмый кала Чынтимер. Бәйләүдә әле генә тып-тыныч торган ике ат, җан өзгеч тавыш белән чыйнап, артларын сикертеп тибенә-тибенә тартылып өзгәләнә башлый. Атлар базарында зурдан тавыш-гауга куба, кычкырыш, сөрән салулар бергә кушылып, берни дә аңламаслык хәлгә төшә базар. Зур буталыш башлана. Үргә ыргыган атларны тынычландырганчы берничә минут үтә. Атларны сыйпаштырып, суккалап, юатып яңадан бәйләп куйгач, шул тирәдәге халыкның исе-акылы китә: Чынтимер белән Камчы Зарифулла икесе дә, ярылган башларыннан аккан канны ярминкә тузанына агызып, аякларындагы үкчәсез, җиңел итекләре белән каткан җирне типкәләп, җантәслим кылып яталар...

Шунда ук җаһитлардан тамгаларын суктырган беркетмәгә полиция офицеры ул икәүнең үлем сәбәбен болай иттереп теркәп куя: «...погибли от удара копыт лошадей, которые без видимой причины начали не по-человечески кричать и прыгать как безумные. При убитых документов не обнаружены. На лошадей документов тоже нет. Восемь лошадей с привязи конфискованы в пользу городского управления Самары. Погибшие видимо продавали ворованных коней...»

Чынтимер белән Камчы Зарифулла һәлак булганнан соң, Чишмә ярминкәсендә ике атны сатып алучы хохол, ике атның да корсагы янында уч кадәрле җәрәхәтләр тапты. Җәрәхәтләр балавызлы майга катыштырган кызыл мәте белән буялган иде. Атларны сатучы, озын буйлы, кырма сакал-мыеклы татарга хохол нәрсәдер әйтергә дип авызын ача башлаган иде, арттан колагына урысчалатып тиз генә пышылдадылар:

— Бери, ухади! Рәвил так сказал!

Салынкы, озын мыеклы акыллы хохол артына борылып карап та тормыйча, калтыранган куллары белән татарга тиешеннән артык өч тәңкәне түләп, ике атны җитәкләп, ярминкәдән дусты өенә кабаланып атлады. Кайткан ыңгайга ук, хуҗаның кыстаганына ике кулын күкрәгенә куя-куя ризалашмыйча атын җигә башлады. Хохолның Чишмәдән тизрәк чыгып китәсе килә иде. Хуҗага рәхмәтләрен әйтә-әйтә, Григорьевкага чыккан юл белән бераз ара киткәч, күктәге кояшка карап өч тапкыр, тиз-тиз кулларын йөретеп, чукынып алды:

— ...Үзең саклый күр басурманнардан?!

Чукынып бетәр-бетмәс артыннан ишетелгән ат тоягы тавышларына борылып карады. Тавыш-тынсыз азрак сул якка янтая биреп иярдә утырган кешене күргәч, атын туктата да башлады. Җайдак шатлыклы елмаеп арбасында утырган хохол янында атын туктата да, әллә кайчаннан бирле белгән кебек аңарга эндәшә:

— Карале, знакум! Син бит атлар сатып алган чакта ун тәңкәне артык иттереп түләгәнең. Безгә кеше хакы кирәк түгел. Тот акчаңны!

Каушап төшкән хохолның зур кулына ике бишлекне тоттырды да, матур булып тезелгән ап-ак энҗе тешләрен күрсәтеп елмайды:

— Атларның корсагын эретеп чучка мае белән сыла. Бер атнадан төзәлер. Тик чыккан йоны гына ак булыр. Тамга сиңа! Кайсы авылдан?

— Григорьевкадан мин...

— Юл ыңгае булса, кунакка керермен. Хуш.

— Рәх-хим ит... егез! Хуш-хуш!

Атын бора башлаган Рәвил тагын елмайды:

— Исән-имин яшә! Кемнән алганыңны, ярминкәдәге татарны әйтүем, оныт!

— Ярар. Ул минем исемдә калмады да инде.

Җиңел иттереп юырткан җайдаклы артыннан, хохол карап калып, арбасында азрак утыргач, атын кузгатты.

— Йә, Ходай, үзең сакла. Рәвил дигәннәре шушы булды, күрәсең...

Юырткан ат артыннан тагын бер тапкыр карап алды да, соклануын яшермәде:

— Бик елгырдыр бу егет. Карале, аты өстендә нинди матур, ыңгайлы иттереп утыра бит!

Кичен, учактан төшкән ут яктысында. Рәвил хохолга атларны саткан Озын Шагалигә акрын гына тавыш белән үгет-нәсихәт бирә иде:

— Андый атларның икесен бер кешегә сатарга ярамый. Самар ярминкәсендә күсәк белән бик шәп итеп эш иттең. Теге көнне. Бу юлысы азрак ялгышлык җибәрдең. Андый атларны урыска сату кулайрак. Хахул — эшен бетермичә, алу-сатуны башкармыйча, хәмер капмый. Ә урыс һәрчак салмыш. Кая ди инде аңарга корсак тирәсен карарга баш дигән әйбер. Саткан чакта атның шул җәрәхәтле корсагы яныннан кузгалмаска иде сиңа. Яисә, атны бер урында басып тора алмаган кебекләр кыйландырып, сатып алучыга атның гел генә бер ягы белән күрсәтергә кирәк. Аңладыңмы?

— Ыы!

— «Ыы» булгач, тагын бер нәрсә сиңа. Бүгенге кебекләр иттереп, акчасын алмас борын, сатып алучының кулына атның тезгенен тоттырасы булма. Акчаны санап алгач кына, кәзәки итәге белән атның тезгенен тотып суз алучыга. Белдеңме инде?

— Ыы.

— Ыы, түгел, белдем, аңладым диярга кирәк!

— Белдем, Рәвил, белдем! Аңладым да!

— Белсәң, аңласаң, бик хуп! Әнә Кинҗәбулаттан үрнәк ал. Күрдеңме атларны ничек күккә сикертте, чыйнатып. Шәп басты янган күкертне корсакларына. Үзе дә өлгер, дус чегәннәре дә төшеп калганнардан түгелләр — кирәкне җиренә җиткереп эшли беләләр. Менә шундый булырга кирәк.

— Ы... күрдем мин аларның шәплеген. Аңладым...

— Менә монысы яңгыш инде тулысынча. Син ярминкәдә ул көнне бернәрсә дә күрмәдең. Чөнки Кинҗәбулат та синең озын чикмәнең астына тыккан чукмар-күсәгеңне күрмәгән дә, белми дә. Аңладыңмы?

— Аңладым Рәвил! Болай булгач, аңламаган кая ди инде. Шәп иттереп аңлата беләсең бит. Аңладым, белдем!

— Белгәч, алайса, әйдә йоклыйк инде. Иртәгә бәйрәм түгел бит, эш күп безнең.

* * *

Самар якларыннан Уралның теге ягында урнашкан Шадринск каласына кадәр ярминкәләргә атларны сату максаты белән күчерү өчен бар ителгән сукмак урап-урап авыл, калалар яныннан уза. Шулай булса да, андый сукмакның барлыгын гади халык белми дә. Сукмакның өч чакрым чамасында узган җире Йомагуҗа дип йөртелгән башкорт авылы яныннан. Бүре үз өне янында кан коймаган кебек, Рәвил дә ул сукмакны авылыннан аз гына булса да читтәнрәк, башкортлар Йомагуҗасы яныннан уздырган. Бу сукмак Ырымбур ягыннан килгән Ат Караклары Сукмагы белән шушы Йомагуҗа авылы янында очраша язып куя. Аралары нибары бер чакрым тирәсе.

Рәвил үзе, ерак казакъ далаларында ат урланган чагында тотылып, кул сугышында һәлак булганнан соң, күп еллар үткәч, Гражданнар сугышы да әллә кайларда калып, еллар тынычлангач, шул Йомагуҗа авылының Нурислам исемле карт башкорт бабае бертуган кустысының ятим улы, җиде яшьлек Рәвил исемле малайга Ат Караклары Сукмагының авылдан ерак булмаган сырт буйлап үткән җирен күрсәтә.

— Син, Рәвил улым, курыска юкә кискәндә бер нәрсәне чамаламадыңмы?

— Нәстәне, бабакай?

— Без бит бу юкәләрне, улым, Ат Караклары Сукмагыннан кисеп болашабыз.

— Нинди сукмак ул, бабакай? Монда бит урман булгандыр?

— Борынгы елларда менә шушы юкәләр үсеп утырган җирдә атлар чабып уза торган сукмак булган. Рәвил исемле ат карагы салган ул сукмакны.

— Нинди Рәвил ул, бабакай? Нигә ул ат урлаган?

— Элекке заманнарда, синең кебек Рәвил исемле бик батыр, гайрәтле егет булган. Тик үзе ат карагы нәселеннән булган шул. Атлар урлаган. Нинди генә кыйналуларга, сугышуларга эләксә дә, исән кала алган. Терелеп һәрчак аякка баскан. Тагын шул ат урлау кәсебенә тотынган. Чөнки, шул ат урлау кәсебеннән башка һөнәр белмәгән ул егет. Менә шушы без синең белән кискән юкәлек Рәвил сукмагындагы юкәлек инде, улым.

— Ул сукмак кая табан алып бара, бабакай?

— Самар ягына, диләр, белгәнрәк кешеләр. Мин бик белеп бетермим инде, улым, ул ягын.

— Белгәнеңне сөйлә син, бабакай?

— Менә шушыннан тау түбәсенә үрмәләп менеп, тау сырты белән байтак баргач, тауның теге ягынарак авышып чыгып, Мукшы күленә барып җитә. Аннан соң Карабалыклы җирләрен уңдарак калдырып, Каенаер янындагы Шәет күленә чыга, диләр. Аннан арырак Хәмбикә ташы яныннан үтеп, атаемның сөйләгәне буенча, Ханнар тавы башы белән башкортлар Караташына китә бугай...

— Ә сукмакның бу җирен сиңа, бабакай, кем күрсәтте?

— Олатаем Баймөрат. Менә бу сукмактагы агачларны, янәшә барган ике генә ат сыярлык иттереп кисеп, тазартып торганнар. Куак чакларында ук.

— Кемнәр кискән, бабакай?

— Табылган инде андыйлар да. Кемгә кирәк булса, шулар кискәндер. Син минә сора миннән, нәрсә дип бу сукмакны күрсәтәсең син миңа, бабакай, дип?

— Нәрсәгә, бабакай?

— Исеңдә калсын дип. Мин үлгәч, бу сукмакны белүче дә булмаячак. Син дә, улым, нинди егетнең исемен йөреткәнеңне белеп яшә. Инде үсеп киләсең, Аллага мең шөкер, атаем юк дип тормыйсың. Аны карак дисәләр дә, Рәвил зур батырлыкка ия егет иде. Ярлы-ябагайга да байтак игелеге тиде аның...

— Син аны белә идеңмени, бабакай?

— Олтайда ике тапкыр кереп кунган ул. Берсендә каты җәрәхәтләнгән булган. Шунда күрдем мин аны. Чыгып китәр алдыннан, терелеп җиткәч. Бик таза чибәр кеше иде дә, тик башы зур, тубал кебек иде.

Малай тынычсыз күзләрен бабакаеннан алмыйча, сорау арты сораулар бирә, тыңлый. Бабакае да, инде үзенең бу дөньядан китәсе көннәрен сизенгәндәй, сөйли ятим малайга ат карагы булган Рәвил исемле чая егет хакында.

— Сиңа шул ат карагы Рәвилнең исемен куштык бит без.

— Ә нигә алай, бабакай?

— Үзем куштырдым мин сиңа ул исемне. Сәбәбе болай иде. Атаең белән инәең өйләнешкәннән соң, унике елга якын бергә яшәделәр. Бик тату тордылар, ләкин торлыкмады балалары. Туган берсе ни сәбәптер бер-бер артлы үлә барды. Сихер эше диючеләр дә булды. Шуннан җиденче бала булып дөньяга син тудың. Карарлык бер җиреңдә юк иде туган чагында. Аяк-кул чыбыктай нечкә инде. Башыңда чәчнең әсәре дә юк. Муен җеп кебек кенә. Авызың ачык, тик ник шунда авызыңнан берәр аваз кебегрәк тавыш чыкса икән. Үзең ябык тавык кебексең. Тәнең күп-күмгәк. Атаң кара көеп чыкты, инәең җылый тавыш-тынсыз гына, монысы да кеше була алмас инде, дип. Кендек әбисе мине чакыртып алды. Алды дип инде, капка төбендә утыра идем, мин дә синең дөньяга килеп, сөрән салып акыра башлаганыңны көтеп. Килеп кердем. Икәүләшеп елыйлар болар. Кендек әбисе дә пошамага төшкән. Бирегез әле үземә, бу Байморат нәселенең яңа кошын, дидем дә, кендек әбисенең кулыннан алдым сине. Исеме бу егетнең теге замандагы, үлемгә каршы нык иттереп сугыша белгән Рәвил ат карагының исеме булсын. Рәвил Фәтхи малае бу, дидем. Шуннан үзебезгә алып чыгып киттем сине. Каршы эндәшүче булмады, рәхмәт анысы өчен барысына да. Тавык тизәген җылы суда эретеп, шуңа ак май кушып, кипкән әрекмәнне төеп, азрак сыер тизәге дә кушып, бик ныклап барысын бергә бутадым. Шуның белән тоташ тәнеңне сыладым синең. Муеныңа хәтлек. Башың гына тырпаеп калды. Аннан соң яңа суйган кара сарык бәрәне тиресенә төрдем үзеңне. Җылы көенә...

— Яңа суйган кара сарык бәрәнен каян алдың, бабакай?

— Һә-әй, юләр мал-ла-ай! Атаклы Байморат нәселендә туган ир-егет өчен, андый чакта сарык бәрәнен кызганып торалар димени.

— Шуннан, бабакай!

— Шуннан соңы, шул, улым. Өч көн буена тагын кара тукал кәҗә сөтен, аз-азлап кына, сава барган ыңгайга, юкә кашыктан, ярты кашыклап кына, бисмиллалап авызыңа салдык...

Бала шатланып көлә:

— Әчтемме, бабакай?

Бабай да көлә вак кына иттереп:

— Хи-хи-хихи-хи! Йоттың инде, кая барасың. Йотмасаң бит, тын алырга кирәк. Хи-хи...

— И-и-и...

— Минә сиңа и-и! Өч көн үткәч, синнән тычкан баласы чыилдаган кебекләр генә иттереп тавыш килеп чыкмасынмы? Күтәрдем дә,

йөгердем сезгә. Анда әтиең әниеңне безгә чыгып китмәсен дип саклап утыра. Үзен елата-елата түшеннән сөтен сава...

— Нигә алай итә, бабакай?

— Синең ризыгыңны пәри балалары ашамасыннар, дип. Сава да утка сибә, тегеләргә булмасын, дип.

— Шуннан, бабакай?

— Шул. Сине инәеңә алып кереп тоттырдым. Инде имдең, инде имдең. Имеп туйгач, авызыңнан имгән сөтең ага башлады. Барыбер имәсең үзең. Атаең тапана инәең янында, туктатма, имсен әйдә, ди. Шуннан башыңны азрак кырынрак кына борып, йоклап киттең. Тәүлек буена уянмастан йокладың. Йоклап туйгач, кычкырып уянып киткәнсең дә, тотынгансың акырырга дөнья куптарып. Атаң безгә кергән йөгереп, мине чакырырга дип инде. Әйдәле, агай, тизрәк безгә, ди. Теге нәмәстә елый, өйдә түзәр әмәл юк, ди. Үзенең куанычыннан, авызы колакларына җиткән. Җыларга көч тапкач, булды гына инде, ди үзе. Рәхәтләнеп көлдем дә, куанычтан, әйттем атаңа. Болай дидем: «Аның иң тәүдә сарык тиресеннән чыгасы киләдер. Аннан соң тавык тизәгеннән арынып, тәнен мунчада, себерке җилендә йомшаттырасы киләдер. Шунлыктан мин мунчаны булдырып куйдым инде»,— дим. Бик үк аңлап бетермәде бугай, күзенә ак-кара күренмичә чыгып та йөгерде бу. Әбекәең белән тәрәзәдән карап көләбез атаеңның кыланышына — язгы пычрактан чаба бу, бер аягында башмак чабата, икенчесендә бернәрсә дә киелмәгән — яланаяк мин синайтим. Куанычыннан сикерә-сикерә пычрак чәчерәтеп, урам буйлап иң пычрак урыннардан йөгерә.

Бабай истәлекләргә бирелеп, кулындагы балтасын да онытткан хәлдә, бик озак басып торды элекке ат караклары сукмагында. Аннан соң авыр уфылдап сулыш алды да, әллә утыз җиденче елның яңгырлы төнендә НКВД килеп алып киткән — Рәвилнең әтисе, үзенең бертуган энесе Фәтхелислам исенә төште, әллә Казакъ далаларында ат урлаганда тәвәккәл башын югалткан атаклы ат карагы Рәвилне исенә төшерде, эчке зур сагыш белән акрын гына сыкрап куйды:

— Кай җирләрдә генә ята икән инде дуамал башкайлары...

* * *

Чынтимер Самар ярминкәсендә һәлак булганнан соң, Ярулла каладан юкка чыкты. Өч атна узгач, Самарны барып ураган Шагали яңалык алып кайта:

— Ярулла юк анда, ярминкәдә. Хәер, ярминкә бетүгә бара инде. Базарларда да юк. Өендә дә юк. Өе шунда, нагузим билла инде. Идел ярын чокып кереп, эче такта белән азрак ныгытылган бер чокыр шунда. Эчендә кәкрәеп беткән бер карчык. Әнисе, ди Ярулланың. Улының кайда икәнен белми икән. Әллә шунда белеп әйтми тагын. Өйгә кайтмаганына ике атнадан артты инде, ди үзе...

— Елыймы?

— Юк, еламый. Соңгы чыгып киткәнендә таякка таянып чыгып китте, ди.

— Таякка таяны-ып?!

— Әйе, таякка таянып, ди.

Рәвил азрак уйланып утыргач, ачык кына бер карарга килә алмады, ахрысы.

— Без болай итеп карыйк булмаса. Яхшы кибиткага парат җиктереп, Самарга кудырыйк. Яруллланы табып алып килегез. Тере булсын.

— Тапсак ярый инде.

— Табыгыз. Бер-бер хәл булырга охшаган монда. Ярулла хәбәр итмичә юкка чыга торганнардан түгел. Белә ул минем аны җир астыннан да табасымны. Ул бәндә үлгәнче миңа хезмәт итәргә тиеш. Шуны яхшы белә ул.

— Чынтимердән соң, Самарга бару да бит әле...

— Без анда күренмәсәк, бездән шикләнүләре бар. Тәвәккәл таш ярган, ди татар. Ходайга тапшырып, башлыйк бу эшне...

Ярулла елдан артык юк булып, икенче елны кар төшәр алдыннан гына, карлы, пычрак көздә өенә кайтып егылды. Сакал-мыек баскан, ябыгып картайган, битендәге тиресе тартышып, каралып, яргаланып беткән. Өстендә иске, күп урыннардан тиредән ямау салынган казакълар туны, башында зур малахай, кулында моннан алып киткән таягы. Анасы улын шул таягына карап кына танып алды. Таныды да, нечкә генә иттереп тавыш чыгарып, сыктап елап җибәрде:

— И-и бала, бала-а-а....

Ярулла җаваплап тормады. Үрелеп, әнисенең башына ябынган иске шәленнән сыйпады да ишегалды кебек җиргә узды. Өе алдында, инде яфракларын коеп бетереп кышны көтеп чишенгән, юеш ботаклары белән Идел аръягыннан искә җилләргә тотынырга тырышып селкенгән каен төбенә, үзе егет чагында ясап куйган урындыкка барып утырды. Бик озак итеп утырды, йөткергәләп. Кургаш төсендәге авыр болытлар агылган күккә, шулар арасыннан аз гына булса да җир өстенә карап алырга тырышкан күзге салкын кояшка, Иделнең аръягында күренеп торган саргылт болыннарга карап, күңелсез генә нindidер караңгы уйларына бирелеп, онытылып, утырды Ярулла. Аз гына йөзенә чыккан елмаюында ниндидер төзәтә алмаслык авыр сагыш һәм мәңге бетмәслек үкенү чагыла иде кебек. Каршысында, иске, йөз җирдән ямаулы бишмәтен кигән, күзеннән бертуктаусыз аккан ачы яшьләрен сөрткәләп, кайгы-михнәттән кәкерәеп төшкән, инди шатлыкның нәрсә икәнен тәмам онытkan әнисен юатырга маташты:

— Йә, йә, елама, әни! Сине күрергә насыйп булды, кайттым менә, Аллага мең шөкер! Мичеңә ягып җибәр. Мин нигәдер бик өшим соңгы айда. Көзгелеккә баргангадыр инде. Азрак акча алып кайттым. Ашарга ал. Миңа өч кадак чамасы яшь елкы ите ал. Яңа суйган булсын. Биянеке. Шулпасын булса да эчеп карарга иде, файдасы тимәсме...

Әнисе улы биргән акчаларны бисмилласын әйтеп кулына алды да, кузгала башлаган җиреннән тукталып калды. Сак кына сорады:

— Теге шайтаннарың очраса, нәрсә дип әйтим. Сине кайтты димме, бернәрсә дә әйтмимме? Күптән килгәннәре юк. Алай да, узган ел бик яфалаганнар ие, сине таптырып. Теге Озын Шагали...

Ярулланың каралып, тартышып каткан битенә аз гына алсулык йөгергәндәй булды.

— Курыкмыйча йөре, әни. Алар мине эзләрлек хәлдә түгелләр инде хәзер.

Ана кеше улының нәфрәт белән кырыслык чыккан тавышына колак салып басып торды да, сәер елтыраган күзләрен күргәч, тетрәнеп китте:

— Әллә...

— Бар инде, әни, бар! Базар тарала башлар вакыт җитеп килә бит. Алар хакында синең белмәгәнең хәерлерәк булыр.

Еллар буена юашлыкта гомерен үткәреп барган карчыкның күзләрендә нәфрәт очкыннары кабынып китте.

— Шулайдыр бик, белмәгәнем хәерлерәктер. Ул тәпән баш Рәвилне көч-куәтем җитсә, мин үз кулларым белән буып ташларыем әле. Кулымнан килми. Арыслан кебек бердәнбер баламны гарипләтеп, кан йоттырып яшәтте, Алланың Каһәрләре генә төшкән башкисәр нәмәстәкәй. Мәлгунь. Теге дөньяга китәр алдыннан миңа да йөрәгемдәге нәфрәт утының ялкынын басарга кирәктер бит инде. Әйт миңа, кайда ул Рәвил, нинди хәлдә, дип сорыйм мин синнән?

Ярулла, кызарган күз кабакларын күтәреп, алдында ачуларын чәчеп таптанган әнисенә карап торды да, ул көтмәгән сүзләрне әйтте:

— Казакъ даласында, ат урлаганда тотылып, бөтен иптәшләре белән бергә, күсәкләр белән сугышканда һәлак булды Рәвил. Ул да, калганнары да. Башын ярып үтерделәр күсәк белән...

Сулыш ала алмыйча, куллары белән туны астыннан күкрәген сыйпаштырып, тоткалап утырды да, акрын гына өстәп куйды:

— Юк инде хәзер атаклы ат карагы кушбаш Рәвил...

Каты ютәл аны буып алды. Утырган жиреннән бөгелеп төште дә, барлык гәүдәсе белән куырыла-куырыла ютәлләргә тотынды.

Кышны әнисе каравында Ярулла зур авырлык белән чыга алды. Акчасы, ашарына бетсә, таягына таянып, Самар урамнары буйлап, базарларда хәер сорашып йөрде. Тик бик сирәк чыкты. Яз житкәнне зур түземсезлек белән көтеп алды. Өметсез — шайтан ди, безнең халык. Ярулла да язгы жылы кояш астында утырып, үзенең терелеп китәчәгенә өметләнеп кышны чыга алды...

Хәер сорашып кайткан әнисе ишегалдына килеп кергәч, куркуыннан, ике куллап капчыгын күкрәгенә кыскан хәлдә туктап калды. Үзе ясаган урындыкта улы Ярулла утыра. Башы, яртылаш кисеп чыгарган муены тота алмаганнан, сул якка кыйшаеп тора. Изү, күкрәк, корсак тирәләре, ике боты муеныннан аккан канга кып-кызыл булып буялганнар. Аяк астында малахае аунап ята. Таянып йөри торган таягы урталай сындырылган.

Рәвил үтерелсә дә, ат караклары бетмәгән икән әле...

* * *

Ике ел элек, Ярулла таягына таянып өеннән чыгып киткәннән соң ай үтәр-үтмәстә иске танышларының берсе аны, Ырымбур каласында, Кәрван сарай янында хәер сорашып торган жиреннән танып алып эндәшкән:

— Әссәлам-мәгаләйкү-үм, Ярулла! Син дөньядамыни әле?

Тик Ярулла башын күтәреп карамаган, сәламен алып, аңарга жавап кайтармаган. Тик кенә, уң кулының учын сузган хәлдә басып торуын дәвам иткән. Әйтерсең лә ул Ярулла түгел дә, сәламнең аңарга карата бер катнашы да юк. Теге бәндә адәмнең әрсезләреннән булып чыкты. Уйлап-нитеп бетермичә, авызы эчендәге теле аркылы шунда ук чыгарып сала торганнарда икән бу.

— Мин, сине кыйнап үтергәннәр икән, үз иптәшләрең, дип ишеткән идем. Болай булгач, үлмәгән булып чыгасың бит инде син. Моны мин ничек аңларга тиеш инде хәзер, ә? Ярулла, дим бит мин сиңа?!

Тик, Ярулланың дәшмичә катып басып торганына аптыраулы карашын ташлап-ташлап алган да, башкаларның үзенә игътибар итә башлаганын күргәч, авыз эченнән генә сүгенеп, Кәрван сарайга кереп киткән:

— ...фәлән иткере. Әллә Ярулла булмады инде. Алай дисәң, бик тә охшаган бит шул мөртәткә. Колаклары да тырпаеп тора, гәүдә торышы да шуныкы. Ходайның әллә кемнәре бар инде дөньяда. Тач Ярулла бит. Кешегә кеше охшаса да охшый икән шулкадәр...

Үзен кемнән дә булса таныту Ярулланың исәбенә туры килми. Шул көнне үк ул Ырымбурдан чыгып сыза.

* * *

Кар сулары китеп, казакъ далалары яшәреп матурландылар. Шул чакта далада бер йолкыш хәерче пәйда булып, жәйләүдән-жәйләүгә жәяү йөреп, хәер сорашып тамагын туйдырып, нәрсәдер эзләнгәндәй көннәрен үткәрә иде. Өстендә иске мең ямаулы көпе, башында кара йонлы колакчы бүрек, аягында зур, каткан күн итекләр. Көпесен озын билбау белән урап буган. Көпесе астында инде төсенең нindидән икәне билгесезгә әйләнгән күлмәге дә күренә.

Болытбай жәйләвенә килеп житкәч, бу хәерче атнадан артык жылкычылар тирмәсендә чыкмастан диярлек ятты.

Дүрт жылкычы тәүлек әйләнәсендә алмашлап мал карыйлар. Көнтөн ияр өстендәләр, зур жылкы көтүен киң далада йөретеп тукландыралар, су буйларына алып барып, тәүлегенә ике мәртәбә эчерәләр.

Яшь үлән әле күтәрелеп кенә килә. Көздән калган үләннәргә, ак башлы кылганнарга дала бай. Кыштан йончып чыккан хайваннар язгы жылы кояш астында рәхәткә талып, тамакларын туйындыралар.

Казакъ жәйләвенә килеп, хәле бетеп тәгәрәгән хәерче — Ярулла иде. Берничә көн жылкычылар тирмәсендә ятып, кымыз эчеп, ит ашап азрак ушын жыеп, кеше кыяфәтенә керә башлады. Куллары һөнәрле иде Яруллаbelонның. Дүрт жылкычыга да камчылар үрде каештан. Жаныбәк дигән казакъ егете үзенә үреп тоттырган камчыны алганда соклануыннан телен шартлатып куйды. Икенче көнне Яруллага баш бармактан аз гына зуррак, озынчарак кургаш кисәге сузды.

— Шушы кургашны очына тегеп, миңа тагын бер камчы үр. Бу камчыдан бер уч кадәре озынрак булсын...

Ярулланың эченә суык йөгергәндәй булды. Азрак тотлыккандай иттереп сорады:

— Нәр...р-рсәгә андый камчы сиңа?

Жаныбәк зәһәрләре ташып торган кысык күзләрен читкә алмады:

— Бүре, төлке алырга да... аннан — ат каракларына!

Кургашны сәрмәштереп озак утырды Ярулла.

Икенче көнне Жаныбәк сорыйсы итте:

— Миңа камчы үргәнеңне бакмыйм. Әллә теләгең юкмы?

Ярулла егеткә күтәрелеп карамады, жавапламады. Камчыны да үрмәде. Жаныбәк тә кабатлап сорамады яңа камчысын.

Икенче көнне Жаныбәк Ярулла янында камчысын «онытып» чыгып китте. Камчының очында каеш эченә кургаш тегелгән иде. Чия агачыннан ясалган, күп куллар тотып шомарган сабы, камчы белән еш сунарга йөргәннәрен күрсәтә. Вакытында дегеткә манчылып, камчыга яхшы карау тигән. Каешларының торышына караганда бу камчы Жаныбәккә йә атасыннан, яки тагын да өлкәнрәктән калгандыр. Тәүлеккә якын Ярулла янында камчысын яткырып, Жаныбәк аны сүзсез генә алып чыгып китте. Тагын ике көн узгач, Жаныбәк Яруллага «камчылап алган» үр куянын кертеп тоттырды.

— Тот, нугай! Куянның иң шәп чаба торганы сиңа. Камчылап алдым. Туна да пешер! Тиресе үзеңә булсын.

Ярулла куянның ярык башына карап, озак утырды тирмә уртасында.

Икенче көнне ул жайлап кына атлап, жылкы көтүен караган Жаныбәк янына китте.

Иркен дала искитмәле булып матурланган. Яшәреп чыккан яшь үлән исеннән авыру Ярулланың башы әйләнә. Зыңгылдап очкан төрле шөпшәләрнең, умарта кортларының тавышлары күңелгә тынычлык бирәләр. Төньяктан, туган яктан искән дымлы акрын жил рәхәтлек биреп битен сыйпап, туган якның төтен исләрен алып килгән кебек. Һавада берсеннәнберсе югарыракка омтылып, кояш нурларына ябышып өскә очып, аннан соң биеклектә туктап жырлаган тургай-кошлар, Ходай тарафыннан, авыру жаннарга дәва биреп, исәннәрнең дәртен арттырып, язгы һаваны үзләренең моңы белән тутырганнар. Шул тургайларны тыңлап атлаган Ярулланың бу дала киңлекләрендә, кояш нурлары астында, язгы, яшел үләннәрне таптап тагын да яшисе килә, бу якты дөньядан китәсе килми. Зәңгәр күктәге күчмә ак болытларга карап бик озак басып торды ул дала уртасында. Ходай бирмеш ул ак болытлар, әле күперенгәндәй зураеп, аннан сузылып озынаеп, кай тарафларгадыр агылалар да агылалар. Алар өчен син бармы, юкмы — барыбер. Күп тә үтмәс, бу дөньядан китеп тә барырсың, ә болытлар бүгенгедәй агылырлар да агылырлар...

Казакъ егете әйтерсең лә бүген Ярулланың үзенең янына киләсен белеп торган инде. Ярулла якынлаша башлау белән сүзсез енә атыннан сикереп төште дә, аны яңа гына күргәндәй, ике кулын биреп күреште, хәлен сорашты.

Ярулла уң аягын тездән бөкләп, көздән калган кылган өстенә утырды. Жанибәк аның эргәсенә чүгәләде. Ул инде бергә яшәгән көннәр эчендә бу авыру нугайның казакъ далаларына нииндидер зур максат белән килгәнен дә һәм аның яхшы ат белгече икәнен дә чамалаган иде. Чөнки Ярулланың күзләре гелән генә яхшы атларда туктала иде.

— Жанибәк!

— Тыңлыйм, чырагым!

— Бу ел жәйләүләрдә ат караклары күренделәрме?

— Иртәрәк бит әле, чырагым. Тагын ун-унбиш көн үтәр дип уйлыйбыз.

— Шулаймы?

— Шулай.

— Ә мин, үтә китсә, бер атна вакыт булыр дип уйлыйм.

Жанибәк тавышсыз гына нугайның тагын да нәрсә сөйлисен көтә.

— Мин Рәвил карак белән берлектә сезнең далаларда күп жылкы урладым. Аның белән берлектә. Рәвил мине гаепсезгә кыйнатып имгәтте. Узган ел Самар ярминкәсендә дустым Чынтимерне үтертте. Инде озаклямас килер далага. Сезнең атларны куып алып китәргә...

— Бик житез, акыллы егет Рәвил...

Ярулла «һык» дигәнрәк аваз чыгарып, күңелсез елмайды:

— Башы зур. Ике башлы ул. Берсе артка чыгып тора.

Нәфрәт тулы, үч алу уты белән янган күзләрен казакъ егетенә тегәде:

— Син мине гайрәтле, абруйлы, батыр казакъ бәгенә алып бар. Шундый кешегә генә ача алам мин Рәвил каракның серен дә, көчен дә, хәйләсен дә.

— Хоп! Шулай итик тә, ди. Ә нигә миңа сөйләмисең Рәвилнең серен?

— Син, Жанибәк, батыр егетсең. Тик син жылкычы гына. Рәвилне тотар өчен, яисә юк итәр өчен зур оештыру кирәк. Кан күп булачак.

Икенче көнне Ярулланы карт, юаш бер бурлы биягә атландырып юлга алып чыгып киттеләр. Жәйләүдән-жәйләүгә йөреп, өч көн бардылар. Барган якларын, кояшны чамалап, Ярулла үзләренең Тургай даласы эченә кереп киткәннәрен чамалаган иде. Өч көн узганнан соң, зур гына күл буенда урнашкан жәйләүгә килеп життеләр. Егермеләп тирмәдән торган жәйләү, бай тугайлар, бик биек булмаган, куе үлән каплаган калкулыклар белән уратылып алынган иде. Килгән уңайга ук зур бер ак тирмә эченә алып кереп, күп иттереп ит ашатып, кымыз эчерделәр. Табынга утыра башлаганда ук Жанибәк каядыр китеп юк булып торды. Аннан соң кулына бик яңадан булмаса да ярыйсы гына ныклы көпе, колакчын һәм соры төстәге әйбердән тегелгән күлмәк-ыштан күтәреп, килеп тә керде. Шул киемнәр арасында зәңгәр буйлы чалбар да бар иде. Ашап-эчеп дога кылгач, барлык киемнәрне Яруллага тоттырды:

— Күл буена төшеп юын, әйбәтләп. Киен шушыларны. Өйлә ашына Дөябайга керәбез.

— Кем ул Дөябай?

— Безнең ыруның бае. Байлыгы белән дала тулган. Сез, аның жылкыларын ике тапкыр куып алып киттегез инде. Рәвилне Дөябай күреп белә.

— Күре-еп белә?

— Күреп, Ырымбур ярминкәсендә ике юртак бия биреп күрсәттергән. Рәвилнең барын без инде белә идек, син килгәнче үк.

— Ничек белдегез?

Жанибай кинәнеп кыска гына иттереп көлде.

— Каян белгәне сиңа кирәкми аның.

Шулай да өстисе итте:

— Ул егет юк инде. Тере түгел. Ул исән булса, бәлки Рәвилне без алган да булыр идек инде.

— Чынтимерме?

Җаныбай җавап урнына башканы әйтте:

— Син әзерлән. Син моннан тик Рәвилнең башын биреп кенә котыла аласың. Әгәр исән калырга уйласаң инде. Шуны яхшы бел.

Ишек төбенә җиткәч, туктап сорады:

— Син, тире капчык турында ишеткәнең бармы?

— Бар. Әллә шул дөресме?

— Дөрес! Анадан тума чишендереп, карт үгез тиресеннән ясаган капчык эченә тыгып, авызын, аз гына һава керерлек иттереп бәйлиләр дә, йә агач ботагына элеп китәләр, йәисә тау-таш арасына ыргыталар. Кояшка. Кеше шул капчык эчендә эсседән, акылыннан шашып бик озак яфаланып җан бирә. Капчыктан чыга алмый.

Ярулланың бөрчек-бөрчек тир баскан битенә карап, мыскыллы елмайды:

— Йә сине, йә Рәвилне көтә шундый капчык. Ун яшәгән үгез тиресеннән Рәвилгә дип Дөябай әллә кайчан тектереп куйды инде ул капчыкны. Тик моңарчы Рәвилне генә тота алганы юк иде әле.

Дөябай сине карарга, тәрбияле ашатырга, эчертергә кушты. Итне күпме телисең аша, кымызны ылкынганчы эч. Терел, аякка бас. Минем белән дус бул. Синең өчен иң яхшысы — минем дуслык. Рәвилне тотарга ярдәмең тисә, акчаң да булыр.

Ишек төбеннән кире атлап, сүзләрен тәмамлап куйды:

— Дөябай белән сөйләшкәндә, Рәвилне эләктергәч, мине җибәрегез дип сөйләш. Рәвилне юк итәргә тырышып яшәгән казак егетләре дә сине бу дөньяда тере килеш тотмаячаклар. Рәвил — егет! Ә син кыю егетне сатасың. Элекке дустыңны...

Җаныбәк сүзләреннән җирәнү сизелә иде...

* * *

Дөябай, утыз яшен яңарак кына узган озын буйлы, киң җилкәле, какча гәүдәле, гайрәт-көче ташып торган казакъ иде. Матурятышлы бай киеме, аягындагы бизәкле Казан итекләре, башындагы чиккән түбәтәе килешле булып, өстендәге киемнәрен бизәп, казакъ егетенең матурлыгын тагын да арттыралар.

Тирмә уртасында җыелган табында табаклар тулы буы чыгып торган итләр өелгән, кымыз куелган. Дөябай янына дәрәҗәләрен белеп, тагын алты казакъ утырганнар. Тик алары байларча ук түгел. Гайрәтле, таза гәүдәле, көчләре ташып торган утыз белән кырык арасындагы бәндәләр. Бераз ашап-эчеп тамак ялгап алгач, Дөябай бер мәлне каршысында утырган Ярулладан сорашуга күчте.

Сүз күбесенчә Рәвил турында барды: Ничә яшьтә, төсе-буе нинди рәк, хәмер яратамы, киемнәре нинди рәк? Менгән аты ни төсле, ничә яшьтә, йөгән иярләре нинди, коралы бармы? Нинди корал? Йөгән-ияре бизәлгәнме? Кулындагы камчысы ничә буынлы? Кургашы бармы?

Ярулла барлык сорауларга да бер әмтекләп җавап бирә барды. Тик Кара Кашка бияне генә сөйләмичә калдырды. Ни өчен шулай эшләгәнен үзенә дә аңлата алмады. Кеше күплеге тәэсир итте, ахрысы. Эченнән генә, Дөябайның үзенә генә сөйләргә ният итте. Чөнки, Дөябайдан иң еракта, ишек төбендә үк диярлек утырган иң яшь казакъның, кашларына төшереп үк кигән колакчыны астыннан үзенә төбәлгән нәфрәтле күз карашын эләктереп өлгерде Ярулла. Сагая төште. Чөнки күз карашындагы нәфрәт өстенә, җирәнү белән ачу да күп иде.

Сорашып беткәч, утлы күзләре белән Дөябай Ярулага карады:

— Нәрсә дип сатасың Рәвилне? Кәсептә күренгәнчә, күп тапкырлар бергә йөргәнсез, җылкыларны бергә кугансыз. Дуслар булгансз. Бәлки, әле дә берәр хәйлә корып, Рәвилне бездән бу тирәдә көттереп, үзегез икенче җирдән без — казакъларның җылкыларын куарга исәп итәсездер? Ә? Рәвилне эләктерә алмасак, сине, нәрсә көткәнен Җаныбәк сөйләгәндер бит?

Ярулланың тирләп, агарып чыккан йөзенә карап, мыскыллап елмайды:

— Шул капчык эчендә йә син, йә Рәвил булачаксың!

Ярулла кулында тоткан кымыз тулы тустакны алдына утыртты. Акрын гына чыккан тавыш белән сөйләп китте:

— Сездән куган җылкы малын Эстәрлетамак ярминкәсендә сатып акчасын биргәч, Рәвил азсынды. Урлап алып калгансың дип бәйләнеп сөйләнде миңа. Мин шулайга гына сатыладыр дигәч, ике тапкыр кыйнатты мине. Урыслар яллап. Берсен үткәреп булды. Бик каты кыйнамадылар. Икенчесендә һавага күтәреп ыргытып, арт белән җиргә утырттылар. Шуннан бирле... кан килә...

Ике зур йотым кымыз алды.

— ...Дөрес, яхшы дуслар идек. Тик Рәвил дуслыкның бәясен санлый белә торган кеше түгел. Бергә кәсеп иттереп китереп чыгарган табышның күбесен үзенә каера, безгә азрак бирә. Алдалый безне. Каршы әйтсәң, йә үзе кыйный, яисә башкалардан кыйнаттыра.

Әгәр ул Чынтимерне үтертмәсә, Самарда, мин сезне эзләп юлга чыкмас та идем. Чынтимернең өч ятим баласы, гарип хатыны, сукыр әнисе калдылар. Ничекләр иттереп дөнья көтәрләр — белмим инде. Бергә кәсепкә йөри башлаган елларда Рәвил гадел, әйбәт иде. Акча бозды аны. Бик явызланды. Хәтта үзе белән барымтага, кәсепкә йөргән иптәшләренә дә...

Ярулланы беркем дә бүлдермәде. Сул кулын бөеренә куеп тыңлады Дөябай. Ярулла туктагач, кабатлап сорады:

— Бәлки, безнең атларны башка яклардан куарга чамалыйсыздыр? Казакъ далалары киң, җылкы малы күп.

Ярулла көпесен чишеп җибәрде. Зур гына симез ит алып согынды да, аның артыннан берничә мәртәбә кымыз уртлады. Кысыла биргән күзләрен Дөябайга текәде:

— Син бу якларның хуҗасы. Бар да сине тыңлыйлар. Мин, инде теләсәм дә, моннан китә алмыйм. Син миңа ышанып бетмисең һәм дөрес эшлисең. Сине ышандырыр өчен, минем синең үзеңә генә сөйли торган сүзем бар. Шуны ишеткәч, аннан соң үзең уйларсың ничекләр итеп хәрәкәт итәргә дә, мине нәрсә эшләтергә дә.

— Шулаймы?

— Шулай.

— Әгәр дә без синең ул сүзеңне барыбызга да сөйләтсәк?!

Ярулла елмайды:

— Мин үзем теләп сөйләмәсәм, мине беркем дә сөйләтә алмас.

— Шулаймы?

— Шулай.

Дөябай азрак уйланып утырганнан соң, үзенең уң ягында утырган зур гәүдәле казакъка карады. Яңак сөякләре нык чыгып торган, кысык күзле, киң битле ул кеше, башын күтәрмәсә дә, хуҗасының үзенә караганын сиземләде. Олы гәүдәсен җиңел кузгатып, урыныннан торды.

— Хоп! Сөйләсен сиңа гына. Кирәк тапсаң безгә җиткерерсең, кирәк тапмасаң, нәрсә эшләргә икәнне кушарсың. Рәвилнең юлын кисеп, үзен юк итеп, бетереп ташларга кирәк. Без күрше тирмәдә булырбыз. Җаныбәк калсын.

Җаныбәктән башкалары, баш җылкычыга ияреп, тирмәдән чыгып киттеләр. Дөябай ишек төбенә күчеп, чүгәләп утырган Җаныбәккә бер караш ташлап алды да Яруллага борылды:

— Йә, нугай ака! Нинди серең бар икән миңа гына дигән, тыңлап карыйк. Сөйлә! Тик мине алдарга болашма, начар булачак! Без, нугайларның урлыгыннан туйдык! Бәясендә тормабыз — Рәвилне тотарга ярдәмләш. Әйт, кайчан һәм кайсы җиргә килә ул җылкылар урларга? Сөйлә, мин тыңлыйм!

Ярулла акрын гына тавыш белән сөйләп китте:

— Рәвилнең өйрәтелгән Кара Кашка биясе бар. Маңгаенда ярты уч зурлыгындагы ак кашка. Аннан сул аягының бәкәлендә, тышау сала торган җирендә, уелганнан, тагын ак йонлы урыны бар. Анысы тик тышау салганда гына күренә. Бия бик сылу гәүдәле, сөлек кебек. Үтә дә акыллы хайван. Рәвил шул биясен сезнең якларга алып килеп, җылкы көтүенә кертеп җибәрә. Төнлә белән. Кара бия көтү башлыгы айгыр белән дуслаша. Кара бияне көтүгә кертеп җибәргәннән соң кайсы чакта өч көн үтә, кайсы чакта дүрт-биш тә булгалый. Кара биянең айгыр белән дуслашуыннан тора инде ул көннәрнең исәбе. Кара бия көтүдә яши, айгыр аның янында. Аннан соң инде бер төнне җылкычыларны бәйләп ташлап...

— Үтергән чакларыгыз да бар бит...

— Кәсеп шундый булгач, нәрсә эшләмәк кирәк инде!.. Җылкычыларны бәйләп ташлап, каршы торганнарын, яисә качарга маташканнарын атларыннан бәреп төшереп юк иткәннән соң, төп эшкә тотынабыз инде. Җылкы көтүен бер тирәдә әйләндереп чаптырып кыздырырга кирәк. Бу эшкә Кара Кашка иң алдан чаба. Җылкы көтүенең башлыгы булган айгыр Кара Кашкадан калмыйча түгәрәк әйләнеп чабарга тотына. Җылкыларны чабып кыздыргач, Рәвил ачы иттереп, сузып сызгырып җибәрә. Шул ук мизгелдә Кара Кашка үзебезнең якка, кайту ягына салдырып чыгып чаба. Айгыр аның артыннан. Айгыр артыннан җылкы көтүе. Безнең бурыч — шул вакытта җылкы көтүеннән кирәкле кадәрне бүлеп алып, үзебезнең якларга куалау...

— Куу юлын ничек билгелисез инде?

— Тургай далаларыннан ук башланган, Уфаны үтеп Самарга кадәр сузылган Ат Караклары Сукмагы бар. Бик күп еллардан бирле, әллә кайдагы борынгы заманнардан ук салына башлап, Тургай далаларын, казакъ якларын безнең җирләр белән тоташтырган Сукмак ул. Рәвил, ул сукмакны мин салдым дип мактанса да, алай түгел. Казанны канга батырып алган Явыз Иванга кадәр үк булган Сукмак ул.

— Ала-ай! Сине тыңласаң, Рәвилнең иртәгә кайсы җәйләүдән җылкы кууын, кай төшкә барымтаг, кәсепкә килүен син әйтә алмыйсың бит инде?

— Төгәл әйтеп булмый. Ә чамалап була. Кара Кашканың килеп чыгуы белән. Синең җәйләүләргә Рәвилнең килмәвенә ничә ел инде?

— Дүрт елдан артык бугай инде.

— Түгел шул. Өч ел тулып, дүртенчегә генә китте. Кайсы җәйләүгә кәсепкә баруын Рәвил беркайчан да, беркемгә дә әйтми. Хәтта иң якын дусты Чынтимер дә белми иде. Кара Кашка көтүгә килеп керү белән тирә-як җәйләүләрдән елгыр егетләрегезне тиз генә җыеп алырга була...

— Анысы инде безнең эш, синеке түгел. Өйрәтмә ул турыда.

Агач тустакларга кымыз агызды да, берсен Яруллага тоттырды.

— Син, Ярулла, ничек уйлыйсың, бу ел Рәвил кай тирәгә килер?

— Бу ел килмәс ул.

— Ничек инде, килмәс?!

Ярулланың битенә нинди дер җылы елмаю җәелде.

— Кара Кашка бу ел колынларга тиеш.

— И-и-и!..

— Әйе, колынларга тиеш. Узган елларга йөгерү тизлеген киметте Кара Кашка. Рәвил ниндидер үләннәр кайнатып эчерә аңарга. Шунлыктан Кара Кашка Айгыр белән кушылмый. Кысыр кала. Кәсепкә йөри. Тизлеге кимегәч, узган ел айгыр белән кушылдырды Рәвил аны. Май

азакларында колынларга тиеш Кара Кашка. Самар ягындагы татар авылына алып киттеләр Кара бияне. Шунда колынлаячак.

— Шулай булгач, син нигә килдең безнең якларга? Киләсе елга гына килсәң, үзеңә җайлырак булмас идемени? Берәр хәйләң юкмы? Җавапла!

— Хәйләм юк. Самарда тәрбия юк миңа. Үлеп китәрмен дә, Рәвилдән үч ала алмый калырмын дип курыктым. Самарда хәер сорашып көн күрүләр бик авыр. Сездәге ит белән кымызда өметем.

— Ашатырбыз, эчертербез, терелтербез. Үлән белән дәва итүчеләр дә бар безнең халыкта. Кымыз җитәрлек. Артыгы белән. Рәвилне алырга ярдәмең тиеп уңышка ирешсәк, акчаны да күп бирербез. Узган ел ничә җылкы куа алдыгыз?

— Ике йөз дә унҗиде. Тик мин катнашмадым. Авырыйм бит.

— Ырымбур ярминкәсендәге хак белән шул җылкылар бәясен бирербез. Тоташы белән. Рәвил кирәк безгә.

Дөябай уйчан күзләре белән бик озак алдындагы кымыз тулы табакка карап утырды да аны Яруллага табан этәрде:

— Аша, эч. Тик үлә күрмә. Рәвилне капчыкка кертер алдыннан аңа сине күрсәтәсем бар. Ничек эләккәнен белеп керсен. Күп явызлык китерде ул безгә. Эч, күпме бара, шул хәтле аша-эч!

— Бик күп эчә алмыйм шул мин аны, үтләтә.

— Һәр көнне аз-азлап кына арттыра бар. Өйрән. Акчаны кулыңа биргәч, бер киңәш итәрмен сиңа.

— Нигә алай?

— Шулай кирәк. Акчаны Ырымбурда бирербез. Монда ярамас. Безнең казакълар сине, акчаң барын белеп калсалар, Ырымбурга җиткермәсләр. Безнекеләрдән бигрәк урысларның таможнясе сизеп калса, бетте башың.

— Киңәшеңне хәзер әйт.

— Юк. Ярамас. Иртәрәк әле.

— Әйтмәгәч, нигә мине алдан искәртәсең?

— Рәвилне тотуда эшләгән... эшләреңне уңышлы иттереп башкарсын дип...

Тагын берничә көн узгач, Җаныбәк Ярулланы Дөябай җәйләвеннән алып китте. Ярулла киткән көнне Дөябай үзе күренмәде. Җәйләүне чыгып байтак ара узгач, Җаныбәк көлемсерәп, Ярулладан сорады:

— Дөябай сиңа яшәргә ике җәйләү билгеләде. Берсеннән икенчесе ерак түгел. Берсендә синнән яшькә олырак бер нугай хатыны бар. Шуның тирмәсе кечкенә булса да, бик җыйнак. Ике малайлары да бар. Зурысы сигез чамасында. Сине шул хатынга кертергә кушты. Риза булмасаң, минем белән китәсең. Безнең җәйләүгә. Уйла, җавапла!

Ярулла күңелсез генә елмайды да җавап бирде:

— Миннән олырак булса да, ул хатынга дәртле ир кирәктер бит инде. Соңгы тапкыр кыйналганнан соң минем ирлегем юк... Тибеп, изеп... кыйнадылар... женси җирне...

Ярулла атын туктата биреп, офыктан күтәрелеп килгән зур, кызыл кояшка бик озак карап торды. Сул кулының бармаклары ат ялын таслыйлар иде. Җаныбәк, эчке бер тетрәнү белән, үзе өчен бу ят булган нугайга, аны кызганып ияре өстендә дәшми генә утыра иде. Ярулла яшь тулган күзләрен җылы кояштан аерып алып, юлдашына карады.

— Бер балалы таныш тол хатынга йортка кереп, караклыкны ташларга ният иткән идем мин. Хараплар гына итте мине Рәвил мәртәт. Бер гөнаһсызга. Чынтимерне үтерткән кебек үтертеп ташласа, бу хәтле яфа чикмәс идем... Әйдә, Җаныбәк, синең җәйләүгә. Әллә бар гомер, әллә юк гомер дигәндәй, аз гына булса да тыныч итеп яшәп карыйм әле...

* * *

Чыннан да, киләсе яз житкәнче Ярулла тыныч көннәр үткәреп яшәде. Ат кылыннан дүртләп төрле юанлыктагы озын-озын аркан-нар үрде. Каештан йөгәннәр текте, аларны чүкеп жиз, көмеш алкалар, бизәкләр белән матурлады. Эреле, ваклы чуклар такты. Казакъ-ларга иң ошаганы Ярулла ясаган иярләр булды. Казакъларның күпчелеге Ярулланың кемлеген белмәсәләр дә, аңарга, оста кулларына зур хөрмәт белән карадылар. Ярулла тимерчелек эшен дә азрак чамалый иде. Шун-лыктан казакъларга пычак-хәнжәрләр, өзәнгеләр, йөгәннәргә авызлык-лар чүкеп ясады.

Җәйге эссе кояш җылысында, тирмә арты чирәмендәге киез өстенә утырып ул, казакъ хатыннарына агач кашыклар, капкачлы тоз савыт-лары, кымыз тустаклары ясады. Яшәеше күңелләнә башлады Ярул-ланың. Үзенең бала чагын исенә төшереп, ярым шәрә хәлләрендә йөгере-шкән казакъ малайларын «Чебенле», «Шаралы», «Уникe чыбыклы» уен-нарга өйрәтте. Барлык дөньясын онытып, гыжылдап тын ала-ала, үзе дә шул малайлар белән уйнады, йөгереште, балачагындагы кебекләр ит-тереп алар белән бергә көлеште. Кая гына барса да, нәрсә генә эшләсә дә, Ярулла янында һәрчак малайлар төркеме булыр иде.

Җаныбәк тә абзасына карагандай карый башлады аңарга. Дөябай, Ярулланың качып китүеннән шикләнеп, Җаныбәкне җылкы караудан азат итеп, тик сакчылык вазыйфасын гына үтәргә билгеләп куйган иде. Малай-шалай уратып алган Ярулланың башына качу уе кермәде дә. Ул инде үз гомеренең озакка сузылмасын белеп яши. Аның шулай буласын казакъ егете Җаныбәк кенә аңлый алмый иде. Ашарга утырганда ул Яруллага итнең симезен тоттырды, ипи-наның зурысын, йомшагын бирде. Яруллага ияреп каештан чыбыркы, дилбегә, камчылар үрергә өйрәнде. Ярулланың нечкә генә уналты каештан камчының беренче буынын үргәнен ул кечкенә малайлар кебек исе китеп, куана-куана, сокланып карады.

— Гу-у-уйй, чырагы-ым, гу-у-уйй! Ничек башың җитә синең бу каеш-ларның һәрберсенең кая барырга тиешлеген белергә-ә! Ай-пай-па-ай!

Ярулла аны чыбыркы, камчы үргәндә иң башта дүрттән үрергә өйрәтә башлаган иде, Җаныбәк ап-ак тешләрен күрсәтеп, башын азрак артка ташлый биреп көлеп җибәрде:

— Дүрттән, алтыдан үрүне һәр казакъ малае белә. Син мине сигездән үрергә өйрәт, аннан карарбыз...

Тыныч кына итеп җәй үтеп китте. Яңгырлы-җилле шыксыз көннәре, төннәре белән көз җитеп, киез тирмәләрне юешләп, эчендәге кешеләрнең күңелләренә шом һәм караңгы уйлар салып, аларны җылы киенергә, хайваннарны күшегергә мәҗбүр итеп яшәтте дә, үзе артыннан салкын, буранлы кыш алып килеп, аңарга кешеләрне газап чиктерүне туктата күрмә дигәндәй, китеп тә барды.

Кышлауларда төннәр озак үтә. Тынчу, сасы, кешеләр күп җыйналган алачыкларда һава җитми. Тибеннән кайткан маллар ярым ач. Кешеләр дә, барлык хайваннар да, аеруча этләр сагынып-зарыгып яз килгәнне көтә. Җәен җылкычылыкта йөргәннәр төрле хәйлә, тозаклар корып, бүре, төлке, куян аулыйлар. Күпләр атларына атланып, кышлыкка якын килеп «кәсеп иткән» бүре өерләрен туздырып тараталар. Бүреләрне атып та, «камчылап» та алалар. Ерак калада тормыш көткән нугай-татарлар-ны барып табып, аларны яллап бүре тиреләрен иләтәләр, туннар, толып-лар тектерәләр. Чапкан уңайга муенын борып, артка карый белмәгән, тик алга гына чапкан бүреләрне ат өстендә бастыралар. Куып җиткәч чукмар белән сугып бүренең сыртын сындыралар, остараклары бүренең киң маңгаен йә чукмар белән, яисә очына кургаш тегелгән камчы белән яралар. Шунда далада ук, туңмас борын, тиресен сыдырып та алалар да, бүре исеннән колакларын шомартып таптанган атларының ияренә тунап

алынган бүре тиресен салындырып салып тагын ауга керешәләр яисә кайтып китәләр.

Ярулланың иң сокланганы — җәй буена үзе белән шара суккан, чебенле уйнаган малай-шалайның, зурларга охшатып, атка атланып, агачтан ясаган чукмарлар тотып, кулларына камчылар алып куян ауларга чыгып киткәннәре. Ютәлен басарга тырышып, җылы тун, йоныктан бәйләнгән яулык өстеннән башына зур колакбүрек, аякларына җылы итекләр киеп, Ярулла да бер мәртәбә шул дус малайлары белән куян ауларга чыкты. Яртылаш сукырайган биягә атланып, малайлар кая барсалар, шунда йөреде. Күнозын шул ыбыр-чыбыр малайлардан калмастан ияреп йөреп, аларның осталыгына хәйраннар калды. Кичне кайткач, тәне кызышып, башы авыртып ике тәүлек буена киез өстендә авырып ятты ятуын. Тик ауга чыкканына үкенмәде, киресенчә, ауда йөрәгеен мизгелләрне һәрчак күтәренке күңел белән телгә ала һәм исенә төшерә торган булып калды.

...Малайлар өере атларга атланып, кышлактан ике чакрымнар тирәсе китеп, кечкенә куаклар белән капланган, кар астындагы елгачык янына җиттеләр. Башка малайлардан гәүдәгә әллә ни зур булмаган Камчыбай исемле малай ауга чыккан ишләрен ике төркемгә бүлде. Камчыбайның өстенлек иткәнен барлык малайлар да таныйлар һәм аңарга каршы әйтмичә сүзсез буйсыналар иде. Беренче төркем зуррак булып, аңарга ат менеп чыга алган барлык ыбыр-чыбыр тутырылган иде. Икенче төркемдә, Камчыбайдан кала, тагын алты малай. Болары инде 13—14 яшьлек ныклап үсеп килгән малайлар булып, алар иярләп менгән атлар да житезлекләрен күрсәтеп, урыннарында таптаналар иде.

Малайларны ике төркемгә бүлеп бетергәч, Камчыбай шул күзләре белән көлеп, Яруллага карап алды да, әйтә куйды:

— Син инде, нугай әкә, безнең белән чыккач, малайлар исәбенә керерсең. Сине куян куарга куям. Тик кычкырып, тамагыңны бетерә күрмә. Яме! Карап, камчыңны селкеп кенә йөре. Кычкыра башласаң, көч килер.

Бәләкәй малайлар төркеме арасыннан берсенең туныша камчы сабы белән төртте:

— Мин елганың теге ягыннан камчы селтәгәч, кузгалыгыз! Узган кыштагы кебекләр иттереп куыгыз куяннарны! Хоап!

— Хоп! — диде теге, беләкәй малайларга баш малай, бөтен йөзе белән куанып. Урыныннан кузгалып төркемне алып та китте. Житезлегенә караганда, булган малайга охшый иде бу. Ярулла да шулар төркеменә иярде.

Зуррак җиде малай, атларын кузгатып, кар астында яткан кечкенә елга агымына каршы киттеләр дә, бераз баргач, елганың икенче ярына чыктылар. Ул як яр сөзәк кенә булып күтәрелгән үргә әверелеп, кечкенә калкулык рәвешендә тауга үрмәли иде. Елганың икенче ягына чыккан зуррак малайлар төркеме азрак тарала биреп, килгән якларына карап атларын атлаттылар. Алар якынлашкан саен бу яктагылар төркемен дулкынлану биләп ала башлады. Тик Камчыбай житәкчелек итәргә калдырган малай аларны тиз тынычландырды:

— Тик торыгыз!

Барысының да күзләре теге яктан кабаланмый гына килгән төркемдә иде. Шулчак Камчыбай уң кулына тоткан камчысын өскә күтәрде дә һавада селкеде. Янындагы егермеләп малайның күкле-тавышлары белән кычкырып, чыйнап җибәргәннәреннән Ярулланың аты кискен итеп читкә тартылды. Хуҗасын егып төшерә язды. Ярулла, ерылган авызын җыеп ала алмыйча, акыра-бакыра елга яры белән кузгалган малайларга иярде. Берсе иренмәгән, җиз тас та алып килгән. Аны даң-доң китереп таяк белән кыйный. Дөнья уятып, шау-гөр килеп, елга ярына ук якын килеп куян куркыта башладылар. Күп тә үтмәде, елгы яры астындагы куакталлар эченнән борхылдап, кар туздырып, зур бер үр куяны килеп чыкты.

Аның артыннан ук икенчесе. Әйтерсең, бергә куна килгәннәр инде. Таллар арасыннан килеп чыктылар, колакларын аркаларына таба яткырып, җан-фәрман чаба, кача башладылар. Алдан чыккан куян, туктамастан, үргә карап элдердеп китеп тә барды. Теге як яр буйлап тавыш-тын чыгармыйча атларын атлатып кына килгән малайлар төркеменнән берсе, куян чапкан якны кыеклатып кисеп, зур тизлектә атын камчылый-камчылый чаптырып, озын колакның юлын кисәргә ташланды. Арттанрак икенче булып чыккан куян этләр, төлке-бүреләр, кошлар тарафыннан күп тапкырлар куылып, зур тәҗрибә алганы булды, ахры. Яр башына килеп чыккан уңайга ук туктады да, арт аякларына баса биреп күтәрелеп, тирә-якны карап чыкты. Шул ук вакытта өстә каратып күтәрелгән ике озын колагы боргаланып тирә-якны тыңлап та өлгерде. Акырып, чаң сугып, елганың теге яры буйлап килгән вак малайлар төркеменә ул карап та тормады. Үрелеп, елга яры буйлап үзенә табан килгән кечерәк төркемне тагын бер кат карап калды да, үргә табан чапмыйча, анда үзен нинди язмыш көткәнен яхшы аңлагандай, елга яры буйлап зур тизлек белән чабып китте. Кар бураны туздырып бераз томырылып-томырылып элдертте дә, туң ярдан елганы каплаган карга сикерде. Азрак күренми торды да, елганың бәләкәй малайлар сөрән салып акырып килгән ярына атылып менеп китте. Туктап тормады, үз хәлен үзе яхшы белә иде бугай, чабып китеп күздән дә югалды...

Казакъ малайлары өйлә авышканчы куян бастырдылар ат белән. Ысуллары әлләни катлаулы да түгел икән. Бер як ярдан акрып яр астында, төнге сәфәрдән кайтып, куаклар төбендә йоклап яткан куянны оясыннан торгызып, икенче як ярга куып чыгаралар. Ә теге ярда инде ул куянны ат менгән малайларның берсе куып алып китә дә, кулындагы агач күсәк белән сугып ала. Исеме дә үр куяны булганнан, тал төпләреннән килеп чыккан куяннарның күпчелеге тау үренә чабалар. Чөнки үр куянының арт аяклары алгыларыннан күпкә озынрак. Шунлыктан куян үргә шәп чаба, ә тау түбәненә чабуы акрыная, янсә озын аяклары комачау итеп ул мәтәлеп тә китә...

Кичләтә башлаган бер чакта кышлакка кайткан дүрт малайның иярендә берәр куян бәйләнгән, ә Камчыбай икене бәйләп куйган. Камчыбай төркеменнән ике малай бер куян да ала алмаганнар. Шунлыктан алар кышлакка кайтып барган малайлар төркеменең иң артыннан киләләр иде...

Ыжгырып, гайрәтләнеп, барлык дөньяны кар белән тутырырга дип котырынган март бураннары кинәт кенә басылып калды. Кыш буена өшеп-туңган бәндәләрне, хайваннарның тәннәрен, җаннарын җылытып күк йөзенә Ходай биргән җылы кояш тәгәрәп менде. Берничә көн карлар күмеп бетергән кышлакларны, инде тибенергә көчләре бетеп барган җылкыларны, аларга ияргән сыер-куйларны карап кояш күк буйлап үрмәләде дә, инде кышка җитте дигәндәй, барлык галәмне ныклап җылытырга тотынды. Казакъ карты колакчыны салып, ак чәчле карт башын күрсәткән кебек язгы җылыга иң беренче булып эреле-ваклы калкулыкларның ак кылганлы башлары ачыла башлау белән, ак кылганнар ашап туену исәбе белән, барлык маллар калкулыклар башына ашыкты. Алдан озын аяклы атлар, бияләр, узган еллардагы колын-тайлар, аннан сыер малы, аннан инде көтүләренең башлыклары кәҗә тәкәләр һәм иң соңыннан өере-өере белән куйлар...

Барысы да язгы җылы җилдә җелфердәп утырган ак кылганнарга ябырылалар.

Гөрләгән шарлавыклар кузгалып, яр буйларын үги ананың сары чәчәкләре, ачылган тау битләрен сары, зәңгәр төстәге эргәзимбай чәчәкләре сырып ала. Эргәзимбай чәчәге, әле эреп өлгермәгән карны тишеп кояшны эзләп килеп чыккан да, калкулыклар, таулар битләрен матурлап утыра. Яшелләнеп килеп чыгып, чыкканына икенче көнне үк сары, зәңгәр

чәчәкләрен балкытып утырса да, эргәзимбайны мал да, кош та ашамый. Ул агулы. Тумыштан ук комсызлык белән янган кыз бала кебек. Ул да бит, үсеп кияүгә чыкса да, алган кешесенә дә, үзенә дә бәхет, тынычлык китерә алмый. Иренең җанын бимазалый, вакытын, тынычлыгын булмастай мал, байлык таптырып, тынычлыгын ала. Тора-бара иренең дә, үзенең дә кешелек сыйфатларын юкка чыгарып бетерә...

Дала матурланып яшелләнеп килгән көннәрнең берсендә, кичен Ярулла йоклап яткан тирмә эченә кызуланып Җаныбәк килеп керде.

— Киен, киттек!— диде ул, тирмә эчендәге әллә нәрсәләргә абынасөртенә.— Ел буена көткән көн килеп җитте бугай. Ат менеп ике көн чабарлык җәйләүдәге җылкы көтүенә син сөйләгән Кара Кашка биягә охшаган бер хайван килеп кергән. Бүген төнен. Егетләр чапкыннарын кызганмыйча куганнар бу якка. Дөябайга китереп җиткерделәр хәбәрне. Дөябай әле тирә-як җәйләүләргә чапкыннар озата, халыкны җыя монда. Бер төркем монда, икенчесе Тимер казык бай җәйләвенә җыйнала. Тор, киен. Син Кара биянең Рәвилнеке икәнне танып әйтергә тиешсең. Бөтен җәйләүләргә малайлар чаба. Зурлар чапса, Рәвилнең берәрсен күреп шиге төшүе бар. Нугайларның буктаган ятагын үзләренә сиздермичә эзләргә идек Дөябай рөхсәт бирмәде. Атларны алырга килгән җирләрендә эләктерергә кирәк, ди.

Ел буе тик ятып, ютәлләве басылып, гәүдәсе түгәрәкләнеп тазарган Ярулла күкрәгеннән чыгардай булып типкән йөрәк сугуын тынычландырырга тырышып, киенә башлады. Хәрәкәтләре салмак, үзе уйчан иде Ярулла. Тик башы тулы чуалчык уйларны бер эзгә салырга тырышса да, булдыра алмады. «Чыннан да Рәвил килдеме? Кара Кашка да аныкымы? Үтереп куйса? Әгәр башка Кара бия булса?»

Иярдән төшмәстән тәүлектән артык атларны кудылар. Атлары тирләп, корсак асларыннан бүрек-бүрек булып күбекләр коела башласа, аларны алмаштырдылар. Ашап тормадылар. Агач чүмечләр белән кабалана-кабалана кымыз эчтеләр дә, тагын атларга атландылар. Ат өстендә чапканда, туктатмыйча гына, бәрән тиресеннән ясалган бурдюктан әрем кебек әче эчемлек эчтеләр. Эчемлек балачакны искә төшереп әллә ниткән үләннәр тәме калдырды авызда. Озак иярдән төшмәгәннән Яруллaның ике аягы да агач кебек катты. Аркасы биленнән алып муенына кадәр ут белән ышкыган кебек сызлый башлады. Муены, башын тота алмыйча, ычкынып киткән кебек тартыша иде инде. Түзмәде, ыңгырашып, атының тезгенен тартып туктата башлады. Тик Җаныбәкнең туктарга исәбе юк иде. Ул бер генә сүзне кабатлады:

— Тизрәк! Тизрәк! Тизрәк!

Тик Ярулла аны аңлаудан узган иде инде. Ике куллап атының муенына ябышып, иярдән шуып төшеп ат тояклары астына егылды. Җаныбәк атыннан сикереп төште дә Яруллaны чишендерә башлады. Теге исә гаҗизләнеп:

— Син... ни эшлә... тәсең мине?..

— Шаулама, Ярулла акә, Шаулама! Хәз-зер юньгә кертәм мин сине.

Анадан тума Яруллaны яр астындагы чишмәгә күтәреп алып төште. Салкын чишмә суына бастырып куйды да, капчыгыннан чыгарган ат коерыгын сабынлап, Яруллaның тәнен нык иттереп ышкырга тотынды. Бурдуктан тагын теге ачы суны күпләп эчерде. Суык су белән Ярулла өшеп калтырый башлаганчы коендырды. Аннан соң ияр букчасыннан зур киндер алып, Яруллaның тәне кызып яна башлаганчы бик ныклап ышкыды. Яруллaны атына атландырды да, тагын дала буйлап чыгып чаптылар. Илле-алтмыш чакрым чамалары узгач, хәле беткән Ярулла күзен йомып ат ялына башып салды. Җаныбәк, шулай буласын әллә кайдан белгәндәй, атыннан сикереп төште дә, Яруллaның аякларын өзәнгедән азат итте. Авырайган гәүдәне иярenә аркылы салды да, кышын Ярулла үзе ишкән кыл аркан белән ике култык астыннан үткәреп, атның корсагы астыннан икенче якка чыгарып, ике тезе астыннан ныклап бәйләп куйды.

Билбавыннан ияр кашагына ныклап бәйләде — шуып төшмәскә. Аты тирәли йөреп чыкты. Үз эшеннән үз канәгать калды. Көлеп алды:

— Ияредән төшмичә тәүлек куу сиңа тирмәдә ятып кымыз эчү түгел. Түз, күп калмады. Кара Кашка белән Рәвил көтә сине!

Ярулла атының йөгән тезгенен үзенең ияре башына бәйләде дә, сикереп атының ияренә менде. Хәрәкәтләре житез һәм кискен иде. Кузгалып киткән Ярулла атына да, үзенекенә дә камчылап яхшы гына тамызды. Тагын бер җәйләүдә туктап атларны алмаштырдылар. Тирмәгә аркасын терәп киез өстендә күзләрен йомып утырган Яруллага таба иелеп, Җаныбәк сорады:

— Корсак яннарың, күкрәгең авыртамы?

Ярулла «юк» дигәнне аңлатып, башын селкеде. Җаныбәк куанып елмайды.

— Життек дияргә була инде. Түз аз гына.

Кояш баер алдыннан кирәкле җәйләүгә килеп життеләр. Аттан чишеп төшергәч, Җаныбәк, кулындагы камчысы белән итегенә шапылдатып суга-суга, Ярулланы бер тирмә тирәли ун тапкыр уратып йөрете. Аннан соң йөгерергә кушты.

— Монысы булмас миннән, Җаныбәк. Хәл юк. Тын алуы авыр бик.

— Булыр, йөгер! Юкса камчылыйм.

— Минеме?

— Сине. Син, Ярулла акә, исән калырга тиешсең. Йөгер!

Ике авыр гер «тагылган» аякларын өстерәп, Ярулла йөгергәндәй иттереп, вак-вак кына атлап китте. Унлап адым үткәч, юыртуга күчте һәм алдыннан йөгергән Җаныбәккә ияpде. Бер тирәдә тупланган тирмәләрне, үзләренә ияргән берничә эт белән берлектә өч мәртәбә урагач, «йөгерүләре» чынга әйләнә башлагандай булды. Көпесе өстеннән пар күтәрелгән Яруллага күзләре белән карап, Җаныбәк бер тирмәнең ишеген ачты.

— Кер тирмәгә! Юынабыз хәзер!

Зур агач ләгәнгә бастырып, Җаныбәк Ярулланы җылы су белән сабынлап юды. Аннан соң боздай салкын су белән коендырды. Тагын зур киндер сөлге белән тәне кызарып чыкканчы каты итеп ышкыды.

— Безне көтәләр. Ашап-эчик тә китәбез. Кара бия тотылган хәлдә бугай.

Караңгы төшә башлаганда Җаныбәк белән Ярулла җылкы көтүе янына киттеләр. Җылкычыларның берсе, Яруллага ишетелмәслек итеп, Җаныбәккә нәрсәдер әйтте. ... «дүрт аягында...» — дигәнне генә ишеткәндәй булды Ярулла.

Нәрсә турында сүз барганны аңламады Ярулла. Аны җылкы көтүе уртасына, казыкка озын аркан белән бәйләп куелган Кара Кашка янына алып килделәр. Ярулла бияне тиз генә карап чыкты. Башын түбән иеп күңелсез генә торган бия, чыннан да, Рәвилнең атаклы Кара Кашкасы иде.

— Рәвил биясеме? — дип сорады Җаныбәк акрын тавыш белән.

— Нәкъ үзе. Кара Кашка.

— Әллә шигең бармы? Тавышың шулайрак.

— Кара Кашка инде. Тик никтер күңелсез әле бу. Ә ул бер урында басып тора алмый торган хайван иде ләбаса.

— Аның күңелсезлегенең сәбәбе бар.

Җаныбәк җылкычыга ым какты:

— Ычкындыр элмәктән. Җибәр иркенгә.

Ярулла атның муенындагы элмәккә ябышты.

— Төнен җылкы көтүен уратып Рәвил сызгырса, Кара Кашка бит көтүегезне алып китәчәк. Ярамый аны иреккә җибәрергә.

— Юк инде, чырагым! Кача алмый Кара Кашка хәзер. Тоткан көенә дүрт аягының да бәкәл тирәли сеңерләрен кистеләр.

Җаныбәкнең тавышы тантаналы яңгырый иде:

— Җәрәхәтләрен куйның туң маен эретеп сыладылар. Киселгән җирләрен, корсагыннан йолкыган йонын ботап май белән сыладылар. Җәрәхәтләре ике-өч көннән бетәр. Тик бетте ул хайван. Җылкы көтүе алдында башкайларын чайкап башкача чаба алмаячак инде...

Ярулла җавап бирмәде. Дүрт аягына да аксап атлаган Кара Кашкага карап йөрәге кыса башлады. Кара Кашканың гарипләнүендә төп гаеп үзендә булганны Ярулла яхшы аңлый һәм бөтен уе, торышы белән биянең гарипләнүе белән килешә дә алмый һәм аның шулай булганына ышанасы да килми иде...

Түземсезлек белән көтеп тагын ике көн үтте. Җәйләүдәге тирмәләр янында ат менеп күренеп, аннары юкка чыккан малай-шалайдан башка ирләр затыннан артык бер генә кеше дә күренми иде. Уртадагы зур ак тирмәгә ул малайларны Җаныбәк берәмләп кенә алып кереп китә. Малайлар, балаларга хас булмаган зур җитдилек белән, зурлар кушкан йомышларны башкаралар иде. Ярулла, ак тирмә эчендә кемнәрнеңдер күренмичә яшеренеп ятып, Рәвилне тоту эше белән җитәкчелек иткәннәрен чамалап алды.

Ярулла уйлый: Җәйләүдән берничә чакрымда гына, Кара Кашка кертелгән җылкы көтүе, күзгә күренмәслек итеп, казакъ егетләре белән уратып алынган. Шулар белән элемтәне вак-төяк малайлар башкара. Тик күпме генә тырышып күзәтсә дә, Ярулла көндезләрен җәйләүне уратканнарны күрә алмады. «Көндез ераккарак китеп, төнлә бәлки алар бөҗра ясап җылкы көтүен кысалардыр?» — дип уйлады ул.

Кара Кашканы Ярулла карап таныганның өченче төне иде. Кыш көне куян куган малайлар белән җитәкчелек иткән Камчыбай, менгән атын кара күбеккә төшереп, җәйләүгә чабып килеп керде. Менгән ат белән анда керергә ярамаганны яхшы белсә дә, атын уртадагы зур, ак тирмә янына куйды. Сикереп атыннан төште дә туктамастан тирмә эченә кереп тә китте. Анда, чирәмгә калын иттереп җәелгән киезләр өстендә берсеннән-берсе таза егермеләп казакъ егетләре ята иде. Камчыбай, берсенә дә карамыйча йөгереп түргә узды да, нәрсәдер сизгер төстә утырган Дөябайга алып килгән хәбәрен әйтеп салды:

— Нугайлар җылкы көтүенә юл тоталар!

Тавыш-тын чыгармыйча бар да торып бастылар да, тирмәдән тиз генә чыгып, күл буендагы әрәмәлеккә йөгерештеләр. Җаныбәк кара тирмәгә кереп, чишенмичә йоклап яткан Яруллaның йөзенә иелде:

— Тор, Ярулла ака! Рәвил килә. Хәбәр бар! Син сугышка катнашма. Кырылыш беткәч кенә, Рәвилне карарсың. Син сөйләгәнне бар да белә. Без аны тере көенчә алырга тырышачакбыз...

Бәрелеш беткәч, Яруллaны шул урынга алып бардылар...

Җылкы көтүен зур гына күл буена китереп, Рәвил өчен качу юлының бер ягын күл белән каплаганнар. Ярты төн уртасында Рәвил алты иптәше белән килеп җиткән. Өч җылкычыны бәйләп, күлнең сай җиренә ташлаганнар да, җылкы көтүен күл ярыннан читкәрәк куганнар. Корырак җиргә күтәрелгәч, җылкы көтүен әйләндереп куа башлаганнар. Тик бу юлысы җылкы көтүе ни өчендер өерелеп әйләнмәгән. Кара Кашканың аяк сеңерләре киселгән булса да, шуңа өстәп, гомере буена җылкычы ияре астында йөрегән икенче биянең муенын аркан белән бәйләп куйганнар. Кара Кашка Рәвилнең тавышын танып, аның җылкы көтүен өереп куyына буйсынып, гарип булса да үз вазыйфасын башкарырга тырышып караган. Тик арканнан ычкына алмаган. Хуҗасы өйрәткәнчә җылкы көтүе алдында уйнаклап чабып өйрәнгән Кара Кашка чыдамаган, арканда тартылып арт аякларына баскан да, кешнәп җибәргән. Биянең кешнәве Рәвилгә җылкы көтүе тирәсендәге фаҗигане ачып салган. Рәвил өзәнгеләрендә аякларын турайтып, җылкы көтүе өстеннән караган да

үзләрен уратып алырга тырышып төрле яктан чапкан күпсанлы атлыларны күреп алган. Камчысын һавада селтәп, иптәшләренә сөрән салган:

— Көтү эченә!

Рәвил белән берлектә, барысы да көтү эченә ташланалар. Тик бәхетсезлекләренә каршы, җир астыннан пәйдә булгандай, жылкы көтүе эчендә атларына тотынып йөгерешкән казакъ егетләре иярләренә сикереп меналәр дә Рәвилгә, аның иптәшләренә ташланалар. Дөябайның атаклы жылкычысы Кара Мөхтәр җитәкләгән шул төркем зур җитезлек белән Рәвилгә һөҗүм итә. Кара Мөхтәр иң алдан зур, түгәрәк башлы чукмарын күтәреп Рәвилнең үзенә якынлаша башлый. Кара Мөхтәрнең зур күсәге, һава ярып, Рәвилне юк итәрлек тизлектә корбанына атыла. Шул ук мизгелдә Рәвил, бөтен гәүдәсе белән ияреннән уң якка ташланып, аты өстеннән юк була. Зур чукмар, бушлыкны ярып, Рәвилнең ияре өстеннән генә сызгырып үтеп китә. Шул ук мизгелдә, өзәнгедән азат ителгән сул аягы белән җирдән этенеп китеп, Рәвил ияре өстенә янә очып куна да, чукмарына ияреп аты өстендә кыйшайган Кара Мөхтәрнең муенына кулындагы чылбыр белән китереп тондыра. Чылбыр сукканнан муены шартлап сынган Кара Мөхтәр, артка авышып, атының өстенә ятып аз гына бара да, аннан соң кулларын җәеп ияреннән салынып төшеп, җирдән өстерәлә башлый. Курыккан айгыр аның гәүдәсен далага алып чыгып чабып, кая барганын да белмичә төрле якка сикергәли башлый.

— Егетләр, минем арттан калмаска!— дип Рәвил бөтен даланы яңгыратып кычкыра да, кайтасы якның киресенә, казакъ даласының эчке ягына каратып, менгән атын камчылап чаптырып китә. Утны, суны кичкән, күпне күргән, күпне кичергән кабак башы белән Рәвил бернәрсәне аңлап өлгерә: кайтуның кире ягына чабып качсаң, ул якта ат каракларын тотучы казакълар бик азлар, яисә бөтенләй юклар. Далага чабарга, куучыларны чаптырып таркатырга, аннан соң күз күрер нәрсә эшләргә. Атлар шәп, иншалла котылырбыз!

Тик Рәвил бик нык ялгыша.

Җиде кешедән торган ат караклары төркемен казакълар ярым ай кебек арттан уратып, артларыннан эзәрлекләп кысып киләләр. Каракларның атлары җитез, чыдам. Тик Дөябай да төшеп калганнардан түгел. Ул да үз егетләрен тизлеге, чыдамлыгы, озын юлда да армыйча чаба торган атларга атландырган. Ел буена казакъ далалары буйлап җыелган атаклы чабыш атлары — казакъ егетләрендә. Рәвил дә, аның иптәшләре дә эшләренең мөшкелләнә барганын берничә чакрым чапканнан соң аңлый башлыйлар. Чөнки ике ара кыскара барып, ат караклары инде казакълар ясап чапкан ярымайның эчендә калганнан-кала бара. Рәвил аңлый: тагын бер ун-унбиш чакрым чапсалар, ярымайның ике очы бергә килеп кушылачак. Дөябай Рәвилнең казакъ даласы эченә качуын да күз алдында тоткан һәм, шулай була калса, ул ат каракларын караңгыда күренмәгән ике күл арасындагы сазлык-баткаклыкка куарга алдан ук карар итеп куйган...

Иң алдан юл ярып чапкан Рәвил, аты баткаклыкка чабып кереп, сөрлегеп киткәч, атының башы аша очып, җиргә барып төшә. Гадәтенчә, җиргә кагылган уңайга ук тәгәрәп китәргә итеп, гәүдәсен җыйнап йомарланып караса да, берни барып чыкмый. Җиргә бәрелүе белән баткактан шуып китә. Арттан килгән өч иптәше Рәвилнең аты сөрлегеп киткәнне күреп, үзләренең атларын арт аякларына бастырып, тыеп туктаталар һәм артларыннан килеп җиткән казакъларның күсәкләре, чукмарлары астына эләгеп, шул ук мизгелдә һәлак булып, иярләреннән җиргә коелып төшәләр. Кара пычрактан сикереп торган атының тезгененнән эләктереп ала да, Рәвил янәдән ияр өстенә очып менә. Баткаклык кырында акырабакыра сугышкан иптәшләренә ярдәмгә ыргыла Рәвил. Җан өчен сугыш китә казакъ даласында.

Исән калган ат караклары Рәвил янына тупланып, чукмарлары, кулларындагы чылбырлар белән үзләрен уратып алган казакъларга каршы

сугыша-сугыша, аларны ерып, тәгәрәтеп, үзләренә чыгып ычкыныр өчен котылу юлын әрчи башлыйлар, алга ыргылалар. Туган якка юл әрчелә башлаган кебек була. Тик...

Дала сугышында казакълар ат каракларыннан остарак булып чыга. Шуның өстенә, күпчелек көч алар ягында иде...

Җан биреп, җан алышып сугыша-сугыша алга барган Рәвилнең төркеме артында каты, көчле тавыш белән нәрсәдер дип акырдылар. Шул ук мизгелдә, атларының авызын авызлыклар белән ерта-ерта ике якка аерылып, ат каракларының артыннан юл ачтылар. Тик арадан берсе аңлый алмый калды. Ул арттан, Минияр исемле ат карагын чукмарга алырга омтылып, һаман, сугыша иде. Рәвил төркеме артыннан барлыкка килгән ачыклыкка, аҗгырып-акырып, ат менгән утызлап казакъ зур тизлек белән чабып килеп керделәр дә туктамастан атларының гәүдәләре белән ат караклары төркеменә китереп бәрделәр. Аяклары, сыртлары сынган атлар җан биргеч, ачы тавыш белән чыйнап кычкырды. Ат гәүдәләре ауды, кешеләр ат тояклары астына тәгәрәп төште. Ачыргаланып кычкырган тавышлар, ыңгырашулар, сүгенүләр бергә кушылып, һавага куркыныч шом салды...

Берничә минут үтүгә, бар да тәмамланган иде. Ыңгырашкан атларны, алар астыннан чыга алмыйча ярдәм сорап кычкырган кешеләрне илледән артык казакълар урап алдылар. Сул яңагыннан аккан канны колакчыны белән каплаган Дөябай беркемгә дә аттан төшмәскә боерык бирде. Түгәрәкләп сугыш беткән урынны уратып алдылар. Ыңгыраша-ыңгыраша атлары астыннан чыга алган өч казакъ егете күренде. Дөябай, камчысы белән күрсәтеп, аларга ярдәм итәргә кушты. Дөябай атлар, кеше гәүдәләре боталанып яткан урыннан күзен алмады. Атлылар уртасындагы түгәрәкне ул бик җентекләп карый иде. Тавыш-тынсыз гына ул нәрсәдер көтә кебек иде. Бераз аты өстендә утыргач, кулындагы чукмарын ияр кашагына элде дә, биленә кыстырган камчысын уң кулына алды. Түземсезләнеп берничә тапкыр итеге балтырына суккалады да уртага карап кычкырды:

— Рәвил, чык! Бетте синең көнең!

Дөябай тавышыннан соң азрак вакыт үткәч, уртада бер гәүдә селкенде һәм зур авырлык белән аягына баса башлады. Өсте-башы баткакка, канга буялган атаклы ат карагы Рәвил иде аягына баскан кеше. Гәүдәсен турайтып баскач, Рәвил кулындагы чылбырын аяк астына ташлады да Дөябайга кан баскан күзләрен күтәреп карады. Карлыккан тавышы белән әйтте:

— Син кем, Дөябаймы?

Җавап урынына Дөябай камчысын һавада селтәде:

— Авыру нугайны китерегез!

Казакълар атларын кузгатып юл бирделәр. Дөябай янына ат менгән, йөзе ап-ак Яруллага керттеләр. Бай аңарга карамыйча, сул кулындагы колакчыны белән яңагын баскан хәлдә, Яруллага мөрәҗәгать итеп уң кулындагы камчысы белән Рәвилгә төртеп күрсәтте:

— Кем бу? Әйт!

Ярулла куркуыннан бергә ябешкән иреннәрен аерып ача алмыйча азаплана иде. Рәвилнең йөзе кыйшаеп, елмаюга охшаш бер хәрәкәт барлыкка килде. Мәсхәрәле тавышы да ишетелде:

— Нигә сатлык Яруллადан сорыйсың син, ир-егет Дөябай. Үзем әйтәм мин сиңа кемлегемне. Синең байтак җылкыларыңны дала буйлап куып алып киткән Рәвил исемле егет мин булам.

Дөябай яктырган йөзен Яруллага борды:

— Дөрес әйтәме?

Ярулланың көче тик баш кагарга гына җитте.

Дөябай аның баш кына кагуына кычкырып ук җибәрде:

— Телеңне йоттыңмы әллә? Кем бу?

Ярулла авырлык белән төкереген йотты да көч-хәл белән авызыннан сүзләрен эткәләп чыгарды:

— Рәвил... үзе...

Рәвил үзен уратып алганнарны акрын гына күздән кичерде.

— Синеке җинде... Дөя-бай! Тик монда, бүген минемчә бетәчәк! Синеңчә түгел...

Ысылдап һавада аркан очты. Тик ул аркан Рәвилнең гәүдәсен уратып алганда соң иде инде... Рәвил яшен тизлеге белән иелде дә уң итеге балтырыннан хәнҗәр тартып чыгарды һәм чыгарган уңайга ук күкрәгенең сул ягына, үзенең йөрәгенә китереп кадады. Аркан тартканга бирешергә теләмәгәндәй, Рәвил алга янтая биреп азрак басып торды да турая башлады. Кулындагы хәнҗәрен кыскан хәлдә тураеп бетте дә, гөрселдәп аркасы белән казакъ даласы җиренә барып төште. Күкрәгендәге хәнҗәр ясаган җәрәхәттән башта аз гына кан чыкты. Аннан соң, үзенә юл тапканга куангандай, чыжылдаган тавыш чыгарып ага башлады...

* * *

Рәвилнең тере калган ике иптәшен, каты җәрәхәтләнгән булсалар да, капчыкларга салып тормадылар. Муеннарына элмәк салдылар да, ат ияренә бәйләп, җирдән өстерәтеп буып үтерделәр. Гәүдәләрен этләргә ташларга уйлаганнар иде, тик җәйләүнең аксакаллары ризалык бирмәде. Ат караклары булсалар да, үзебезнең мөселман бит, диделәр. Картаеп, инде бөтенләй бетеренгән кечкенә буйлы, аяк-куллары калтыранып торган, шулай булса да зиһене һаман да үткерлеген җуймаган Мөхәммәт Әюп аксакал, үзенең сүзен әйтеп, барысын да тыңлата белде:

— Җылкы малын куар өчен барымтага йөрү безнең ата-бабадан да, нугайларныкыннан да калган егетлек санала ул борын-борыннан. Куып алып китә алса, аныкы, инде дә эләккән икән, җанын калдыра далада. Шунсыз далада яшәүнең кызыгы кимегән. Мөселманча җирләргә кирәк бу гаярь егетләрне...;

Дөябай кушуы буенча Рәвилнең гәүдәсен иптәшләре белән бергә, җаннары киткән урыннан ике чакрым чамасындагы Җамантау дип йөртелгән тау итәгенә күмделәр. Каберә салганда Ярулла кабер янына якынлаша башлаган иде, артыннан ысылдадылар:

— Егет каберенә якын килмә, гәүдәсенә тотынма! Үләксә!

Рәвилне иптәшләре белән бергә дога укып җирләделәр. Кабердән ерак түгел, тауга табанрак ком астыннан күренеп торган зур кара ташны кәйлә, көрәкләр белән казып чыгардылар. Көчәнә-көчәнә тәгәрәтеп кабер өстенә китереп куйдылар...

Бик күп еллар узды. Яңа буын җылкы асраучы казакълар, яңа буын ат караклары дөньяга килеп, килгән тарафларына китеп бардылар. Далада инде Рәвил каракны белмәгән Ходай бәндәләре өчен бу урынның исеме «Җамантаудагы Рәвил карак ташы» булып калды...

* * *

Ун көннәр чамасы узгач, Ырымбурның Кәрван Сарае янында Дөябай Яруллага Рәвилне саткан өчен әҗерен түләде. Көпесен ачып, шыгырдап торган йөзлек акчаларны Ярулланың куенына тыкты да, бер генә дә сүз әйтмичә, борылып китеп барды. Дөябай белән бергә килгән Җаныбәк азга гына баеннан торып калып, ниндидер үкенечлелек тулган сүзләр белән Ярулланың җанын телгәләде:

— Рәвилне юк итеп шатлыкка ирешә алмадык. Без дә, син дә. Ходай безне ярлыкагыл кылсын инде ул эшебез өчен. Сине бигрәк тә инде. Аны үтерү үкенечкә булмаса ярый инде...

Аска игән башын күтәрмичә сүзләрен бетереп куйды:

— ...Баедың инде хәзер. Тере булырга тырыш... Гомерең озакламый киселер синең...

Ярулланың сүзләре тоныкчыкты:

— Минем бу дөньяда яшисем дә килми инде. Рәвилнең... иптәшләре табарлар мине... Ә акчаларны таратып чыгам мин... балаларына...

— Хуш Ярулла әкә...

Җаныбәк әйтеп бетерә алмаган үкенеченме, ачынуынмы селтәгән камчысы белән аңлатырга теләде бугай. Тиз-тиз атлап Дөябай киткән якка томырылып юк булды.

* * *

Рәвил каберенә үлән чыга башлаган көннәрнең берсендә өлкән җылкычы Дөябай хәбәр китерде:

— Бай! Ачуланма без җылкычыларыңа! Кичә төнлә Рәвилнең Кара Кашка биясе көтүдән качкан да туган ягына юл тоткан. Кара айгыр да шул бия белән киткән...

Бай, аптырагандай итеп, сүзсез генә алдында таптанган җылкычыга карап утыра бирде. Тик кулындагы кымыз тулы тустаганын алдындагы ашъяулыгына куйды. Кымыз кайгысы китте байдан.

— Куып тоттыгызмы?

— Юк шул... Җылкычы зур кулларын куярга урын таба алмый башлады.—...Безнең җәйләүдән әллә ни ерак китә алмаганнар. Биянең дүрт аягының да сеңерләре киселгән бит. Тиз иттереп юырта да, чаба да алмый. Сәлим белән Бүләк куып җиттеләр. Кара бия Ырымбур ягына китеп бара. Ә Кара айгыр бия янына якын да җибәрми. Ерткыч кебек ташлана якын килгәннәргә. Ялларын, коерыкларын кабартып биядән торып кала да җылкычыларга ташлана. Ни кылыйк?

Дөябай, үзе дә нәрсә эшләргә белмәгәнлектән, шул ук сорау белән җылкычыга карады. Тик ул җылкычының күзләрендә әллә кайда төпкә яшерелгән булса да, барыбер сизелеп торган ниндидер билгесез булган шатлык очкыннары күрде. Шуны чамалап сорады:

— Тота алмыйча, җылкычылар кире кайттыларлармы?

— Сәлим хәбәр белән кайтты, Бүләк калган. Бия белән айгырны җибәрмәскә тырыша шунда.

— Җибәрмиме?

— Бия туктамастан атлый бирә. Ә айгыр Бүләкне бастыра, аның белән сугыша икән.

Алдында басып карар көткән җылкычының барлыгын да онытып, Дөябай бик озак, башын түбән иеп уйланып утырды. Алдындагы ит тә, тустагы белән кымыз да онытылды. Байның башы чишелмәслек уйлар белән тулган иде.

Җылкычының түземлеге бетә башлады. Ул йөткергәләп, басып торган урынында таптанып алды. Дөябай аңарга күңелсез күзләре белән карады да эчке сыкрануын белдереп әйтте:

— Инде Рәвил юк. Ә үлеме миңа шатлык китермәде. Китсен Кара Кашка кайтып. Туктатмагыз, тимәгез.

— Ә айгыр?

— Кара айгырмы ул?

— Әйе. Кара айгыр.

— Ул да китсен. Туктатмагыз, тотмагыз. Ходай аларга ярдәм бирсен...

Җылкычы үзе өчен бу көтелмәгән шатлыктан куанып, тиз генә тирмәдән чыгып китте. Тупырдап чабып киткән ат тояклары тавышы ишетелде. Дөябай шул ат тояклары тавышы басылганчы хәрәкәтсез утырды да, аз гына елмаеп, алдындагы кымызга үрелде...

* * *

Сугыш башланганда Чижук Хәйдәргә унбер яшь тулып килә иде. Әтисе Биктимер сугышның тәүге көннәреннән үк хатыны Кәмиләне, ундүрте тулып үткән кызы Фәридәне һәм бер-бер артлы тупырдашып үсеп килгән өч малаен калдырып, немец фашистларына каршы сугышырга дип чыгып китте. Биктимер чыгып киткәндә сугыш алдындагы уңышлы елларда трудка алынган икмәк ел буена җитәрлек иде әле. Германны тиз генә җиңәргә исәпләп, гармуннар акыртып, җырлап чыгып китте авылдан игенчеләр. Дүрт баласын кочаклаган килеш, елап шешенеп беткән Кәмилә иренең китүен озакка дип санамады. Барыр да, фашистның кирәген бирер дә, кайтыр. Ходай боерган булса! Шунлыктан көндәлек тормышын үзгәртмичә яшәргә булды. Тик алай барып чыкмады шул.

Ире белән сугышка чыгып киткән Песәй Тимербулаты урынына бригадирлыкка калган Җиһанша бабай, Биктимер киткәнгә атна-ун көн үткәч, иртә белән Кәмиләнең өенә килеп керде.

— Исәнлек-саулыкмы, Кәмилә килен? Нихәлләр итеп кенә яшәп ятасыз? Балалар исәнме?

— Әйдүк, әйдүк, Җиһанша езни! Мактап кына йөрисең икән. Әйдә, түрдән үт! Утыр безнең белән чәйгә!

— Рәхмәт, килен, рәхмәт! Яса булмаса берне. Самавырыңның тавышы бигрәк моңлы икән. Күңелгә ятышлы.

Киез эшләпәсен салып, ишек янагындагы агач чөйгә элде дә, бисмилласын укый-укый, сәке йөзлегенә килеп утырды. Ризык капмыйча гына шопырдатып бер чынаяк чәй эчте дә битен сыпырып, сүзгә керешге.

— Мин сиңа, килен, калхуз йомышы белән кердем бит әле.

— Синең шулай тиештер инде, Җиһанша езни. Үзең дә хәзер бригадир булып, калхуз хуҗаларының берсесең бит инде.

— Анысы шулай инде, шулайлыкка. Әййе. Син шуны аңлагач, миңа синең белән сөйләшү дә җиңелрәк булыр. Шулай дип уйлыйм мин. Әййе. Минем кергәнем синең өчен дә, калхуз өчен дә, минем өчен дә кулай булыр дип уйлыйм инде мин уйлавын.

Кәмилә сагая төште, тик сиздермәде.

— Тыңлыйм, езни, сөйлә.

— Мин уйладым-уйладым да, синнән дә кулай кеше таба алмадым. Син килен, Биктимерең урынына бригат атларын карарга, куних булырга тиешсең. Мин шулай дип уйлап кердем сиңа.

Камилә бу сүзләрне ишеткәч, ашъяулык читен бөгәрләп, дәшми генә уйланып утырды, шуннан соң гына Җиһанша бабайга карамыйча риза булып бетмәгәндәй тавыш белән акрын гына әйтте:

— И-и-и, езни-и! Ат-тарта тирәсендә эш итү бер генә дә хатын-кыз һөнәре түгел инде ул.

— Түгел, килен, түгел. Аның шулай икәнен мин дә яхшы беләм.

— Соң шулай булгач! Үзең дә җөпләп торгач, нәмәстәмә дип анда мине куярга итәсеңдер, белмим?

— Сине ат карарга куюның сәбәбе мондый, килен. Өченче ел Биктимерең, язын сарай башыннан кар көрәгән җиреннән җыгылып төшеп ике кабыргасын сындырган иде. Син карадың атларны аның өчен, начанства аны вредитель дип әйтмәсен дип...

Камилә кулын гына селти:

— Э-эй, аның хәтле генә инде-е...

— Алай димә, килен, алай димә-ә. Ул эшең синең ике айга якын вакыт тарткандыр әле.

— Шулай ук булды микәнни?

Камилә, исенә төшерергә тырышып, аз гына сүзсез утырды да өстәде:

— Хәер, бардыр. Чөнки Биктимер аягына басып, эшенә тотынганда үлән сыер авызына тиярлек булып күтәрелгән иде шул.

— Шула-ай. Биктимер китте, ә кем дә булса эшләргә тиеш.

— Эшләвен эшләрсең лә ул, эштән курыккан юк. Тик менә ат, арба тирәсендә йөрү хатын-кыз эше түгел инде диюем.

— Ярар, килен. Эшли алырыңа икебез дә ышандык болай булгач. Бу иртәгәсе тормышның икенче ягын карыйк хәзер.

— Биктимер киткәч, минем тормышның кайсы җирен генә карыйсың инде аның. Ул киткәч тормышның барлык кызыгы, бөтен өметем юкка чыкты да куйды. Ничекләр генә яшәрбез икән инде? Әйтергә генә ансат — дүртәүләр бит, дүртәүләр!.. Аларны бит ашатырга кирәк, киендерергә...

— Ту-то, менә! Мин дә сиңа шуны әйтергә уйлыйм. Балаларың ваклар. Хет зурысы малай түгел, кул араңа керергә. Балаларың яшәргә, үсәргә тиешләр. Шуңа дип дөньяга килгән ул сабыйлар. Зур улың, яшькә әле бәләкәй булса да, эшкә бик чос. Бик ярата мал-туар арасында йөрергә. Ат күрсә — бетте инде. Ул тотмаган, менмәгән ат юк бригатта... Син, килен, атлар карарга риза бул да, атлар двуры янындагы өйгә яшәргә күчен. Биктимер кайтканчы, иншалла, кайтуына өмет белән яшик, шунда яшә, көн күр, дөнья көт.

— Кит инде, езни! Анда ничек яшәмәк кирәк ди. Ул пычрак анда, ул тәмәке тарткан ир-ат, малай-шалай. Шул өй эчендә бөтен камыт-ыңгырчак, дуга-аркан. Кит, кирәкми, әйтмә дә, сөйләмә дә...

— Әйтәм, килен, сүзеңне бүлеп әйтәм. Син минем әйткәннәрне тыңлап эш башкарсаң, соңыннан миңа мең рәхмәтле булачаксың.

— Үз йортым сарай кебек. Шуны ташлап ул ат дворында миңа нәрсә калган.

— Анысы шулай ул шулайлыкка. Йортың сарай кебек, дөрес әйтәсең. Тик азагына хәтлек уйлап бетерә алмыйсың. Ирең Биктимерең өйдә юк бит. Утын, печән, ашарга, кием...

— Кайтыр Алла боерган булса. Исән генә йөресен...

— Амин, килен, шулай булсын. Тик ул кайтканчы яшәргә кирәк бит әле. Утыны кирәк ягарга, малларыңа курмасы кирәк, балаларыңа ашатырга кирәк, кием кирәк. Кирәкнең иге-чиге юк...

Җиһанша бабай сөйләгәннәренең иң кирәкле җиренә килеп җитте. Сул кулының бармаклары белән чал төшкән сакалын сәрмәштереп алды да ныклы ышанычлы тавыш белән җөпләп куйды:

— Калхуз дбурына күченсәң, Камилә килен, сиңа утын да, курмы да булачак. Утынны китертеп бирәбез нәрәт белән, печән инде — күпме телисең. Карышма, күчен. Тыңла мине. Теге Герман сугышында өч елдан артык сугыштым мин. Нимесне ярыйсы гына беләм. Бу сугыш бер елда, ике елда гына бетә торган түгел. Биктимер, исән-сау йөрсә дә, тиз генә кайта алмас әле ул.

Сөйләгәннәрен янә җөпләп куйды:

— Күчен, эшләп алып кит. Аннан соң күз күрер.

Камилә дә эшләрнең кая таба барганын чамалый башлаган иде. Җиһан бабай авырлык белән урыныннан кузгалды: — Алла, Алла! Әй, шушы билне. Бер эләктерсә, бетерә бит инде, малай. Ә эшләргә кирәк. Минем хәзер бит тормастан намазлык өстендә генә утыра торган чагым да бит. Насыйп булмады. Дөмеккере бу Гитлерны. Бетәр инде үзе дә бер бетүен, тик безгә генә насыйп булмас матур көннәрне күрергә...

Ишек төбендә тукталып, Камиләгә соңгы сүзләрен җиткерде:

— Син, килен, Биктимердән калган игенеңне күз алдында тотып, бер нәрсәне аңлап бетермисең әле. Сугыш бетмичә торып трудка иген бирүләр бетте хәзер. Үскәннең бөтенесен сугыш йотып торачак. Сугыштагыларның тамагын туйдырырга кирәкме — кирәк! Булган игенеңне бик саклап тот син, ипине бик күп ашатма балаларыңа. Элекке кебек ашъяулыкка төреп тотма, бүлеп кенә бир, ашарга утырганда гына. Зур нужа, зур михнәт килә безнең башкайларга. Бу сугыш ике-өч елда гына бетмәс дип уйлыйм мин. Тик кешегә ишетелә күрмәсен. Әйберләреңне җыйна,

күчен тизрәк. Мондый урынга кешесе табылуы бар. Колак кагып калырсың. Өеңә, әнә ниместән качып килгән ябрәйләрне керт. Акчалары күп аларның — базарда сатулашып та тормыйлар, бөтен азык-төлекне сугып кына алалар.

Уң кулы белән ишек тоткасын сәрмәнеп тапты да, сүзен бетерде:

— Биктимер энекәш кайткач әйтерсең, бу эшкә урнашырга Җиһанша ярдәм итте, дип. Үз хәлемне үзем генә беләм инде мин. Бер елдан артыкка бара алмам. Исән-сау яшәгез... Китим әле. Халыкны жирда кисәргә җибәрергә кирәк. Чәең өчен рәхмәт, килен. Сау бул.

Камилә урыныннан торып, Җиһанша бабайны капка төбенә кадәр озата чыкты, аның авыр итеп атлап китеп барганын артыннан байтак карап калды.

Өч көн үтүгә, Камилә колхозның дүртенче бригадасы атларын карарга дип, «дбурга» күченде һәм шул көннән башлап зур улы Хәйдәр белән атлар карый башлады.

* * *

Үз йорты белән, үзе теләгәнчә яшәп өйрәнгән хатынга, тәүлек буена утызга якын атны карап, көнен-төнен кеше кереп-чыгып таптанган, тәмәке тарткан «двур»да яшәве башта бик авыр булды. Иртән иртүк карт-коры бабайлар, ирләренең атларын җигәргә куелган хатыннар, укуларын ташлап колхоз эшенә җигелгән 10—16 яшьлек малайлар, эшкә китәр өчен җигәргә дип, ат алырга киләләр. Алар килгәндә әле яктыра да башламаган була. Ә атлар ашатылган, эчертелгән булырга тиешләр. Шунлыктан Камилә төнге өчләр тирәсендә торып киенә дә, атларны кое янына эчерергә дип алып китә. Төне буена салам катыш печән ашаган ябык хайваннар Камиләне, авыз эчләреннән генә мекердәп каршы алалар. Кешеләрдәге кебек инде — һәр атның үз холкы. Баштарак Камилә атларга өйрәнә алмыйча азапланды, алардан курыкты. Араларында, көзен түгәрәк тәнле, якынлаша башласаң, колакларын шомарайтып тешләргә үрелә торган Бурлы бия бик хәтәр иде. Тәүге көннәрдә Камилә аның янына якын барырга куркып, печәнне сәнәге белән үреләүрелә күрше ат торган бүлектән генә сала торган иде. Астын тазартканда да, якын бармыйча, астындагы тизәкләрне агач тырманың сырты белән тартып ала иде. Әллә алдына азык азрак эләккәнгәме, әллә асты бик үк тазартылып бетмәгәнгәме, Бурлы бия Камиләгә карата көннән-көн кырыслана барды. Ул якын килә башласа, ачуланып пошкырды, күзләрендә ут чаткылары уйнатты, колакларын шомрайтып тешләргә үрелде, ясә арты белән борылып, тибәргә чамалады. Ябыкканнан-ябыкты. Атны җигеп йөрегән Сәйти карт бер көнне Камиләгә эндәште:

— Камилә кызым! Минем Бурлы бия ябыга башлады бит әле. Үзе ялангга барса, ашап туя алмый. Барган җиреннән юл читендәге корыган үлән башына тикле үрелә инде мона. Ни сәбәптер инде, ә?

Камиләнең җылардай булып, сөйләгәнен, бүреген кырынрак салып тыңлады да, кыска гына иттереп көлеп куйды:

— И-и, кызым, кызым! Ул бит иртә белән иркәләп дәшкәнне, аркасыннан сөйгәнне өмет итә. Шәңгәрәй бай биясе иде бит ул. Ә Шәңгәрәй бай бик тә киң күңелле мөселман бәндәсе иде. Урамнан үткән чакта да малайларның башыннан сыйпап, кәнфит биреп китә торган иде. Бу биясен би-ик иркәли торган иде. Кулыннан ипи генә ашатып тота торган иде. Үзен-үзе сиңа күрсәтергә тырыша ул бичара. Иркәләү өмет итә. Иртәгә иртән күрсәтермен мин сиңа аның белән ничегрәкләр иттереп мөгамәлә кылырга икәнлекне. Атлар эчерергә үзем килермен иртә белән. Ат дигән хайван би-ик акыллы бит ул. Сөйләргә теле генә юк.

Сәйти бабай чыннан да икенче көнне иртүк атлар эчерергә килеп җитте. Камиләне ияртеп, Бурлы бия янына якынлаша башлаган иде, ат тешләрен ыржайтып, аларга таба борылды.

— Әнә, Сәетгәрәй абзый, күрдеңме. Көн дә шулай гадәте. Тешләре бит һәрберсе бармак озынлык бар. Эләктереп алса-а...

— Йә, хайванкай, йә, йә! Иплән кыйлан, иплән! Йә, йә...

Бабай кабаланмый гына йомшак тавыш белән сөйләнә-сөйләнә атның янына ук үтте дә, сул кулы белән сыртын сыйпый-сыйпый, уңы белән куеныңа үрелде. Ни гаҗәп, әле генә колакларын шомрайтып, тешләргә хәзерләнеп торган Бурлы бия танымаслык булып үзгәрде. Бабай сул кулы белән атның ял төбен тоткалады, уңы белән куенынnан чыгарган кечкенә ипи кисәген атка каптырды да, аның тамак төбен кашый башлады. Ат муенын сузып, рәхәтләнеп басып тора иде.

— Менә, кызым, шушылай иттереп игътибар ит син аңарга. Хуҗасы Шәңгәрәйне оныта алмый инде ул бичара. Шуның иркәләве җитешми аңарга. Сугышка киткән улым Габбас артыннан ияреп үк йөри торган иде ул. Биктимерең дә бик әйбәт белә иде хайваннарның холкын. Һич кенә дә сукмый торган иде малкайларга. Син дә кара, өйрән холыкларын аткайларның. Әнә теге Кара биянең уң күзен ак каплаган. Уң яктан күреп бетми. Шунлыктан уң яктан килгәнне яратмый ул. Капылтлар килеп чыккач, куркадыр инде. Әнә теге алмачуар ат — исеме Малайка — бик тә көчле. Олы гәүдәле ирләр кебегрәк, бик тә эшчән үзе. Күп тә ашый, йөкне күпме салсаң да тарта инде. Үзе талымсыз. Печәнне дә ашый, саламны дә җиппәрә. Ә менә бу зур корсаклысын, кем Җирән Кашка ди, ә кайберәүләр Миңгерәү Кашка диләр. Аны җигә башлаганда иң тәүдә ыңгырчакны аркасына салып, ныклап бәйләп куярга кирәк. Аннан соң гына камыт кидерт. Шулай итмәсәң, камыт кигән көенә кача. Җәй көннәрендә бигрәк тә. Эшне бик яратып бетерми. Ялкау хатыннар кебегрәк инде... Әнә теге кечерәк гәүдәле атның исеме Даружный. Үзең дә исемнәрен белеп бетереп барасыңдыр инде. Ул ат утыз алтынчы елны калага шасе юл салганда, әллә каян килеп чыгып, кушылды безнең бригат атларына. Анысының да бер алама гадәте бар. Җәй көннәрендә тотарга барсаң, бастыра да алып китә килгән кешене. Шунлыктан чыбыркы белән барырга кирәк. Күрсәтеп өстәвенә. Ә инде әнә теге Туры ат дип йөретелгәне тау түбән ала да олага. Күзенә ак-кара күренми андый чагында...

Авыл агае туганнан алып, тәгәрәп үлеп киткәнче шул ат көче белән көн күргән. Кулыннан килгәнчә атның да елгырын, көчлесен, авыр йөк тартырга сәләтлесен, ерак юлга чыдамын тотарга тырышкан. Авыл халкы атына карап хуҗасына да бәяне бирә белгән. Аты, арбасы, тәгәрмәчләре, дирбияләрее әйбәт булса, аты көр таза булса, хуҗаның да авылда абруе зур булган. Әгәр берәр авыл кешесенә кылган эшләренә карап бәя бирергә теләмәсәләр, аның турында сөйләгәндә болай диебрәк кенә җибәргәннәр:

— Кит әле, кит! Шуны кешегә санап, тел әрәм итеп сөйләп тә торма. Үз гомерендә бер юньле ат җигә алмады. Сөйлисең шуны кеше рәтенә кертеп. Куй! Атын-арбасын кара да, дирбияләрен! Аннан соң үзең үк әйтерсең пүчтәк ул дип!

Колхозга кергәндә, элекке аерым хуҗалыклардан җыйналып бригадаларда тупланган шул колхоз атларын хәзер күпчелек хатын-кыз җигә. Ирләре сугышка чыгып киткәннән соң калган атларны Җиһанша бабай бригададагы хатыннарга беркетеп бирде. Хатыннарга иң авыры атларны җигү иде. Ир-ат кулы астында тәртә арасына үзеннән-үзе кереп җигелергә әзер торган атлар, хатыннарны бөтенләй тыңламыйча азапладылар. Хатын-кызның ат-тун ягына сәләте югын хайван булсалар да, атлар да яхшы аңлыйлар икән. Хатыннар камытны йә агач ягы белән кидерәләр, яисә ыңгырчакны арты белән ат сыртына куялар, аркалыкны бик нык иттереп күтәрәләр яисә төшереп бәйлиләр. Җигелгән атка сулыш алырга һава җитми, яисә камыт муенын суга. Өстәвенә дугасы ыңгырчак өстенә төшеп яткан — ат мескен урам көлкесе булып лыртлап кына юырта. Чөнки җигелүе килмәгән. Шуның өстенә хатын-кыз өчен иң яратмаганы,

иң хәтәре булып, чөелдерек кысу тора. Элек-электән оялчан, сабыр татар хатыны өчен бот күтәреп, чабата башын камыт агачына терәп, итәк асларын күрсәтеп чөелдерек кысу, үлем белән бер. Баштарак ат җигү өчен ике-өч хатын ат сарайлары янына бергәләп чыктылар. Җиһанша бабай аларны ат җигәргә өйрәтте.

Атларда акыл ягы иситкеч шәп бит. Ир-атның бер дәшкәненә буйсынып, тәртә арасына кереп, камыт-ыңгырчакны кидергәнне көтеп торучы тыңлаучан хайваннар, хатын-кызга бөтенләй баш бирмиләр икән. Күрәсең, хатыннарның кыяфәте генә түгел, исләре дә атка ошамыйлар. Бер аягын сыңар тәртәне атлап баскан көнчә ат тәртә арасына керүдән баш тартып, туктый да кала. Хатынның үзенә ярарга тырышып, сыерына дәшкән кебекләр иттереп «на хайван, на малкай», дип әйтүләре ат өчен юк аваз ул. Ат колакларын да селкетмичә, аякларын башкача кузгатмыйча тик кенә басып торуын гына белә. Тәртә арасына керми. Әгәр инде хатын кулына чыбыкмы, чыбыркымы ала икән, ат кире чигенеп, бөтенләй үк тәртә арасыннан чыгып китә, элегрәк атлап куйган аягын да кире ала. Һәм арба янынннан бөтенләй читкә үк китеп тә бара әле ул. Хатыннарның икенчесе инде ике аягы белән тәртә арасына кереп баскан Миңгерәү Кашканың ике аяклы арт санын ике куллап этеп тәртә арасына кертергә булыша. Еласаң ела, көлсәң көл. Ә атларның кайберләре тәртә арасына кереп бассалар да камыт кидерергә башларын бирмиләр. Җиһанша бабай атларның шулай «баш бирмәүләрен» гап-гади иттереп аңлата белә:

— Сез эшчәннәрем, атны, тәртә арасына сул яктан кертегез. Шулай өйрәтелгәннәр алар ничәмә-ничә йөз еллар буена. Чөнки камыт бавына дуга да бит иң башта сул яктан кидерелә. Ыңгырчак та шул сул яктан салына һәм шуннан эләктереп куела. Аннан инде дуганың икенче башын уң якка биргәч үзегез дә чыгасыз шул якка. Уң тәртә башына диюем инде. Уң якка чыккач инде, камыт бавының икенчесен дугага эләктерәсең, чөелдерекне кысасың, аннан соң гына инде аркалыкны күтәрәсең. Аркалык күтәрү үзе бер осталыкны сорый. Нык күтәрсәң — камыт атны буа. Күтәреп бетермәсәң инде, муенын камыт суга. Ат җиккәндә менә шуларны исегездә тотсагыз иде.

Үзе сөйләгән арада берничә атны җигеп тә куйды. Атлар да, үзләрен ир кеше җиккәнгә куангандай, тыңлаучанлык күрсәтеп, үзләре үк тәртә арасына керә бардылар. Ай үтәр үтмәстә, хатыннар да өйрәнде бу һөнәргә. Өстәвенә араларында ирләргә охшатып катлы-катлы иттереп сүгенеп җибәргәннәре дә күренә башлады. Хатыннар белән берлектә малай-шалай да ат җигеп колхоз эшенә йөределәр. Тик кырык беренче елның көзе-кышында алар арасында аерым ат җигеп йөргәннәре бик сирәк иде әле. Яз җитеп, карлар эреп бетеп, җир кибә башлагач, чәчү башлангач колхозчылар арасында кул көче җитешмәгәнлек бик нык сизелде. Менә шул сугыш башланганнан соң килгән тәүге язда өченче-дүртенче сыйныфларда укыган малайлар дәррәү күтәрелеп укуларын ташлый башладылар. Иң тәүдә «начар» һәм «уртача» билгеләренә укыган малайлар тайдылар мәктәптән. Укуга ялкау да, баш ягы да бик җитеп бетмәгән ул малайлар белән бертуктаусыз көрәшеп ялыга башлаган укытучы халкы, эчләреннән генә аларның әллә башкача укымаячакларына куандылар инде, белмәссең. Чөнки берсенең дә өенә, нигә укуыңны ташладың, әйдә кире мәктәпкә дип бармадылар. Әллә инде балаларны кире кайтармаска күрсәтмә алдылар. Тик ул малайлар укуларын ташлагач, мәктәп директоры да укытучылар да бер нәрсәне аңлап алдылар. Дәресләрдәге шуклык белән шаяруларны да, тәнәфес вакытларындагы уйнау-шаяру, чабышларны да шулар, килде-китте укып йөргән малайлар оештырган икән. Үз тиңдәшләре арасында алар йөргәннәр икән малайларга «башлыклар» булып. Ай үтүгә һәр сыйныфтан кимендә биш-алты малай укуга йөрүдән туктап, ат сарайлары янында, колхоз тимерчелегендә, бабайлар, хатын-кызлар белән бергәләп колхозның бетмәс эшләрендә йөриләр иде.

Хәйдәр кыш буена, мәктәптән кайткач, әнисе янында атлар карап үткәрде. Март бураннары башланганда, суык тидереп түшәккә егылган әнисе урынына, үзеннән өч яшькә зур апасы Фәридә белән бергәләп атлар карады. Тик апасының күңеле атлар караудa түгел иде шул. Ундүртен тутырып унбишкә киткән, буй җитә башлаган кызый бер-ике сәгать эшләү белән, минем дәресләрем күп дип, өйгә кереп китүне, яисә мәктәпкә таю ягын гына карады. Байтак эшләп азрак тамак ялгап алу исәбе белән өйгә кергән улын авыру ана яткан җиреннән калкына биреп каршы ала:

— Әнә, Хәйдәр улым, учак утында бәләкәй чүлмәк белән сиңа дип пешергән кайнар бәрәңге. Сәкедә савыт белән катык. Капкалап ал.

Әниләре күкрәген ярып килгән йөткерүен басарга тырышып тын ала да, яткан җиреннән торып утыра. Зур улының ашаганын барлагандай аңарга карап-карап ала. Аның бик тәмләп бәрәңге белән катык ашаганын карап утыра да, ястыгы астына кулын тыгып, тастымалга төрелгән бер ипи кисәге китереп чыгара.

— Мә, улым! Синең кебекләр иттереп ирләр эшен башкарган егеткә иписез ярамас.

Хәйдәр дәшми генә әнисе биргән ипине кулына ала да, абыйлары кулындагы ипидән күзләрен ала алмыйча шым гына утырган ике энесенә күз сирпеп куя. Тегеләргә шул җитә кала, икесе беравыздан суза башлыйлар:

— Аб-бый!..

— Ай Алла! Тик кенә утырыгыз, әгәренки! Тик кенә! Бирермен менә мин сезгә, абыйны! Аша, улым, үзең генә аша!

Хәйдәр әнисенә карамаска тырышып, ипине өч тигез кисәккә бүлә дә, икесен Зөфәр белән Хәлимгә тоттыра.

— И-и, бала, бала...

Әнисенең үзен шелтәләп нәрсәдер әйтергә теләгәнен бүлеп, Хәйдәр аңарга сорау бирә:

— Әни, син белмисеңме, Банка биясе кайчан колынларга тиеш ул?

— Бер дә белмим шул балам. Аны белсә Җиһанша бабаң яки Исхак бабаң беләдер.

— Исхак бабай безнең бригат түгел бит ул. Каян белсен инде?

— Калхузның пеләмә айгырларын ул карый бит.

— Ә-ә...

— Нигә сорадың әле син ул бия турында?

— Күп ята. Аз ашый үзе.

— Син аны балам торгызып, алып чыгып йөретеп кер.

Хәйдәр әнисенә карамыйча гына, сүзне башкага күчерде:

— Мин, әни, ышкулга башкача бармам инде. Бердән, минем өчен укуның кызыгы бетте, икенчедән, эшнең күплеген үзең күреп торасың.

Ана, утырган җиреннән авыр сулап куя да, сул кулының сырты белән күзеннән чыккан яшьләрен сөртә-сөртә ишетелер-ишетелмәс акрын тавыш белән үзенең карарын әйтә:

— Ярар, балам, язмышың шундыйдыр инде. Алла кушып әтиең исән-сау кайтса, шуннан соң укырсың. Ат карарга да, калхузда эшләргә дә кем булса да кирәк бит инде. Бернәрсә дә кылып булмый. Азагы хәерле булсын. Бар балам, эшлә...

* * *

Кеше авырмаса, исән-имин булса, аның башына нинди генә нужа төшсә дә, ул бирешми, тереклек итә, эшли, көрәшә, яшәргә кирәклекне аңлап, дөнья күтәргә барыбер җаен таба.

Сугыш башлангач та шулай булды. Ирләре сугышка чыгып киткәч, бер өер балаларын кочаклап торып калган хатын-кыз, курку билән алган

йөрәкләрен урынына утырта алмыйча ике-өч ай аптыраш һәм каушау белән яшәделәр. Тик көннәр, атналар, айлар үтү белән хәлләр үзгәрә барды. Әти китте дип тормый икән, бала-чага ашарга сорый, кием кирәк, малга салам кирәк, печән кирәк, мичкә ягарга утын кирәк. Ир юк дип утырып булмый икән — кәсеп итәргә кирәк яшәү өчен. Урман кисәргә, печән чабарга, колхоз эшенә йөрергә, анда азлап кына булса да урлашырга өйрәнергә, балаларны киендерергә, аларны укытырга кирәк икән. Ире барда утынлыктагы утынны да чапкалап алырга «иренгән» хатын-кыз, билен биштән буып, кышкы зәмһәрир суыкларда урман кисәргә чыгып китәргә өйрәнде. Эченең әллә кай җирләрендә, әллә нәрсәләре өзелгәнне ыңгырашып баса-баса, юан-юан бүрәнәләр күтәрде. Урманнан кайткач эченең, биленең авыртканына түзә алмыйча берничә көннәр, төннәр канга батып урын өстендә ятты. Тагын торды, тагын китте урманына, чалгысына тотынды, урак алды кулларына. Билсез-сынсыз түшәгенә кайтып тагын тәгәрәгән чакларында, ястыгы астына ак чәчләре күренә башлаган башын тыгып, өй эченә тавышын чыгармаска тырышып, елап та алды. Ястык мөешен тешләп. Төнге йокы биләп алган берсеннән-берсе вак балалары йокы аралаш аналарының эссе тәненә килеп сырыштылар. Ана янында йөрәкләренә тынычлык таптылар. Ул алар өчен әллә кайдагы немец белән сугышка китеп юк булган аталарын да алмаштырган бердәнбер терәкләре иде. Шул балаларның мышкылдап тын алулары, йокы аралаш көндезге уеннары, бетмәс-төкәнмәс балаларның төрле эшләре белән саташулары, сөйләнгәләп куюлары, аяк-кулларын бәреп салып йоклаулары, көне буена эштә ватылып кайткан аналарына өмет һәм көч бирәләр иде. Кайсы корама юрган, кайсы аталарыннан калган тун-толыплар ябынып йоклаган сабыйлар, таң атып, көн туу белән тагын дөнья нужасының аны көтеп торганын, аның белән көчәнә-көчәнә тартышырга кирәклекне ярым уяулы-йокылы яткан ялгыз хатынның исенә төшерәләр, күңеленә кара шом салалар, тамагына төер китереп тыгалар иде.

Бер ел үтәр-үтмәстә колхозда Камиләдән үткер һәм уңган ат караучы юк иде. Юантык көчле гәүдәле, атлаулары да ирләрнекенә охшап тора ат карый башлаганнан бирле. Атлар караганда тавышы көр чыга, үзе ягымлы булып яңгырый. Башкарган эшен җиренә җиткереп, атларга зур игътибар күрсәтеп эшли белде ул. Ә улы Хәйдәр шул кырык икенең язында язгы чәчүгә чыгып киткәннән соң, җәй буена ялан эшләре башкарган атларны карап, көзен суыклар башланыр алдыннан гына өйгә кайтты. Атларның күпчелеге кыр эшендә, яланда куна-ятып эшләгәннән, Камиләнең кышкылыкка караганда җинелрәк булды. Яланда ат карап кына ятмады Хәйдәр, Фазулла бабайдан сабан көйләргә өйрәнде, чәчте, тырмалады. Иң уңган малайларның берсенә әйләнде. Гәүдәгә бик зураеп китә алмаса да, эштә көче, сәләте артты. Язгы чәчүгә чыккан беренче атнада, үләп күтәрелгәнче атларга гына ашатырга дип калдырган кибәннән сарут печән ташыды. Көне буена сабан, чәчкеч өстерәп алҗыган атларның алдына төне буена җитәрлек иттереп ямь-яшел печән салып куйды. Эш авыр, солы булмаганнан, атлар күзгә күренеп суырылдылар, ябыктылар. Янбашлары сулып, кабыргалары мәктәп рәшәткәсе кебек булып килеп чыктылар. Күз карашлары да моңсу кебек тоела иде аларның.

Чәчүдә йөрегән картлар арасында да, малайлар арасында да төрлеләре бар. Картлык белән балалык икәүләшеп әзмәвердәй ирләргә дә авыр булган чәчү эшен алып барырга тырышалар. Чөнки фронтка икмәк кирәк. Язгы чәчү ай буена барып, май аеның уртасына кадәр җитә язды. Шул язгы көннәр, төннәр эшләп, авылга бик сирәк кайтып күренгән малайлар, бабайлар язгы чәчүне җиңеп чыктылар тәки.

Картлыгыннан һәм йончуыннан бөкрәя төшкән Җиһанша бабай, иртәгә авылга кайтабыз дигән кичне малайларның барысын да учак янына җыеп утыртты. Зур, корымга буялган кара чиләктә тәмле исләр

чыгарып тары боткасы быгырдый. Учак ялкынына тирә-якта ниндидер шомлы шәүләләр селкенгән кебек. Атлар пошкыра. Асларына бишмәт, чыпта, туннар салып, учак тирәләп кайсысы яткан, кайсысы утырган малайлар Җиһанша бабайның сүзләрен тыңлыйлар.

— Аллага мең шөкер, оланнар, җиңдек без бу эшне. Картларны кайтарып җибәрдем. Сезгә генә әйтәсе сүзләрем бар. Тәүге көннәрне, чәчүгә чыккач, эшли алырыгызга бик ышанып бетми идем. Инде ышандым артыгы белән. Ходай-Тәгалә сезнең аяк-кулларыгызны сызлаусыз итсен, гомерегез буена. Көч-куәтне күп бирсен сезгә. Үсегез, балалар, имгәнмәгез. Иртәгә иртүк авылга кайтырбыз. Сабан-тырмаларны ат сарае янына бушатыгыз. Камилә апагыз күрсәтер кайсы урынга өяргә икәнне. Инде хәзер печәнгә төшәргә әзерлек күрә башларбыз Иншалла, мәнә килеп җитәр ул. Кайткач төп-төгәл бер атна ял итегез. Мунча керегез, йорт тирәләрен карагыз, балтырганга барыгыз. Кымызлыкка, какыга, кузгалакка, балыкка...

Җиһанша бабай сүзләре беткәндәй дәшмичә, янган утка карап байтак утырды. Аннан соң учак тирәләп тезелгән малайларны берәм-берәм күздән кичереп чыкты.

— Хәзер мин әйтәсе сүзләрне, малайлар, мин әйтмәдем, сез миннән ишетмәдегез. Алай-болай миннән яшереп алган тарыгыз булса, минем арбадагы капчыкка салыгыз. Агуланган тары ул, ашасагыз, эчәкләрегезне кискәләячәк. Агуы бик яман. Язгы чәчүдә сорамыйча алырга өйрәнмәгез. Агулыны ашап үлүегез ихтимал. Күрше бригаттагы Сәвәләй Бакирның малае Фәрит кебек. Үзегез беләсез...

Җиһанша бабайны бүлеп аның артында утырган берәү акрын гына тавыш белән әйтте:

— Өйдә ашарга юк бит, Җиһанша бабай.

Бабай авыр иттереп көрсенде дә, артына борылып карамыйча гына малайга җавап бирде:

— Шулай, Габделхак улым, бар дип әйтә алмыйм инде. Шулай булса да, сез ул алган тарыгызны минем арбадагы капчыкка илтеп бушатыгыз инде. Сезнең өчен әнә минем куыш эчендә агуланмаган ике капчык әйбәт тары бар. Каян алганын сорамагыз, анысы сезгә кирәк түгел. Шуны кеше-кара күргәнче тигез иттереп бүлешеп алыгыз. Берәр чиләктән артыграк та булыр әле. Гыйззәт бабагызга да өлеш чыгарыгыз. Ул да тере җан иясе бит, шул сез дип тырыша. Тик телегезне озайтып, Җиһанша бабай бирде тарыны, дип, юк сүз сөйләп йөри күрмәгез. Үзегез дә утырырсыз өтермәгә, мине дә алып китәрләр. Алла сакласын. Гөнаһын, Аллам каршына баргач үзем барлармын, Ходайга. Үзем табармын җавабын да. Ә мәнә инде милициягә барып капсаң, берничек тә котылу булмаячак. Сак булыгыз. Аталарыгыз сугышта дип тормаслар, илтәрләр дә тыгарлар.

Укуын ташлап колхоз эшенә тотынганнан соң, Хәйдәрнең башында тик бер генә уй калды: ничекләр итеп кенә тамак туйдырырга? Барлык яшәеше, узган көннәре, эшләгән эшләре, үткән юллары тик шул уй белән генә сугарылган. Балачагы аның бөтенләй булмады да. Шулай да кыш көннәрендә Зөфәр янына җыйналган малайлар белән бергә кушылып, ул онытылып качышлы уйнап ала. Уйный уйнавын, тик ни өчендер сугышка хәтлек булган уеннардан тәм тапкан кебекләр иттереп уен тәме таба алмый. Ярты сәгать чамасы уйный да, тагын сәнәгенә, көрәгенә тотына. Чөнки качышлы уйнаганда да аның башы тулы эш була. Ничекләр иттереп тирес түгәргә, печән салырга, ат асларын тазартырга...

Авыл өчен иң авыры 1943 елның язы булды. Көз яңгырлы килеп, өлгергән игенне җыйнап ала алмадылар. Үргән ашлык күп ятып калды кошелләрдә. Мәскәү яны сугышларында ике аягының да бармакларын туңдырып, шуларны госпитальдә кистереп кайткан Җомагилов дигән читтән килгән берәүне колхозга рәис иттереп куйдылар. Сугыш башланганчы, өч баласы белән хатынын ташлап килеп, монда икенчегә өйләнеп,

яңа гаилә корып җибәргән иде ул. Бик тә комсыз, кеше мәнфәгатен бер генә дә исәпкә ала белми торган бәндә булып чыкты. Колхозга хуҗа булып алган көненнән үк ул, чабатачы Хәйбулла бабай әйтмешли, халык канын эчәргә тотынды. Яланда, иген урылып алынган кырларда башак җыярга чыккан әби-сәби, бала-чагаларны тарантаска җигүле, колхозның кара пләмә айгыры белән өереп бастырды. Ул кара эшендә үзенә ярдәмче дә тапты. Авылда мәкерлеге һәм явызлыгы белән дан тоткан Заһит таз дигән карт иде анысы. Гомере буена әфиун чәйнәгән, таз башлы, агарып бетә язган мыек-сакаллы карт кеше иде инде үзе. Шулай булуына карамастан, иярле ат менеп, кулына камчы тотып көннәр буена ялан-кырларны таптады аты белән. Башак җыючыларны кырдан куды, башаклы капчыкларын тартып алды, каршы әйткәннәренә камчысын озайтты. Кул арбасы белән печән, утын тартып ташыган карчыкларның, бала-чагаларның ден дошманы булды Заһит таз. Ияр капчыгыннан чыгарган бәләкәй, үткер балтасы белән кул арбаларының тәртәләрен чапкалады, колхоз сабаннарыннан урлагансыз дип, тимер тәгәрмәчләрен салдырып алды арбаларның. Авылның карт-корысы, бала-чагасы зар елаңкылар Җомагилов белән Заһит таздан. Тик кырык өчнең август аенда ике култык таягына таянып, ике орден, дүрт медаль тагып, госпитальдән кайтып төшкән Шиһаб Әхмәте авылда күренгәч кенә икесе дә азрак басыла төштеләр. Тик ныклап, бөтенләйгә басылмадылар барыбер.

Кайтуына атна үтүгә, Әхмәт орден-медальләрен тагып колхоз идарәсенә барып, Җомагилов белән байтак сөйләшеп утырган. Кичләтеп кенә кайтып, аяклары сызлаганга төне буена йокламыйча чыккан. Бөтенләй булмаса да, азрак басылдылар икесе дә. Халык арасында йөргән имеш-мимешләргә караганда, Әхмәт аларның икесен дә куркыткан, имеш. Миңа барыбер озак яшәргә калмады, киткәнче икегезне дә юк итәм, дигән икән. Булыр аңардан, дип җиңел сулап куйдылар авылда. Разведчик кешеләрне бик тә тәвәккәл була, диләр. Дөрестер, ахрысы. Ничек булгандыр инде, билгесез. Тик ул ике явызның азрак басыла төшүләрен халык Шиһаб Әхмәтнең тәэсире дип бәяләде. Әхмәтнең авылда дәрәҗәсе үсеп китте. Кәнсәләргә шак-шок килеп таякларын идәнгә суккалап кергән дә, Җомагиловка әйткән икән: «Әгәр дә Заһит Таз белән бизабразиягызны туктатмасагыз, икегезне дә юк итәчәкмен. Ирләре фронтта немецкә каршы кан коялар, сез монда хатыннарын, бала-чагаларын ач тотасыз. Кем ирек бирде сезгә ат белән балаларны таптарга? Минем югалтыр нәрсәм юк, икегезне дә бетерәчәкмен. Яхшы чакта туктагыз!» — дигән ди менә.

Авыл өчен Җомагыл да, Заһит Таз да түгелләр иң куркынычы. Авылның иң курыкканы Чолык Зәйнәбе дигән таза, чибәр хатын иде. Ире, Чолык Хәбибрахманы кайсы яктан алып кайткандыр инде ул Алла каһәрләгән хатынны. Дөрестерме, түгелдерме, урман ягыннан Мәчетле якларыннан дип сөйлиләр. Шул якларда бармы икәнни шундый да дөнья хәшәрәте хатыннар. Ходай үзе сакласын андыйлардан. Чолык Хәйбере революциягә кадәр үк ат караклары, базар маклерлары белән буталып даны чыккан начар кеше. Сугыш башлангач, колхоз эшенә йөрүдән бөтенләй тукталды. Үпкә белән авырый ул, эшкә ярамый, диде хатыны бригадирга. Уфадан алып кайткан справкасын да күрсәтте. Чыннан да авыру икән справкасы буенча. Шул әйтүе булды Зәйнәпнең, ирен эшкә әйтүдән туктадылар. Чөнки Чолык Зәйнәбе авылда финагент булып эшкә урнашкан иде. Авыл халкы шул елан-хатыннан кырык сигезенче ел беткәнче канлы яшьләр түгеп елады.

Зур, таза, мәһабәт гәүдәле, чибәр йөзле, көчле тавышлы (Ходай иң начар кешесенә дә бирсә бирә, кызганмый икән!) ул хатын барлык авылны үзенең кабартма кебек симез кулларына нык иттереп кысып алды да сугыш вакытында, немецне җиңеп «җиңүчеләр» кайткач та тиз генә ычкындырмады.

Юлларны туңдырып, кар төшү белән Чолык Зәйнәбе авылның Түбән очында Сәгыйт Елан дип йөртелгән, Хуҗа Насретдин кебек җор телле дә, үткен акыллы да, тик башын тиле сымагракка сала белә торган, кешенең йортына кичләтеп кенә килеп керә.

— Исән-саулармысез! Сәгыйт абзый кая, өйдә юкмы әллә?

— Идарәгә киткәние, кайтыр инде.

— Ә—ә, шулаймы? Син, Гыйльминиса апа, самавыр куй, миңа чәй әзерлә. Аннан берәр тиз йөри торган малаеңны урамнар буйлап йөгерт. Менә шушы исемлектәге кешеләрне хәз-зер үк шушында, синең өеңә чакырып кайтсын. Бик тиз килеп җитсеннәр дип әйтте финагент Зәйнәп Макашева дисен. Тиз килергә кушсын.

Күрше хакы бар бит. Гыйльминиса Зәйнәпнең үз йортына килеп кергән кебекләр иттереп килеп керүен өнәп бетерми. Үзенчә каршы торырга болаша:

— Син, Зәйнәп иркәм, ул кешеләреңне силсәвиткә генә чакырта алмассыңмы икән. Ике балам авырулар, үземнең дә баш өянәгем кузгалды. Кичәдән бирле ике күземнән очкыннар оча инде менә.

— Һе, авырый имеш, ул! Ирең янында, трудәрмиягә китмәгән. Әйттем бит мин сиңа, куй самавырыңны дип. Мин силсәвитнең салкын бинасында ач утырыйммыни? Мин фронт өчен эшләргә килдем монда. Уйнап йөрмим. Бел шуны! Зур ягыгыз заемга падпис иттереп беткәнче минеке. Кирәк була икән, милицияне дә китертербез. Райком үзебезнеке.

Зәйнәп белә — Гыйльминисага шул сүзләр җиткән. Ире әллә кая бара торганнардан түгел. Зәйнәп яхшы белә — бу гаиләдә муен да, баш та Гыйльминиса. Сәгыйт Еланның төп вазифасы ирлекне башкару да, аннан көн-төн эшләү, мал табу.

Кәҗә якалы пальтосын түргә элеп, Зәйнәп киң аркасына, зур, түгәрәк түшләренә мамык шәлен сала да, түрдәге түгәрәк өстәлгә ике бикле портфеленнән күп кенә кәгазьләр чыгарып сала. Хуҗа хатын эреле-ваклы балаларын алгы якка куып чыгара-чыгара, Чолык ишетмәслек итеп кенә авыз эченнән сукрана:

— Каһәр сыккыры! Килмешәк себерке! Тагын атналар буена каның эчә инде халыкның. Кертмәс идем, ат хәтлек заем салып бетереп куя бит инде. Ярый да кунып ятмаса. Шунысына рәхмәт әйтерлек булырсың.

Бер сәгать чамасы узуга Гыйльминисаның уникe яшьлек улы Нәбиулла хәле-тыны бетеп «кешеләргә әйтеп» кайта.

— Киләләрме? — дип сорый Чолак малайдан.

— Балаларны ашаткач, сыер саугач карарбыз, диләр күпчелек.

Зәйнәп алдындагы счет түгәрәкләрен шак-шок суккалап, нәрсәдер исәпләгән җиреннән туктый.

— Син, малай актыгы, пнимаеш, әйбәт иттереп әйттеңме?

Нәбиуллада атасы Сәгыйт Елан каны. Җавапны кайтканда ук әзерләп кайткан.

— Әйбәт иттереп әйттем. Финагэт Чолык Зәйнәп апа килгән. Ачуы чыга башламас борын тизрәк килегез, дидем.

Зәйнәп күгәреп зәңгәрләнә.

— Малакасус нәстә! Ни эшләп мин агэт булыйм ди, ә?

Нәбиулла күзләрен ашереп борынын лышкылдатып тарта. Дәшми.

Ишек төбендә генә басып торган Нәбиулланы әнисенең зур кулы теге яктан үрелеп тартып ала. Артына берне биреп тә ала, ахрысы, Нәбиулла ризасызлык белдергән тавыш белән:

— Йомышка барып кайткан кешенең күтенә сукмыйлар инде, әнешкә-ән! Бүтәнчәк бармам да куйма-ам.

— Һе-ей, Елан баласы-ы. Аталары Елан, балалары да елан. Бу хәтлек охшасалар охшарлар икән, — дип ысылдаган тавыш ишетелә ябылып бетмәгән ишектән...

Сәгыйт Еланның өй эчендә төн буена хәрби заем тирәсендә сатулашу бара.

— Җә инде, Заки-ир абзый! Сатулашмасана инде. Барыбер язылырга кирәк хәрби заемга. Ки-ирә-әк!

— И-и-и, Зәйнәп хәрендә-әш! — дип суза карт, чабаталарындагы кар эри башлаганнан аякларын кая куярга белмичә. Нинди язылу, ди инде тагын. Язылмаганга китергәннәрен дә түләп бетереп булмый әле монда. Ул сөт, ул йон, ул күкәй, ул ит. Каян алыйк ди инде, син әллә бездә Әндри казнасы бар дип беләсеңме? Ә? Налукны түләп бетереп булмый әле монда, налукны-ы? Ә син займы дисең! Язылмыйм!

— Сыерың бар. Ике сарыгың бар. Тавыкларың уннан артык. Бер мамык кәҗә тәкәң бар...

Картның абзарында нәрсәләр барын Чолык картның үзеннән дә әйбәтрәк белә икән. Тик карт та бирешергә уйламый.

— Шулай синең кебегрәк иттерепләр санасаң, бар кебек ул. Бар кебе-ек. Хәзер үзең уйлап кара инде налук ягын. Бер карап торган мескен сыер. Шуңарга миң литр налук сөте түләргә кирәкме? Кирәк. Шул налукны түләп юньле сөт-май күргән юк, сыер тоткан исәпләнеп тә. Менә монысы сиңа бер. Инде ит мәсьәләсе. Менә миңа утыз биш кила ит бирергә кирәк хөкүмәткә. Ул инде, әнә шул син белгән минем абзардагы ике сарык дигән сүз. Эчәгең, үпкәсен алгач, ул ике сарык җитми дә кала әле ул. Йөз илле йомырка. Мин аларны каян җиткереп бетерим ди инде, ә? Ел әйләнәсенә сукыр аш, умач белән яшибез бит. Син аз гына уйлый аласыңмы безнең хакта, юкмы? Займы-ы?

— Бер сиңа килмәгән, абзый кеше, ил белән шулай. Ил белән! Сугыш бара, аңлыйсыңмы-ы син, сугы-ыш? Фронтка ярдәм кирәк.

— Сугышмыни-и? Кара син аны, ә? Ә минем арысландай ике улым, өч киявем кайда дип беләсең син? Шунда түгелмени? Инде Габделхәем белән Габделкадыйрның үле хәбәре килгәнгә елдан артык. Кечесенең хатыны урын өстендә ята, урманнан имгәнеп кайтты, ике баласы бар. Кем карарга тиеш аларны? Аларны кем ашатырга тиеш хәзер? Займы-ы. Языл үзең бик алай кирәк булгачтын!

— Син монда, абзый кеше, контр сүзләр сөйләп утырма. Кем ашатырга тиеш, имеш! Кара син аны, әллә сиңа управа тапмаслар дип уйлыйсыңмы? Сат сарыкларыңны, йомыркалар сат, ә заемга языл. Танклар, самолетлар кирәк малайларыңа исән кайтыр өчен. Синең малайларыңа, синең кияүләреңә, синең урында яткан килененә кирәк ул хәрби заем. Бел шуны!

— Хөкүмәт ясатсын самалютларын да, танкларын да. Шуңа налук түлибез дә без, үзебез ашамыйчак. Күкәй сат, имеш! Саттың — сатмыйни-и! Каян аласың ул күкәйне? Тавык бичара салып өлгерәлми — налукка здавай давай! Тавыкның артында мамыгы калмады инде, йомырка салдыра-салдыра.

— Син монда Совет влачына каршы сөйләп утырасың! Мин монда милиция Тәмечне чакыртырга да күп сорамам. Иттем, тыктым әнә рәшәткәле йортка!

— Кайсы Тәмечне? Теге, милиция Сәлимгәрәйнеме?

— Әййеме! Ятарсың кәбестә суында!

Карт ничектер тынычланып китте. Тез өстендәге колакчан бүреген әүмәкләп, аның белән «киңәшеп» алды да салмак кына, азрак елмайгандай иттереп әйтте:

— Ай, чакыртсаң чакыртырсың инде. Ял итепләр чыгармын. Кәбестә суына өйрәнгән җаннар без — теге Герман сугышында Пинск сазлыкларында күп чөмердек без аны кәбестә суын. Кәтилүктән генә.

Карт финагентка мыскыллап күзенең агы белән генә карый. Арыган тавыш белән өсти:

— Юк минем башкача көчем дә, акчам да. Теләсәң ни эшләт, соңгы сүзем шул сиңа!

Бүлмәдә тынлык. Тыштан алып кереп очлары ике урындыкка куелып киң тактадан ясалган «эскәмия»дә утырган, шулай ук «заемга язылырга»

чакыртылган хатыннар «Закир абзыйның Чолык белән алышканын» тыңлап, авыр иттереп уфырып куйгалыйлар. Өсләрендә салынмаган кышкы, калын кием. Аякларында күбесенең тула-оек, чабата, сирәк кенә төпле пима. Өй эчендә эссе, тынчу. Һава җитми.

Байтак дәшми утыргач, Зәйнәп телгә килә:

— Син, Закир абзый, болай булгач, Гитлерның ярдәмчесе булып чыгасың бит инде.

Карт дертләп куя, тик сер бирмәскә тырыша.

— Һе, шулайдыр бик. Фронтлар тулы минем малайлар, кияүләр сугышалар Гитлер белән. Син бик ычкынып китмә, сүзеңне үлчәп сөйлә.

— Үлчәп, белеп сөйлим шул мин. Менә нимескә төбәп атып аны үтерергә кирәк. Ә синең улыңның патроны беткән. Шул патрон булсын дип төннәр буена утырам бит мин. Ул хәрби заем сиңа кирәк ул, миңа түгел. Синең сугыштагы малайларыңны, кияүләреңне исән-имин кайтару өчен кирәк. Балалары янына кайтарырга.

Карт кулындагы йонтәс бүреген зур куллары белән изгәләп, аның белән тагын «киңәш» итә. Улының патроны беткәне карт солдатның миенә кыйпылчык булып утыра. Ул үзен малаеның алай-болай булып китүендә гаепле итеп сизә башлый. Чолык иң авырткан җиреннән эләктерде Закир картның.

— Шула-ай! — дип суза карт. — Нимес атакага дип синең акупка табан кырлы штыгын сузып йөгерсә-ә, синең патрун бетсә — эш хана инде, малай! Ну, Зәйнәп, бер генә тиенгә дә язылмам дип бә-әк ныгытып килгән идем үземне. Булмады! Ике йөзгә яз инде булмаса. Ни булса, шул булыр. Тик менә кайткач, карчыкка нәрсәләр генә диярмен инде? Анысын бер Ходай беләдер инде. Яз, ике йөз тәңкә диген, Әхмәров Закирҗаннан диген. Патруннар алырга диген. Ул ике йөзгә байтак патрун ясатып буладыр, иншалла...

— Юк инде, абзый кеше. — Чолык килеп чыккан уңышны җәелдереп, киңәйтеп җибәрергә уйлый. Чөнки эскәмиядә утырган хатыннар карт белән барган тартышуда, сүзләре чыкмаса да, катнашып утыралар.— Монау хәтлек олпат гәүдәң белән ничек оялмыйсың син ике йөз белән кайтып китәргә? Әнә синең артта хатын-кыз утыра. Итәк тулы балачагалары белән. Иту алар дүрт-биш йөздән кәмга язылмаячаклар...

— Соң, Зәйнәп иптәш...

— Юк, биш йөз, и бер генә тиенгә дә ким түгел...

Ике арада сузыла башлаган аңлашу җебен Закир карт кырт өзеп ыргыта, юк итә.

— Син юк дисең, мин дә — юк! Теләсәң нәрсә эшләт, шул ике йөз тәңкә и бетте, китте шуның белән. Монысы инде сиңа Әхмәров Закирҗан дигән ир-егетнең сүзе. Вчо!

— Шулаймы?

— Шулай!

— Алайга киткәч, без инде менә болай эшлибез. Син әнә эскәмиянең иң теге очына барып утыр. Уйла ныклап. Биш йөзлек турында уйлат карт башыңны, аннан миңа әйтерсең. Бар!

— Күпме утырырга тиеш инде мин анда?

— Биш йөз булганчы.

— Ала-ай...

Карт авыр кузгалып, эскәмиягә күченеп утыра. Инде үзалдына сөйләнә башлый:

— Ясый башлаган чабатамны алып киләсе калган икән. Хет тукып бетереп кайтыр идем. Ничекләр иттереп бернәрсә эшләмичә утырырга инде кич буена...

— Ясаттылар ди монда синнән чабата, ясатмый ни. Тик кенә утырып кара әле менә. Белерсең тик утыруның нәрсә икәнен.

Зәйнәпкә ничек кенә булса да Закир картны сындырып, аны биш йөз сумга заемга яздырырга кирәк. Әгәр шуны эшли алса, аларның

«чәкәләшкәнен» тыңлап утырган хатын-кыз ике-өч йөзгә каршылыксыз язылачаклар.

Закир карт урнашып бетми, шулчак өй ишеге ачылып китә. Һәм аннан бишмәте өстеннән билбау буган, башына түгәрәк бүрек, аякларына тула оек-чабата кигән йорт хуҗасы Сәгыйт Елан кайтып керә. Бала чагыннан ук үткерлеге, хәйләлеге, житезлеге өчен Елан исеме алган адәм ул. Аннан соң кирәк җирендә башын юләргә дә сала белә. Янәсе, теле сөйләгәнне башы аңлап бетенкерәми инде. Бите, азрак очлаеп артка, өскә табан сузылган, бик зурдан булмаган кырган башы, очлаеп алга чыгып торган авызы, чыннан да, еланны хәтерләтәләр. Кергән уңайга ук башындагы колаксыз түгәрәк бүреген салып, аның эченнән каешланып каткан түбәтәен кире кия-кия өе эчендә утырган халыкны барлагандай бер кат карап чыкты да, телгә килде:

— Ә-ә-ә, ахирәтлә-әр! Эшләрегез шулаймыни-и? Хөртимени-и? Сез бит болай булгач, сапсим прапал бит инде? Ә-ә-ә-ә! Зәйнәп җилегегезне суырамы-ы? Ул суырыр шул, суыры-ыр. Ничаклы күп суырса, үзенең алган акчасы шул хәтлем күбрә-әк була аның. Белә-ә ул, ахирәтләр, нәстә эшләтергә-ә. Жалтуньясы ша-әп аның, ша-әп...

Финагент тимгел-тимгел булып кызарган-агарган битен кергән хуҗага табан борып чәрелди башлап, аның сүзләрен бүлә:

— Мин монда хөкүмәт кешесе. Мин кушканны эшлим. Күп сөйләнсәң...

— Шулайдыр бик, кушканныдыр. Авызын ачса, үпкәсе күренеп торган ялгыз хатыннарны таламасаң, түзә алмыйсыңдыр. Кем ашата ул балаларны...

Шулчак, малае Нәбиулланы тартып алган кебек, Гыйльминиса ире Сәгыйт Еланны теге якка тартып ала. Арт ягына сугуын сукмый бугай, тик ишетелә:

— Биш ел гына элек утырып чыкканыңны оныттыңмыни-и! И-и-и, Елан! Шул килде-китте акылың белән китеп барырсың инде тагы-ын.

Сәгыйт Елан хатынын үлепләр ярата, каршы әйтеп тә тормый, чишенергә тотына.

Ә бу якта финагент Чолык Зәйнәбе хатыннарны «кысарга» тотына.

— Йә, Гөльямал, син нәрсә әйтәсең инде безгә?!

— И-и-и, Зәйнәп апа! Нәрсәләр генә дияргә инде. Биш бала. Олысына унике дә тулмаган әле. Иң бәләкәе өч белән генә китте. Барыем киткәнгә өченче ел. Утын юк, печән җитәрлек түгел, сыер бозауламаган. Салам...

— Ярар алайса! Хәлеңә кереп әйтәм: өч йөз!

Гөльямал кулындагы калын шәлен әле бер, әле икенче кулына күчерә дә, күзләрен идән тактасыннан алмыйча, риза түгеллеген бедереп, башын селки. Күзләре тулы яшь, сүз әйтергә көче җитәрлек түгел.

Эскәмиянең теге башыннан Закир карт телгә килә:

— Кешедән оялмасаң, Зәйнәп, Алладан оялыр идең.

Чолык Зәйнәп карт ягына тиз иттереп борыла:

— Синнән сораган кеше юк. Тик утыр. Юк Аллаң белән баш катырма монда карт башың белән. Безнең Аллада эшебез юк. Гитлерны дөмектерәсебез бар. Ирләрегез тизрәк кайтсын дип кыешам мин көн-төн монда.

Гөльямал лышык-лышык килеп, акрын гына еларга тотына.

— Ир... кайт...кач, аның ку... кулына балаларын... ык... тапшырырга... кир...әк бит. Каян ал...ыйм мин ул ак...чаны-ы...

Азрак тынып тора да тынычрак итеп сөйләп китә:

— Кич булдисә, Равилем бер нәрсә күрми. Тавык күзе булды. Биемем урында ята тормастан. Ике ай булды. Фәүзиям...

Зәйнәп утырган җиреннән өстәлгә суга:

— Җитте! Тукта! Бар кайт, биемең белән киңәш ит! Иртәгә шушы вакытка килеп җит. Түлке өч йөз дип кил. Бар кайт!

Атна буена Түбән очтагы Сәгыйт Елан йортында хәрби заемга язылу бара. Язылу тәмамлангач, «Колхоз ударчысы» дигән йон газетасында мәкалә басылып чыга.

«Районыбызның «8 март» колхозы хезмәткәрләре данлы Кызыл Әрмиябезне коралландыруны тагын да ныгыту өчен быел үткәрелгән Хәрби заемга үзләре теләп язылуда зур активлык күрсәттеләр. Шулар арасында 4 нче бригада колхозчыларыннан актив катнашучылар: Ахмеров Закирҗан улы, Тайгунова Гөльямал Авгыйз кызы, Абсаттаров Сәгыйдулла улы булдылар. 8 март колхозчылары заемга үзләре теләп язылып, хөкүмәт кассасына унбиш мең сумнан артык акча тапшырдылар.

Финагент Зәйнәп...»

Ул заемнан Камилә дә читтә кала алмады. Тик, кичләрен атлар карарга кирәклектән, ул Сәгыйт Елан өенә барып йөремәде. Вакыты булмады. Шунлыктан Чолык Зәйнәбе аның эшләгән җиренә үзе килде. Кыза башлаган иде, Камилә сәнәген күтәреп атлары арасына керде дә китте. Шуннан Чолык аны кычкырып чакырып чыгарды да, сарай капкасы төбендә йөз иллегә тамгасын суктырды. Камилә яза белми иде.

Язылу тәмам булгач, Сәгыйт Еланның өендә берничә кичне ярты төнгә кадәр утырып, өч йөз сумга язылган Закир Таракан авыл урамнарын тутырып сөйләнеп йөреде:

— Язылдым, нигә язылмаска, ди. Малайларга, кияүләргә нимескә каршы атарга патрун кирәк. Теге трухлинейный винтуфкага. Әййе. Әнә, гәҗиттә дә язып чыгарганнар, үзе теләп язылды дип. Иң беренче булып минем фамилиям тора. Ахмирыф дигән, Закирҗан дигән, Шакирҗан малае диелгән. Язылабыз, нигә язылмаска. Тик Гитлерны гына дөмектерсеннәр. Хәзер патруннары җитәрлек булыр инде. Тик исән-сау кайтсыннар малайлар да, кияүләр дә. Кирәк икән тагын язылырбыз, түләрбез. Нигә түләмәскә ди, үзебезнең влачка бит, читкә түгел...

Язылмаска озак тартышкан Закир Тараканнан әнә шулай патриотизм аңкып, чигеннән чыгып ташып тора иде заемга язылу беткәннән соң...

Иң авыры кырык өченче елның кышы бетәр алдыннан башланды. Сугыш алдыннан хезмәт көненә мул итеп алынган ашлыклар бетте. Кыш уртасында ук авылда ачлык башланды. Язгы чакта ачыласы бәрәңге базлары вакытыннан алда ачылды, ябык сарык-кәҗәләр суелды, авыр эштән үлгән ат түшкәләре ашалды. Азрак кием-салымнары булганнар җыйналышып, бәләкәй чаналарга шуларны төяп, өч-дүрт кеше бер булып тартып урыс авылларына шул киемнәрне игенгә, бәрәңгегә алмаштырырга агылдылар.

Ачтан алҗыган кешеләрнең ялан-кырларда адашып, суыкта туңып үлүләре табигый хәлгә әверелә башлады.

Никадәр генә авыр дип саналса да, Камилә гаиләсенең хәле башкалардан әйбәтрәк иде. Чөнки Камиләнең каралы-аклы зур, ябык сыеры бар. Барлык ашаганы сөткә китеп торганга ябык ул хайван. Атлар янында сыерның да тамагы тук. Балалар бәхетеннән сыер февраль башларында бозаулады. Сөт янына аз гына булса да бәрәңгесе бар, алабута ипие. Зөфәр белән Хәлим өлгерә башлаган көенә бакчалардан алабута җыйдылар, аны киптерделәр, суктылар. Көзен капчыклап Урман Авызы дигән якындагы имәнлеккә имән чәкләвегенә йөрделәр. Хәлим бәләкәй булса да, Зөфәр абыйсыннан калмастан, кышлыкка азык әзерләүдә зур тырышлык күрсәтте. Бәләкәй генә булса да, ачлыктан курку аның канына гомерлеккә сеңгән иде инде. Шул имән чикләвеген мичтә киптереп, кабыгыннан арындырып, алабута белән катыштырып тегермәндә тарттырдылар. Кара-көрән төс бергә кушылган үзенчәлекле он булды. Шул оннан кыш буена таба күмәче салдылар. Ашарга авыр, тәмсез. Аннан соң иң авыры — эч ката. Ачлыктан котылырга башка юл булмаганнан, шул ипине барысы да тавыш-тынсыз гына кимерәләр. Ярый әле сыер бар, ярый әле аның ап-ак сөте бар. Зур ала сыер тире белән

сәяктән генә тора. Биктимер аны сатып алган чакта, сыер хуҗасы — башкорт әйткән:

— Син энем, бу хайванның ябыклыгына, тышкы ямьсезлегенә карама, ал сатып. Илләмә дә сөткә шәп инде! Бер сауганда чиләк ярым бирә, үзе бик тә талымсыз, сөте куе. Сатмас җирдән сатам — кустымны утырттылар. Ярдәм кирәк шуңарга...

Сыер, чыннан да, шәп булып чыкты. Теге, башкорт соңыннан да берничә мәртәбә килеп, сыерның хәлен белеп чыкты. Елмаеп Камиләгә дәште:

— Син, килен, катык салып бир инде минем сыер сөтеннән оетканын. Төшләремдә күреп уянам шул катыкны.

Өч ел узгач, янә килеп, тана бозавын ярыйсы гына хак түләп сатып алып китте дә, башкача күренмәде башкорт агай.

Озак көтеп алган яз җитеп, карлар китеп җир ачылгач, авыл халкына көтелмәгән зур афәт килде. Кыш азагында ачка какланган кешеләр көздән кар астында калган иген-башакларны эзләп, ялан-кырларга агылдылар. Кар астында калган башакларны җыйнап алып кайтып, тиз генә мичтә киптереп, кул тегермәннәрендә тартып ярма ясадылар. Шул ярмадан... өйрә, ботка пешерделәр. «Аллага шөкер, карага бастык, иншалла тамаклар туйды, инде үләнгә дә барып җитәргә күп калмады. Булыр анысы да болай булгач,» — дип куаныштылар, ашап, тамакларын туендыргач. Тик...

Куанганнары бушка булганмы, кар астында кышлаган башактан ярма ясап, ботка пешереп ашаганнар аның агулы икәнен берничә көн үткәч кенә аңладылар. Тик соң иде инде. Шул берничә көн үткәч, кешенең башы авырта башлый, тәненә кызыл тимгелләр чыга. Ул хәлсезләнеп урын өстенә егыла. Аның авыз-борыныннан, колагыннан кан китә. Башына юеш чүпрәк ябалар, борынына, колакларына чүпрәкләр тыгып канын туктатырга тырышалар. Ләкин дә ярдәме тими инде. Кан килә башлаганга ике-өч сәгать вакыт үтми, кеше йокыга киткән кебегрәк иттереп күзләрен йома да җан бирә.

Кар ачылганнан соң атна-ун көн үтмәде, авылның бик күп өйләрендә әҗәл үзенә корбаннар тапты. Сугыштан сул аягын имгәтеп, кырык икенче елның җәендә өенә кайту бәхетенә ирешкән Ябрәй Хәсәне, хатыны Нәкыя һәм алты баласы дүрт көн эчендә үлеп беттеләр. Шул дүрт көннең берсендә атлар карарга чыгып килгән Камиләгә ике тәгәрмәчле арба тарткан шул Ябрәй Хәсәненең уналты яшьлек кызы Рабига эндәште:

— Камилә апа! Монау арбаны өстерәргә хәлем юк. Әнине тартып балниска китергән идем. Врач апа әйтә, әниең үләр инде, иртәгә килеп ал, ди. Илаһым, барыбыз да үлеп беттек, бер үзем торып калам инде...

Камилә кызны чәчләреннән сыйпады:

— Елама акыллым! Үлмәс, бәлки әниең. Әйдә кер, сөт эч азрак. Хәлең булса, әниеңә дә илт. Бирермен. Нәкыя апаның изгелеген күп күрдем мин...

Икенче көнне кыз арбасын алырга килмәде. Әнисе кушканча Хәсәннең өенә барып кайткан Зөфәрнең йөзе тулы курку иде.

— Рабига апа үлгән, әни. Вич канга буялып беткән. Сәкедә мендәр почмагын тешләп үлгән. Үзенең күзләре ачык, әни. Мендәре тоташ канга буялган.

Кеше күп үлгәнлектән, авыл советы зур чокыр казытып куйды. Камилә Хәйдәр белән барып больницадан Нәкыя апаның мәетен алып кайтып, кызы Рабига белән икесенең битләрен юып, шул зур кабергә илтеп, икесен бергә куйды. Эт-коштан сакларга кабер янына ике картны билгеләгәннәр. Икесенә бер чүлмәк сөт бирде. Берсе дога кылып битен сыпырды да, исенә төшерде:

— И-и дөньялар, дөньялар! Егерме беренче елгы ачлыктан шушылайлар иттереп ике зур ямыга тутырганнар иде ачтан үлгән халыкны. Тагын килде афәт. Нинди ахрызаман каһәр төште соң әле безнең халыкка, ә? Сибгатулла абзый, диюем!

— Әйтмә дә инде, Бикмөхәммәт энем! Җимереп ел саен иген үстерәбез. Ә көн-төн эшләгән кешене ашатуны уйлап та бирми бу хөкүмәт. Сугыш икәнен дә беләбез, солдатка икмәк кирәген дә беләбез. Тик аталары сугышта чакта, монда өйләрендә балалары кырылып ятырга тиеш түгелләр бит инде ачлыктан? Җиңдек тә ди инде бу Гитлерны. Шуннан әтиләре кайтырлар инде, исән калганнары. Нәрсәләр дип җавап бирербез инде без аларга, кая безнең балалар дип сорасалар? Минемчә, урыннарда утырган начанства уйлап бетерә алмый. Яисә монда дошман кулы уйный дип уйлыйм мин. Нимес бирәр нәстә сиптермәдеме икән...

Чарасын күреп өлгергәнче, авылларда халык кырылышмы кырылды...

1945 елның март башында, солдатча киенгән, кара күзлек кигән ул кешенең каладан транспорттан кайткан чанадан төшкән чагында ук урамдагы малай-шалай шәйләп алды иң башта. Шунда ук уратып та алдылар. Солдатның уң беләгеннән тоткан кызыл иренле, солдатча киенгән марҗа урысчалатып сорады:

— Н-ну, узнаете своего земляка?

Малайлар арасыннан җавап бирүче булмады. Шулчак кара күзлекле солдат телгә килде:

— Малайлар, сезнең арагызда Зөфәр йә, Хәлим юкмы?

— Кайсы Зөфәр ул?

— Песәй Зөфәре.

Шулчак малайлар арасыннан берсе башкаларны аралап алга чыкты.

— Абзый, син әллә аларның әтисе Биктимер абзыймы?

— Әййе. Мин аларның әтисе булам.

— Алар бит хәзер ат двурында торалар. Дүртенче бригатныкында. Чаңгы шуарга да безнең янга түгел, зират тавына йөриләр. Анда бик шәп сикәлтә бар.

Балаларга хас булган ихласлык белән малай турыдан-туры сорап куйды:

— Раниный булып, әллә күзләрең сукырайдымы, Биктимер абзый?

Биктимер аңарга җавап бирмәде, кулы белән сәрмәнеп, аның кул башларыннан нык иттереп тотты да чана янына этте:

— Әйдә, юл күрсәт... шул двурга. Үзең соң кем малае буласың?

— Ясаклы Миниярныкы. Вәсим мин.

— Әтиеңнән хат киләме?

— Юк шул. Соңгы хаты Сталинградка озаталар дип килгән ие, шуннан соң юк бер хаты да. Ике елдан артты инде. Син күрмәдеңме минем әтине, йөрегән, сугышкан җирләреңдә, Биктимер абзый?

— Юк бит, малай күрмәдем бит. Әйдә, Вәсим, алып бар инде син мине.

Шатлык белән бергә кайтып керделәр двур өенә. Биктимернең ике күзе дә дөм сукыр иде. Ничек сукырайганын ул сөйләмәде дә диярлек. Польша җиренә кергәч, үз янында шартлаган бомбадан һушын җуеп егылган. Озак кына Мәскәүдәге бер госпитальдә дәвалаганнар. Тик ярдәме тимәгән шул.

Атнадан артык двур өенең ишеге ябылмады диярлек.

Көннәр, атналар, айлар үтте.

Тормышының үтә дә авыр икәнен эшсез, өендә, хатынының, балаларының кайтканын көтеп утыру белән аңлады Биктимер. Өстәвенә, хуҗалыкта булган барлык эшләрне башкаручы Камилә тик олы уллары Хәйдәр белән сөйләшеп, киңәшеп кенә хәл итәргә өйрәнгән иде. Ире сукыр булгангамы, хатын кеше үзе дә аңлап бетермичә, барлык йорт эшләре башкарудан ирен читтә калдырды. Биктимер өчен иң авыры — эшсез өйдә утыру иде.

Тугыз яшендә әнисез дә, әтисез дә торып калып, әтисенең бертуган энесе Сәләхетдин абзасында үсте Биктимер. Абзасы аңарга үзеннән ике яшькә олы булган, шушы Камиләне башкодалап алып бирде. Биктимергә ул чакта уналты гына яшь иде. Инде менә дөнья көтәргә кирәк, ә йорт

эчендә Биктимер эшли белә торган эш юк. Бетмәс-төкәнмәс башы тулы дуамал уйларының башына чыга алмыйча, Биктимер көннәр буена сөйләшмичә нигездә утырырга күнегә башлады. Госпитальдә, кирәк булса кире кил шушы адрес белән, дип озатканнар иде аны. Шул турыда ул инде, язгы кояш астында утырып, сугышта ватылган тәненә, җанына ял бирергә болашып ныклап уйлана башлады. Нәрсә булып беткән булыр иде ул уйларның очы, әгәр дә бердән бер көнне...

Йорт нигезендә, авыр уйлар басымы астында утырган сукыр солдат янына авылның Ясаклы урамында яшәүче Кара Куян Зәйнулла дигән карт килеп керде:

— Әссәламегаләйкү-үм, Биктимер энем!

— Вәгаләйкем әссәлам! Тавышың таныш инде танышлыкка. Тик кем диеп кенә әйтим икән инде сине. Ясаклының... Зәйнулла абзый дисәм инде,—диде кыяр-кыймас кына кулларын сузып.

— Әййе, мин булам, энем. Кара Куян Зәйнулласы. Ыы! Авыл биргән исемнән качып та котылып булмый. Рәхмәт, тавыштан таныйсың бит әле.

— Тырышасың инде, тик утырганнан, аптыраганнан. Без бит синең белән калага атлар җигеп транспорт йөрегән кешеләр. Сугыш алдыннан, исеңдәдер. Әллә утыз өч иде инде, әллә утыз җүртенче елны. Кыш салкын иде бик...

Биктимернең бик тә сөйләшәсе килә иде Зәйнулла Кара Куян карт белән. Карт аны тиз аңлап алды.

— Соң, истә булмыйча тагын. Сәгыйт Елан безнең солыны урлый торганые үзенең атына. Син солыга күмер кушып, тәки тотканыең бит шуны...

Икесе дә әллә кайларда калган истәлекләрдән күңелләнеп китәләр.

— Үзеңнең хәлләр ничегрәк, Биктимер энем. Үз хәлеңә үзең күнегәсеңме, дип сорарга да тартындыра инде. Шулай да, ничегрәк яшисең дип, хәл белергә килүем иде.

— Хәлләрне үзең күреп торасың инде, Зәйнулла абзый. Тәфсилләп сөйләп торасы юк. Бөтенләй диярлек хатын-кыз кулына, бала-чага карамагына калып барам инде. Берәр нәрсә кылырга булсалар, йорт эшләре, дөнья нужасы буенча, хатын белән малай чыш-пыш сөйләшеп алалар. Мин читтә калам. Кирәгем юк. Чөнки эшли алмыйм бит. Эш килми бернинди дә минем кулдан, бар белгән эшем кабыклы бәрәңге пешереп тору, эштән кайтканнарга, укып йөрегәннәргә.

— Шулай-ай, энем. Синең кебек арсландай ир-егеткә өй эчендә тик утыру авыр инде. Кичә кич йокларга ятканда җиңгәң әйтә: «Биктимерне бер малае җитәкләгән, урам уртасыннан киләләр икәүләшеп. Йөрәкләрем өзгәләнде инде икесен дә кызганып»,—ди. Шунда сине күргәч, башына бер уй килгән хатынның. Мине кичтән үк наказлап куйды, бүген сиңа килергә. Мин бит сине һөнәргә өйрәтергә дип килдем бүген.

— Нинди һөнәр ул, әйтеп кара!

— Әйдә, мин сине чабата ясарга өйрәтәм. Ни өчен чабата дисәң, хәзер аңлатам. Үзең беләсең, мин авылның иң маһир чабата ясаучысы. Миңа җиткән кеше юк. Алты-җиделән дә үрәм, кызлар чабатасы да үрәм. Авылның бөтен кызларына мин үрәм чабаталарны. Өйгә киләләр сорап. Шул хәтлек куллар остарды чабата ясарга, күзләрнең гүпчем кирәге дә юклар. Чабатаны күз белән күрмичә дә ясап була икән. Бүген иртән торгач, җиңгәң кызыл яулыгы белән бәйләп куйды минем күзләрне. Бер сыңар чабатаны «ә» дигәнче үреп ташладым. Шуннан тукып, шул чабатаны карамыйча бетереп килдем синең янга. Менә кара...

Зәйнулла карт аяклары янына куйган киндер капчыктан Биктимергә ярарлык бер пар чабата чыгарды.

— Кара диюем ялгыш инде. Син күңелеңә авыр алма берүк. Мә менә кулыңа бирәм. Тот! Сиңа болар!

Биктимер калтыранган куллары белән чабатаны алды да, бик җентекләп сәрмәргә тотынды. Аннары карлыккан тавыш белән картка шиген белдерде:

— Белмим шул инде, Зәйнулла абзый. Мин булдыра ала торган эш микән инде бу? Ул чабата ясау би-ик катлаулы, четрекле эш бит. Күзле чакта да, кешеләрнең чабата ясаганын карап утырып кына да исләрем китә торган иде. Шул хәтлек юкәләрне кайда, ничек белеп тыгып бетерергә кирәк тә, каян чыгара белергә кирәк. Каян беләләр икән шуларның барысын да дип аптыраплар утыра торган идем.

— Булдырырсың, энем, син юкны гына уйлама. Аннан мин сине чыпта сугарга да өйрәтермен әле. Анысын инде калхуз кирәгенә сугарсың. Иншалла, озакламас сугышлар бетәр, калхузлар тагын ныгып, труддингә икмәк бирә башларлар. Нык ышанам мин икмәкләр ашаячагыбызга, күкрәкләргә терәп кисеп, Алла боерса. Зур малаеңа әйт, бүген кичләтеп миңа килеп чыксын әле. Без аның белән төнгелеккә курыска барып килербез. Атын җигеп килсен. Балта бар миндә. Үткере, чарлап куйганы. Күрсәң... эһ-һем, эһ-һем... белсәң дип әйтүем инде. Түбән оч төпкелендәге юкәләрнең курыска шәплекләрен.

Юк-барны уйлама син, Биктимер энем. Күз юк дип, кул салындырып утырып булмый. Сукыр Суфыйны гына исеңә төшер. Әлхәмделилла шөкер, менә дигән иттереп итек-читекләр тегеп көн күрде. Теге кырык өченче елны гына казакъ ягына чыгып китте. Мулла булып йөри, диләр, хәзер шул якларда.

— Бик авыр бит, Зәйнулла абзый. Ай-һа-ай, көннәр, төннәр үткәрүләре-е...

— Яшәргә, тереклек итәргә кирәк, энем. Аннан онытма, синең өч малаең бар, кызың. Үсеп җитәрләр, өйләнешерләр барысы да. Китәрләр оныкларың. Алда әле, Биктимер, синең иң асыл көннәрең! Алда! Оныкның исен искәсәң, барлык дөньяның кайгы-михнәтләре юкка чыга да бетә алар. Бабай кеше, иң кирәге оныкларга. Әкиятләр, хикәятләр сөйләргә, киңәш-уңашлар бирергә. Башың яшь әле синең бик белеп бетермисең.

— Рәхмәт сиңа, Зәйнулла абзый! Югыйсә мин бик авыр уйларда йөри идем әле соңгы чакларда.

— Сер булмаса,ниндирәк уйлар инде алары?

— Сер түгел дә, тик алары ике арада калсыннар инде. Мин башны алып чыгып китәргә дип уйлап йөри башлаган идем. Соңгы көннәрдә, Гуспиталдәге генерал әйткән иде, өеңдә начар булса, монда кил, слипуйлар артиленә эшкә урнаштырырбыз, дигән иде.

— Анысы нәрсә инде тагын?

— Минем кебек сукырларны бергә җыйнап, шунда һөнәргә өйрәтеп яшәргә урын биреп, акча түләп, яшәтә торган урын була. Пима бастыралар, итек тектерәләр, агач эше. Әзмени инде.

Зәйнулла карт аз гына уйланып утырды.

— Анысы синең эш инде, энем. Тик хатыныңны, монавы хәтлек асыл малайларыңны ташлап китү ир-егет эше түгел инде. Аннан соң онытма, монда синең туган илең, туган авылың, туган җирең. Агай-энең, туганнарың, күрше-күлән, дус-иш. Эчкән суың торып калачак.

Ю-у-ук, Биктимер энем! Безнең яклар кебек асыллыклар юк башкача җир йөзендә. Мин Герман җирләрен дә, Кытай җирләрен дә күргән кеше. Беләм мин. Туган як, диләр шуңа күрә. Туган й-а-ак!..

Тормышы үзгәрде Биктимернең шул көннән соң. Зәйнулла бабай көн саен килеп, Биктимерне чабата үрергә өйрәтә башлады. Кабаланмыйча, һәр юкәнең юлларен өйрәтеп, кая салырга, ничекләр иттереп китереп чыгарырга башка юкәләр арасыннан — барысын да Биктимернең куллары хәтерендә калырлык итеп өйрәтте. Беренче чабатаны өч көн үрделәр. Бабай Биктимернең кулларыннан тотып юкәне ничекләр буйга тигез иттереп ярырга, ничек итеп аның каерысын аерырга, ничә сәгать ул юкәне суда тотарга, аннан ничекләр иттереп чабатаны үрә башларга —

барысын, барысын жентекләп, кулларыннан тотып, жиренә житкереп өйрәтте дә өйрәтте. Икесе дә тирләп, алжып чыктылар беренче көннәрдә.

Чабаталарның башы кыеш чыкты. Алды киңрәк, арты таррак булды. Калыпка утыртып тукый башлаган чакларда Биктимернең куллары калтырый торган булды. Шулай булса да, эш акрынлап кына алга барды. Иң беренче чабатасын Биктимер Камиләгә ясап кидерде. Чабата кия башлаган хатынының күзләреннән аккан яшьләрен күрмәде Биктимер. Сорады:

— Йә, ничегрәк? Ярыйсымы аякларыңа?

— Әййе! — диде Камилә яшьләрен йотып.— Бик җайлы булганнар.— Уңайсызланып кына ирен кочаклады:

— Рәхмәт инде сиңа... чабаталарың өчен дә...

Биктимернең сугыштан кайтканнан бирле елмайганы юк иде. Күңелле итеп, бөтен йөзен балкытып елмайды:

— Тагын нәрсә өчен?

Камиләнең үзе генә белгән сере бар икән. Шуны иренә житкерүне кирәк тапты:

— Авырлымын бит... Биктимер. Тагын бишенчегә балабыз булачак... бел син дә...

Биктимер катып калды. Камилә сакланып кына аның йөзенә карады да, тетрәнеп китте. Иренең сукыр күзләреннән шатлык яшьләре ага иде...

— Алайга киткәч, күбәябез икән. Син бар, әй, эшләреңне кара. Мин... чабатага утырыйм инде. Балаларны ашатырга кирәк бит...

Көннәр буена Биктимер тормастан чабаталар ясарга утырды. Зур, калын гәүдәсен кәкерәйтеп, эшләде дә эшләде ул. Ике-өч сәгать утырганнан соң торып, уллары ишек алды буйлап сузып биргән тимерчыбыкка бауга тотынып, арлы-бирле йөрештереп алды. Утынлыкта сәрмәнеп утын кисте. Кечкенә кул пычкысы белән. Чабата ясарга курыс яклары да җайланды Биктимернең. Улы Хәйдәр ат белән йөрегәннән курысны күп алып кайтты. Зөфәр белән Хәлимне утыртып, төнгелеккә чыгып киттеләр курыс урларга. Малайлары үзе кебек уңган иде Биктимернең.

Әзер чабаталарны базарда кече улы Хәлим сатты. Сату-алу эшенә сәләте зур булып чыкты малайның. Товарын сатып бетермичә кире алып кайткан чагы булмады. Базар көнне сатып бетерә алмаса, бәләкәй базарга чыгып, шунда эшен бетереп керде.

Сукыр булса да ир әле ул диделәр, Биктимер турында, сугыштан ирләрен көтеп ала алмаган, тол калган хатыннар. Һәм ул шулай да иде. Зәйнулла бабай килеп чабата үрергә өйрәткәннән соң, тормышлары җайлана башлады Камиләләрнең. Тик сугыш афәтләре бу йортны онытып бетермәгән икән шул...

Госпитальдән кайтканда ук йөткергәли иде Биктимер. Кырык алтынчы елның ачлыгында нык бирешге. Көне-төне бөкерәеп чабата өстендә утыру да файдага булмады — үпкәсендәге немец бомбасының корыч кыйпылчыгы үзенең кара эшен акрынлап кына эшләде. Тәрбия дә житмәде әзмәвердәй гәүдәле иргә. Биктимер үпкә авыруы белән ныклап сырхаулый башлады. Һәм кырык җиденең язгы сулары белән бергә бу дөньядан китеп тә барды. Камиләсенә дүрт бала өстенә бишенчегә туган, инде икенче яше белән китеп, тупырдап йөгергән малаен да калдырып китте...

Биктимерне җирләгәч, ай тулыр-тулмаста Камилә үз йортына күченеп кайтты. Һәм атлар караудан да чыкты. Кыяр-кыймас кына тагын бер ел эшләгәнен үтенгән бригадир Тимеркәйгә җавабы кыска булды:

— Булмый, житте. Балаларны укытасым бар. Житте зурысы надан калганы да. Калхуз гына димәгән минем балаларыма. Үлсәм, үләм — укытам. Үз йортым таркала, аны да уйла син.

Тагын бер сәбәбе бар иде, двурдан үз өенә кайтуының. Эшләгән жиреннән кайтып кереп, двур өенең ишеген ачып кергән уңайга, чабата ясап утырган Биктимере, күрмәсә дә, башын хатыны кергән якка борып

карар кебек тоела иде. Биктимернең утырган урынының буш икәнен күрү, хатынның йөрәгенә ярып кон дә җәрәхәт ясый, ялгызлыгын көчәйтә генә...

Әтисе сугыштан кайткач та, эшнең авыры Хәйдәр җилкәсендә иде. Сугыш беткән елны унбиш яшен тутырган Хәйдәр инде киң күкрәкле, күлмәге эченнән түгәрәкләнеп сизелеп торган көчле кул-башлы, зур куллы егеткә әверелеп килә иде. Бодай тутырылган биш потлы капчыкларны ул җирдән уйнатып кына күтәреп алып, аркасына китереп сала. Урманга кем белән генә барса да, бүрәнәнең юан башыннан күтәреп ала. Кыш көннәрендә яландагы эскертләрдән печән, салам ташыганда шул эскертләрдән дүртәр, бишәр йөккә печән, салам ыргыта. Бригадада иң тырыш, эшчән яшүсмерләрнең берсе. Җиһанша бабай урман кискәндә агач астында калып һәлак булганнан соң, аның урынына бригадир булган Тимеркәйнең иң ышанычлы эшчесенә әйләнде. Кырык өченче елның кышында җигә башлаган Банка биясе дип йөртелгән кара бияне җигеп йөреде колхоз эшенә. Двурда да эшләде, бригада эшләрендә дә өлгерде.


Әтисен җирләгәч, йортка хуҗа булып Хәйдәр калды. Әтисе исән чакта да барлык авыр эшләрне Хәйдәр алып барганлыктан, төп көч аңардан, хуҗалык аның өстендә иде.

Иреннән торып калган әнисе Камилә хәтта гәүдәгә дә кечерәеп, бәләкәйләнеп калгандай булды. Дәшмәскә әйләнде. Кая барса да, итәгенә ябышып, калмастан ияреп йөрегән Рамил исемле улы белән һәрчак бергә булдылар. Анысы — Биктимернең, күрше-күлән әйтмешли «сугыштан алып кайткан малае» булып, төсе, кыланышы, атлаулары, гәүдәсен тотышы белән тач әтисе иде.

Үз йортларына кайткач, сарыклар санын арттырып җибәрделәр. Казүрдәк үрчеттеләр. Тавыклар саны да артты. Тик әллә ни мантый алмадылар. Чөнки колхоз хезмәткә аз бирде, турысын әйткәндә, бернәрсә дә түләми иде. Җәй көннәрендә эшләгәндә көненә ике-өч граммнан ашарга бирелгән онга «аванс оны» дип бригадир һәркөнне исәпләп, аерым дәфтәргә теркәп бара.

Шул җыелган онны көз көне «труд»ка биргән игеннән исәпләп тотып алып калалар. Ә көз көне «труд»ка нибары ике-өч йөз грамм ашлык эләгә. Ашаганың белән вәссәлам көз көне. Җәй буена эшләгәнең бер күтәреп алып кайтырлык төенчек була. Келәтләр янына барасың да, ындыр табагында көшел-көшел булып өелеп яткан гәрәбәдәй бодай, тары, арыш, солы өемнәренә карап, кая, кемгә озатыла инде болар дип, эчтән генә зар елап кайтып китәсең...

*Ахыры бар.*





## Иделбикә

### Триптих

*(Айвазовскийның мәгълүм сурәтенә)*

Шанлы рәссам! «Триптих»ыңнан уйга баттым.
Өч бүлекле сурәтеңдә сер (астыртын),
Таңы-төше-киче адәм гомеренең
Кинаядә гәүдәләнеп, өртелгән тын:

I

...Диңгез өсте — зәңгәр күзгә. Кораб — шәмдәй,
Кояш нуры очларына бәйләнгәндәй.
Ак корабта яшьлек төшкән сәяхәткә,
Гомер башы ак хыялдан эрләнгәндәй.
(Адәм язы ал нурларга сарылганда
Хәвеф-хәтәр өерелгәсен кая шәйләү!)

II

...Тик Җир-Күкне каплый давыл... Кайда кыйбла?!!
Шашкан дулкын ак корабка сыпырыла.
Мачта ава, кораб кырып, диңгез сыный...
Көчсез җаннар, гәүдә ташлап, аерыла.
(Гомер шулай атламыймы уртасына?
Язмыш-хыял тәңгәл килми, күңел сына...
Тәңре әмерен онытып, мохит көнең кора,
Кануннарын җан өнәми, сын буйсына).

III

Диңгез тынган. Алышлар да тәмамланган.
Исән калган төркем карый әнә ярдан.
Ватык агачларга сыенып, дулкын кичкән —
Җиңгәннәрнең ак йөзләре кара янган...

(Дисәләр дә: «Бәхет кору — тик үзеңнән»,
Айкалмыймы адәм гомер дингезеннән?!

## Мине генә

Язгы чәчәкләрне җыеп,
чыгам каршыларыңа.
Үзәк өзеп әйткәннәрең
куша каршы алырга.
Мине, мине очратырга
үстем, дигән идең бит.
Мине генә, мине генә
сөйдем, дигән идең бит.
Төнбоеклы зәңгәр күлгә
парлы аккош төшәчәк.
Пар аккоштай булсак кына
бәхет күрер киләчәк.
Мине, мине, мине генә
сөям дигән идең бит.
Мине генә очратырга
киләм дигән идең бит.

## Сембергә багышланган тезмәләр

Идел өстендә күпер,
һәр килгән кеше күрер:
Текә ярлы, биек таҗлы
Семберкәем, син — тик бер.
Сембер, күпереңнән карыйм
Иделен дә, Зөясен.
Бу хозурлык иясенә
килә башым иясем.
Сембер, Сембер, Семберем,
Иделдә бердәнберем.
Юлын үтеп, еллар гизеп,
яшәгән гүзәл җирем.
Аллеяларың кыркылган,
сын ясап кистергәнсең.
Чибәрләрнең чибәрләрен,
Сембер, син үстергәнсең.
Гөлбакчаларың ишәйде,
ия утырта белеп.
Ярларында чүплек иде
егерме еллар элек.
Вырыпай да бар бездә,
Даманск та бар бездә.
Ике атна барасы юк —
Камчатка үзебездә.
Семберле көтми авызына
алма пешеп төшәсен:
Эсэнгы көнләп күзәтә
Сембернең «кәрзинкәсен».
Яшә, Сембер, яшә, Сембер,
кагылмасын кайгылар...

Бәлки, язган җырларым да
йөз телендә яңгырар?!.

## Кемнең хакы бар

Чиксез галәм җәйрәвендә
иң кодрәтле нәрсә бар?!
Тик ҖИР-СУ-ҺАВА яраткан
Үзең, Тәңре — Хөкемдар!
Бар табигать — тереклеккә,
Кешелеккә җан өрдең.
Бөек изге үлчәмеңдә
тере дөнья төзедең.
Кояш-Аең, урман, диңгез —
уч төбендәге садә
аң үтмәслек бәйләнештә,
гап-гади күренсә дә.
Тетрәтә, адәм-зат кыра
шул зур мирасны бирдән,
бушлай кулына төшкәнгә,—
һич куркусыз Тәңредән!
И Тәңрем! Ничек йолырга
кыргыйлыктан йөгәнне?
...Җимерергә базсын адәм
тик үзе төзегәнне!

## Сагынам

Сагынамы йөрәк кайтмас назын:
Үз көенә күчә тагын сазым,
Җанландырып куя күз алдыма
Бәхет чорларының кайтавазын.

Оча уем Кавказ итәгенә...
Күрәм гөлләр үргән яшел тавын.
Өндә кайтам сыман яшьлегемә
Тыңлар өчен дулкыннарның шавын.

Үтәбез күк кулга-кул тотышып,
Тагын парлап шаулы яз эзеннән.
Умырзая, энҗе чәчәкләрсе
Моңсу карый синең күзләреңнән...

Көннәр-төннәр үткәргесез озын,
Кышы-җәе түгел синсез кызык...
Кая ярсый-ярсый янган гомер?
Кая безне кавыштырган сызык?...

## Калфак

Җәеп энҗе чәчәк, энҗе яфрак,
Кара бәрхет нечкә каелган.

Әнкәй бәгърем чиккән энҗе калфак
Энҗе күздән карый кай елдан?

Кыз чагының серле күләгәсе,
Ел тутыгы аңа төшмидер
Еллар аның бәхет кинаясе
Иқәнлеген генә сөйлидер.

Кулы чиккән энҗе калфак киеп,
Кара чәчкәйләре өстеннән,
Алсу йөзле чибәр, өмет көтеп,
Карагандыр аңа көзгедән.

Их, бирәсе иде үзенә ял...
Кыймыйм омтылырга уена:
Калфак чиккәнендә туган хыял
Чыкты микән тормыш юлына?

## Алтайга

Сүнмәс, Алтай, сиңа мәхәббәтем,
Йөрәгемне биләп тотырдың.
Уралымның сихри әкиятен
Мин яңадан синдә укыдым.

Онытылмас, сырлап, гаскәр кебек
Тезелешкән эрбет, чыршылар.
Акчарлактай канатларны җәеп,
Чаңгы белән синдә очулар!

Күңелемдә һаман зәңгәр күгең
Зәңгәр чатыр булып җәелер.
Ылысларың тоткан кар өеме
Энҗе пәрдә булып сибелер.

Тау-түбәләр үрләр зәңгәр күккә
Ерак — күз күреме җиткәнче,
Бата-бата әкрен зәңгәрлеккә,
Зәңгәрлеккә батып беткәнче...

# ТЫНГЫСЫЗ САБЫРЛЫК



Минем аны Шәһидә Максудова дип тә, Гөлшәһидә ханым дип тә әйтәсем килми. Чөнки минем өчен ул — һәрвакыт Шәһидә апа. Аның сабырлыгы, тыйнаклыгы, акыллы булуы сокландыра. «Мин — язучы хатыны, ике язучының әнисе, язучы киявебезнең әбисе»,— дип кенә әйтеп куя ул, үзенчә бер шаярган төсле итеп.

Шәһидә апа 1926 елның 29 ноябрендә Әгерҗе районының Уразай авылында мулла гаиләсендә туган. Кызга биш яшь тулыр-тулмаста аның әтисе Габдрахман мулла, совет хакимиятенең җәбер-золымнарына түзә алмыйча, асылынып үлә. Гариф Ахуновның «Идел кызы» романындагы Габбас хәзрәтнең прототибы Габдрахман мулла әнә шул була инде.

Шәһидә апа үзләренең туган авылы Уразай мәктәбендә татарча, Казанда исә урысча алмаш-тилмәш укый. Шуңа күрә ул татарчаны да, урысчаны да камил белүгә ирешә. Казанда аны апасы Маһирә («Идел кызы»нда Нурия) тәрбияли.

Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда ук алдынгы студентлардан булып, Тукай стипендиясе алуга ирешә. Шул елларда Гариф Ахуновка кияүгә чыгып, инде менә 45 ел буена тату яшиләр. Шәһидә апа ул хакта сүз кузгалгач, мин Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновка түгел, студент иптәшемә кияүгә чыктым, ди.

Бишенче курста Шәһидә апа «Сибгат Хәким лирикасы» дигән темага диплом эше яза. Әлеге хезмәте 1953 елда «Совет әдәбияты» журналында, аерым мәкалә булып, тулы килеш басылып та чыга. Соңрак С. Хәким турындагы мәкаләләр җыентыгына да кертелә. Моңардан тыш Шәһидә апаның Бари Рәхмәт, Нури Арслан, Мостай Кәрим иҗатлары турындагы мәкаләләре дә басыла. «Башкортстан белән очрашу», «Айгөл иленә сәяхәт» исемле очерклары дөнья күрә. Ниһаять, ул иҗаттагы төп эшенә — әдәби тәрҗемәгә керешә. Нәшрияттан аңа беренче эш итеп Лев Толстойның балалар өчен язган хикәяләрен бирәләр. Китап 1953 елны басылып та чыга. Мәхмүт Максуд әлеге тәрҗемәгә югары бәя бирә, аның чын татар телендә тәрҗемә ителүен әйтеп, әдибәне канатландыра.

Шәһидә Максудова аннары инде Д. Батровның «Дустыбыз Хосе», С. Антоновның «Аленка» исемле хикәя һәм повесть китапларын, В. Тельпуговның «Зирәк кеше» исемле хикәяләр җыентыгының бер өлешен, казакъ язучыларыннан С. Санбаевның «Аруана», А. Кекильбаевның «Хатынгол хикәяте» повестьларын, И. Ракша, А. Емельянов, И. Друце хикәяләрен һ. б. күп кенә әсәрләрне урысчадан тәрҗемә итә. Шәһидә апа архивында, В. Чивилихинның «Урман-чытырман» повестын аерым китап итеп бастырып чыгаргач, автордан килгән җылы рәхмәт хаты саклана.

Ниһаять, 1971 елны аның «Минем кала алуым» исемле үз повесте «Казан утлары» журналында басыла. Повестьны Рәшит Ахунов тәрҗемә итеп, «Волга» журналына җибәрә. Күренекле урыс язучысы һәм «Волга» журналының баш редакторы Николай Шундик тәрҗемәчегә һәм әсәр авторына соклануы хат яза, повестьны үзе редакцияләвен әйтә. Әлеге повесть азактан Йошкар-Олада һәм Мәскәүдә ике мәртәбә урысча басылып чыга. Әмма аның татарча китап булып чыкканы юк. Автор үзен язучы буларак чамадан тыш тыйнак тота. Моны без гап-гади бер мисалда да раслый алабыз. Шәһидә апаның беренче әсәре 1953 елда басылып чыга, ә ул Язучылар берлегенә 1993 елны гына кабул ителә. 40 елдан соң! Бер дистә китап бастыргач!

Шәһидә апа Максудованы (әдәби псевдонимы буенча Гөлшәһидәне) олы юбилее белән кайнар котлыйбыз, озын гомер, бәхетле тигез тормыш теләп, аның акыллы сабырлыгының тагын бер ягын укучыларга ачып бирәбез. Ул гомер буе шигырьләр язган икән, тик аларны бастырмаган, чөнки Тукай, Такташ, Туфан кебек шагыйрьләрдән соң шигърияттә исем дәгъвалауны үзе өчен артыкка санаган.

Әйдәгез, соң булса да уң булсын дигәндәй, аның шигырь бакчасына сәфәр кылыйк әле.

**Рашат НИЗАМИЕВ.**

# Гөлшәһидә

## МОҢНАРЫМДА — ҖИДЕ КЫЛ

* * *

Кулларым минем, кулларым,
Киң учлы, кытыршы кулларым,
Булдымы сезнең сулыштай җиңел,
Чәчкәдәй нәфис, назлы чагыгыз? —
Оныттым инде, күптән оныттым.....

* * *

Керфекләргә куна күбәләктәй карлар,
Кайнар биткә бәрелеп эриләр.
Әкрен генә кочаклыйлар җирне,
Таптап узасымны белмиләр.

* * *

Ап-пак карда яфрак ямь-яшел —
Тамып калган җәйнең күз яше.

* * *

Матур кызкай,
Кулларыңны синең
Камыл кисмәгән,
Камыл түгел,
Кояш нуры кискән.
Кояш нуры!
Әллә белмәдең?
Авыл читеннән үк башлана
Бер басу кояш нуры!
Иңләп чайкала —
Күзләр чагыла.
Яз житүгә, ир егетләр чыгып,
Кояш күренүгә —
Бөртек саен бер нур бәйләп,
Кабартылган жиргә күмделәр —
Кич житүгә кояш нурсыз калды.
Әллә күрмәдең?
Үзем дә мин
Әле генә белдем —
Хезмәт белән Нурның
Күзне чагылдырып
Чайкалуын.

* * *

Тал агачы,
Зифа тал агачы,
Тик бер генә көнгә
Алмашыйкчы урыннарыбызны.
Барып торчы
Мин булып син
Безнең өйгә.
Тик бер генә көнгә.
Ишетим әле чык төшкәнен яфракларыма.
Яфрак саен йөреп,
Әйтсен миңа серен
Ераклардан килгән
Кыю жил.
Күримче бер генә
Ай нурының
Су өстенә юл түшәгәнен —
Барып торчы
Безнең өйгә
Тик бер генә көнгә,
Тик бер генә көнгә.

* * *

Кызарып пешкән алма үзәгеннән
Тап-таза биш төш чыкты тәгәрәшеп.
Ташлар идем — әрәм. Тәрәз гөлем төбенә
Төртеп куйдым.
Болай гына,
Гамьсез генә эшләнде бу эш.

Һәм онытылды.
Көз үткән. Кышны яз алыштырган.
Йокыга талган алмагачлар уянган.
Төшләрем кабынды яшел очкын булып.
Инде миннән нидер өмет итәләр,
Су сипкәнемне көтәләр.
— Син чакырдың безне тормышка,
Онытырга хакың юк, апай,—диләр.


* * *

*Нәҗибә Ихсановага*

Җаны җиде кылдан булса,
Уйнаса шуның алтысы,
Җиденчесе әле һаман
Чиертүчесен көтә сыман.

Кул тимәгән кыз баладай,
Үзе назлы, үзе кыргый:
Баш бирмәгән Туфанын да
Җылатырлык итеп җырлый.

Ачылып бетмәгән гөлнең
Чыклы таңнары алда:
Уйнар, җырлар җиденче кыл,
Моңнары булса җанда.



# Чәчмә әсәрләр



## Барлас Камалов

КЫСКА ХИКӘЯЛӘР

# КҮҢЕЛДӘГЕ СҮЗЛӘР

I

Авыл карты икәне беренче карашка ук күренеп торганга, аның иртәнге сигез тулыр-тулмаста профсоюз гәзите редакциясенә килеп керүенә Тәбриз бер дә гаҗәпләнмәде. Һәр көнне диярлек килә торган авыл апаларының һәм агайларының берсе. Поездлан, автобустан яисә теплоходтан төшәләр дә туп-туры шушы йортка килүләр. Хезмәт Сараена. Йомышлары мең төрле була аларның. Бигрәк тә бу болгавыр заманда...

Озын буйлы кешеләрнең аркаларында, олыгая башлауга, бөкре сыман нәрсә калкучан. Бу агай да шундый, алга сөрлегебрәк тора. Тәбриз иң әүвәле шуңа игътибар итте. Аннары гына картның кояшта, җилдә какланып, бронза төсенә кергән җыерчыклы йөзенә карады.

— Миңа Саматов дигән иптәш кирәк иде.

— Мин булам.

Шулай дигәч, карт аңа төсе уңган зур зәңгәр күзләрен чекерәйтеп карап торды, гүя, аның Тәбриз Саматов булуына шиге бар иде.

— Йомышым сиңа минем алайса...

— Тыңлап карыйк...

Урта буйлы, туп кебек нык Тәбриз әйләнмәле урындыгында кымшанып куйды да, уң терсәген өстәлгә терәп, ияге белән учына таянды. Карт исә тамак кыргалап алды, кул аркаларын ышкыштыргалады, сүз башлыйсы кыен иде бугай аңа.

— Син, кем, энем...

— Тәбриз.

— Ие, ие, Тәбриз энем, Тау ягындагы Алмыш авылын беләсеңме?

— Беләм. Шуннан?—Тәбриз терсәген өстәлдән алды, гәүдәсе белән картка таба авышкандай булды. Аның кысынкы коңгырт күзләрендә очкыннар елтыраша башлады.

— Хәбирә дигән кызны да белә идеңме? Калхуз кәнсәләрендә хисапчы чагын, ие...

— Белә идем! — Тәбриз моны әллә нинди ялган күтәренкелек белән әйтте. — Тик бу күптәнге хәлләр бит инде, абзый.
— Хак әйттең, утыз биш ел, кем, энем... Ул чакта мин дә кырыкка атланырга гына тора идем әле.
— Сез Низаметдин абыймы?
— Өстенә генә бастың, нәкъ үзе!
— Гафу итегез, йомышыгыздан алда сорыйм әле, Хәбирә ни хәлдә? Яшьлегендә коточкыч фаҗига кичергән дип ишеткән идем.
Низаметдин абзый көмешләнгән кечкенә түгәрәк сакалын сыпырып куйды, тирән, бик тирән итеп тын алды.
— Шулай булды шул, Хак Тәгаләнең әмере, шулай булды. Башка сыймый торды ул хәлләр... — Агай әледән-әле төкереген йота, һава җитмәгәндәй еш-еш сулый иде. — Алтмышынчы елның язында кияүгә чыкты ул... Чыгасы иде... Егете монда, Казанда эшләгән чагы иде. Гидраструй диләр идеме соң?.. Казанны су басмасын дигән кантур...
— Әйе.
— Э-э, шул. Кыскаватырда иде кияү буласы кеше. Баракта бер почмак бирәсе булганнар фатир итеп... Ну язганнан уза алмыйсың икән. Кремльле урамдагы загыста язылышып чыкканнар болар. Яннарында ике-өч кеше — иптәшләре дә булган. Ул елларны бит әле машиналар үкертеп йөрүләр әллә ни күп юк. Микрасов урамына кайтырга чыгалар. Без шунда никах укытырга дип көтеп торабыз... Күрәләр: алыптай бер азгын бичара бер картны дөмбәсләп ята. Кияү буласы авылдаш егет түзмәгән, картны яклап, араларына кергән. Теге исерек бандит моның йөрәгенә пычак белән бер генә кереп чыккан. Бар иде кияү — юк инде кияү!.. Авылга кайтарып җирләдек. Кыз, ир күрмичә, тол калды. Бүтәнгә чыгуны уйлап та карамады. Телсез-өнсез гомер итте. Кантурга барды — эшләде, өйгә кайтты — эшләде. Моннан җиде ел элек әнкәсе дөнья куйгач, өйдәге бар шөгыле мине тәрбия кылуга әйләнде... Тамугка күнгән шәйтан кебек, күнгән идек инде ике тол көн итәргә. Янә бәла килде, Хәбирәнең үпкәсендә яман шеш котыра... Сулды, саргайды...
Низаметдин тынып торды. Кыяфәтенә карап, уйлары бик ерактадыр дип чамаларга мөмкин иде. Тәбриз аны ашыктырды. Хәер, ул үзе дә ни үле, ни тере дигәндәй утыра иде.
Ничә минут сүзсез торган карт, өстенә салкын су сипкәндәй, кинәт дертләп китте һәм, югалып калуы өчен кичерү сораган төсле, сүз башлады:
— Минем йомыш дигәнем шул җәһәттән... Кызымның миннән бертек тә сере юк. Бер җан кебек яши идек тә соң... Хәле хуҗега бара, күңелен боз тотканын сизәм. Үзе барысын да белеп, аңлап тора. Әле өченче көн генә гозерләде. «Әткәй, Тәбризне табып әйтсәнә. Минем аны чирек сәгать кенә күрәсем килә. Бу дөньядан киткәнче әйтәсе сүзем бар. Хатыны белән парлашып көнендә генә килеп китсеннәр әле, зинһар. Бик читен булса да, мине битәрләми генә бер ялваруымны тыңлый күр», — диде. Аңлашам бит, безнең сүзне тыңлап кына чыгасы кияве дә дөньядан гаип булгач, сине уйлап кына яшәгән икән. Кузгалдым юлга, аманәтен тапшырдым. Өстемнән тау төште. Калганы — синең хөкемеңдә...
Карт күз яше белән елый иде. Тәбризнең җаны дөрләде.

## II

Заманында тирә-юньдә дан тоткан тимерче, гомерлек умартачы Низаметдин картның ак өе түрендә бер-берсен утыз биш ел күрмәгән ике зат сөйләшә.
Хәбирәгә авылның шәфкать туташы әле генә укол ясап киткән. Ул диван артына терәгән мендәргә аркасын куеп утырган. Иңнәренә мамык шәл салган. Тышта чәчәкле июнь — саратан челләсе. Өйдә дә һич суык түгел. Ә Хәбирәгә салкынчадыр, күрәсең.

Аның тавышы тыныч, йомшак. Әүвәлгечә матур итеп көлүе генә югалган. Елмаюы да бик кыска. Йөзендәге балкышны каһәрле чир урлаган. Ябыкканлыктан, төз-килешле борыны сузаеп калган. Күзләре генә әүвәлгечә. Зәңгәр күл! Куе керфекләре — җикән камышлар. Янә борынының уң яфрагы читендәге миңе элеккегечә. Шушы миңдә иде булса кирәк яшьлегендә аның сөйкемлелек ноктасы...

Тәбриз, урындык алып, авыруның каршысына утырган. Күз карашын һич аермас иде бу сырхаудан, яхшысынмый. Алай дисәң, Хәбирә үзе дә аңа томырылып карап туймый...

Сүзләре — төрле тарафка тәгәрәшкән терекөмеш тамчыларыдай, бергә җыеп ала торган ише түгел. Әле бер нәрсәне хәтерлиләр, әле бөтенләй бүтәнне сөйләп китәләр. Мәгәр үткәндәге бер хатирәгә ике кат кайтып төртелделәр инде.

Университет студентлары белән авылга концерт куярга килгәч, җыр остасы Тәбризнең Хәбирәне бик нык ошатуын сиздергәннәр Низаметдин агайга.

«Кәҗә — мал түгел, артист кеше түгел», — дигән тимер остасы. — Тирәсендә җыен шалапут уралсын дип үстергән кызым юк минем!»

Тагын ике елдан, читтән торып укырга күчкәч, Тәбриз ниятен ирештергәч тә, җавап шул чама булган иде:

«Китап кортларының настоящи ир булганын күргәнем юк. Өметен сузып йөрмәсен штубы! Йодрыгым кувалдадан ким түгел».

Шуннан юллар аерылды инде.

...Чирек сәгать күптән үтеп китте. Сәгать кенә дә түгел күрешкәннәренә. Тик барыбер бүген мәңгегә хушлачаклар алар. Шуны бик ачык тоеп, Хәбирә әйтте:

— Минем сәгатьләрем исәпле, Тәбриз. Сине бер күрим дип кенә яшәдем. Өмет күпмедер яшәтә икән. Тик аның да чиге бар. Соңгы чиге житкәч, әткәйдән сине чакыруын гозерләдем. Оят дигәнен дә онытып... Инде хуш! Бәхил бул!..

Хәбирә елап җибәрде. Тәбриз юатыр сүз таба алмады. Ярый әле, хуҗабикә үзе тиз тыелды. Кайдан көч ала диген?! Диванның аргы башындагы ап-ак тышлы мендәре астыннан бер дәфтәр алды һәм Тәбризгә сузды.

— Юлда укырсың. Хуш, бәхилләшик!

Тәбриз дәфтәр тышындагы «1960—1991» дигән саннарга дикъкать итте...

### III

Станциягә чак килеп өлгерде Тәбриз. Буа-Казан поезды кузгалырга тора иде.

Вагонга кереп, бераз тынычлангач, сумкасыннан теге дәфтәрне алды. Ни өчендер, иң соңгы битеннән укып китте.

«...Авыл башындагы кушкаен әле дә булса син киткән юлга карый. Каен түгел, мин шулай. Кушкаен кайсыбызныдыр гаепли. Бәлки икебезнедәдер. Сине кыюлыгың җитмәүдә, мине урлап китмәүдә гаеплегә чутлый, мине — ябышып чыга белмәүдә. Гаепли дә, жәлли дә ул безне. Жәлләмәсә, һәр көзне сары яфракларын күз яше итеп коймас иде. Ул яфрак койганда, көзгә сагыш мине кыршау булып кыса һәм дөньяда яшәвемнең соңгы сәгатьләрен сөйләп кисәтә. Мин моңарчы да синең барлыгыңны рухан тоеп кына яшәдем бит! Йә, мәңгегә хуш, чынга аша алмаган хыялым!»

*Сентябрь, 1992.*

# ХӨСЕТЛЕК

Сәлимә белән Галимә күрше кызлар иде. Алар Таллыяр авылының Өч Инеш урамында үсеп буй җиттеләр. Холыклары төрле була торып, су сипсәң дә аера алмаслык дус-сердәш иделәр.

Сәлимә йомры гәүдәле, өлгер-җитез хәрәкәтле, җор телле чибәр кыз булып, күпләрнең күз карашын үзенә тартты. Озын толымнары дисеңме, бит очлары багалмадай алсуланып торган түгәрәк ак йөзенә сибелгән матур кара миңнәрен әйтәсеңме, куе керфекләр каймалаган зәңгәр күзләрен телгә аласыңмы, чәчкә тажыдай иреннәренә дикъкать итәсеңме — табигатьнең үзенең бу баласына күркәмлекне кызганмый биргәнлегенә инанасың. Чибәрлеген ул үзе дә бик белә, шунлыктан горур, тәкәббер йөрүчән иде. Тулаем тәэсирне фәкать бер сыйфаты киметә төшәр булды. Сәлимә, аягы тездән бөгелмәгән сыман, торна адымнары беләнрәк йөрүчән иде.

Кыз зәвык белән киенде, гаиләләре хәлле булды, теләгәнчә киенергә мөмкинлеге дә бар иде. Чытнай ак кофта белән карга канаты кебек җете кара итәкне, кара туфлиларны яратты. Чәчүргечкә дә кара тасма сайлаучан булды. Гомумән дә, кара төсне бик үз күрә, хәтта салават күперендә шул төс булмауга да сәерсенә иде.

Бөек Ватан сугышы алдыннан Мәскәүдә метро төзелүне могҗизага санап чыгарылган бер җыр аның җанына якын булып ирешге.

Кара ки, дустым, кара ки,
Ерактан танышырбыз,
Җир астыннан юллар салып
Булса да кавышырбыз...

Җир астыннан юллар салып газапланырга туры килмәде. Авылның менә дигән егете, армия хезмәтен тутырып кайтып, колхозның беренче йөк автомашинасында шофер булып эшли башлаган көрәшче Сәлмән аңа мәхәббәте барлыгын сиздерде. Кыз баштарак назланса-ялындырса да, соңрак йөреп киттеләр. Тик аянычка дип әйтикме, егет өчен хәерлегәме, дуслыклары озакка бармады, кавышу насыйп булмады. Әллә Сәлимәнең артык горур, әллә пычак теллелеге егетнең гайрәтен чигерде, ул Сәлимәдән дәррәү читләште һәм ахирәт дусларның икенчесен — Галимәне ярата башлады.

Галимә күршесенә караганда буйлырак, мәгәр чибәрлектә аңардан күпкә калыша торган, сипкелле булуына чиксез пошынучан, тыйнак бер зат иде.

Сипкеллелеген сөйкемлелеккә чутлап, гадилеген, ихласлыгын, уңганлыгын кыйммәтләп, Сәлмән тиз арада аңа өйләнеп тә куйды. Парлы тормыш белән яши башлагач, Сәлмән шаяртып әйтә иде:

— Шигырьле хатыңда болай дигән идең бит:

«Челтәр җилфердәтеп җилдә кулың талдыра күрмә.
Бөтен өметләрем синдә, ятка калдыра күрмә».

Шулаймы?

— Шулай, хакны әйткән идем,— дип җавап бирүчән булды Галимә.

— Ул тезмәнең бүтән юлларын хәтерләмисең инде, әйеме?

— Төгәл үк түгел... Кайда әле ул безнең кавышуга сәбәпче хат?

Аннары ул түр шкафтагы котыйчыктан дәфтәр битенә язылган хатны алып, укып китәр иде:

«Челтәр бәйлим, челтәр бәйлим,
Челтәрем йөз бизәкле;
Ниләр уйлыйсыңдыр, белмим,

Шунысы өзә үзәкне.

Челтәрләр тоттым якама,
Челтәр тоттым җинемә;
Чишалмыйм серем ятларга,
Сөйлим сиңа — тиңемә»..

Галимә сорап куяр иде:

— Син язган нинди җырга җавап иде соң болар? Хатларыңның берсендә халык җырын язган идең бит:

«Яшел койрыклы саескан
Оя ясый камыштан;
Син үләрсең вакыт җитеп,
Мин үләрмен сагыштан»..

Вакыт томанына да уралырга өлгермәгән гыйшыклы көннәрен шулай хәтергә алучан булдылар.

Галимә белән Сәлмәннең никахы Сәлимә йөрәгенә агулы ук булып кадалды. Шул көннән Галимә аның кан дошманына әйләнде. Исәнләшмәс, сөйләшмәс булдылар. Галимә тупырдап торган ир бала да китергәч, яшьлек дусты Сәлимә дөньясының асты өскә килгәндәй булды. Аның җанында кыямәт купты. Шул мәхшәрдән арынырга җан атып, Сәлимә күрше авылның мичкәче Хәйриен йортка кертте. Тик ходай аларга бала бирмәде.

Элеккеге җан дусларның дошманлашуын ил өстенә килгән афәт немец фашистларының сугыш башлавы да юып ата алмады. Күрше хатыннар кан коюлы, каһәрле сугыш чорын бертигез чамада михнәт белән кичерсәләр дә, Сәлимәнең күңеле чуерташ булып кала бирде, Галимәгә карата адәм рәтле уй-тойгыларына йозак салган иде ул. Чыраен ачмады, сәлам бирмәде. Иңнәренә таш булып яткан кайгы килгәч тә,— шофер Сәлмән дә, Хәйри дә яу кырында һәлак булдылар,— кара хәсрәтне уртаклашмадылар.

Еллар үтте. Күп гомер узды. Галимәнең улы буй җитте. Институт тәмамлап, Казан каласында экономист булып эшли башлады, өйләнде. Илфак хатыны белән туйның дәвамын итәргә Таллыярга, әнисе йортына кайткач, мәҗлес гөрләп торган сәгатьләрдә хөсетлеге чик-чамадан ашкан Сәлимәнең йөрәге тотты. Авылдагы фельдшер кыз ике-өч тәүлек буена аны саклады, райүзәктән врач килде. Йөзе киндер төсенә кереп калган Сәлимә атна-ун көн үтмичә ишегалдына да атлап чыга алмады. Әмма кара көнчелеге тырнак очы кадәр дә кимемәде. Күршесенең имин тормышы турында уй кыйпылчыгы пәйда булды исә, йөзе кара күмер төсенә керә иде.

Янә бихисап җилләр исте, янә бихисап сулар акты. Сәлимә белән Галимә дә гомер юлларындагы чакрым баганаларының җитмешенчесен узып киттеләр. Ул арада Илфакның улы, Галимәнең оныгы университетның соңгы курсына килеп җитте. Югары уку йортын тәмамлавы шәрәфенә Галимә оныгына бүләк итеп мотоцикл алырга булды. Сыер саткан акчасын да, әүвәлдән аз-азлап җыя килгән сумнарны да шуңа багышлыйсы итте.

Авылдаш егетләр мотоциклны алып кайтып, Галимәнең лапасына куйган көн Сәлимә өчен күк гөмбәзе ишелеп төшкәнгә тиң булды. Кояш тикле кояш аңа корымга баткан түгәрәк сыман күренде. Күз алдына кара пәрдә эленде, үзен бизгәк тота башлады. Дарулар кабып та карады, дерелдәү-калтырау узмады. «Үз-үземә кул салыйммы әллә?» дигән көфер уйга барып җитте. Аннары кайдан көч-ныклык алгандыр, торып басты, үзенә үзе катгый әмер бирде: «Мәлҗерәмә, Сәлимә! Син дөньядан китсәң, сөйгәнеңне тартып алып, мәсхәрәгә калдырган Галимә сөенәчәк бит.

Син алардан калып яшәргә тиеш! Кирәксә, аның каберен барып таптарга тиеш әле син!»

Могҗиза диярсең, калтырау-дерелдәү узды. Шул минутларда иманга зәгыйфь Сәлимә үз күңеленә кара төен төенләп куйды.

Коры җәйнең бер алсу таңында Галимәнең лапасы дөрләп яна башлады. Таң яктысы чигенеп калгандай булды. Тирә-юньдә энә төшсә, энә табылырлык якты иде. Татлы йокыларыннан күзләрен тырнап ачкан халык җыелды. Акылына зыян килер кимәлдә ярсынган Галимә, мотоциклны чыгарырга дип котырынып янган лапас эченә ташланды һәм бүрәнәгәме, тагараккамы абынып егылды. Гомере шунда киселде...

Хөкем залында Сәлимә үзен берәү дә күз алдына китерә алмастай дәрәҗәдә базу тотты.

— Әйе, утны мин салдым. Чыдаша алмадым. Галимә — минем бәхетемне урлаган кеше. Һәр угры җәзасын алырга тиешле... Ә аның утка ташланасын кем белгән? Комсыз иде ул, намуссыз. Аллаһы тәгалә аны шуның өчен фани дөньяда ук тәмуг белән җәзалады. Аның әҗәлендә минем бөртек тә гаебем юк...

Суд залыннан аны конвоирлар култыклап алып чыктылар. Мәгәр ул булышуга мохтаҗ түгел иде. Башын югары тотып, түшен киереп, торна адымнары белән атлады. Ләкин эчендә җәһәннәм утлары кайный иде.

*1994.*





**Фәрит Нәгыймов**

# КЫҢГЫРАУ

хикәя

Сыерны инде кичтән үк ашатмадылар. Ул, зарлангандай, иртәдән бирле мөгри башлады. Төш вакытында хайваннарны суйдылар...

Алар өчәү иде: «Ганнибал» кушаматлы сугымчы Гани абый, әтисе Лотфи һәм аның улы Радик. Иң әүвәл кем нишләргә тиешлеген киңәштеләр, аннары малны аякларыннан бәйләделәр. Яшүсмер егет Радик бауны бар көченә тартты, әтисе белән Гани исә яшь сыерның аяк астына бәрделәр. Хайван, башын гайрәтле генә селтәп, җиргә ауды. Кар өстендәге салам кисәкләрен читкә уфырдатып, ул тирән сулый, ә гәүдәсе калтыранып куйгалый иде. Кычкырмасын өченме, әтисе аның авызын бау белән чорнап алды. Сыер һаман да шаулатып сулый, көянтә сыманрак бөгелеп калган зур гәүдәсе әле җыерылып килә, әле уңга-сулга бәргәләнә иде. Әтисе бастырыкка үрелде. Баулар арасына тыгып, шуның белән малның аякларын җиргә таба кысрыклады. Гани абый ике куллап чалбарын өскәрәк күтәргәндәй итте дә Радикка кычкырды:

— Әй, теллигент, мөгезләреннән тот, балаларым өчен куркам! — Битенең бер як яртысы аз гына кыйшаеп алды, күз кысарга тырышып каравы иде, күрәсең.

Радик үз-үзен читтән күреп тора шикелле: шәһәрчәрәк кыяфәтле егет өстендә әтисенең бишмәте һәм дәү генә итекләр. Әтисенекенә охшаш куе кашларын өскә күтәрә төшеп көлемсерәде ул. Сыерның маңгай чәчләре читендәге кабыргалы мөгезләр кайнар иде, шулар аша егетнең кулларына хайванның яңак сөяге хәрәкәтләре көчте шикелле.

Читкәрәк карап, карлыккан тавышы белән бисмилла сүзләре әйткәннән соң, Гани абый нindидер яшеренлек, озын-озак хәрәкәт белән итеге кунычыннан сугым пычагын тартып чыгарды, бирчәйгән куллары белән сыерның бугазын капшады. Бу кагылудан сыер түгәрәк күзләрен ачып-йомып алды, ул арада Гани абый кинәт егылгандай хәрәкәт белән аска иелде, кулындагы пычагы кояшта ялтырады! Әлеге пычак ә дигәнче мал муенындагы кызыл йоннар арасына кереп югалды. Радик сыер муенында

---

Фәрит НӘГЫЙМОВ (1970) — *Оренбург өлкәсендә туган. Армия хезмәтеннән соң Мәскәү әдәбият институтын тәмамлый. Хәзер Алма-Ата шәһәрендә яши.*

миңнәр барлыгын күреп өлгерде. Егеткә юеш, эссе иде, битенә сәер кайнарлык бәрелде.

— Тизрәк! — дип чырылдады әтисе. Әйтерсең, кемдер аны артыннан типкәләп ашыктыра иде.

Үз эшен эшләгән Гани күтәрелде, тураеп басты һәм бер читкә «черт» итеп төкерде. Маңгаендагы борчак кадәрле тир бөртекләре алсу-кызгылт төстә иде шикелле. Бәлки, шәфәкъ ягына караганлыктан шулайдыр? Әтисе, улы һәм аларның сыерлары янында Гани баһадир бер сурәттә басып тора. Күзләре аның хәзер инде икенче төрле, башкачарак иде. Сыер, бугазы белән авыр сулап һәм былт-былт килеп, язмышының соңгы минутларын саный иде. Аның зур һәм тонык күзләре Радикка бәкедән төбәлгән шикелле иде. Егет әле сыерга, әле аның тирәсендәге кан җәймәсенә карады, күккә һәм ишегалдына караш ташлады. Дөньяның берни булмагандай тын, үзгәрешсез калуы аның өчен гаҗәп һәм сәер иде.

Әтисе белән Гани аракы эчәргә җыендылар. Әйтерсең, әлегә кадәр кемдер аны кысып-тотып торган — Гани кинәттән йомшарып китте, күзләренә җан керде. Терек-терек атлап хуҗа артыннан иярде.

— Ә Радик эчмимени? — дип гаҗәпләнеп сорады ул егетнең әтисеннән.

— Эчми дә, тартмый да! — Әтисе тыйнак кына җавап кайтарды.— Ул бит, Ганинибал, безнең кебек калхузниклар түгел.

— Күрче, Лотфи Әмировның малае эчми бит, ә! — дип, янә гаҗәпләнде Гани.

Үзенең беренче чәркәсен Радик армия хезмәтеннән соң, әтисенең дуслары арасында эчкән иде. Әтисе хәйран гына сәрхүшләнгән булса да, сүз арасында үтенеч беләнрәк әйтеп куйды:

— Бүтән эчә күрмә, улым, кирәге юк аның...

Радик сискәнеп киткән иде ул чакта, әтисенең тавыш төсмерләре гаҗәпләндерде аны. «Мондый тавыш белән, мөгаен, улын шәһәргә — ул чакларда бик тә дәрәҗәле саналган тракторчы һөнәренә укырга җибәрү турында үз әтисеннән үтенгән минутларда гына шулай сөйләшкән иде бугай ул»,— дип, уйга чумды егет. Әйе, Радик әтисеннән еракка ракк китте — «теллигент» кисәге. Анда — шәһәрдә, кайчакны аз-маз гына эчәргә һәм тартырга туры килгәнлеген ул әти-әнисенә беркайчан да әйтмәячәк, билгеле.

«Менә укып кына бетерим, аннары акчаны эшләп күрсәтермен,— дип хыяллана егет, төн уртасында сарайга кереп бер генә тәмәке тарткан чагында.— Өйгә чит ил машинасы белән кайтып төшәм, нәрсә инде, авызда сигарет булырга мөмкин? Машинаны әтигә бүләм итәм, әнине дәвалау өчен иң затлы санаторийга алып китәм...» Сарай почмагындагы җәтмәсендә үрмәкүч хәрәкәтләнеп ала. Хыялый егетнең уйларын хуплагандай итеп, өй кыегының бер читендә чыпчыклар нәни кыңгырау сыман чеңгелдәп ала.

Тиздән әтисе белән Гани өйдән әйләнеп тә чыктылар. Аларның бит һәм иреннәре кызарынган, күзләрендә уйчанлык билгеләре төсмерләнә иде.

— Булган да бит әнә! — диде Гани, хәрәкәтсез оеп яткан малның гәүдәсенә ишарәләп.

Егет күрде: сыерның коңгырт төстәге теле, аксыл-саргылт тешләр арасыннан, бер як кырыйга озынаеп салынып төшкән иде.

Әтисе, мазутлы киемен салып, рәшәткә баганасына элде. Гани сыер түшкәсен эшкәртә башлады, әтисе улы белән аңа ярдәм итте. Сугымчы түшкәне түгел, гүя таза-эре алманы ботагында килеш вак-вак кисәкләргә бүлгәли иде.

— Син, Ганнибал, рецидивистлардан ким кыланмыйсың,— дип, үзенчә мактап куя аны әтисе.

Мондый мактау сүзләре ишеткәч, Гани хәйләкәр генә елмая, баш бармагы белән тир-тозга баткан бүреген рәтләп куя.

— Гани, мәйтәм...— Әтисе, сыер аягын тотып торган килеш, һаман сүздән бушамый.— Әгәр колхозны тараталар икән, безгә синең белән кооператив оештырырга кирәк. Син сугымчы, ә миндә көч.— Әтисе шул арада күзен кыса төшеп, тәмәкесен суырып, улына таба күз салырга да өлгерә.

— Син нәрсә, «Кировец»ны ташлар идеңме, Лотфи дус? Ә кем җирне сукалар...

— Җир өчен мин үзем дә борчылам анысы.

— Ә нигә борчылырга?— дип борын астыннан үзалдына мыгырдана Гани.— Әнә, ярдәмгә улың бар ич.

— Минем кебек калхузчы булып калсынмы?— Әтисе сыер аягын кулларыннан ычкындырды.— Юк-ук, укый бирсен әйдә. Әнә, Гайдай белән Катаня ЗИЛ сатып алдылар һәм шабашка куалар. Ә без нәрсә, паровоз сыман туры юлдан барырга юләрме әллә, шулай бит, Радик?!

— Шулай, эти! Хәзер акча аяк астында аунап ята, җыйнап ала бел генә.

— Ә бәлки, Лотфи дус, безгә кооператив ачып җибәрергәдер,— диде Гани бик эшлекле кыяфәттә.— Интерес өчен дип әйтүем. Миндә акыл, сездә көч.

Әтисе икенче аякны шулкадәр нык тартты ки, хәтта сеңерләрнең шыгырдаганы ишетелде. Аннары, телен шартлатып, Ганинең осталыгына сокlануын белдерде. Аңа ярдәм итә торгач, эшнең ахырындарак үткен пычак йөзен бармагына элэктерде. Бер мәлгә аның күзләрен курку пәрдәсе каплап узды. Балачактагы куркуы да шулайрак булды микән аның?

— Хәзер, Ганнибал, бераз гына «чиртеп» алырбыз,— диде әтисе, кан саркыган бармагын сыйпаштыргалап.— Хатын анда бишбармак әзерләп ята.

Ул арада Радик түшкәнең барлык кисәкләрен кухняның сап-салкын бүлмәсенә ташыды. Сыерның башы һәм эчке әгъзалары гына тышта калды.

Аннары егет өенә атлады. Сак басарга тырышты, чөнки аяк астындагы кар бик тә авырту-зарланулы шыгырдый иде. Киемнәрендә кан табы юк микән дип, өс-башын бер кат күздән кичерде. Өйдә күңелне кузгатырлык җылы, рәхәт, йомшак. Мичтә учак чытырдап яна, агач диварда кызыл атлар шәүләсе биешә. Күзләр суыктан соң, ниһаять, җылыга ияләште. Радикның әнисе Гани абый белән өстәл артында утыралар, әтисе исә мич алдында тәмәке көйрәтә иде. Әнисе биленә шәл, башына яулык бәйләгән, халатының бер кесәсе ертык.

— Минем эти Алпыс булган,— диде Гани, көтмәгәндә кулларына себерке бәйләмен алып.

— Нинди Алпыс тагын?

— Анысын сорамагыз... Мин аның янына йөрмим. Безнең гаилә бәхетсез булды. Мине әбием тәрбияләде. Аңа бик рәхмәтлемен.— Гани себерке чыбыкларын скрипка кылларын тикшергәндәй хәрәкәтләр белән барлап чыкты.— Ул хәзер юләрләр йортында. Шулай берчакны барган идем янына... Чәчләре ап-ак, карый миңа, ләкин танымый. Еладым шул чакта.

Гани себерке алдына иелә төште, җиңелчә генә тамак кырып алганнан соң чыбыкларга чирткәли башлады:

— Диңгел-диңгел, диңгел-диңгел. Йөрәктә утлар яна...

Далада бәрәнен югалткан сарыкның авазын җилләр ничек йолкып алса, аның тавышы да әнә шулайрак сүрән чыга иде. Гани урындыкта чайкала, терсәкләрен як-якка йөретә, күзләре исә эрактагы учак утыдай җемелди.

— Син, Гани, себерке кылларында казакъ думбрасыннан ким уйнамыйсың! — дип елмая әнисе.

— Кая инде! — дип башын чайкап, Гани себерке бәйләменә кызганычлы караш ташлый.— Чиртәсең, чиртәсең, чуртым да юньләп тавышы чыкмый. Ә мин болай гына, күңеллерәк булсын дип тырышам.

Шул арада ул өстәл өстендәге чәркәгә караш ташлады да уң кулы белән тезен шапылдатып:

— Айн момент, Лотфи абый, Лена җиңгәчәй, сезнең улыгыз Радик өчен эчеп куясым килә! — диде.

Чәркәләргә эчемлек салганда әтисенең куллары калтыранып куйды шикелле.

— Бәлки, безнең белән берәрне эчәрсең? — дип сорады ул улыннан, кулындагы шешәсе ирексездән өстәл өстендә «эленеп» калды.

Егетнең гәүдәсе җыерылып килде, ул әтисенә күтәрелеп карарга уңайсызланды.

— Ю-юк, әти. Беләсең бит, миңа баш миен аек килеш сакларга кирәк.

— Дөрес әйтәсең, улым, кирәге юк аның... Аңладыңмы, Гани, улымның кем икәнен!

Гани гәүдәсен турайтты, як-ягына каранды:

— Кһ-м... Ну, Радикҗан, алайса сиңа Себер тазалыклары, Кавказдагыча гомер озынлыклары. Сәламәт бул!

Табындашларына карап алганнан соң кинәт башын артка ташлады һәм аның соңгы хәрәкәте Радикта рюмканы йотты сыманрак тәэсир калдырды. Аның төлке кыяфәтле йөзе тагын да сузаеп килде, иреннәре бүрәнкәләнде, гүя ул утлы савытка орынган иде.

— Безнең Гани шәп тост әйтте! — дип, әтисе горур бер сурәттә әнисе ягына төбәлде.

— И бала, ничек эчсен инде ул! — Әнисе үзенчә сукалый бирде.— Мәктәптә дә шул иде, хәзер дә шул. Ә шулай да өйләнер чагы җитеп килә аның.

Гани тагын сүзгә кушылып китте:

— Өйләнү димәктән, мин үзем ике тапкыр өйләнеп карадым, уңмадым. Балалары булмады... Ни итте, ни сөте дигәндәй...

Сугымчы ир, себерке бәйләмен эзләгән атлы булып, янәдән аска иелде. Борынын тартып алды һәм тамак кырды; кунычындагы пычагы, чалынган сыер күзләредәй, ут яктысында ялтырап алды.

Әти белән әнисе бер-берсенә карашып куйдылар. Чәркәләрне тутырганнан соң йорт хуҗасы күңелле генә сөйләп китте:

— Ә без, хатын, Гани кордаш белән зур планнар кордык әле. Аяклы малны суя торабыз, шәһәрдәге бәҗай станок таба. Шәһәрдәге шикелле, колбаса ясый башлыйбыз. Ул чагында инде авыл хуҗалыгының барлык әтрәк-әләме безнең каршыга йөгереп киләчәк, ә Ганнибал?

— Әй бабай-бабай, картаеп акыл кермәгән нәрсә! — дип кызартырга тотына әнисе.— Эчә башладымы, улым Радик, үзенә дуслар эзләп йөри башлый ул. Ә эчмәгән көне сирәктер...

Битен әтисеннән учы белән каплый төшеп, Радик күз карашы ярдәмендә әнисенә теләктәшлек күрсәтә.

— Булды, җитте. Әйттем! — Әтисе кашларын җыера, күзләре кысылып килә. Вакыт аның йөз-кыяфәтен байтак үзгәрткән булса кирәк: борыны очлайган, кашы дугаланган, көнозын диярлек бүрек астында йөргән маңгае йомшап агарынган. Болар хакында уйланса, Радик әтисен битлек кигән кешегә охшатып куя.

— Минем сүз — закун! Хатын-кызны тыңлап торасы ди тагын...

— Сез нәрсә чәбәләнергә генә торасыз,— дип, Гани сүз дилбегәсен үз кулына алмакчы.— Әйдәгез, тана хөрмәтенә... Бик тә майлы үзе! Ничек аны шулай тәрбияләдегез?

— Үз авызыңнан өзеп бирсәң, мал таза була ул! — Кулындагы савыт-сабасын шалтыратып, әнисе сугымчының сүзләренә җавап кайтара.

— Карале, мәйтәм,— дип, Гани тагын хуҗа хатынга таба борыла.— Аның бит әле бер дигән бозавы да бар иде!..

Төргән тәмәкесен әтисе тирән итеп эчкә суырган мәлдә өй эче кинәт алсуланып яктырып китә.

«Менә нәрсәне миннән яшергән икән әти. Менә ни өчен минем сорауга җавап бирмәгән икән ул!» Радик хәзер барысын да аңлады.

— Син нәрсә, хатын, Ленин буржуазиягә караган сыман текәлдең?— Йорт хуҗасы тавышын күтәрә төште: — Нәрсә, кыш буе бармак суырып ятаргамы? Радикка да шәһәр өчен акча бирергә кирәк. Аңламаса да аңламый икән бу хатын-кыз!

— Их син, картлач! — Инде әнисе кызып китте.— Мин бит сиңа әйттем, кисәтә килдем. Эчәр өчен генә малны пычак астына тыктыңмы?

— Әйдә, Лотфи, саулык өчен берне җибәрик тә...— Гани тагын да гайрәтлерәк итеп башын артка ташлады.

— Син әниеңне түгел, мине тыңла, Радик! — Әтисенең кулындагы рюмка чайкалды да чалбарын чылатты.— Без әллә ниләр майтарырбыз әле! — Кулы белән чалбарын сөртте дә уч төбен ялап алды.— Ә син, укып бетергәч, миңа «Тойота» сатып алырсың. Кешеләр яныннан Гани белән пан-король сыман узып китәр өчен!..

Шушы урында әтисе кинәт кенә яңгыратып көлеп җибәрде. Шулай кыңгырау чыңлагандай итеп, ул мөгаен, бала чагында гына көлә белгәндер.

— Әйе, әти, укып бетерергә миңа күп калмады. Ләкин сез бик эчмәскә тырышыгыз инде...


Егеткә кинәт күңелсез булып китте. Ике өлкән кеше — шешәдәш ирләр янында утыруы өчен уңайсызланды. Радикның фуфайкасы мич буена сөяп куелган иде. Ул киенде һәм ишегалдына чыкты. Сулыш алу шулкадәр җиңел тоелды, әйтерсең аркада тишек хасил булган. Егет сарай ишегенә сөяп куелган соры капчыкны күреп алды. Балта белән инде бозлана башлаган капчыкны урталай ярып җибәрүе кая, аның эчендә кечкенә бозау башы күренде. Чү, авызына нәрсәдер капкан түгелме ул?

Әле туып та җитмәгән бозауның йомры, тешсез авызыннан чынлыкта теле күренеп тора иде. Газап белән йомылган, дөньяны күрүдән мәхрүм ителгән күзләрендә нинди моңнар яшеренеп калды микән?

Радик бозауның нәни гәүдәсен кулларына алды. Барысы да үз урынын табып өлгергән — муенында миң, сары тояклары чәчәк бөресен хәтерләтә, кабыргалары эчтән төртеп тора. Егет нәрсәнедер аңлагандай булды, аның кычкырасы килә иде. Селәгәен йотты. Янәшәсендә генә әтиәнисе барында ул билгесез бер йөкне күтәреп тора — сәер хәл иде бу. Аның урамга чыгып йөгерәсе һәм дөньяга барлык белгәннәрен кычкырып сөйлисе килә иде. Тик аркасы белән тоя: чыгып йөгерергә дә, беркемгә бернәрсә турында сөйләргә дә ярамый аңа.

Тана муенында кыңгырау бар иде. Ике ир аны иртән бавы-ние белән кисеп алдылар. Бозауның нәп-нәни гәүдәсе нигәдер әнә шул кыңгырауны хәтерләтә иде... Радик башын югары күтәрде. Күк шулкадәр чиста, анда ул үзенең чагылышын күрде шикелле. Йомгак-йомгак болытлар да шәйләнә. Авылда гаҗәеп бер кышкы тынлык, хәтта ерак-еespecially

*Русчадан Рашат НИЗАМИЕВ тәрҗемәсе.*



# КУТУЙ — ҮЗЕ БЕР ДӨНЬЯ УЛ

Роберт Батулланың бер акыллы гыйбарәсе бар: күпмилләтле татар халкы, ди. Чыннан да шулай түгелме икән?

Чин илләре, фарсы илләре аша да госманлы империясенә барып җиткән, Ататөркнең киңәшчесе була алган Садри Максудыйлары гына да ни тора. Ә Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый кебекләр? Төрек милләтен аякка бастырган татарлар бит алар.

Еракка китәсе юк, елга аша гына күршеләр бар: Бабич, Гафури, Фәридә Кудашева, Рим Хәсәновлар... Чыннан да, күп милләтле татар халкы килеп чыга сыман.

Борис Годунов кебек патшаларны, Карамзин, Державин кебек сүз осталарын, Гата Камский кебек шахмат осталарын, Нуриев илә биючеләрен, Сәгъдиев илә галимнәрен, Галимҗан Хөсәенов, Ринат Дасаев, Илгиз Һидиятуллин кебек туп осталарын да искә алсаң, башлар әйләнеп китә. Һәй дә, бу яктан сайламыйк әле, башка якка карыйк.

Урта Азия якларына сәфәр чыгып, казакъ, кыргыз, төрекмән кебек тугандаш халыкларга беренче әлифба, беренче театр бүләк иткән кан кардәшләрне санап китсәң, ай-һай, күп лә ул! Казакъ халкының милли музыкасына нигез салган Латыйф Хәмиди үзе генә һәйкәлгә лаек зат лабаса. Әйтүләренә караганда, аның һәйкәлен ишеп төшереп, урынына юл салып яталар, ди.

Тарихи чынбарлык шунда ки, нигездә «күпмилләтле татар халкы» дәүләтле колонизаторга — олы братка хезмәт итте. Бөтен афәт әнә шуннан килеп чыкты. Күп гасырлар дәвамында эшкәртелеп, әнә шулай урыс телле татар барлыкка килде. Бу шаукым татар хатын-кызлары тәрбияләп үстергән башка халыкларга да күчте. Казакъстаннан әбисенең Олжас Сөләймановы барлыкка килде, кыргыздан — Чыңгыз Айтматовы барлыкка килде, татардан Мостай Кәриме, белорустан башкорт язучысы — Бикчәнтәе пәйда булды. Ә безнең җирлектә дә андый хәлләр байтак.

Безнең Казан җирлегендә иң талантлысы — Рөстәм Кутуй бар.

Не читал я Коран. Иль я слеп?
Эй, Аллах! Я тебе не верю!
Добр тот дом, где хлеб на столе,
Зол тот глаз, что стоит за дверью.
Россиянка,
возьми мою звонкую кровь,
точный глаз,
и тонкую голень,
ты роди же мне сына, чтобы мягкая бровь,
Но рука, чтобы тверда, как корень.

Не глядя на меня, когда тронет глаза закат
Кровь взорвется... Погоди, успокоюсь,
Погоди,
умирает во мне азиат
и уздечку ищет рукою.

Рөстәм абый Казанда туган, Казанда үскән, атаклы «Ташпырылмаган хатлар» әсәре авторының улы. Татарча белми дә сыман, әмма без Аккош күлендәге иҗат йортында урысча сөйләшмибез. Ул барысын да аңлый. Безнеңчә әйтсәк, төбәсе тишек. Чыннан да, эт кебек, барын да аңлый, сөйләшә генә белми. Ә язса, язып күрсәтә инде. Рус теленең казанында кайнаган өлкән братлар бер ягында торсын! Әдәби жанрның чәчмәсендә дә тезмәсендә дә оста. Үзенең фәлсәфәсе белән дөньядагы тирәлеккә, шул тирәлектә мыжгып торган бәндәләргә үзенчәлекле мөнәсәбәте белән Кутуй — үзе бер дөнья ул!

> Словно темный ручей
> табунок по доли не петляет,
> и задумчивой трубкой курится аул.
> Это сердце мое,
> а не угли в камнях пылает.

Мин авылда тудым, авылда үстем. Әмма инде «И задумчивой трубкой курится аул» дип әйтә алмадым. Мондый сыйфат чордашларымнан Зөлфәттә генә бар бугай. Рөстәм Кутуй белән мин башка кызыксынмадым. Моннан 30 ел элек, 1966 елны булса кирәк, (Ленин каласында хәзер Петербург диләр бугай) Эрмитажда йөргәндә В. Солоухин дигән бер язучы сорап куйды: «Как там наш Кутуй?»

Мин мәгънәсез исә Гадел Кутуйның сугышта ук поляк җирендә һәлак булганын сөйләп киттем һәм аның «Ташпырылмаган хатлар»ы турында нәрсәдер сөйләп маташтым. Владимир Солоухин миңа сәерсенеп карап торды да: «Вы, молодой человек, что-то попутали»,— диде. Авылдан килгән малай булсам да, ул кадәр үк надан түгел идем. Владимир Солоухин дигән урыс язучысы бар икәнен дә белә идем. Кутуйның Рөстәм исемле язучы-малае бар икәнен дә бик яхшы белә идем. Өстәвенә әле, шул елларда гына Равил Фәйзуллинның шигырьләрен тәрҗемә итеп, хәерхак теләп, Мәскәүдәге зур гына газетада да чыгарган Рөстәм Кутуй бит ул! Шуның аркасында Равил Фәйзуллин урыс арасына кереп киткән беренче шагыйрь булды. Бу хәлдә Солоухин дигән мужик алдында гарьләндем, тиешенчә җавап бирә алмаганыма гарьләндем. Казанга кайту белән бу шәхес белән кызыксына башладым: чәчмәсен укыдым, тезмәсен — ягъни шигырьләрен. Үзе белән беренче танышуга ялгыш сүз ычкындырдым: «Вы нам чужой, вы инородец». Рөстәм абыйның чиста йөзе шакмакланды, күзләре томанланды, ул әллә нинди хәлгә килде. Яшьлегем белән мин үземнең нинди сүз әйткәнемне дә аңламаганмын. Аның татар җанлы икәнен ул чакта кем белгән лә! Әнә шулай биш-алты ел гомер үтте, мин аны якыннан белә башладым. Иң беренче чиратта, Рөстәм абый мине үзе белгән Казан белән таныштырды, Казанның төпкеле белән. Урыста аны «дно» диләр бугай. Авылдан килгән малайга Казан астындагы подвалларда — җир астында яшәүче бу дөньяны миңа Рөстәм абый ачты. Минем алда әнә шул төпкелдән Геннадий Капранов, Леонид Топчий кебек шагыйрьләр калкып чыкты.

Казанда Яңа бистә дип аталган татар төбәге дә бар икән. Аның белән дә мине Рөстәм абый таныштырды. Ул таныштырган Әхәт Закир дигән сәхнә рәссаме кайда йөри икән? Югыйсә бит, «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрен сәхнәгә күтәргән, бизәкләгән рәссам. Атаклы рәссам, бер исеме дә юк иде, олы шәхес, Яңа бистә егете. Кайчагында, «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрен сәхнәгә куеп званиеләр алган кешеләр башын ашады микән дип уйлап та куям.

Кулына гармун алып, Яңа бистә урамнарын иңләп, җырлап килгән егет Илдус Вәлиев. Татар театрында аның кебек авыл агаен уйнаган башка кеше юк иде һәм аның кебек гармунда турыдан-туры уйнаган кеше юк иде. Хәзер гармун тарталар, язмада бирәләр. Яшь кенә килеш һәлак итсәләр дә, ул әле (Кутуй исән) дә минем өчен исән.

Рөстәм абый белән безнең кызлар бергә үсте, минем — Айгөл, аның — Рината. Балаларны Кече тирән күлдә йөзәргә өйрәтәбез.— Без үзебезнең язган әсәрләрне йөзәргә өйрәтәбез түгелме,— ди, Рөстәм абый. Алла белә, дип куйдым.

Инде алар да буйга җиттеләр. Без дә олыгайдык. Ә һәр язган әсәребезне үстерәсе, кеше итәсе килә. Хәзерге заманда мөмкин микән, ай-һай ла! Аның белән без — гөмбәчеләр. Кыздыра да, тозлый да, киптерә дә беләбез сыман. Моңысы ашый торганы — Рөстәм абыйның болдырыннан атлап керү белән төрледән-төрле агачта күбекләнеп пайда булган гөмбәләр тора. Кайсы тәмәке көллеге хезмәтен үти, кайсы шәмдәл хезмәтен. Бу да үзенә бер дөнья. Сәер дөнья, әмма хикмәтле дөнья. Аның бик күп әсәрләрендә гап-гади агач гөмбәләрен күреп шаккатабыз. Чөнки алар халыкка көллек һәм шәмдәл хезмәтен үтиләр.

Кайчагында язмаучы язучылар Аккош күлендәге иҗат йортында бик зурдан кубып җыелыш уздыралар. Һәм шунда сүз китә. Имеш, Рөстәм Кутуйның җире

буш тора. Анда, имеш, бөтнек үсә. Анда, имеш, балан үсә. Анда, имеш, төрледән-төрле чәчәк тулган. Анда, имеш, ике каенны, ике алмагачны кисәргә кирәк һәм шуннан соң җир барлыкка килә. Алырга кирәк! — дип кычкыра язмаучыларның хатыннары. Алмый торыгыз әле — дип уйлап куям, — анда балан бар, анда Рөстәм Кутуй дигән баланнан да ачы балан бар, аны инде беркая да куя алмыйсың. Чөнки ул язучы, бары тик язучы гына. Иҗат йортында язучының үз эше:

Станет горькой жена.
Станет сытым бессонницей стол,
и бумага — оставшее белое сало.

Рөстәм абыйның шигырьләрен мин үзем өчен генә тәрҗемә иттем. Рәхәт! Тәрҗемә итеп үз телеңне өйрәнәсең — анысы да рәхәт. Безнең әдәби дөньябызда ул үзе бер дөнья! Әйтүләренә караганда, аңа 60 тула икән. Алтмыш кына түгелдер сыман, юктыр. Әгәр аңа 60 кына булса, бу кадәр хезмәт эшли алмас иде. Шул мактаулы олуг дөньяның бер читенә татар телендә дә кагылып алыйк әле. Матур дөнья бу!

Шәт, гөнаһ булмастыр.

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ,
1996, 29 сентябрь.

# Рөстәм Кутуй

## Килеп чыгышым

Кайда булганмын мин,
Кайда яшәгәнмен
Пәйда булганчы бу якты дөньялыкка?
Кайсы далаларның зәңгәр киңлекләрен
Атта гизгән бабам.
Кайда соң ул нокта?

Шадра битле йөздә
Учактай күз сүнгән...
Һәммәсе дә элек, элгәргедән элек,
Мин юкта, мин юкта, мин юкта...

Кайнаганмын йолдыз, тояк йә кош булып,
Инкарь итеп яуны,
Ханга
Хәнҗәр кайрап яттым,
Киек каз юлын мин йөрттем керфегемдә,
Кайнар сулыш өрде күккә ярсу атым.
Ә көткәнем — якын!

Атлар табуны артыннан йөгерә төрки кызы,
Аның иңеннән зәңгәр ай күккә менеп китте...
Аргамагым ялын учлап мин ияргә мендем,
Кыпчак кызы күзләрендә атны алып китте.

Көнбаешның карашы миңа кагылмый да.
«Оч!» ди уем,— «атың ялын сеңдереп кочакка»
Усалланам.
Минем бабам — аңлатырдыр, бәлки,
йөрәккә күмер утыдай
калдырган ул — Чакма.

Урда килә! Ишетәм тояк тавышларын,
Тирә-юньне әнә үлем уты ялый.
Ә Батыйның аның үз үпкәсе үпкә
Хан хан инде, җаны кара саранчадай.

Кодрәтле һәм бөек кысык күзле бөркет,
майлы иреннәрен ат итенә сона,
Аллалар — кол аңа. Берәм-берәм сүнә.
Алдады да куйды барысын уптым гына.

Йончыган шагыйрьләр күләгә шикелле
далада саныйлар киселгән баш санын.
күзләрен хан шулай дөм сукыр ясады,
Әнә бит саныйлар,
санаган күк кавын.

Хан бик күп чыгарды күз алмасын чокып,
Пылауны алгандай чокып алды кулы.
Табында касәсен югары чөйгәндә
еландай бөтерелде неп-нечкә муены.

Ишелеп килде урда, себереп һәм ягып,
шундый горур, усал, күз карашы үткен.
Ә юл гүя тере, бәргәләнеп килә...
Сузылып-сызылып килә... килә, әйтерсең лә
каерып ачылган авыздан чыккан тел.

И дала, хәтерлә, кызыма «Хуш!» әйтеп,
төнлә чыгып чапкан ул соң мин түгелме?
Төшмәсен дип тешкә хәнҗәрен тешләгән,
Максатына җиткән, ул соң мин түгелме?

Тирмәсен таныдым. Зиннәтле Батыйның
бугазына хәнҗәрем батырдым,
төбенә тикле.
Сызгырып кан чыкты... һәм җаны
җәһәннәмгә китте.

Кайнады учаклар бармактай йөгереп,
Минем сагыш булып акты курай моңы.
Адашкан төн килеп ябырылды миңа:
«Уйна әле тагын, уйна әле шуны...
Оныт сугышларны, оныт яу чабуны.
Хан кадалды инде, кипте кара муек...»

...Егерменче гасыр. Күз яше һәм диңгез —
икесе дә тозлы. Шуны торам тоеп.
Ә мин уйныйм әле... кылычлар күгәрә,
Җир шары әйләнә — ә мин уйныйм һаман.
Яңа сулыш белән бураем өретелгән,
учак күмерләрен дымлы чык каплаган.

## Курай

Азия. Бөркү.
Каерып ачылган авыздан чыккандай,
даладан, капланып атларның ялына,
канга баткан хәлдә, оран сала-сала
бүселеп чыкты урда.

Тоташ алтын гына!

Алтын шаулап акты,
алтынга әйләнеп
ага иде бергә әдәмнәрнең каны.
Күмердәй каралган дала-кортка гына
пешеренә иде,
ачлыктан сап-сары.

Хатын-кызлар әнә кипкән елга кебек,
дала үләнендә канны юа-юа,
башкайларын чайкап җыр сузалар иде
дала өстендәге бөек яу турында;

Ачы язмышлары йөзләренә чыккан,
киек җәнлек кача учаклардан өркеп.
Күзләре бәйләнгән атлар төркеменең
өстендә әйләнә ябык ана бөркет.

Хатыннар ишәю эше белән мәшгуль,
ярым ай чайкалып йодрыкларны кисә.
Тудыңмы — чытырдап ябыш ат ялына,
үлем белән бер ул ычкындырдың исә.

Усалланам?!
Җирдә ятып
Кылычлар тутыккан,
Янам, янам,
Усалланам?!
Тамырлар юлымны кисеп
актарылып чыккан.

Күмергә өр!— астында ут...
сулышыңа бөркеп
май кебек
килеп сыланыр
Яман ачы төтен;
Сихерләр дә, үз дигәнчә
чәйнәр... сине дала,
кайнар ат сулышын тояр
синең салкын битең.

Кемдер, өй-урын-җир, дигән,
нәрсә уйлап табып,
нәрсә кырган?—ияр, йөгән
затын кире кагып —
Нәрсә кылган?!
Шыбырдаша кылган...

Кулларымны җәеп күзләремне йомам,
офыкларга ашып
дала белән яшим...
Иңнәремнән төшә үлем михнәтләре —
сукса суксын яшен!

Коръән укымадым,
Сукырайдым, бугай?!
Хәзергәчә, сиңа ышанмыйм мин, Аллам.
Өстәлемдә ипи торган нигез изге,
ишек артындагы астыртын күз — Яман!

Урыс кызы, мә ал,
зеңләп торган каным! —
Үзем белән зеңләп зирәк күзем тулсын,
мамык кашлы тылсым тудырып бир миңа,
тик куллары аның татлы тамыр булсын.

Бу син түгел, түгел,
офык карый миңа...
тукта!.. тынычланыйм...
каным...
Җаным актарылды.
Тукта тынычланыйм.
Шәрыкъ үлә миндә —
азиат үлеп ята,
йөгән эзли кулы...

# ИР КЕШЕЛӘР

Кайчан булса да без аның белән балыкка китәрбез. Тагын моннан ике тапкыр зуррак күлмәк киярлек булып үссен дә — барысы да рәтләнер. Ул кармакларны һәм суалчаннар тутырган тартмасын күтәрер. Мин — ишкәкләрне. Шайтан алгыры, һәрвакыт бер җилкәмдә ишкәк, ә икенчесендә — кармаклар күтәреп йөрү туйдырды да инде.

— Тизрәк үс әле син.

— Әлбәттә. Кара, мин синең кай җиреңнән инде.

— Әй-йе-е...

Мин аның якты башын үземә тартам, аның алдына чүгәлим, һәм без бер-беребезнең күзләренә карыйбыз. Мин — аның күз карасында, ул — минекендә.

— Синең башың Кояш кебек,— дим мин һәм «Кояш»ны кулым белән сыпырам. Әнисе шулай итеп аны, кояшкай дип тә атый, ә миннән бу сүзләр беренче тапкыр шулай ычкынды һәм аның алдында бераз уңайсыз булып китте.

— Синдә дә чалбар, миндә дә чалбар,— дип фикер йөртте ул.— Синдә дә ботинка, миндә дә ботинка. Икебезнеке дә кара... Мин бөтенләй сиңа охшаганмын.

— Кем әйтте аны сиңа?

— Әни әйтте. Минем борыным да синеке кебек. Һәм тагын маңгаем да... һәм тагын мин дә синең кебек ачулы.
— Анысын уйлап чыгардың инде.
— Һәм тагын... Ә колаксыз яшәп буламы? (Эх, кайчы белән кисеп булса!). Мин колаксыз эт күрдем.
— Була,— дип елмаям мин.— Ләкин син кайгырма. Колаклы булып яшәү яхшырак.
— Яхшырак,— дип килешә Андрейка.— Борынлы булу да яхшы.
— Томат согы телисеңме?
— Телим. Ә әнигә әйтмибезме?
— Юк, ярамый.
— Яхшы.
Без киоскка килеп туктыйбыз һәм мин кесәмнән вак акча эзлим. Ул кесәмә карый һәм, колагын якын китереп, вак акча шалтыраганны тыңлый.
— Син бай,— ди ул һәм ике кулы белән минем бармагыма тотына.
— Ул стаканның яртысын эчә. Нәкъ яртысын.
— Эч,— дип миңа суза,— син дә телисең бит.
Эсселек басыла, күк йөзе куера башлый, ул йолдызларын тәгәрәтеп чыгарырга әзерләнә. Бер почмакта чәчәкләр саталар. Чиләкләп су бөркиләр дә саталар — зәңгәр, ак, кызгылт, сары төсләләр. Кыз кулында алар тирбәлеп, җирдә түгел, ә аның кулларында үскән төсле булып, кичке чыкның эре тамчыларын чагылдырып торалар.
— Синдә тагын акча бармы?
— Бар.
— Берне генә. Алыйк. Әнигә.
Ул йөзе белән сузылып астан өскә карый, кинәт акча булмас та мин: «юк» дип әйтүдән курка. Аннан бер кулына чәчәк тотып бара, икенчесе белән миңа тотына. Машиналарга борылып карый.
— Ә миңа шундый күлмәк тегәсезме? Синеке шикелле.
Мин көләм. Ул көнләшеп минем ковбойкамны карый.
— Минем дә җиңем сызганган, синеке дә сызганган.
Ах, безнең барысы да бертөсле булуны нинди тели ул!
Иртән ул идәндә яланаяк шапылдап йөрде һәм аягын минекеләр белән чагыштырды. Ә мин, аның тар, яссы табанына карап, армиядә бер лейтенантның миңа: «Кыймылда, яссы табанлы шагыйрь... Мин сиңа ничек шигырьләр язарга күрсәтермен»— дип кычкырганын искә төшердем. Лейтенантның ачуы миңа бер җыр аркасында килгән иде. Аннан аны барысы да җырлап йөрделәр. Лейтенант кына җырламады һәм мине кухняга нарядка билгеләде. Наряд артыннан наряд.
Без пенсионерларсыман ашыкмый гына атлыйбыз. Без эшне төгәлләдек. Мин Андрейкага балалар бакчасына заводтан гайка алып кайттым, һәм ул аны кесәсенә эчкәрәк тыгып куйды. Ул тәрбиячегә: «Сау булыгыз!» диде һәм безнең эш көнебез төгәлләнде. Хәзер без йөрибез, ул юеш чәчәк күтәреп бара һәм аны бертуктаусыз исни.
— Ис килә,— ди.
— Нәрсә исе?
— Салават күпере исе. Ә ничек атала ул?
— Син беләсең ич.
— Ю-у-у-к!
— Салават күпере атала. Син нәкъ эзенә бастың. Әниеңә дә: «Сиңа салават күпере бүләк итәбез!» диген.
— Ярый.
Әлбәттә, бу чәчәк ниндидер пион дип түгел — ә салават күпере дип атала. Атла, сабый — исеме матур чәчәкнең.
— Ә Кояш кая югалды?
— Кояш? Ничек кая? Безнең йорт кайсы якта?
— Анда.
— Ә Кояш кая төште?

— Шунда.
— Димәк, безнең сарайга качкан.
— Әй-лә!
— Әлбәттә. Менә күрерсең. Кайтып җиткәч, әниең чәчәкне стаканга куяр да, без сарайга кереп карарбыз.
— Әйдә.
Аннан без дәшми генә барабыз. Ул да уйлана, мин дә уйланам. Зур йортлар бетте, каршыдан бәләкәйләре йөгерә. Алар бер-берсеннән аерылганнар, җирне түтәлләргә бүлгәләгәннәр һәм минем Андрейкама караңгы йөз белән карыйлар.
— Бу йортлар искергәннәр,— дим мин.
— Безнеке дә искеме?
— Безнеке дә. Менә машиналар килерләр дә, аларның берсе дә калмас. Чокып чыгарачаклар аны. Зур йортлар куячаклар. Белдеңме?
— Этләр дә калмасмы?
— Этләр дә. Син аларны яратасыңмы?
— Әгәр тешләмәсәләр.
— Тешли торганнарын куачаклар. Ә тешләми торганнарын калдыралар.
Сабый шикләнеп калын коймаларга текәлә. Эт кётә. Һәм ул пәйдә була. Ул тәпиләрен коймага куя да борынын селкетеп куя. Аның күзләре усал, зур булып ачылган. Авызы — кып-кызыл.
— Син курыкма.
— Ә мин курыкмыйм.
— Минем аяк артына яшеренмә. Яле, кулымны җибәр.
Эт өрә һәм чылбырларын шылтырата, ләкин Андрейка минем кулны ычкындырмый һәм, койма ягына бөтенләй карамыйча, минем алдан бара.
— Комсызмы ул?
— Әйе. Тик аваз сала күрмә. Чәчеңне дә рәтләбрәк тот.
Өйтүр бакчадан бер ир кеше чыга, тузган чәчләрен кашый һәм тәрәзә капкачларын яба башлый. Ул эшермәләрне шылтырата-шылтырата озак итеп яба. Ә без карап торабыз.
— Нигә яба ул?— дип шыпырт кына сорый Андрейка.
— Йолдызлардан,— дим мин дә шыпырт кына.
Минем сабыем шыпырт кына атлый, һәм аның кулында чәчәк чайкала.
Кар ява да без аның белән чаңгы шуарга китәрбез. Үземнең кызыл шарфым белән аны урармын да китәрбез. Аю өне эзләргә. Кайнар кофе белән термос алырмын. Аз гына туңа башладымы — мин аңа бер стакан кофе. Парланып торганын. Ә тирә-якта кар түгел, шикәр. Безнең әз генә кар ашаганны әнисе күрмәс.
— Ардыңмы, Андрейка?
— Юк, ә нигә йолдызлардан яшереналәр? Әйт...
— Чөнки аларның сандыклары зур. Күрәсеңме, нинди коймалар... Төнлә йолдызлар күзәтеп торырлар, дип куркалар. Тәрәзә капкачлары, коймалар... Менә машиналар килер дә...
— Тиздәнме?
— Тиздән.
Кичә мин өйгә әтинең орденын алып кайттым. Андрейка бабасының орденын. «Ватан сугышы. Беренче дәрәҗә». Матур орден.
Андрейка:
— Кайдан бу?— диде.
— Бабаңа бирделәр.
— Ә ул бит... Аны бит фашистлар үтергәннәр.
— Беләсеңме, бу күптәнге орден. Бабаңа аны бирергә онытканнар. Төрле кәгазьләрен югалткан булганнар. Ә бүген тапканнар да, менә миңа бирделәр.

— Ә алай буламыни?
— Була.
Андрейка авыр сулап куйды.
— Хәзер бабай юк...
— Акчалата түләсеннәр иде, ичмасам,— диде Андрейканың әбисе.
Ләкин без бернәрсә дә ишетмәгәнгә салыштык.
— Хәзер аны кем тагып йөрер?
— Син.
Ул кызарынды, башын түбән иде.
— Беркет... ә?
Һәм мин беркеттем. Свитерына тишек ясадым да беркеттем. Кемдер орденны тагып йөрергә тиеш иде бит. Бабасы Андрейка өчен һәлак булган.
— Свитерны бозма,— диде Андрейканың әнисе.— Тишеге зурая.
Ләкин без тагын бернәрсә дә ишетмәгәнгә салыштык. Андрейка ордены белән йоклады һәм, уянгач көзге алдында озак кына басып торды. Ә аннан бабасының портреты янына килде.
— Хәерле иртә, бабай...
Хәзер дә мөгаен: «Өйгә кайтуга орденлы свитерымны киям. Балалар бакчасына орден белән ярамый. Тәрбияче әрли. Киярмен дә чәй эчәргә утырырмын... Аннан сарайдагы Кояшны карарга булыр» дип уйлыйдыр.
— Андрейка, Аркаша абзыйларга керикме? Безнең аңа күптән кергәнебез юк. Хәтерлисеңме? Чәй эчкән идек. Пычак белән май да кискән идек.
— Киттек, ул сугыш турында сөйләргә тотыначак.
— Юк. Син аннан бернәрсә турында да сорама. Аңладыңмы?
— Аңладым.
Без тәбәнәк кенә йортка якынлашабыз. Мин Андрейканы күтәрәм, һәм ул ләззәтләнеп бармагы белән кнопкага баса...
Һәм йорт стенасы артына Андрейка шалтыраткан кыңгырауның матур зыңгылдавы тарала.
— Сеззз икәнсеззз — дип шатлана кыңгырау.
Ләкин безгә беркем дә ачмый. Мин тезем белән ишеккә төртәм һәм ул тар коридор күрсәтеп ачылып китә. Андрейка коридор буйлап чаба, ике куллап башка ишеккә төртелә.
— Аркаша абзый, без килдек,— дип кычкыра ул.
Аркадий йөзе белән стенага карап урынга яткан.
Бүлмәдә караңгы. Өстәлдә колбаса кабыклары һәм алюминий кружка. Һәм кәгазь битләре. Аркадий кулы белән сызгаланып беткән кәгазь битләре. Йөзләр, каскалар, куакчык һәм чәнечкеле тимерчыбык. Кемнеңдер елмаюлы йөзендә чәнечкеле тимер чыбык.
— Ә-ә-ә, синме бу, Андрейка,— ди Аркадий.— Утыр.
Андрейка урындыкка менеп кунаклый. Кружкадан су эчә.
— Ничек яшисең?
— Яхшы.
— Димәк, яхшы яшисең.
— Яхшы.
— Бик шәп. Йөрдегезме?
— Йөрдек.
— Һәм миңа кердегез?
— Аркаша абзый янына кердек.
Мин аның урынына якын килеп, Аркадийның зур кулларыннан алам.
— Нәрсә, тагынмы?— дим мин.
— Тагын.
— Һәм көчлеме.
— Шулайрак.
— Кайчан бетәр соң бу, картлач?

— Белмим. Бәлки, беркайчан да? Заводта тәртипме?
— Тәртип.
— Мөгаен, беркайчан да... Йөрегез. Андрейка үсә инде. Кичкә яңгыр булыр ахыры.
Ул тәрәзәгә карый. Андрейка да тәрәзәгә карый. Мин дә. Кояш кереп киткән җиргә карыйбыз.
— Вакыт, Аркаша... Без бер минутка гына бит.
— Тәпиләгез, шайтаннар. Ә мин иртәгә аякка басармын.
— Басарсыңмы, Аркаша абый?
— Әлбәттә.
Һәм Андрейка тагын коридор буйлап чыба. Бусага төбендә туктый. Күзләре зурлар, сафлар, пакьләр.
— Ул авырыймы?— дип сорый.
— Ул сугыш белән саташа, Андрейка.
— Ә ул куркынычмы?
— Куркыныч.
Урам. Үлән. Ялгыз нарат болытка сузылган.
Ике күк канаты югары — күк күгәрчен диярсең.
— Җырла әле,— дип үтенәм мин Андрейкадан.
Һәм ул акрын гына, пышылдап ук диярлек җырлый, ләкин мин Андрейканың җырын яхшы ишетәм, ишетәм, ишетәм.
Һәрвакыт булсын Кояш,
Һәрвакыт булсын һава...
Киң урам уртасында аның тавышы бөтенләй ишетелми. Андрейканың тавышы ничек соң? Кычкырса да беркем ишетмәячәк. Мин генә ишетәм аны. Мин аны теләсә кайда ишетәм. Мин Андрейканың кулын ныклап тотам. Һәм без өебезгә атлыйбыз. Алда Андрейка, арттa — мин. Уртада — җыр. Без өйгә керәбез. Әнисе Андрейканы капшый. Берәр җирен имгәнмәгәнме. Ә ул аңа чәчәк суза һәм:
— Сиңа салават күпере бүләк итәбез,— ди.
— Уйлап чыгарасың да инде,— ди әнисе, кызарып.
Хәзер ул сарайдагы кояшны хәтеренә төшерәчәк.
Ул бер вакытта бер нине дә онытмый. Мин болдырдан җиз ләгәнне алам, мамык алган шикелле, акрын гына алам һәм аяк очларына басып ишеккә елышам.
— Син кая?— дигәне ишетелә.
— Хәзер. Син чәчәкне стаканга куй.— Һәм мин ишек алды аркылы сарайга йөгердем. Ләгәнне сак кына, караңгылыкның нәкъ уртасына, арткы стенага сөяп куям. Әз генә хәл алам. Һәм артка.
Андрейка бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә, аның күкрәгендә бәхетле орден.
— Әгәр сугыш булса, без дә синең белән сугышка барырбызмы?
— Әлбәттә. Башкача ничек тагын.
— Нишләп син бала белән сугыш турында сөйләшәсең?— Бу Андрейканың әнисе. Аңа каршы дәшү мөмкин түгел.— Сез, әлбәттә, сок эчкәнсез. Күпме әйттем, үтендем...
Ә без Андрейка белән дәшмибез. Һәм ул, әлбәттә, сарайдагы кояшны исенә төшерә.
— Ул һаман андамы?
— Анда.
— Карыйкмы?
— Әйдә. Тик сарайга кермәскә. Пешәсең.
— Ул кайнармы?
— Әлбәттә.
Андрейка сарайдан биш адымлап читтә тора.
Мин караңгылык эченә фонарь яктысы юнәлтәм. Андрейкага кычкырам:
— Күрәсеңме?

— Күр-рә-әм!— дип ухылдый ул. Ә ләгән ялтырый.
Өстәл артында Андрейка әнисенә:
— Безнең сарайда кояш бар,— ди.
Ул кашыгын минекечә итеп тота. Бер якта кашык, икенчесендә ипи.
— Лыгырдама,— ди әнисе Андрейкага.
— Без синең белән ир кешеләр,— дип иелә ул миңа таба.— Ә әни кыз кеше...
— Өстәл артында сөйләшүне туктат,— ди Андрейканың әнисе, кашыгын төшереп.
Кухнядан әбисе кычкыра:
— Утын китергәннәр! Бар бушат!
Ул өй янындагы утыргычка утырган, һәм менә утын китергәннәр.
— Яңгыр килә! Бар бушат!— дип кычкыра Андрейканың әбисе.
— Син аша,— дип әмер бирә әнисе.— Син аша, Андрейка!
— Мин булышырга чыгам,— дип пышылдап үтенә ул.
— Утыр.
Утын бушатабыз. Озак. Инде бер йолдызсыз сукыр караңгылык. Кыска бүрәнәләрне турыдан-туры сарайга ыргытам.
— Яңгыр кирәкне бирәчәк хәзер,— ди шофер. Ул тәмәкесенә ут кабызырга өлгерми, караңгылыкта шыбырдау пәйдә була, ә аннан: шоп-шоп... Коела, түгелә башлады. Күлмәк юешләнеп иңбашларына ябышты.
Без соңгы бүрәнәне тәгәрәттек һәм аска сикердек. Фаралар капкага буй-буй юл сызды лар. Ике юл болдырдан коймага авышты.Шул яктыда мин зонтик астында торучы Андрейканы күреп алдым. Ул болдырда басып тора иде. Мин аның янына чаптым.
— Син нәрсә?
— Анда...
Мин аңламадым.
— Рәтләп сөйлә.
— Анда бит кояш...
Һәм күз яшьләре яңаклар буйлап олы бәладән туган бөек күз яшьләре ага. Күзләре дә яшькә тулы. Мөлдерәмә тулы.
— Сарайда... син анда ыргыттың...
Мин аннан Андрейканы зонтигы-ние белән кочаклап алдым.
— Кызык син. Елама. Мин Кояшны арткарак тәгәрәтеп куйдым. Барысы да тәртиптә, Андрейка.
— Син пешмәдеңме?
— Юк. Чөнки ул йоклый бит инде. Сиңа да йокларга вакыт. Иртән кояш очып чыгар. Очар.
— Ә төнлә аны беркем дә урламасмы соң?
— Курыкма, сабыем. Син миңа ышанасыңмы?
— Ышанам.
Ул тынычланды. Йокларга әзерләнә башлады. Бабасы портреты янына килде.
— Хәерле төн, бабай,— диде ул, һәм орденга карады.
Кояш өчен тыныч иде инде ул.
...Төн буе аның төшенә кояш керде. Төштән, җиңел, якты төштән күчкәндәй иртән ул, яңгырда юынып, бик зур булып, озын нурларын салындырып чыкты, һәм йокыдан уянуга Андрейканың күзләрен камаштырды.

*Әхмәт РӘШИТОВ тәрҗемәсе*

# ҖЫР БЕЛӘН ТҮЛӘНГӘН ӘҖӘТ



**Шагыйрь Роберт Рәкыйповка бу айда (10 ноябрьдә) 60 яшь тулган булыр иде. Әйе, иде дибез, чөнки ул моннан ике ел элек арабыздан вакытсыз китеп барды. Үзе турында истәлекләр, моң калдырып, һәм, әлбәттә инде, шигырьләре, җырлары белән бергә дөньяны яратырга васыять итеп китте. Шуны тәкърарлый бу шигъри аһәң: «Талларым, талларым, талларым»...**

**Чүпрәле районының Яңа Чокалы авылында туган, урта мәктәп тәмамлагач һәм Тын океан флотында хезмәт итеп кайткач, югары белем алгач (Казан университетының механика-математика бүлеген тәмамлаган), ул озак еллар туган ягында (үз авылы, аннан Иске Кәкерле, Мунчәли авыллары мәктәпләрендә) укытучы, мәктәп директоры булып эшли. Аннары — Әлмәткә күчкәч тә, шул ук укыту, мәктәп тормышы...**

**Әмма шигырьгә ул туган якны сагыну һәм диңгезчe хисләре белән керде: җитмешенче еллар азагында «Диңгез хикәяте» кебек повестен һәм диңгез җиле исе килгән шигырьләрен бастырды. Шул ук хисләр белән «Сагыну» исемле китабын (1981) мәйданга чыгарды. Аннан — «Сиңа гына ачам күңелемне» (1983), «Яшьлегем башкаласы» (1985) һ. б. китаплары...**

**1984 елдан ул — Язучылар берлеге әгъзасы иде. Әлмәттә яшәде, шул төбәк әдипләре арасында кайнады, язды...**

**Әмма аның өчен иң газизе, кадерлесе — туган як хисе, таллар, кырлар, нигез чакыруы булган. Һәм туган җиргә мәңгелек бурыч тойгысы, җыр белән түләнәчәк әҗәт...**

**Әйе, «җыр белән кайтарган», хәтта гомер белән түләнгән шигъри әҗәт...**

**Шуны белгәнгә дә моңлыдыр ул — таллар!**

**Рәдиф ГАТАШ.**

# Роберт Рәкыйпов

## Җыр кайтарам

Җыр кайтарам мин чишмәле тауларыма,
Җыр кайтарам кырыкмыш колын, тайларыма,
Җыр кайтарам алтын башак — игеннәргә,
Җыр кайтарам Сөн, Зәй, Чулман, Иделләргә.
Җыр кайтарам дөньяда бер матур кызга,
Җыр кайтарам сыерчыклы якты язга,

Жыр кайтарам Чокалыма, Әлмәтемә,
Жыр кайтарам шигырь биргән әйбәт төнгә.
Жыр кайтарам дан, көч, намус — өчесенә,
Жыр кайтарам гади хезмәт кешесенә,
Жыр кайтарам чәчәкләргә, үләннәргә,
Жыр кайтарам давылларда үлгәннәргә.
Жыр кайтарам сакта горур торганнарга,
Жыр кайтарам диңгезләргә, урманнарга,
Жыр кайтарам Сөембикә әбиемә,
Жыр кайтарам газиз әти-әниемә.

Мин аларны берәмтекләп җыйган идем,
Бүләк иткән иде миңа туган илем.
Жыр кайтарам, бурычка дип алган җырны,
Шуңа зурлыйм тугайларны, алан, кырны.

Мин аларны алган идем кошлардан да,
Җәйләрдән дә, көзләрдән дә, кышлардан да.
Миңа алар һәрвакытта дәрт һәм терәк,
Ләкин хәзер бурычларны түләү кирәк.

Жыр кайтарам барыгызга, барыгызга,
Кояш булсын алар — туган ярыгызда...

## Җылылык

Кояш белән шигырь — коллегалар,
Икесе дә җылы бирүче.
Яктылык һәм җылы иҗат итү —
Чын мәгънәдә менә ир эше!

Җылысы юк йөрәк таш белән бер,
Жыр җыр түгел, җылы булмаса.
Салкын булса туфрак, андый җирдә
Чүп үлән дә үсми ләбаса.

Җылы өйдә генә җанга рәхәт,
Җылы караш кына сөйкемле.
Җылысы юк көлү көлү түгел,
Баласы юк бишек шикелле.

Өметләрен җуйган кеше җаны
Салкынрак салкын тимердән.
Җылыт әле җаннарымны дияр
Мәхәббәткә яшьли тилмергән.

Кояш — кояш, йөрәк — йөрәк түгел,
Шигырь шигырь түгел ялкынсыз.
Җылы кирәк җанга, җылы кирәк —
Яшәп була җирдә алтынсыз.

Җанга җылы иңә эч бушатсаң,
Дуслар белән бергә җыелып.
Җылы өрсәң, таш та терелер диләр —
Тормыш үзе сүнмәс җылылык.

* * *

Заман шундый: кайгылыга — кайгы,
Кайгы бирүчегә дәрәҗә.
Күзләрендә йоклый караңгы төн,
Йөзең — төнге утсыз тәрәзә.

Җаным йомшак минем, йоклый алмыйм,
Яннарымда кеше җыласа.
И күңелем, төнне кояшлы ит,
Ыңгырашуларны җыр яса!..

* * *

Дөбердәде якорь чылбырлары,
Баш селкиләр төп-төз нәратлар,
Зәңгәр күктә йөзә акчарлаклар,
Диңгезләргә китә кораблар.

И кораблар! Мин табышмак чишәм,
Кая таба сезнең юлыгыз?
Алыгыз сез мине үзегез белән,
Мин дә сезнең туган улыгыз.

Диңгез белән җир тоташкан төштә
И буласым килә минем дә.
Офыкларны сыйпап карыйм дигән
Теләк тибә минем күңелдә.

Текә дулкыннардан курыкмыйм мин,
Булса булсын куе ак томан.
Өлкән акыл белән ашкынам мин,
Яшь йөрәгем белән омтылам.

* * *

Беләм, әни, Иделдә көн хәзер,
Камчаткада төпсез төннәр әле.
Ә йолдызлар гүя чиксез галәм
Бушлатының алтын төймәләре.

Хәтеремдә, әни, мин киткәндә
Күзләреңне тутырып карап калдың.
Шуңадыр ул, ышанычың кебек
Кичке уты яна корабларның...

* * *

Яттан беләм үткән гомеремне,
Хаталарым булды, яшермимен.

Әгәр сиңа әрнү биргән булсам,—
Тәү адымым иде, кичер, Илем.

Яннарымнан чапкан елларымны
Саклык белән генә барлап барам.
Борылып карыйм, кемнәр килә икән
Мин тигезләп киткән юлларымнан?..

## Чокалым

Ник тавышым бүген — моңсыз чишмә,
Җаным — сандугачсыз киң бер алан?
Бу тик шуңа, туган җирем, шуңа —
Еракларда калган мин бер балаң.
Кырларымның сагышларын тоям,
Хәсрәтләрен тоям Чынлы-суның.
Бу тик шуңа, туган җирем, шуңа,
Синдә генә булган чын моңсуым.
Көннәр үткән саен аһәңеңне,
Карашыңны миннән качырасың.
Бу тик шуңа, туган җирем, шуңа,
Кайт, кайт, улым, диеп чакырасың.





# ОНЫТЫЛМАС ОЛУГ ЗАТ

Моңнар чишмәсе

Халкыбызның һәр җәһәттән уңган, батыр халык булуын без һәркайчан горурлык белән искә алабыз. Бу безгә башка халыклар белән аралашканда да йөз аклыгы булып хезмәт итә, чамадан тыш кыен хәлләргә дучар булганда да, изелеп төшмичә, батыр йөрәкле ир-егет булып калырга ярдәм итә. Мин моңа мисаллар китереп тормыйм. Бу урында Муса Җәлил һәм аның иптәшләренең тиңдәшсез батырлыгын искә төшереп узу да бик җиткән.

Тормышның җиңел булмавы, кыенлыкларга каршы көрәшергә кирәклеге турында безгә борынгы бабаларыбыз да әйтеп калдырганнар. Бу васыять исемнәре безгә килеп җитмәгән борынгы шагыйрьләребез һәм композиторларыбыз җырында аеруча үтемле итеп, аеруча образлы телдә әйтелгән:

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә;
заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә.

Бу изге васыятне иң талантлы һәм хөрмәтле җырчыларыбыздан Илһам Шакиров шундый тирән моң белән баетып, шулкадәр үзәкләргә үткәреп җырлый, хәтта моны чынлыкта Илһам түгел, бәлки карагайлы кара урман эченнән борынгы бабаларыбыз үзләре җырлап баралар кебек ишетә башлыйсың. Моның сере нәрсәдәдер, болай ишетелсен өчен тавышны ничегрәк итеп көйләргә кирәктер, анысы җырчының иҗат сере, әмма шунысы хак, җыр чыннан да куе урман эченнән ишетелгән кебек тәэсир кала.

Халыкның тарихын өйрәнгәндә үзеннән-үзе алга шундый сөаль килеп баса — халкыбызга күп гасырлар дәвамында таркалмыйча бербөтен булып сакланып калырга, барыннан да бигрәк, аның нинди асыл сыйфатлары ярдәм итте икән? Минем белүемчә, моңа галимнәребезнең күбесе туган тел дип җавап бирәләр булса кирәк. Беренче карашка дөрес фикер инде бу. Моңа мисаллар да күп китерелә. Шулай да, минемчә, бу әле тәмам ныгып аксиома дәрәҗәсенә күтәрелеп җиткән каттый фикер үк булып җитә алмый. Чөнки бу раслауда кешенең шәхес буларак өлгереп җитүендә бик тә әһәмиятле урын тоткан, борынгырак әдәбиятыбызда сәнгать нәфисә дип йөртелгән илаһи бер тармак, шуның эчендә моң дип аталган гаҗәеп бер кешелек сыйфаты бөтенләй читтә кала. Хәлбуки адәми затның теле ачылганда аның инде күңелендә авазлар гармониясе дә, ягъни бик примитив формада гына булса да, моң да барлыкка килгәндер. Моң исә ул, белем кебек үк, кешенең рухи байлыгы, аның да иң нечкә, хискә иң бай өлеше. «Сүзнең куәте җитми башлаган урында музыка эшкә керешә» дигән А. Пушкин.

Бу «моң» дигән төшенчәнең русча исеме юк. Гадәттә аны русчага «мелодия» дип тәрҗемә итәләр. Ләкин, моң ул әле көйнең үзе түгел, һич юк. Моң ул көйнең эчке сыйфаты, аның әйтергә кирәк, эчке байлыгы, аның җаны. Көйнең сыйфатына, гадәттә аның моңы нинди булуга карап бәя бирәләр. Моңсыз көй була алмый торгандыр. Әгәр дә инде күңелдә бернинди игелекле хис тә уятмый торган, урамдагы җил сызгыруы сыман дуамал, буш авазлардан гына оешкан җансыз берәр нәрсә барлыкка килә икән, ул инде башкача, мәсәлән, бәлки «такмак» дип атала торгандыр. Моңсыз көйне тозсыз аш белән тиңләүләрен дә ишеткәнем бар. Бик аяныч хәл инде билгеле, ләкин андый җансыз авазлар җыелмасын соңгы елларда шактый ук еш ишетергә туры килә.

Моң хакында алып барылган бу тәфсилле әңгәмәне, күрәсең, Сара ханымның иҗатына кереш сүз дип аңларга кирәктер. Мәгълүм ки, Сара Садыйкова иҗат иткән көйләр моңга бик бай була торган иде. Хәер, монысы инде үзеннән-үзе аңлашыла торгандыр. Чөнки җырларына моң җитмәсә, ул халык арасында шундый популярлык казана алмаган булыр иде. Үзенең сөйләвенә караганда, аны кечкенә чагында ук «Моңлы бала» дип йөрткәннәр. Җыйнак кына гәүдәле бу чибәр туташның сәхнәгә курчак кебек матур киенеп чыгуын, ягымлы тавышын өлкән буын кешеләре әле хәзер дә хәтерлиләр булса кирәк. Минемчә, Сара ханым табигате белән үк сәхнә өчен яратылган зат иде. Аның сәхнәгә килеп чыгу белән үк халыкны үзенә карату сәләте мине һәрвакыт хәйран калдыра торган иде.

Әгәр дә хөрмәтле артистларыбыз, «бу агай кирәкмәгән урыннарга борын суза» дип шелтәләмәсәләр, мин, җыр сәнгатенә бик тә хәерхаһ кеше буларак, тагын бер фикер әйтер идем. Әгәр дә артист, хәтта ул зур талант иясе булса да, һәр чыгышында унынчы, егерменче мәртәбә берүк фикерне, берүк интонацияне кабатлый башласа, ул тыңлаучыны бик тиз ялыктыра. Сара ханымны исә һәрвакыт якты чырай белән каршы ала торганнар иде.

Артистка чагында Сара Садыйкова нинди генә борынгы көйләрне башкармады икән! «Ашказар» дисеңме, «Әллүки»ме, «Зөлхиҗҗә», «Бөдрә тал» һ. б. бик күпләр. Бу җырларны нәкъ элекке осталардан ишеткәнчә һәр борылышын, һәр үзенчәлеген тәмам җиренә җиткереп башкару җырчыдан зур тырышлык һәм талант таләп итүе һәркемгә мәгълүм.

Бу урында ни сәбәпле бу җаваплы истәлекне язарга алынуымның сәбәбен аңлатып узарга кирәктер. Бәлки Сара ханым хакында мин түгел, музыка белгече язарга кирәк булгандыр? Моның үзенә күрә бер җитди үзенчәлеге бар.

Сара Садыйкова, башка танылган артистларыбыздан аермалы буларак, үз гомерендә ике төрле иҗат шатлыгы кичергән зат. Яшьрәк чакларында ул халкыбызның талантлы җырчысы булып танылган иде. Аның Мәскәү консерваториясенә кергәндә имтиханны ничек бирүе хакында көлке итеп сөйләгәне бар. Профессор аңа классик опералардан нинди дә булса бер ария җырларга кушкан. Сара ханым исә, үзенең әйтүе буенча, Аллага тапшырып, аңа «Уел» көен җырлап күрсәткән. Профессор аның җырчылык осталыгын һәм тавышын ошаткан.

Шулай, артистка булып танылып җиткәннән соң да байтак еллар уза. Сара ханым картаерга теләми, ул икенче төрле иҗат шатлыгы кичерә башлый. Бу баскычтан икенчесенә күчеңү шулкадәр табигый бер хәл буладыр ки, без аны хәтта сизми дә калдык. Әйтерсең, шундый хәл булырга тиешлеген халык алдан ук сизеп, белеп торган. Сара ханым көйләр иҗат итү кебек катлаулы бу иҗат процессын да шаярып, гади бер тормыш эпизоды итеп сөйләштергәли иде.

— Каядыр барырга чыктым да трамвай көтеп торам. Шунда һич көтмәгәндә күңелемә бер көй килеп кермәсенме! Нишләргә? Ярый ла бу яңа көй өемә әйләнеп кайтканчы онытылмаса! Түзеп булмады, кире өемә кайтып, яңа көйне нотага салмыйча булдыра алмадым.

Шулай, ул күңелендә яңа көйләр иҗат итү сәләте сизгәннән соң, үзеннән-үзе билгеле инде, Язучылар союзына якынлашып, шагыйрьләр белән якын иҗат мөнәсәбәтенә керә. Бәлки моңа Сара ханым белән Композиторлар союзы арасында аңлашылмаучылык чыгу да сәбәп булгандыр. Беренче карашка бик ачык мәсьәлә кебек. Шактый талантлы музыкаль әсәрләр язган кеше Композиторлар союзына кабул ителергә тиеш кебек. Ләкин ул союзның уставы буенча союзга фәкать консерваториянең композиция факультетын тәмамлаган кеше генә алына имеш. Халык исә аның кесәсендә композиторлык билеты барын-югын тикшереп тормый бит инде. Аның җырлары бөтен Казанга, Республикага, безнең халык яшәгән башка өлкәләргә тарала. Менә шул елларда шагыйрь Мостафа Ногман белән алар районнарда концертлар оештырып йөриләр, аларның шөһрәте бик еракларга таралды.

Шулай, Сара ханымның җырларга язган көйләре һәр тарафта гөрләп шөһрәт казанган еллар иде бу. Минем «Җидегән чишмә» романын язган җырларыма көй яздырырга киңәш иттеләр. Җыр текстына салынган эчке мәгънәне музыка телендә кем әйтеп бирә алыр икән? Уйлаша торгач Сара ханымга тукталдык. Гөлшат ханым Зәйнашева да шундый ук киңәш бирде. Сара ханым бик теләп риза булды.

— Ярар, башта җыр текстын һәйбәтләп укып чыгыйм әле,— диде.

Берәр атнадан без Сара ханым белән рояль янында очраштык. Кызганыч ки, аның «Җидегән чишмә» сүзләренә язган беренче көе миңа ошамады. Нишләргә соң миңа? Мин бик кыен хәлдә калдым. Аның башка әсәрләрен күкләргә чөеп мактыйлар, уңышлары белән тәбрик итәләр. Аның күңеленең бик тә күтәренке чагы. Кыскасы, ул «бу көең миңа ошамый» дигән тупас сүзне ишетергә әзер түгел иде. Икенче яктан мин дә вөҗданыма хыянәт итә алмый идем. Җыр бит халык өчен языла. Үзеңә ошамаган көйне ни җаның белән халыкка тәкъдим итмәк кирәк? Бу бит халыкны ихтирам итмәү булыр иде.

Нихәл итмәк кирәк? Кыен булса да дипломатия методын кулланып әйттем инде.

— Алай икән...— дип суздым башта.— Тирәнгәрәк кереп киткәндә, бу җырны җырлап урам әйләнүче егетләрнең бик моңсу чаклары инде болай. Иртәгә читкә китәләр бит. Әти-әниләре, сөйгәннәре кала... Шуның өстенә еллар да тыныч түгел: Әфганы, фәләне, дигәндәй. Әллә исән-сау әйләнеп кайталар, әллә юк... Димәк, нинди җыр җырларга кирәк боларга!

— Озын, моңсу җыр булырга тиеш инде ул...

Сара ханым исә кыска көй язган иде. Әңгәмәне дәвам иткәндә Сара ханым түземсезләнеп мине бүлдерде:

— Хуш, тагын нинди моңы-зары бар җыр авторының? — диде.

— Аннары килеп, мин ул җырның сүзләрен үзем дә Аккош күленең айлы төнендә Җидегән йолдызга карый-карый, аның белән киңәшеп язган идем бит...

Сара ханым һич көтмәгәндә бик рәхәтләнеп бер көлеп алды:

— Ышанам, булыр, булыр... Мин үзем дә шундый хыялыйрак бәндә. Алай... Мин сизендем инде, бу көй сезне канәгатьләндерми, әйеме?

— Гафу итегез, Сара ханым, турыдан-туры әйтеп салырга телем бармаган иде. Иң дөресе шулай. Бәлки тагын бер эзләнеп хыялланып карарсыз? Озын көй, моңсу көй һич тә тумыйча калмас!..

— Шулай туры килә инде... Нихәл итәсең...

Тагын бер-ике атна узды шикелле, без янадан Габдулла Тукай клубында очраштык. Сара ханым барыбыз белән дә исәнләшә дә, гадәтенчә сәхнәдәге рояльгә таба юнәлде. Күреп торам, аның чырае якты, күңеле күтәренке, аны нидер рухландыра иде. Бәлки иҗатында берәр зур уңышы бардыр? Бәлки әле... Алдан кычкырган күкенең башы ярыла, диләр бит. Сара ханым рояль янына менеп утырды да бик матур итеп бер елмайды.

— Йә, иптәшкәй, инде монысын да ошатмасагыз, аннары белмим инде...— диде.

Сүз «Җидегән чишмә» көенең икенче варианты хакында бара иде, билгеле. Мин инде Сара ханымның йөзенә карап ук аңлаган идем: булган көй, булган! Һичшиксез һәйбәт көй туган!.. Шул рухландыра аны!

Шулай булып чыкты да. Сара ханым яңа көйне рояльдә үзе уйнап, үзе җырлап башлап җибәрүгә залдагы халык әсәрләнеп кинәт тынып калды. Сәнгать дөньясының талантлы яңа әсәргә баеган куанычлы минутлары иде бу! «Җидегән чишмә» дигән бу яңа көй моңының байлыгы, үзенчәлеге, халкыбызның борынгы көйләренә якын торуы белән үк әсир итә иде.

Җидегән чишмәләрдә җиде улак
Челтер-челтер ага көмеш су.
Көмеш сулар ага, кошлар сайрый
Шул чакларда бигрәк ямансу...

Менә кайчан гамәлгә ашты минем хыялым гына булып яшәгән ул моңлы көй! Шагыйрь булмаган кеше өчен бу бик зур шатлык иде.

Җырлап-уйнап бетерүгә язучы халык Сара ханымны сырып алды да, тәбрикләргә керешә. Сара ханым куана, мин куанам, аны кочаклыйлар, кулын кысып тәбрик итәләр. Минемчә, бу Сара ханымның бик тә бәхетле минутлары иде. Бу көй аңа яшьлек елларын кире кайтарды, булса кирәк.

Менә шулай туды ул моңлы җыр. Без ул җырны беренче башкаруны һәммәбез бер авыздан талантлы яшь җырчыбыз Зөһрә ханым Сәхәбиевага тапшыр-

дык. Әгәр хәтерем ялгышмаса, ул «Җидегән чишмә» җырын гастрольдә йөргәндә Пермь якларында татар авылларында башкарды булса кирәк.

— Бер ишетеп алгач бу җырны башкармыйча мине сәхнәдән чыгармый башладылар. Җыр минем үземә дә бик ошый, тавышыма да килешеп кенә тора. Әйтерсең лә минем өчен генә язылган... Мин аны җаным-тәнем белән бирелеп, чын күңелдән яратып җырлыйм...— ди җырчы.

Әле сүз хөрмәтлебез Сара ханым хакында бара бит. Татар халкының хәзергә «Чио-Чио-Сан» яисә «Аида» кебек шөһрәте бөтен дөньяга таралган мәшһүр опералары юк әле югын. Ләкин алар юклыктан гына аны музыкаль халык түгел дип әйтеп булмас иде.

Мәшһүр борынгы җырларыбыздан «Ашказар», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Иске карурман», «Әллүки», «Каз канаты», һ. б. бик күп мәшһүр җырларны һичшиксез зур талант ияләре иҗат иткәндер. Без аларның исемнәрен белмәсәк тә, һәрвакыт ихтирам белән искә төшерәбез.

Инкыйлабтан соң гына да безнең музыкабызны С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, З. Хәбибуллин, М. Мозаффаров кебек зур талантлар бик күп яңа әсәрләр белән баеттылар. Минемчә, гәрчә Сара ханым гомеренең беренче өлешендә артистка булып танылган булса да, нур өстенә — нур дигәндәй, аның гомеренең икенче яртысын да халык зур хөрмәт белән искә ала. Ул иҗат иткән талантлы музыкаль әсәрләр халкыбызны киләчәккә таба бик озакка кадәр озата барачаклар дип уйлыйм.

Безнең С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, Н. Җиһанов, А. Ключарев, З. Хәбибуллин кебек халкыбызның моң хәзинәсенә мәңге онытылмаслык гүзәл көйләр бүләк итеп калдырган талантлы композиторларыбыз бар. Хөрмәтлә Сара ханым Садыйкованы да без әнә шул бөек затлар белән янәшә куеп искә алабыз.

**Гомәр БӘШИРОВ,**
Татарстанның халык язучысы

## Моңнар эзләргә китте...

Вакыт елгасы туктаусыз ага... Сара апабыз вафат булганга да 10 ел вакыт узып китте... Йөрәкләрне өзгәләгән аерылышу сәгатьләре ерагая барган саен, Сара апабызны сагыну, юксыну хисләре артканнан арта, тирәнәя, көчәя бара... Сөякле композиторыбыз Сара Садыйковага булган мәхәббәтебез еллар үткән саен яктыра, яңа төсмерләр алып, күңелләрне сагышлы яңа кичерешләр дәрьясына сала...

Рөстәм Яхин белән Роберт Миңнуллин иҗат иткән «Әнкәйнең ак чәчләре» дигән гаҗәп матур бер җыр бар. Ул җырда «Әнкәйләрнең бөеклеген яши-яши аңлыйбыз» дигән тирән фикерле сүзләр бар. Бу канатлы сүзләрне мин Сара апага багышлап әйтер идем. Сара апаның бөеклеген дә без яши-яши аңлыйбыз, еллар үткән саен төшенә барабыз. Әнкәйләргә карата әйтелгән бу сүзләр Сара апага бик туры килеп тора. Чыннан да, Сара апа бик күп, бик күпләргә әни кебек иде шул. Җырларын башкаручы йөзләгән җырчылар, аның белән якыннан аралашып, дуслашып яшәделәр.

Җырларын Сара апа үзе пианиносында уйный-уйный, үзе җырлый-җырлый өйрәтергә ярата иде, шуңа күрә аның өеннән җырчылар сукмагы өзелмәде, күренекле җырчыларыбыз Зөһрә Сәхәбиева, Хәйдәр Бигичев, Миңгол Галиев, Рафаэль Ильясов, Габдулла Рәхимкулов, Гөлзада, Зилә Сөнгатуллина һәм башка бик күпләргә ул әнкәләре кебек якын кеше, дус, киңәшче, чын мәгънәсендә остаз булды. Кулыннан җитәкләп ул зур сәхнәгә алып килгән Рәбига Сибгатуллина, Шамил Әхмәтҗанов, Флера Сөләйманова, Ринат Мифтахов кебек артистлар, композиторлык юлына әйдәп, бу иҗат эшенә фатиха биргән Мирсәет Яруллин, Мәсгудә Шәмсетдинова кебек композиторлар, җыр шигыре язарга дәрт биргән бик күп шагыйрьләр өчен Сара апа кайгыртучан әни кебек иде.

Ярым ятимлектә үскән, ана назы күрмәгән мин фәкыйрегезгә дә Сара апа әнкәм кебек булды. Ул хәтта үзе миңа еш кына: «Син минем үз кызым»,— дия



*Сара Садыйкова «Качкын» операсында (Н. Җиһанов) Рәйхана ролендә (1939—40 еллар)*

иде. Шатлыгым булса, уртаклашучы, кайгы-хәсрәтем булса, бүлешүче иң якын сердәшем, өлкән дустым Сара апа минем иҗат юлымда бик зур роль уйнады. Иҗат юлымда авырлыклар килеп туганда, ул миңа үзенең аналар кайгыртуы, акыллы киңәшләре белән һәрвакыт ярдәм итте. Мин аңа килеп әнкәмә сыенган кебек сыена идем. Вафат булырына 2 еллап калганда, аның өенә еш барып йөрдем. Кулымнан килгәнчә аңа тормыш-көнкүрешендә ярдәм итәргә тырыштым. Шул көннәрдә ул кызы Әлфия Айдарская белән икебезне ике ягына утыртты да, бер кичне: «Әлфия — минем олы кызым, ә син, Гөлшат — минем кече кызым!» — диде. Бу сүзләре минем өчен зур бәхет, зур куаныч булды.

Әлеге жырда әйтелгәнчә, чынлап та без аның бөеклегенә, халкыбызның даһи композиторы, сөекле кызы икәнлегенә төшенә барабыз. Ә бит ул үзе исән чакта бөеклек-мазар турында уйламый да иде. Без дә аңар тиешле бәябезне биреп житкезә алмаганбыз, аның бөеклеге турында уйлап житкезмәгәнбез. Менә хәзер — үзе бу якты дөньядан киткәч кенә — ачынып шушы фикергә килә барабыз. Ни аяныч, Тукаебыз әйтмешли, кеше үзе үлеп күрсәтмичә, аның кадерен белми торган, кешене бәяләп житкерми торган гадәтебез бар шул... Үзе исән чакта Сара апа бернинди өстенлекләргә дәгъва кылмыйча, бик гади, тыйнак гомер итте. Аның яшәү рәвеше гади халык яшәү рәвеше иде. Балда-майда йөзеп, уңга-сулга акча түгеп, кәеф-сафа корып яшәрлек байлыгы да булмады, холык-фигыле дә андый түгел иде. Күп вакыт аның гап-гади генә көн күрер өчен акчасы да булмый торган иде. Күп язды, күп эшләде! Аның 400 гә якын җыры бар, 2 музыкаль комедия язып, сәхнәгә куйдырды, 30 лап спектакльгә музыка язды. Безнең «коммунизмга» килеп житкән җәмгыятебез иҗат кешеләре өчен тудырган «шартларда» гадәткә кергәнчә, бушка диярлек хезмәт итте. Ярым бушка хезмәт итәм дип уйлап тормады, фидакарьләрчә язуын гына белде. Бик кызык, көлке хәлләр истә калган. Бер елны без Сара апа белән бер жыр яздык, аны «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналы бастырып чыгарды. Почта аша безгә гонорар килде: Сара апага 4 сум 17 тиен, миңа 3 сум 12 тиен. «Нишләп бик аз җибәрдегез? — дип, Сара апа редакциягә шалтыратты. — Бәлки, ялгыш җибәргәнсездер?» — ди хәйләкәр елмаеп. Редакция хезмәткәрләре болай дип җавап бирделәр: «Сара апа, без бу жырга 25 сум күләмендә акча билгеләдек. 15 сумын нота күчереп язган художникка бирдек. Калган 10 сумын Гөлшат апа белән Сезгә бүлеп җибәрдек. Налоглар тоткач, почта расходлары чыккач, калган сумма шул инде...»

Сара апа кайнар холыклы, бик туры сүзле иде бит. Телефон аша ул аларны каты гына кыздырды, туры әйтеп, хаклыкны ярып салды: «Ничек инде нота күчереп язу кебек техник эш башкаручы кеше композитор белән шагыйрьдән күбрәк гонорар ала? Бу нинди гаделсезлек?! Сез нишләп иҗат эшенә тиешле бәя бирмисез?!» — диде.

Сара апа гаҗәп дәрәҗәдә тыйнак тормыш алып барды. Хаклык, гаделлек эзләүчән булса да, тәкәбберлек, масаю аңа хас түгел иде. Ул үзенең җырлары искиткеч популяр булуын белсә дә, масаймый иде.

Аның халкыбызга калдырган иҗат мирасы саф сулы, мөлдерәп торган диңгез кебек мул, бай мирас икәнлеге турында озын итеп, тулы итеп тә язып булыр иде. Киләчәктә әле музыка белгечләребез бу эшне башкарырлар да дип өметләнәбез. Журнал укучылар үзләре дә Сара Садыйкова дигән композиторның гаять олы

музыкаль хәзинә калдыруы турында беләләр, чөнки аның җырлары һәркемнең күңеле түрендә, һәркемнең колагында чыңлап, яңгырап тора. Өлкәннәр дә, яшьләр дә аның җырларын үз итә, яратып җырлый, бирелеп тыңлый. Шуңа күрә мин сүземне кыскарак тотарга тырышам. Шулай да Сара апа Садыйкованың тууына 90 ел тулуы уңае белән эшләгән кайбер эшләр турында кыскача гына әйтеп китик. Билгеле булганча, Сара апаның якын дусты, шәкерте Әзһәр Хөсәенов тырышлыгы белән оештырылган Сара Садыкова Мәдәни-хәйрия фонды аның иҗатын пропагандалау, иҗатын һәм кадерле исемен мәңгеләштерү өчен күп кенә эшләр башкарырга өлгерде. Казанда Сара Садыйкова музеен булдыру, аңа һәйкәл кую кебек зур эшләр планлаштырды. Кызганычка каршы, бу эшләрне башкарып чыгу өчен акча юклык фондны кыен хәлгә куя. Хөкүмәт җитәкчеләребез, халкыбыз вәкилләре бердәм күтәрелеп бу эшләргә ярдәм итмәсә, фонд үзе бу эшләрне җиңеп чыга алмый. Татарстан китап нәшриятында Сара апаның 90 еллыгы юбилеена 3 китап чыгарырга планлаштырылган иде. Композиторның моңарчы башкарылмаган җырларын туплап, бер җыентык, тормыш һәм иҗат юлын чагылдырган, 1987 елны басылып чыккан «Сара Садыйкова» исемле китапның яңа басмасы һәм Сара апа турында хатирәләр, кызыклы язмалар тупланган сувенир китап әзерләнгән иде. Бу китаплар юбилейга чыгып җитәрме — әйтә алмыйм. Чөнки шул ук аянычлы сүз — акча юк!.. Нәшриятның хәле авыр. Бу китапларны әзерләп нәшриятка тапшыручы буларак, мин бу юбилейны бик борчылып каршылыйм, Сара апабызга булган хөрмәтебезне, аңа булган мәхәббәтебезне тиешенчә күрсәтә алмабыз шикелле.

Әлбәттә, мондый борчулы уйлар уйласам да, халкыбыз күңелендә Сара апага карата зур, иксез-чиксез һәм тирән мәхәббәт саклануын беләм, шунсына куанам. Үзе безнең арабыздан китеп барса да, аның якты образы, күп еллар узу белән дә һич кыймматен югалтмас энҗе-мәрҗәннәргә тиң җырлары, моңнары халкыбыз рухын һаман-һаман сафландырып, халкыбыз күңелен балкытып, аның тормышында рухи таянычы булып һәр тарафта яңгырап торыр.

Халкыбызның сандугачы, җыр сәнгатебез күгендә якты йолдызы Сара Садыйкова — заманыбызның, халкыбызның горурлыгы ул.

Сүземне очлаганда шагыйрь Кави Латыйпның бер шигыре искә төште. Сара апага багышланган бу шигырен Кави Латыйп мондый юллар белән тәмамлый:

Юк, үлмәде чал сандугач,
Моңнар эзләргә китте.

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА, шагыйрә,**
Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты

## Тау ягының кадерле баласы...

«Зинһар, кайтарыгыз мине Тутаема, үз баласыдай һәрчак якын күргән Кызыл Тау авылы кешеләре янына. Хәлем авыр, ябыктым. Соңгы вакытта әнә тамактан бүлнис ризыгы да үтми. Ә авылда... Анда чибәр, сөйкемле ханымнар яшь килennәрдәй вак-вак турап, бик тәмле итеп токмачлы аш пешерәләр, мәтрүшкәле чәй, каймаклы салкын катык белән сыйлыйлар. Авырып ятканда әнә шул нигъмәтләр, мине сагынып көтеп торучы ахирәтләрем Мөслимә, Сәгъдияләр күз алдыма килә. Токмачлы ашларын ашасам, каен себеркесенең хуш исен иснәп, мунча парында рәхәтләнеп, изрәп утырсам, сырхавым бетәр, бер авыруым да калмас, Алла боерса...

Хәлим наным, авырыксынма, теге чактагы кебек җиңел машинаңа утыртып, тагын бер кат алып кайт әле авылга. Гозерләп сорыйм!..»

Сара апа Садыйкованың соңгы үтенече булды бу. 1986 елны, үләренә 4 көн кала әйтте әлеге сүзләрне. Инде 80 яшен тутырып килсә дә, яшәү көче, иҗат дәрте ташып тора иде аңарда. Язылып бетеп, җырчыларга тәкъдим итәргә өлгермәгән яңа әсәрләре, ниһаять, «Сөембикә» операсына алынырга әзер булуы турында

сөйләп утырды, үзе белгән авылдашларымның хәл-әхвалләрен сорашты. Тик аңа Апас ягына бүтән әйләнеп кайтырга язмаган икән, ямьле июнь иртәләренең берсендә ул якты дөнья белән мәңгелеккә хушлашты...

Кайгылы хәбәр Апас ягы кешеләрен аеруча тетрәндереп җибәрде. Алар Сара Садыйкованың башкалабыздагы Яңа бистә кызы икәнен белсәләр дә, үзен олылап, гел «данлы якташыбыз» дип йөртәләр иде. Хәзер дә шулай хөрмәтлиләр, җырларын яратып башкаралар. Моның сере, кайберәүләр уйлаганча, мәшһүр композиторның нәсел шәҗәрәләре Тутай, Кызыл Тау авылларына барып тоташу белән генә бәйле түгел. Сара апа балачактан ук әткәсенең туган ягын ихлас күңелдән үз итте, эш сөючән, эчкерсез, мөлаем кешеләрен яратты, шуңа да язылачак җырларына иң матур моң-аһәңнәр эзләп ямьле Зөя, Бола буйларына, әчләренә кереп адашырлык Бакырчы, Кайбыч урманнарына һәм, әлбәттә инде, өянкеле, күл-чишмәле Тау ягы авылларына ашкынып кайта иде.



*Сара Садыйкова 1957 елда*

Сара апаны беренче күрүем һәм аңа карап соклануым мәктәпкә укырга кергәч булды. Ул чакта күршедәге Тутай авылында Ленинның көрәштәше, күренекле революционер Садыйк Әхтәмовка бюст ачу тантанасы оештырдылар. Апастан да, Казаннан да кунаклар күп. Нотык сөйлиләр, шигырь укыйлар, иң популяр җырларны башкаралар. Үзәктә — бик килешле итеп матур күлмәк, ялтыравык, затлы калфак кигән бер апа басып тора. Ул кулын сузып, сәхнә күперчегенә артистларны чакыра.

— Менә Тутайда туып-үскән композитор Сара Садыйкова шушы була инде, — диде әти миңа. — Садыйк Әхмәтовны күреп белгән ул, аңа багышлап өр-яңа җыр язган...

Бу бәйрәм ничек төгәлләнгәндер, анык хәтерләмим, әмма Сара апаның үзен күрү, тын да алмыйча аның җырларын тыңлау иң зур истәлек булып, бүгенгәчә күңел түрендә уелып калган...

Күренекле якташым Сара апа Садыйкова белән очрашулардан алган тәэссорат-хатирәләр күп. Минем өчен алар барысы да якын-кадерле. Әйтик, мәктәп елларында тәүге тапкыр авыл сәхнәсенә менеп, Сара апаның үзе өйрәткән җырларын башкару, аннары, университет студенты булгач, бергәләп «Йөрәкләрдә җыр янара» дигән яңа җыр язу һәм аны зур артистлар Фәйзи Юсупов, Җәвәһирә Сәлахова, Рафаэль Ильясов һәм шагыйрә Гөлшат Зәйнашевалар белән Апас районы авылларында халыкка «тапшырып» йөрү, төрле төбәкләрдә гаҗәеп күпкырлы талант иясе Сара апа Садыйкованың иҗат кичәләрен үткәрү бүген дә әле шул үзенчәлекле, җырга-моңга мәйдан киң булган чорның зур вакыйгаларыннан берседер, дисәм, ялгышмамдыр.

Сәяхәтләрдә Сара апа бик җитез, тәвәккәл һәм һәрчак шат күңелле, шаян иде. Без аңа ияреп йөрсәк тә, булыр-булмас дәрәҗәбезне «төшерүгә» юл куймады ул һәм урынын белеп кенә мактап та ала иде. Берчак поездга утырып Апас-Каратун ягына таба барганда Фәйзи ага Йосыпов, мәшһүр композитор алдында бурычлы булып калмас өчен, махсус «шигырь» язды һәм аны «труппабыз» алдында кычкырып укыды:

Утырабыз да китәбез,
Каратуннарга карап.
Син үлмәсәң, без яшәрбез
Һич картайма, Сара апа!

Мондый шаяруларга остазыбыз, әлбәттә, үпкәләми иде. Бу юлы да елмайды гына. Әнә шул елмаюлары, аерата кешелекле, үтә зыялы булуы һәм гомере буена чын фидакарьләрчә газиз, сөекле халкына хезмәт итүе белән минем һәм милли-

оннарның күңел түрендә иң лаеклы урынны алды ул. Һич шик юк, аның якты образы киләчәктә дә халкыбыз хәтереннән җуелмас...

**Хәлим ГАЙНУЛЛИН, журналист,**
Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министры урынбасары.

## Минем гадәти булмаган пациенткам

Казан каласында яшәүче һәрбер кеше кебек, мин (Казанда 1947 елдан бирле яшим), еш кына татар халкының җырчысы, композиторы Сара Садыйкова фамилиясен ишетә идем. Радиодан аның җырларын тыңлаганым бар, аның иҗат эшчәнлеге турында укыганым да бар иде. Ләкин безнең йөрисе юллар, сукмаклар бергә туры килер дип һич башыма да китерми идем.

1976 елда без яңа квартирага күчтек, күршеләребез Сара Садыйкованың якын кешеләре — кызы (танылган балерина Әлфия Айдарская) белән кияүе (күренекле музыкант Всеволод Грекулов) булып чыкты. Тиз арада без күршеләр буларак танышып, дуслашып та киттек.

1984 елның язында Әлфия Айдарская миңа әнисенең авырып торуы турында әйтте, киңәшләремне сорады. Ул вакытта Сара Гарифовна 2-нче Республика больницасының хирургия бүлегендә ята иде. Авыруны карагач, тикшерү нәтиҗәләре белән танышкач, мин Сара ханымның җитди онкологик авыру белән авыруын, операция таләп ителүен белдем. Сара Гарифовнаны операциягә психологик яктан әзерләү өчен шактый вакыт кирәк булды. Без аңа авыруы турында чын дөреслекне әйтмәдек. Башта киңәшеп сөйләшкәннән соң, кызы Әлфия Газизовнаның әнисенә операция ясарга ризалыгын алдым. Шунысын әйтим, бу эш белән мин үземә икеләтә җаваплылык та алдым. Чөнки, беренчедән, пациент инде шактый олы яшьтә; икенчедән, ул гадәти шәхес кенә дә түгел, ә бөтен татар халкы белә торган, чит илләрдә дә танылган кеше. Декабрь аенда операциягә әзерләгәндә аның түземлегенә, оптимизмына, юморга бай булуына сокланмый мөмкин түгел иде. Тыштан тыныч, сабыр күренә, шаяртып, тапкыр сүзләр әйтә: «Роман Константинович, әгәр дә мин операциядән соң уянмасам, катырак итеп яңакларыма сугыгыз, ныграк итеп борынымнан, колакларымнан тартыгыз!» — ди.

Сара Гарифовна операцияне чын батырларча үткәрде. Хирургик операция әйбәт ясалды, ләкин киләчәккә прогноз ачык һәм аяусыз иде. Операция булып узгач, бер-ике көннән чираттагы визитым белән авыру янына керсәм, исем китте — авыруым башына матур итеп кыйгачлап ефәк яулык бәйләгән, битенә иннек, кершән яккан, елмаеп, көлеп, бик дәртле, канәгать чырай белән ярым утырып каршы ала! Кызы Әлфия Газизовна больницада аның яныннан китмәде, әнисен бик карады. Сара Гарифовна операция аркасында бүленгән эшен больницада да дәвам итте, иҗат белән шөгыльләнде. Ул яткан бүлмә больница палатасына түгел, музыкаль лабораториягә охшыйрак төшә иде, һәркайда музыкаль язмалар, ноталар. Янына гел сәнгать кешеләре: композиторлар, музыкантлар, җырчылар, язучылар, журналистлар, дуслары, якыннары килеп тордылар, аның палатасындагы өстәлдә һәрвакыт тере чәчәкләр булды.

Өч атна үткәч, без аны больницадан чыгардык, ул үзенең гадәти тормышына чумды, иҗаты белән шөгыльләнә башлады. Без телефоннан гел сөйләшеп, киңәшеп тордык. 1985 елның май бәйрәме алдыннан мин аңардан күңелне тетрәтерлек котлау хаты алдым. Хатында шундый юллар бар иде: «...Илләребез тыныч булсын, халкыбыз сугыш күрмәсен, ә Сез, Роман Константинович, әле һаман солдат, фронттагы кебек солдат, Сез Кеше тормышы өчен көрәшәсез. Димәк, Сез җирдә тынычлык өчен, бәхет өчен көрәшәсез. Сезнең алда баш иям! Рәхмәт Сезгә! Мин әле өйдә утырам, беркая чыкмыйм, музыка язам... 9 майда радио аша минем «Мин ышанам — сугыш булмас» дигән яңа җырым яңгыраячак, бәлки, тыңларсыз?.. Мин дә солдат, мин дә тынычлык өчен көрәшәм. Ләкин миңа аяклар шешенә...»

Берничә айлар вакыт үтте. Сара Гарифовна миңа өйгә шалтыратты, кәефенең шәп түгеллеген әйтте, кереп чыгуымны үтенде. Мин килеп кергәч, ул бик шатланды. Ләкин аның авыруы турында сөйләгәннәре мине бик борчуга салды. Мин аны

карадым һәм аңладым, гомере бик чикле калган... Сәламәтлеге начарлана барса да, ул үзен батырларча тотты, һаман иҗат белән шөгыльләнде, хәтта концертларда катнашып сәхнәләргә чыкты. Кызганычка каршы, 1986 елның апрелендә ул үзен бик начар хис итә башлады, без аны янадан больницага салырга мәҗбүр булдык. Аның тормышын озайту өчен бөтен булган мөмкинлекләрне файдаландык. Ләкин, нишлисең, ачы хакыйкать — кеше гомере чикле... Гомеренең соңгы көненә кадәр ул бирешмәде, төшенкелеккә бирелмәде, зур планнар корып, зур фикерләр уйлап яшәде.

**Роман ХАРИТОНОВ,**
хирург-онколог.

## Беренче адымыма булышты

Сара Садыйкова исеме минем күңелемә кече яшьтән үк үтеп керде. Чөнки аны һәр татар гаиләсендә беләләр иде.

Театрдагы беренче адымнарым да аның исеме белән бәйләнгән. Әйе, ачыграк итеп әйткәндә: Хәй Вахитның «Кияүләр» исемле музыкаль комедиясенә Сара апа бик әйбәт музыка язган иде. Бу әсәрдә миңа да бер роль бирделәр. Һәм Сара Садыйкованың сихри музыкасы миңа сәхнәдәге беренче ролемне уйнарга, таләпчән тамашачы каршындагы имтиханны уңышлы узарга булышты.

Ә инде Сара Садыйкованың җырларына килсәк, ул көйләрне колоратур борылышлар белән баетырга, бизәргә ярата иде. Аның М. Хөсәен сүзләренә язылган «Вальс турында вальс»ы да әнә шуңа бер мисал булып тора. Бу әсәр әзер булгач, без аны ничек башкару турында да киңәштек. Сара апа әсәрне Штраус вальслары рухындарак башкарырга киңәш бирде. Мин шулай эшләдем дә. Нәтиҗәсе дә әйбәт кенә килеп чыкты шикелле.

Тагын бервакыт мин Сара апага С. Рахманиновның «Монда шундый рәхәт» романсын җырлап күрсәткән идем. Ул аңа бик тә ошады һәм Сара апа шуннан рухланып, дәртләнеп китеп «Болыннарда икәү йөргән идек» романсын язды (С. Шакир сүзләре). Гомумән, романс жанры аңа җиңел бирелә иде. Аннары шунысын да басым ясап әйтергә кирәк: кайсы гына жанрда иҗат итсә дә, Сара Садыйкова әсәрләренә иң хас булган бер сыйфат, ул — моң, моңлылык.

**Зилә СӨНГАТУЛЛИНА,**
Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы.

## Сара Садыйкова феномены

Сара ханым Садыйкова турында истәлекләр аз язылды диеп булмый. Чыннан да, ул менә дигән артистка, җырчы, музыкант иде. Бик тә кызыклы, һич кабатлана алмый торган шәхес иде ул.

Ләкин хәзер, минемчә, композитор буларак Сара Садыйкова феномены турында язар вакыт җитте. Татар халкының иң яраткан композиторы булып танылырга аңа нәрсә ярдәм иткән соң? Ул иҗат иткән көйләрне халык ни өчен аеруча якын итә?

Бу сорауга мин үз җавабымны биреп, үз карашымны билгеләп карыйм әле.

Утызынчы-кырыгынчы елларда Татарстанда яңа бер буын иҗат интеллигенциясе үсеп җитә — алар Мәскәүдә укып белем алалар, урыс һәм көнбатыш Европа мәдәнияте традицияләрен үзләштерәләр. Алар арасында Сара Садыйкова да була. Ул 1922—28 елда Мәскәү консерваториясендә, ә инде 1934—39 елларда татар опера студиясендә укый.

Менә шушы елларда яшь кыз җанында югары театраль тәрбия, көчле фантазия һәм тумыштан килгән музыкальлек — өчесе бергә нечкә үрелә һәм тора-бара аның үзенең дә көйләр чыгарасы килә башлый. Әлбәттә инде, ул елларда бөтен СССР халкы җырлаган жанрларда һәм формаларда. Татар милләте өчен әле яңа булган вальс һәм танго жанры аеруча активлаша. Мин инде бер(е)дә Сара

Садыйкованың бу төр иҗатта беренче булып баруын әйтеп тормыйм, мин башкасын — җыр жанрында Көнбатыш һәм Көнчыгыш традицияләренең нечкә үрелүен генә әйтергә телим.

Тагын бер үтә мөһим нәрсә: үзе бик тә эмоциональ һәм музыканы тирәннән тоючы кеше буларак, Сара ханым үзенең әсәрләрендә татарның иң чын, иң халыкчан көйләренә хас булган төп сыйфатны — моңны саклап кала алды. Татар җырының җаны булган әнә шул олы хәзинәне нечкә чагылдыра алды. Ә бит «моң» дигән әлеге асыл сыйфатка югары музыкаль белем алып кына ия булып булмый. Хәтта әле укыганда Көнбатыш традицияләре тәэсирендә киресенчә дә килеп чыккалый: уку дәверендә еш кына талантлы гына иҗатчыларның да әнә шул моңлылыгы югалып куя торган була.

Ә Сара ханым Садыйкова уку дәверендә үзенең моңлылыгын саклап кала алды. Көнбатышның жанрларын һәм формасын Көнчыгыш традицияләренә буйсындыруга иреште. Ул үз иҗатында Шәрык кызы, чын татар кызы булып кала алды.

Сара ханым Садыйкова феноменын аңлау өчен тагын Көнбатыш җыр сәнгате белән Көнчыгыш җыр сәнгате (ике төрле музицирование) арасындагы аерманы белү, тою да кирәк.

Көнбатышның халык музыкасында аерым аваз үзе артык мөһим түгел, ул тембры ягыннан әлләни матур булмаска да мөмкин — бары тик нота төгәл һәм тигез ишетелсен генә. Бирeдә тавышларның дөрес тәңгәллеге, янәшәлеге мөһим. Мәсәлән, Балтыйк буе халыкларының күп тавышлы җырларында шулай.

Ә менә Көнчыгыш музыкасында исә авазның, аның сыйфатының, ул авазның мәгънәви һәм эмоциональ тулылыгының әһәмияте — гаять зур. Мелизмнар, мордентлар, тремоло ярдәмендә аваз аз гына үзгәрсә дә; күтәрелү яисә түбәнәю ягына таба бераз гына тонның «саф»лыгы кимесә дә, аваз бераз гына «уйнап» алса да — менә болар һәммәсе көйнең асыл мәгънәсе белән бәйле була. Шулай итеп, авазның үзендә үк «музыкаль информация» салынган. Көйнең музыкаль байлыгы һәм тулылыгы — Көнчыгыш музыкасы өчен (һәм шул исәптән татар җыры өчен дә) — аның иң зур кыйммәте, хәзинәсе.

«Музыкаль авазның, көйнең матурлыгын нечкә тою» дигән әнә шул мөһим сыйфатны Сара Садыйкова үз иҗатында ахыргача саклап кала алды.

Тагын бер фикер.

Гомеренең соңгы елларында Сара ханым опера язу турында хыялланды, миңа үзенең бу юнәлештәге уй-ниятләрен сөйләде, «икәү бергә эшлик әле» дигән чаклары да булды. Шуңа күрә, тәмамланып бетмәгән җырларын тәмамлауны үтенсә — мин моңа һич тә гаҗәпләнми идем. Мин аның дүрт җырын эшләп бетердем һәм әле күптән түгел аның тагын ике гүзәл көен алдым. Аларны берничә мәртәбә җырлап чыктым, уйнап алдым, аларның «эченә кердем». Һәм шуны аңладым: бу көйләр бик тә матурлар! Хәзер инде аларга бары тик талантлы һәм сизгер башкаручы гына кирәк!

**Леонид ЛЮБОВСКИЙ,** композитор,
Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе.

## Сара апаны сагынабыз

Халкыбызның сөекле композиторы Сара апа Садыйкова иҗаты белән мин беренче тапкыр Бөек Ватан сугышы елларында фронтта таныштым.

1944 ел иде. Ватан сугышының авыр чоры. Безнең гаскәрләр фронтларда фашистлар белән каты сугышлар алып баралар.

Мин, 19 яшьлек сугышчы, яраланып хәрәкәттәге армия госпиталендә ята идем.

Шулвакыт госпитальгә яраланган бер яшь лейтенантны китерделәр. Ул безнең Татарстан егете иде. Фронтта якташымны очрату — зур бәхет бит ул.

Без госпитальдәге яралы татар сугышчылары аның яныннан китмибез, туган як турында сөйләшәбез. Лейтенантның Татарстаннан китүенә берничә ай гына, ә безнең күбебез 2—3 ел фронтта, туган якларны бик сагынганбыз.

Лейтенант музыка һәм әдәбият сөюче дә икән. Кичләрен ул безгә үзенең моңлы тавышы белән әкрен генә җырлый. Туган як көйләре ничек сагындырган!

Яраткан көйләребезне берничә тапкыр җырлатабыз, үзебез дә кушылып җырлыйбыз.

Беркөнне лейтенант без беркайчан да ишетмәгән яңа җыр җырлады:

Син кайларда йөрисең икән
Алтыным, көләч йөзле иркәм...

дип башлана иде ул җыр.

Барыбыз да сихерләнгән кебек тынып калдык. Ниндидер илаһи моң, йөрәк өзгеч сагыну һәм шул ук вакытта яшәргә, туган якларга, сөйгәннәр янына әйләнеп кайтуга ышаныч, өмет яңгырый иде бу җырда.

Моңы йөрәкләргә үтеп керә, күңелнең иң нечкә кылларын чиртә. Әйтерсең, безгә сөйгән кызларыбыз, яраткан хатыннарыбыз, сөекле әти-әниләребез һәм сеңелләребез эндәшә:

Кайтырсың дип мин өмет итәм,
Мин сине һаман көтәм, көтәм...

Безнең якыннарыбыздан аерылуның сәбәбе — сугыш. Шуның аркасында менә күпме айлар, еллар без фронтларда газап чигәбез, ә илдә якыннарыбыз авыр шартларда яшиләр. Безнең илгә кайту тик явыз дошманны җиңгәннән соң гына мөмкин булачак. Димәк, җиңүне тизләтергә кирәк. Җыр шуңа өнди:

Синнән башка бер ямь юк миңа,
Син кайтмасаң бәйрәм юк миңа.
Таң балкуы кебек кайт, иркәм.
Мин сине көтәм, көтәм, көтәм!..

Соңгы куплетны барыбыз да аяк өсте басып, култык таякларына таянып, сүзсез генә тыңлыйбыз. Һәркайсыбыз эчтән: «Без кайтырбыз, кайтырбыз» дип ант итә. Лейтенант аптырап кала:

— Әллә ошамадымы? — ди.

— Искиткеч! Их, җырлыйсың да соң! — дибез бер-беребезне бүлеп.

— Бу яңа көй, аны композитор Сара Садыйкова, сүзләрен Әхмәт Ерикәй язган, — ди лейтенант кечкенә блокнотына карап.

— Нинди матур көй! Үзәкләргә үтә... — диешә-диешә яралылар лейтенантны кабат-кабат җырлаталар.

Сүзләрен аңламасалар да, көйне башка милләттән булган яралы сугышчылар да ошаттылар.

— Бу нинди матур җыр? Тәрҗемә итегез әле, — диләр. Аны болай тәрҗемә иттек:

Где теперь ты ходишь, мой родной,
Золотце мое, мой дорогой.
Я надеюсь, ты придешь ко мне,
Жду тебя скучая и любя...

Җырның русча сүзләре иптәшләргә ошады. Инде җырны бөтен палаталар белән, башка халык җырлары белән берррәттән, җырлый башладык. Күп тә үтмәде, без савыгып, фронтның алгы сызыгына киттек.

Ә сугыш беткәч исән калганнарыбыз төрлебез төрле якка таралыштык.

Сугыштан соң шәһәр һәм авылларда җыр-бию кичәләре оештырыла, аларның берсе дә Сара апа Садыйкованың халык арасында «Татар тангосы» дип йөретелгән бу мәшһүр җырыннан башка үтми иде.

Сугыш беткәч мин Уралда, аннан соң күп еллар Татарстан Министрлар Советының мәдәният һәм социаль учреждениеләр бүлегендә эшләдем. Хезмәтем буенча республиканың мәдәният-сәнгать хезмәткәрләре белән аралаша идем. Сара апа Садыйкова белән шушы вакытта танышып, күп еллар дуслашып яшәдек. Ул үзенең иҗат эшләре буенча миңа еш кына телефоннан шылтырата, очрашканда мәдәният-сәнгать мәсьәләләре буенча фикер алыша идек.

Сара апа гомер буе татар халкы мәдәнияте-сәнгатен үстерү өчен янып яшәде, бик күп әдәбият-сәнгать әһелләре аның якын танышлары-дуслары иде, аларның иҗат уңышларына ул чын күңелннән шатлана, аларга нинди генә булса да ярдәм күрсәтергә тырыша иде.

Ә җырчылар — аның якын дуслары-сердәшләре, аларның һәр уңышына ул шатланып бетә алмый иде. Бервакыт ул миңа:



11*

— Искиткеч матур тавышлы Зөһрә Сәхабиева җырлый башлады, киләчәктә ул безнең йолдызыбыз булыр. Шунсы да шатлыклы — Зөһрә һәм Хәйдәр Бигичев дуслаштылар. Икесе дә — талантлы, акыллы. Ходай Тәгалә аларга исәнлек, бәхет бирсен. Шундый ук шатлык хисләрен ул Зилә Сөнгатуллина, Зөһрә Шәрифуллина турында да куанып сөйләгән иде.

Ул үз әсәрләрен җырчыларның тавышын, башкару сәләтләрен белеп яза иде. Тәүге җырларын безгә пианиносында уйнап күрсәткәндә:

— Бу җыр — Илһам Шакиров, бусы Зиннур Нурмөхәммәтов башкаруында матуррак булыр,— дияр иде.

Без Сара апа белән галим-фольклорчы, татарча җыр китаплары төзүче Илбарис Надиров, журналист Гарәф Шәрәфетдинов гаиләләре белән бәйрәм мәҗлесләрендә очраша идек. Сара апа пианинода уйнап, яңа җырларны җырлап безне сокландыра иде.

Без Сара апа белән күрше йортларда яшәдек, бик еш бер-беребезгә кереп йөри идек. Бервакыт хатыным Әминә белән (ул — врач, Сара апа белән бик дус яшәделәр) Сара апага керсәк, кунакта Гомәр ага Бәширов белән чәй эчеп утыралар. Сара апа:

— Минә дусларым, сезгә Гомәр ага сүзләренә язган яңа җырымны пианинода уйнап, җырлар күрсәтәм,— дип, «Җидегән чишмә» җырын җырлады. Җыр безгә бик ошады, Гомәр агага:

— Романыгыз халкыбыз укучыларының гомер буе яратып укый торган романы булса, «Җидегән чишмә» яратып җырлый торган җыр булыр,— дип, Сара апа өчен дә, Гомәр ага өчен дә шатландык. Бу җыр, чыннан да, шулай булып кала.

Сара апа — үзенең онытылмас иҗаты, халкыбыз яраткан җырлары белән гомергә безнең күңелләрдә.

Аның иҗатын мәңгеләштерү турында практик эш башларга вакыт җитте. Иң беренче — Сара Садыйкова музее турында. Инде кайбер экспонантлар да бар — аның яраткан пианиносы һәм өй әйберләре.

Сара апа иҗаты турында бездә, аның дуслары һәм якыннарында бик күп әйберләр (фотолар, магнит тасмалары һ. б., һ. б.) бар, алар җыелып, фәнни анализ ясалып халыкка җиткерелсә иде.

Музей Сара Садыйкова исемен йөретсә дә, хәзер онытыла барган татар халкының сәнгать йолдызлары — З. Басыйрова, Г. Кайбицая, Р. Кушловская, Г. Сөләйманова, В. Шәрипова, Р. Ибраһимова һәм башка хатын-кыз талантларыбызны халык күңелендә мәңгеләштерүгә хезмәт итәр иде. Татарстан хөкүмәте һәм башкалабыз Казан музей өчен бүлмә табар дип ышанабыз.

Сара апа Садыйкова гомере буе Казанда халыкка тугры хезмәт итте, татар халкының сөекле композиторы булып танылды. Казан каласының бер мәйданында матур итеп ясалган Сара Садыйкова һәйкәле булыр дип өмет итәбез.

Сара апа Садыйкова вафатыннан соң шактый вакыт узды, аның исемен йөреткән урам, концерт залы һаман да булмау аңлашылмый. Матбугатта күпме Казан урамнарының Татарстанга, халыкка, тарихка бер төрле дә катнашы булмаган шәхесләр исемен йөртүләре турында күп язылды инде. Татар халкының сәнгать йолдызы Сара апа Садыйкова халык өчен шатланып иҗат иткән. Казанның ул йөрегән урамнарының берсе аның исемен йөртергә тулы хакы бар дип ышанабыз.

**Рифкать ИСМӘГЫЙЛЕВ,**
Ватан сугышы ветераны, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

## Әнием турында

**1939** ел. Минем Ленинград хореография училищесында укып йөргән чагым. Көннәрдән бер көнне әнием Сара Садыйковадан хат килеп төште. Ул анда бик тә шатланып үзенә Татарстан Республикасының атказанган артисты исеме бирелүен хәбәр итә һәм инде хәзер бу югары дәрәҗәне аклау өчен тагын да тырышыбрак эшләргә, иҗат итәргә кирәк булачагын яза иде.

Билгеле, ул чакта мин үземнең яшь акылым белән әни тормышындагы бу олы вакыйганы бик үк аңлап, чын-чынлап төшенеп тә бетермәгәнмендер. Менә хәзер генә искә төшереп утырам.

Ә бит инде ул сугышка хәтле үк, дөрестән дә, танылган артистка иде. Илнең бик күп урыннарында булган иде инде ул. Аны Мәскәүдә дә яхшы белгәннәр, ул Зур театр сәхнәсендә һәм Бөтенсоюз радиосында җырлаган. Буш вакытларында шагыйрь В. Маяковскийны тыңларга чапкан, режиссер Г. Станиславский белән аның өендә һәм театрда күп мәртәбәләр очрашкан. Еш кына аны «татарның сандугачы» дип йөрткәннәр. Әнием 1928 елдан бирле үк Муса Җәлил белән дә таныш була, шагыйрь әнием башкаруында татар һәм башкорт җырларын тыңларга яраткан.



*Сара Садыйкова сиксәненче елларда*

Әниемә гаять зур бәхет — татарның профессиональ музыка сәнгате туу процессында катнашу бәхете насыйп булган. Ул үзе дә сәнгатьнең өч тирәндә җигелеп тарта: башта Мәскәүдә, аннары Казанда драма театрында артистка була һәм Тажи Гыйззәт, Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев кебек корифейлар белән бергәләп, алар язган әсәрләрдә бер-бер яртлы яңа образлар иҗат итә; аннары ул опера һәм балет театры җырчысы була, беренче татар операларында җырлый (аның тавышы лирик-колоратур сопрано була), хәтта беренче татар операсы «Сания»дә аның тавышы өчен махсус язылган була. Бу хакта Фатих Әмирхан болай дип яза: «Сания» операсындагы төп рольне С. Габәши С. Садыйкованың чылтырап аккан чишмәдәй саф тавышын күздә тотып иҗат итә. Яшь җырчы Казан тамашачылары алдында зур сынауны бик уңышлы үтә, сәнгать сөючеләрнең күңелендә истә калырлык гүзәл кыз Сания ролен тудыра».

Һәм, ниһаять, әнием иҗат иткән өченче тармак: ул халыкның яраткан композиторы иде, безнең милләттә беренче булып ул танго, фокстрот, блюз стилендә җырлар язды, үзенең соңгы сулышына кадәр бу эштән аерылмады.

Сара Садыйкова — милли музыкага муеныннан гашыйк кеше иде. Ул әдәбият-сәнгать эшлеклеләрен халык иҗатын өйрәнергә, милләтнең үткәнен, тарихын белергә үгетли иде. Шуның белән бергә әнием яшь талантларга да ярдәм итте. Мисал өчен, җырчы Фәхри Насретдинов һәм Габдрахман Хәбибуллин сәнгать дөньясына тәүге адымнарын атлаганда әнинең ярдәмен тоялар. Яшьрәк буын вәкилләре арасында да мондыйлар күп.

Әйе, Сара Садыйкованың татар җыр сәнгате өлкәсендә зур шәхес булуы инде бәхәссез хакыйкатькә әверелде. Бүгенге татар эстрадасына да аның иҗатының тәэсире бик зур. Үзенең 65 елга сузылган иҗади гомерендә әнием иҗат иткән көйләр хәзер татар халкының күңел байлыгына әйләнделәр.

Менә шуларның барысын да искә алып һәм тагын озаклапмый Сара Садыйкованың тууына 100 ел тулачагын да күздә тотып, хәзер аның исемен онытмау максатында түбәндәге эшләрне эшләргә иде:

1. Татар эстрада җырларының Сара Садыйкова исемендәге конкурсын оештырып җибәрергә.
2. Башкалабыз Казан шәһәренең үзәгендәрәк аның исеме белән берәр урамны атарга иде. Әниемнең Казан турындагы җырлары да шактый бит.
3. Казанда аның музеен булдырырга иде.
4. Аның музыкаль мирасын пропагандалау максатында моңа кадәр басылмаган җырларын дөнья күрсәтергә иде, элек басылганнарын яңадан бастырырга иде.
5. Халыкның яраткан композиторы Сара Садыйковага һәйкәл куюны да, ниһаять, тормышка ашырасы иде инде.

6. Элегрәк басылган «Сагыналар сине якын дуслар...» дигән истәлек китабын урыс телендә дә чыгарасы иде. Яшь буын һәм бүтән халыклар да аның турында белсеннәр иде.

**Әлфия АЙДАРСКАЯ.**

## И язмыш, язмыш...

Талантларыбызның кадерен белергә без кайчан өйрәнербез икән соң? Җәмәгатьчелек Сара апаны элек-электән чын композитор, профессиональ композитор итеп кабул итте, аның җырларын татар яшәгән күпме төбәкләр өзмичә-куймыйча җырлады, тыңлады. Әмма «махсус югары белеме юк» дигән булып аны Композиторлар берлегенә озак еллар буе кабул итмәделәр.

Менә минем кулда шундый бер белешмә, архив белешмәсе. Ул ничек язылган булса, мин аны шул рәвешле, урысча китерәм.

**«Архивная справка.**

**В документальных материалах архивного фонда Московской государственной консерватории им. П. И. Чайковского имеются записи, свидетельствующие о том, что гр. Садыкова Сара Гарифовна обучалось в техникуме при Московской государственной консерватории на отделении «Хоровая специальность с правом сольного пения» у проф. Цебушенко М. Г. с 1922 года по 1928 год.**

**Основание: 1. Личное дело студента музыкального техникума при МГК Садыковой С. Г. с 1922 г. по 1928 г.»**

Әле күптән түгел табылган икенче бер таныклыкның күчермәсе белән дә танышып үтик.

**«Всесоюзный комитет по делам искусств при СНК Союза ССР. Московская государственная консерватория. Татарская Оперная Студия. Свидетельство. Настоящее свидетельство выдано тов. Садыковой Саре Гарифовне в том, что она вступила в Татарскую Оперную Студию при Московской государственной консерватории в 1934 году и за время прибывания в ней музыкально приготовила следующие партии** (монда аның кайсы партияләрне башкаруы әйтелә — (Ә. Х.).

**Выпускную работу по специальности сдала 30 ноября 1938 г. с оценкой «отлично». На основании всего вышеизложенного тов. Садыкова Сара Гарифовна считается окончившей курс Татарской Оперной Студии при Московской государственной консерватории с общей оценкой «отлично». Специальной комиссией тов. Садыкова С. Г. признана пригодным для оперной сцены на партии первого плана. 22 декабря 1938 г.».**

Менә шундый хәлләр. Ә бит безнең кулда әле тагын Сара апаның үз хаты да бар: «Я обращаюсь в высший партийный орган... с просьбой, даже с мольбой (я доведена до этого) помочь мне найти правду, помочь мне встать на ноги, восстановить мои права; права деятеля искусств...»

И язмыш, язмыш... Үз халкының сөеклесе булган, шушы халыкка нинди гүзәл моңнар бүләк иткән, аның кайгысын-шатлыгын җырлары белән уртаклашкан Сара апа яза бит шундый аянычлы-рәнҗүле сүзләрне.

Чын иҗат кешесе, үз заманына, үткәнгә һәм киләчәк көнгә хезмәт итүче буларак, (табигатьтән шундый фал салынышмы) үз заманының хакимияте белән каршылыкка да керә. Хәтта җәмгыятьнең үзе белән дә каршылыкта яшәргә мөмкин ул. Үз сүзен, үз иҗатын раслау өчен ул барлык киртә-каршылыкларны җиңеп узарга тиештер инде. Әнә шул чакта хакимиятнең һәм җәмгыятьнең сине тануы да кирәк бит әле...

Менә минем алда тагын бер документ — Сара Садыйковага Татар опера студиясе тарафыннан 1934—35 елларда «Лучший ударник учебы» булганы өчен бирелгән Мактау кәгазе.

Әнә шулай үзен һәрчак раслап-дәлилләп яшәргә күнеккән Сара апа музыкада да иң яхшы ударник иде шул. Әмма шунысы бар: кемнедер башта хакимият

«таный», шуннан соң гына аны халыкка тарата-таныта башлыйлар. Ә менә Сара Садыйкованы иң башлап халык таныды. Үз кызы, артисткасы һәм композиторы итеп таныды...

Бездә җырлар язган бик күпләрне гел-гел «үзешчән композитор» дип кенә атап килделәр. Имеш, чын композитор булу өчен югары белем кирәк, симфоник әсәрләр язу кирәк! Ә менә Сара апаның бер җыры үзе бер симфоник әсәр булырлык! Татарның беренче тангосы «Син кайларда йөрисең икән»не генә алыйк. «Җидегән чишмә»сен, «Беренче мәхәббәт»ен генә алыйк! «Өченче көн тоташ кар ява» дигән тетрәндергеч җыр турында уйланыйк! Мондый музыканы иҗат итү өчен, мөгаен, сугыш-фронт дәһшәтләрен, коточкыч фаҗигаләрне үз күзең белән күрү кирәктер. Йә булмаса, Ходай биргән чиксез сиземләү-тоемлау хисе, чынлап күзаллау мөмкинлеге, кабатланмас сәләт булырга тиештер. Биргән Ходай, биргән Сара Садыйковага боларның барысын да!

Ә нинди эшчән, хезмәт сөючән, мәңге ару-талуны белмәс, армас-ялыкмас кеше иде бит Сара апа! Менә аның М. Горький исемендәге клубта халык хорын җитәкләгән чагындагы бер эш планы:

1. Хор белән эшләү;
2. Солистлар белән күнегүләр;
3. Концертлар кую мәсьәләсе.

Бер кичтә, бер көндә эшләнәчәк эшләр планы бу. Хордагы һәр кеше белән, көнен-сәгатен билгеләп, аерым шөгыльләнгән ул. Мондый тыгыз-киеренке эш планын, мөгаен, шул заманның иң фидакарь, иң талантлы тел-әдәбият укытучысы да төземәгәндер! Флёра Сөләйманова, Зөһрә Сәхабиева, Шамил Әхмәтҗанов, Рабига Сибгатуллина, Рәгъде Халитов, Мәсгудә Шәмсетдинова, Алмаз Имаев — менә бу талант ияләре барысы да Сара апада укыган, аның рухи мәктәбен үткән кешеләр.

Шагыйрьләр, җыр текстлары авторлары белән эшләве, эшли белүе ифрат үзенчәлекле иде Сара апаның. Ул шигырьдәге һәр сүзне, мәгънәле-моңлы сүзне тирәнтен тоя иде. Әле менә барлап, санап чыктык — ничәмә-ничә авторның сүзләренә җыр язган икән?

Менә бу язмама да мин композиторның Сибгат Хәким сүзләренә иҗат иткән җырыннан исем алып куйдым. Сибгат ага үзе исә бер мәкаләсендә «Җидегән чишмә» турында яза. Сара апаның Гомәр Бәширов шигыренә язылган бу җырын ул да чын йөрәктән кабул иткән: «Сүзләр табылган, халыкчан сүзләр. Шул сүзләргә кемдер канатлар куярга тиеш бит әле. Андый кеше — Сара Садыйкова. Нинди бәхетле очрашулар. Композитор Сара Садыйкова — борынгы халык моңнарының бүгенге яңгырашы. Ике өлкән буын кешесе борынгы моңнарда очраша. Үзем дә җыр күп яздым. Андый сихри мизгелләр сирәк була иҗат тормышында. Җырның җыр булып яңгыравы өчен өченче кеше кирәклеген мин күптән беләм. Моңнар дәрьясы эченә җырчы алып керә...»

Халык моңнары дәрьясы... Сара апа халык сүзләренә генә дә ике дистәдән артык җыр язган!

«Актаныш таңнары»н, «Әй ямьле син, Минзәләм ягы»н, «Казан кичләре»н, «Чирмешән»не, «Арча кичләре»н, «Татарстан минем республикам»ны искә алыйк. Республикабыз төбәкләре турында гына да берничә дистәдән артык җыр язган икән ул! Ә бит аларны, Мостафа Ногман белән икесен, авыл саен җыр язасыз, дип, тиргәделәр. Хәзер генә ул, әнә, тиргәүче юк, дигәндәй, авылларга багышлап «коммерческий» җырлар язып кына торалар. Ә бит Сара апа колхоз-совхозлардан акча «каерыр» өчен язмый иде, туган туфракка, туган халкына үз ягы турында җыр бүләк итә иде ул. Аның бу туган җиргә мәхәббәте, халыкта аңа мәхәббәт тәрбияләве үзе бер батырлык-фидакарьлек!

Сара Садыйкованың гаҗәеп бер сыйфатына — югары кешелеклелек сыйфатына игътибар итик әле. Сез карагыз аның нинди авторлар белән эш иткәнлеген! Мостафа Ногман, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Гөлшат Зәйнашева, Гамил Афзал кебек олпат әдипләр белән иҗатта да, тормышта да якыннан аралашкан бу композитор йөздән артык авторның шигыренә җырлар язган бит. Яшерен-батырын түгел, кайберәүләр, кем әйтмешли, «однолюб» булалар бит: бер композитор, бер шагыйрь белән үзара дуслашып ала да, тотыналар бер-бер артлы җырлар чыгарырга! Ярый ла, бу иҗат дуслыгы кабатлауларга китереп җиткермәсә. Ә бит күп очракта иҗат очышы тумый кала, кабатланган хисләр-төсләр күбәя. Сара Садыйкова исә эреләнмәде дә, вакланмады да — гел үзе булып калды, эзләде, тапты. Яшь авторлар арасыннан да тапты ул шигырь-җыр сүзләрен. Әле моңарчы беркайда да шигырь бастырмаган, каләм тибрәтеп

кенә килгән яшьләр-өлкәннәр арасыннан да тапты. Күңел киңлеге! Аның саекмас чын моң чишмәсе әнә шуннан да киләдер!

Тагын шул «үзешчән»лек турында бер сүз. Чөнки бу сүз аркасында күпме талантлы композиторларыбыз иза чикте. Фәтхерахман Әхмәдиев та әнә шуларның берсе иде.

Әле композитор Риф Гатауллин белән дә шул хакта сөйләшеп тордык. Ул үзе дә бу изаларны чикте, укып чыкты, композитор буларак танылды. Әмма Риф үз «үзешчән»нәрен ташламады, аларны үз янына туплый белде. «Безнең музыка белгечләре халык җырларын иң югары сыйфатлы җырлар рәтенә куярга ярата,— диде Риф.— Ә бит нәкъ менә шул җырларны — халыкның аһын-гамен, телен-моңын саклый торган җырларны — халык арасыннан чыккан «үзешчәннәр» язган...»

Хәер, хәзер әлеге «япон тактасы» дигән техника заманында көй-җыр чыгаручыга җиңелрәктер дә... Ләкин Сара апалар заманында...

Кайчак Сара апаның җырларын һәм бүгенге концертларның репертуарын чагыштырып карыйм.

Сүзләре дә, көе дә артык сай булган көйләр менмәдеме безнең бүгенге сәхнәләргә? Ни гаҗәп, бүген Заһид Хәбибуллин, Рөстәм Яхин, Җәүдәт Фәйзи, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов һәм Хөснул Вәлиуллин көйләре бик сирәк яңгырый. Хәтта Салих Сәйдәшевны да ишетмибез! Өч-дүрт сәгатьлек концертны тыңлап-карап чыгасың, ә күңелдә, җанда — бушлык. Үзең дә буш чыгасың, күңелдә калырлык көй дә юк...

Сара Садыйкованың мирасын барлау, туплау, өйрәнү — безнең намус эше. Ул үз-үзен һич җәлләмәде һәм без дә аңа мәңге бурычлы.

Сара апаның Казанда үз музее, үз урамы, үз һәйкәле булсын иде. Ул заман белән бергә яшәде, бүгенге заман да аны сакларга, аның кадерен белергә тиеш!..


Татарстан телевидениесенең Сара Садыйкова иҗатын-мирасын барлауда, туплауда зур эш башкаруын билгеләп, әйтеп үтәсем килә. Дөрес, моңарчы да Сара апаның җырлары радио һәм телевидениедә еш яңгырады. Һәм менә «Татарстан» телерадиокомпаниясе Сара Садыйкова турында документаль фильм, ә ул йөргән төбәкләр-районнар, аның җырлары багышланган яклар турында истәлек — «Моңнар дөньясына сәяхәт» дигән фильм әзерли. Режиссеры — Идмас Үтәганов. Сценарий авторы — Гөлшат Зәйнашева. Директоры — мин фәкыйрегез.

Документаль фильмның исемен дә без әнә шулай «Моңсара» дип куярга булдык. Әлбәттә, кино хәтле кино төшерү бу заманда бик четерекле эш. Сүз монда документлар туплау, архивларда казыну турында гына бармый, эш әлеге дә баягы, чыгым мәсьәләсенә килеп тоташа. Әгәр дә Сара Садыйкова турындагы бу фильмга, аның дөнья күрүенә битараф булмаган кешеләр табылса, үзләреннән хәл кадәри матди ярдәм кылса, бик тә игелекле эш эшләнер — фильмны тизрәк өлгертер идек!

**Әзһәр ХӨСӘЕНОВ.**
Сара Садыйкованың мәдәни-хәйрия вакыфы рәисе.

# ИГЕЛЕКЛЕ ТАЛАНТ

(РӘССАМ РУШАН ШӘМСЕТДИНОВКА — 50 ЯШЬ)



Халкыбызның мәдәни тормышында үз урынын алган, аның ихтирамын яулаган, киң даирәгә танылган шәхесләр бар. Алар — безнең милли горурлыгыбыз. Күренекле рәссам Рушан Шәмсетдинов — әнә шуларның берсе.

Рушан Галәф улы Шәмсетдинов 1946 елның 25 ноябрендә Казан шәһәрендә дөньяга килә. Элгәреге заманнарда ук атаклы зыялыларыбызның гамәлләре-эшчәнлекләре белән тыгыз бәйләнгән, халкыбыз тарихының аерылгысыз өлеше буларак танылган Татар бистәсенең борынгы урамнары, йортлары гасырлар дәвамында милли вәзгыятьне, рухны саклаулары белән кечкенә Рушанның нечкә күңеленә дә көчле тәэсир ясый. Ул үз йортларыннан ерак булмаган Мәрҗани мәчете манарасының кичке шәфәкъта алсулануын күзәтә, еш кына Кабан күле буена чыгып утыра, бертуган абыйсы Инар белән әбибабалары каберләрен зиярәт кыла, ара-тирә чал Кремль диварлары буена барып чыга, Сөембикә манарасына текәлә. Аны кызыксындырган сораулар арта, уйлары куера бара: «Элегрәк Казан нинди булган? Йөз, ике йөз... җиде йөз еллар элек? Ул туган йорт нигезендә кемнәр яшәгән? Кабан күле нинди серләрне саклый? Борынгы бабаларның шөгыльләре, кылган гамәлләре нинди? Их, бер генә минутка булса да шул чорларга барып кайтырга! Кайткач, күргәннәрең турында сөйләргә... Юк, сөйләгәнне бит күреп булмый, ул дәверне ясарга иде! Әйе, ясарга, рәсемгә төшерергә!»

Тиктормас малай үз хыялларына гына бикләнеп ята аламы соң? Юк, әлбәттә. Сораулар әти-әнигә дә, туганнарга да житә. Әниләре аларны җавапсыз калдырырга теләми, борынгы шәҗәрәләрнең сызыкларына, түгәрәкләренә бармагы белән ишарәләп, сабыр гына нидер аңлата, сөйли. Улы йотылып тыңлый. Таң калмаслык та түгел бит! Әнә, әниләренең шәҗәрәсе үзенең тамырлары белән Казан ханлыгы дәверендә яшәгән Сәгыйть мирзага барып тоташа, Каюм Насыйри белән булган туганлык җепләре дә шәйләнә.

Милләтебезгә асыл затларны күпләп биргән Шәмсетдиновлар нәселе зыялы буыннардан оеша. Рушан әфәнденең әнисе ягыннан әбисе — Шәмсебану апа — заманында акушерка була, ә бабасы Гали агай мәктәп-мәдрәсәләрдә дәресләр бирә. Аның әтисе ахун Йосыф хәзрәт ятим балалар тәрбияләнгән йортларның попечителе буларак мәгълүм, патша хәзрәтләре үзен алтын медаль белән бүләкли. Алар барысы да — чыгышлары буенча Казаннан. Рәссамның әтисе ягыннан бабасы Гайнетдин агай һәм әбисе Бәдриҗамал апа — шулай ук укымышлы кешеләр — чыгышлары белән Апас төбәгеннән булалар. Алар бераздан Урал якларына күчеп китеп, Серов (Надеждинск) каласында төпләнәләр, ике катлы йортта яшиләр. Бәдриҗамал апа музыкага хирыс була, курай, аккордеонда, баянда һәм мандолинада уйнарга ярата. Аның музыка сәнгатенә карата булган мәхәббәте улларына — Рушанның әтисе Галәф агайга һәм аның энесе Исмай әфәндегә дә күчә. Галәф агай буш вакытларында пианино артына утыра, думбра чиртә. Өлкән улы Инар озак еллар дәвамында Татарстан радиосында тавыш

режиссеры вазифаларын башкара, гармун-баяннар ясаучы буларак та танылa. Исмай Шәмсетдинов исә татарның атаклы профессиональ композиторы һәм музыканты була. Булачак рәссам әнә шундый милли-мәдәни мохиттә, борынгыдан килгән асыл традицияләр сакланган гаиләдә тәрбияләнә, үсә, җитлегә.

1961 ел. Туган халкының тарихын, милли мәдәниятне һәрьяклап рәсем сәнгатендә чагылдыру теләге Рушанны Казан рәссамнар училищесына китерә. Ул зур белгечләрдән һәм сәнгатькәрләрдән дәресләр ала. Программада каралган курслар белән генә чикләнмичә, киңәшләр сорап еш кына галимнәргә, тарихчыларга, археологларга, фольклорчыларга һәм әдәбият белгечләренә мөрәҗәгать итә. Талант һәм тырышлык үз җимешләрен бирә.

1965 елда әлеге училищега татарның күренекле галиме Фуат Вәлиев килә һәм махсус лекцияләр укый башлый. Ул Рушанның тарихи тематикага тартылуын тиз арада сизеп ала һәм аның планнарын, уй-омтылышларын хуплый. Хуплап кына калмый, шәкертнең «Сөембикә» темасы буенча диплом эшенә керешергә теләге зур булуын белгәч, Фуат Хөсәеновичның шатлыгы эченә сыймый. Ул Рушанны рухландыра, әлеге ниятен гамәлгә ашыруга үзенең фатихасын да бирә.



Шәкерт дәртләнеп китә, ул заманнарда атаклы рәссамнарны да шүрләткән тема («Сөембикәнең ире Сафагәрәй белән хушлашуы») өстендә эшли башлый, эскизлар әзерли. Әмма хезмәтне тәмамларга насыйп булмый. Чөнки, мәгълүм, ул чорларда дөньялар башкачарак иде — партия, милли тарихның, мирасның «зарарыннан коткарып», «интернационализм», «патриотизм» кебек шигарьләрне алга сөрде. Мондый шартларда, әлбәттә, Рушанның «Сөембикә»се рәсми идеология белән яраклаша алмый, традицион кысаларга да сыймый. Ул темасын алмаштырырга мәҗбүр була; майлы буяу белән «Җәлилчеләр» картинасын язып, 1966 елда әлеге әсәре буенча диплом яклый, рәссам-педагог белгечлеге ала.

Уку еллары артта кала. Яшь рәссам эшкә Казанның 13 нче мәктәбенә, рәсем һәм сызым укытучысы итеп билгеләнә. Рушанның хезмәт юлы шулай башлана. Иҗади эзләнүләр педагогик эшчәнлек белән бергә үрелеп алып барыла. Ул укыту процессын кайбер яңа алымнар белән баетырга омтыла.

Тормыш шаулы диңгезне хәтерләтә. Рушанны да ул үз дулкыннары белән бөтереп ала. Ул иҗат сәләтен төрле жанрларда сынап карый, төрле газеталарда («Социалистик Татарстан», «Яшь ленинчы») нәфасәт мөхәррире вазифаларын башкара, төрле оешмаларда эшли. Казан сувенирлар фабрикасының читтән килгән туристлар тарафыннан бик яратып алынган продукциясе арасында Рушан әсәрләре дә була.

Остазы Р. Г. Төхвәтуллин аның уңышларына сөенә, әмма кырыс укытучы да була. Беркөнне Рәшит Габдрахманович шәкертенең остаханәсенә гадәттәгедән иртәрәк килә һәм, ишекнең нык ябылуына ышангач, җитди генә сүз башлый:

— Энем, соңгы эшләреңне күргәннән соң, миндә шундый фикер туды: сиңа укуыңны дәвам итәргә кирәк. Зур корабка зур дәрья кирәк булган кебек, талантың югары уку йортына керергә әзер икәнлегеңне күрсәтә. Әйтик, Мәскәүгә...

— Мәскәүгә? — Кечкенәдән үк тыйнаклыкта тәрбияләнгән шәкерте кыюсыз гына башын күтәрә.

— Әйе, Полиграфия институтына. Рәссам-график белгечлеген алырга кирәк. Китап бизәүче рәссамнар — зур гыйлем ияләре, гаять югары дәрәҗәдәге әзерлек үткән белгечләр. Һәр рәссам да китап бизәү серләренә үтеп керә алмый.

Рушан ризалашып ияк кагып куя. Остазының элегрәк тә әйтелә килгән әлеге сүзләренең хаклыгына ул 1968 елдан Татарстан китап нәшриятында бизәүче-

рәссам булып эшли башлагач та ышанды. Китап рәссамы булу — аңа иллюстрацияләр ясау гына түгел, аның тулаем нәфасәт төзелешен дә эшләү. Үзе бер дөнья.


Рәшит абыйсы «син әзер» диде дә... Әмма бит эш талант һәм белем белән чикләнмәскә дә мөмкин. Бигрәк тә Мәскәү хәтле Мәскәүдә...

Ул өченче омтылышта гына Мәскәү полиграфия институтына керү бәхетенә ирешә, ә 1981 елда аны рәссам-график белгечлеге буенча уңышлы тәмамлый. Шул ук елны Мәскәүдә уздырылган сәяси плакатлар күргәзмәсендә беренче урынны яулый! Менә бит ә, Рәшит абыйсы ялгышмаган икән...

Мәскәү дипломын алып кайткач, эшен Татарстан китап нәшриятында рәссам-график буларак дәвам итә. Дистәләгән язучыларның һәм галимнәрнең китаплары аның бизәлешендә дөнья күрә. Алар арасында Акмулланың сайланма әсәрләре, Н. Исәнбәтнең дүрт томлыгы, С. Хәкимнең ике томлыгы, «Татар пьесалары» антологиясе, Х. Туфан, С. Сөләйманова, И. Юзеев, М. Шабаев, М. Әгъләмовның шигырь җыентыклары, С. Баттал, Ә. Гаффар һ. б. әсәрләре, Р. Фәхретдин, З. Вәлиди, А. Халиков, С. Алишевларның тарихи хезмәтләре, Н. Фәттах һәм М. Хәбибуллинның тарихи романнары, фәнни монографияләр, дәреслекләр, төрле календарьлар бар. Рәссамның үзе өчен бигрәк тә үтә затлы итеп эшләнгән «Идегәй» китаплары кадерле. Шулайдыр да, чөнки әлеге басмалар — бер үк вакытта, Татарстан китап нәшриятының һәм татар китапчылыгының да олуг казанышы. Милли китап басу эше дөнья югарылыгына күтәрелеп, үзенең лаеклы дәрәҗәсен яулый икән, биредә Р. Шәмсетдиновның да өлеше зур.

1993 елдан ул — Татарстан китап нәшриятының баш рәссамы, нәфасәт редакциясе мөдире. Ягъни бөтен татар дөньясындагы иң зур вә иң мәртәбәле басмаханәдә дөнья күргән китапларның нәфасәт камиллеге һәм бизәлеше өчен ахыр чиктә Рушан әфәнде җаваплы.

Әлеге асыл затның игелекле иҗаты турында сүз барганда, аның эшчәнлегенең тагын бер юнәлешенә тукталу зарур. Ул — вакытлы матбугатта фидакарьләрчә хезмәт итү.



Мәгълүм булганча, 1991 елның ахырында «Мирас» журналының беренче саны дөнья күрде. Аны оештыру чорыннан алып, редакциядән киткәнче Р. Шәмсетдинов бөтен күңелен биреп, йөрәк җылысын салып эшләде. Аның искиткеч гүзәл, тарихи-мәдәни чынбарлыкны яңача ачкан, тирән фәлсәфи мәгънәгә ия булган рәсемнәре әлеге басманың тиз арада танылуына гаять зур өлеш кертте, көчле этәргеч ясады. Рушан әфәнде Мәҗлиси, Котб, Фирдәүси һ. б. әсәрләренә, милли мирас үрнәкләренә иллюстрацияләр тудырды, милли рәсем сәнгатендә беренче тапкыр тарихи шәхесләр, дәүләт эшлеклеләре (Болгар, Алтын Урда, Казан дәүләте ханнары-хөкемдарлары) портретларының тулы галереясын иҗат итте. Ул берничә дистә берәмлектән тора, аның тарихи-ышандыру көче гаять зур.

Мин аның белән шул чорда, бер коллективта эшләгәндә, якыннан таныштым. Чын иҗат кешеләренә хас тыйнаклык, үтә таләпчәнлек, туры сүзлелек һәм саф намуслылык, хезмәт сөючәнлек һәм сабырлык бөркелеп торган Рушан абый беренче күрешүдә үк миндә тирән ихтирам уятты. Иң җитди мәсьәләләр тугында аның белән һәрдаим киңәшләшә торган булып киттем.

Рушан әфәнде иҗатының төп үзенчәлеге — аның милли традицияләргә, тарихи документализмга нигезләнүе. Рәссам һәр әсәрен иҗат иткәнче махсус әдәбиятны, тарихи чыганакларны җентекләп өйрәнә, фәнни казанышларга мөрәҗәгать итә, галимнәр белән киңәшә. Аның өчен барысы да мөһим: персонаж булачак тарихи шәхеснең ничек киенүе дә, холкы-гамәлләре дә, рухи дөньясы да, хәтта нәрсә ашавы да...

Рәссам үз эчендә генә бикләнеп яшәми. Ул — мәдәни хәрәкәтнең үзәгендә. 1966 елдан бирле республика күргәзмәләрендә даими катнашып килә. 1993 елда Г. Тукай музеенда Р. Шәмсетдиновның шәхси күргәзмәсе була. Аның төрле жанрларда иҗат ителгән әсәрләре куела. Күргәзмә залы ул көннәрдә халык белән шыгрым тулы иде. Бу — республикада гына түгел, халкыбызның мәдәни-сәнгать тормышында, гомумән, зур вакыйга булды. Иҗатының төп мәсләге останың: «бабаларыбыз тарихын бернигә дә алмаштырмыйм» дигән сүзләрендә үк төсмерләнә. Ул Вермеер ван Дельфт, Рембранд, Батичелли, Суриков, Н. Рерих, Врубель, Камалетдин Бикзат, Хокусай, Хиросигэ иҗатларына гашыйк; XVII гасырда яшәгән испан портретчысы Диего Веласкес әсәрләренә сокланып туя алмый.

Р. Шәмсетдиновның иҗаты күпкырлы. Ул плакатлар, портретлар яза, открытка-буклетлар әзерли, товар билгеләре ясый (үзе әйтмешли, маркалар һәм акча гына ясаганы юк икән). 1969 елдан бирле аның тарафыннан утызлап товар билгесе иҗат ителгән, алар халыкара каталогка кертелгән.


Бервакыт аңардан: «Рушан абый, әгәр дә мөмкин булса, кайсы чорда яшәр идегез?» — дип сорадым. Рәссам тәмләп сигаретын суырды да, бер мәлгә уйга калды. Тынлык озак дәвам итмәде: «Беләсеңме,— диде ул,— бу сорау турында уйлаштыргалыйм мин. Хәер, төрле чорларга «кереп чыгарга» туры килә. Нигә дисәң, тарихи әсәр тудыру өчен үзеңне шул чорда дип хис итәргә кирәк. Шулай да, Алтын Урдада, Үзбәк хан заманында яшәр идем»,— дип җаваплады ул.

Әйе, инде бик күп эшләр башкарылган. Ул бизәгән китапларның саны-исемнәре дә берничә йөзләп исәпләнә. Әмма Рушан әфәнде кул кушырып утырмый, яңа планнар белән яши. Менә тиздән Ибне Фазланның Идел буена сәяхәте турында С. Шәмси белән бергәләп оештырган, искиткеч затлы китап та дөнья күрер. Рәссам тыйнак холкына, саф намусына тугры хәлдә яшьнәп иҗат итә. Без аны юбилее белән котлыйбыз, иң изге теләкләребезне юллыйбыз. Уңышлар вә саулык Сезгә, Рушан әфәнде!

**Илшат ХӘЛИУЛЛИН.**

Ф. Әхмәтова-Урманче

# МЕҢНӘР АРАСЫННАН БЕР ЙӨЗ ЭШ



**Татарстанның һәм Россия Федерациясенең — халык, Казагыстанның атказанган рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе (1967) Бакый Идрис угылы Урманче озын һәм күп төрле эшләр башкарган гомер юлы кичте. Ул 1897 елның 23 февралендә хәзерге Буа районы Күл Черкене авылында Идрис мулла һәм Мәгъҗүбә абыстай Урманчелар[1] гаиләсендә дүртенче бала, беренче угыл булып дөньяга килә. Аның тагын өч апасы (Кануга, Мөхсинә, Маһирә), өч сеңлесе (Сафия, Фатыйма, Нәҗибә), ике энесе (Һади һәм Барый) булып, әниләре Мәгъҗүбә абыстай исә уллары Габделбакый белән Габделһадиенең Соловкига — Ак диңгез утрауларына сөрелүен, берсе 5 елдан кайтып, зур рәссам булганын, ә икенчесен 10 ел төрмәдә утыргач, атканнарын да белми дөньядан үткән. Әтисенең һәм сеңелләре Сафиянең (1992 елда вафат), Нәҗибәнең тормышлары бу хәлләрдән соң тәмам пыранзаран килә. Әтисе Идрис хәзрәтнең, имамлыгы алынып сөрелгәч, 1931 елда Казанда авылдашы Гүзәлбаев өендә дөнья куйганын да өч ел соңарып, иленә кайткач кына белә рәссам.**

**Әйе, Бакый Урманче Мәскәүдә укып, 1926 елда Казанга укытырга кайтканда ук бу эшкә әтисенең хәер-фатихасын алган була. Әнисе һәм тәтәнкәсе Маһибәдәр абыстайларның, Бакый ага үзе әйтүенчә, иkende-ахшам арасындагы догалары кабул булышмыдыр, сөргендәге 5 елын 4 елда тутырып Казанга кайтуга, ул биредә калу хәвефле икәнен чамалый һәм торырга Мәскәүгә күчә. Анда Рәссамнар Берлегенә алынып (1937), Донбасска, Башкортстанга иҗат юлламалары белән йөри. Аннан язып кайткан эшләре яхшы бәяләмә ала тора.**

**1941 елда Бакый Урманчены Абай Кунанбаевның 100 еллыгын уздыру эшләрендә катнашыр өчен Алма-Атага чакыралар. Казакъ халкының бөекләре Абай, Амангельды, Җангилдин, Җамбул, Җандәрбәкова, Сатпаев, Әүвәзов, Мокаnов, Мөсрепов, Куанышбаев, Букеева, Таҗиева һ. б.ларга багышланган әсәрләрен аңа шунда Бөек Ватан сугышы елларында иҗат итәргә туры килә.**

**Сугыш бетеп, гаиләсе белән Мәскәүгә кайтуга, репрессияләнгән кешеләргә**

[1] Бу фамилия элек гарәп алфавитында «ь», «е» икесе бер хәреф белән билгеләнгәндә язып калынган, һәм соңрак рәссамның псевдонимына әйләнгән. Аннан соң инде Бакый ага аны хәзерге орфографиядәгечә Урманчы дип төзәтмәгән.

39 башкала һәм порт шәһәрләрендә торырга ярамау хакында СССР хөкүмәте карары чыга («-39» режимы). Шулай, гомеренең иң парлак, иң эшлекле 30 елын ул башта Соловкида, аннан шушы карар нигезендә: Мәскәү ярамый — Владимирда, Ташкентта ярамый — Сәмаркандта, Алма-Атада түгел — Балхашта һ. б. урыннарда яшәп, җан асрарга мәҗбүр ителә.

Казанга кайту турында хыяллана да алмаган бер вакытында аны Ташкентка яңа ачылган Театр һәм Сәнгать институтына скульптура факультетында укытырга чакыралар. Балачактан бирле балчык изеп, агач юнып, инде Казан Сәнгать училищесында укытканда керамика цехлары ачып йөргән рәссамга бу тәкъдим күктән иңгән бәхет булып төшә. Беренче скульптураларыннан «Тукай»ны ул шунда башлый. Хәзер үзләре олуг осталар булып җитешкән Х. Ситдиков, Х. Крымшамхалов, Я. Шапиро, Н. Пак, Н. Ким, А. Назаров, Е. Мельников, С. Абдуллаев, Р. Хәбиб кебек шәкертләрен укыта гына башлауга, аны Мәскәүдә (Ч. Әхмәров, И. Гайнетдинов белән бергәләп) Татар әдәбият-сәнгать декадасын бизәүгә дип эзләп табалар (1957). Шул вакытта Н. Җиһанов, Ш. Сарымсаков кебек сәнгать әһелләре Татарстан хөкүмәте алдында аны Казанга кайтару мәсьәләсен күтәрәләр. Алтмышын узган рәссам чын ирек алып, иленә кайту шатлыгы, яшьлек дәрте белән ашкынып, эшкә чума һәм гомеренең соңгы 30 еллыгында барлык хезмәтләренең 90 процентын иҗат итә.

Ташкентта көйләгән юнәлеш белән Б. Урманче Казанда иң әүвәл скульптура эшләренә керешә. Уралдан платформасы белән 12 блок ак мәрмәр кайтарта.

Әле остаханәсе дә булмаган көйгә, шәһәрнең төрле почмакларында, корымлы подвалларында ап-ак мәрмәрдән Тукай, Әмирхан, Муса, Дәрдемәнд, Кол Гали, Насыйри, Кариев, Ямашев, Камай, Исәнбәт, Воздвиженский, Терегулов, Ленин, Шейнкман һ. б. сыннарын бик тиз арада чокып куя, алар өчен 1967 елда туган иленең Г. Тукай бүләгенә лаек була.

Бронзага бетон кушкан үз рецепты белән янсә башка металлдан — Г. Ибраһимов, Кырлайда һәм Түбән Кама өчен — Г. Тукай, Мамадыш өчен компрессор заводында — Шәйхи Маннур ярымфигурасын, Горбунов исемендәге заводта — Горбунов бюстын, Кокушкинодагы — М. А. Ульянова, Алексеевский районындагы — В. И. Ленин һ. б. бюстларын ул металлдан койдырып урнаштырды.

Ул вакытта исемен телгә дә алырга ярамаган бөек Мәрҗани хәзрәтләренең ярымфигурасы исә шул көе гипста калды. Ул аны граниттан чабарга, салкын мәрмәрдән ут очкыннары сибеп, Риза Фәхретдин, В. Радлов, М. Булатова һ. б. портретларын ясап куярга җыенган иде. Ләкин, гөнаһ-шомлыгына каршы, көч-хәл белән юнәтеп, ун-уникe ел буена үлемсез эшләрен майтарып калган аның шәхси остаханәсе урынында (Соцгород, Трамвайная, 1) завод поликлиникасы корылырга тиеш булып чыга. Бар эшләрен, агач-богач, таш материалларын, эш әсбап-коралларын 50 метрлы фатирына күчергән вакытта аның унбишләп гипс эше (бердәнберләр!) кырылып юк булды. Фотога да төшереп калмаганбыз: профессор Терегулов, студентка Гөлсинә, Володя Ульянов һ. б. истә калган. Мәрмәр Дәрдемәнд ярымфигурасының гына утырып калуы ватучының аңа кулы күтәрелмәвен дәлилләгән сер булып калды.

Шулай тагы бер пыран-заран килү булды. Сынчыга башкорт «Разуриййә» бәетен генә җырлап утырасы да бит — юк, утлар-сулар кичкән Алып шуннан 40 еллар элек «Мин зур эшләр өчен туганмын» дип шигырь язган булса, бу юлы да үзенә хас үҗәтлек белән «Монда минем шедеврларым ясалачак!» дип, үз остаханәсен фатиры астына, Мөхәммәдьяр урамындагы торак мәйданына күчерә. Һәм, чыннан да, өч бүлмәле квартир шартларында зәңгәр балчыктан Салих Сәйдәш, Фәрит Яруллин, Мәҗит Гафури, Шамил Усманов, Шәехзадә Бабич, Салих Батыев, Давид Күгелтинов сыннары барлыкка килә. Дәрдемәнд, Тукай, Әмирхан, Исәнбәт һ. б. бюст яңадан гипстан коелып, кубларга беркетелә. «Су анасы һәм малай» композициясе уймалана. Йомшак агач эченнән «Сөембикә» (юкә), «Намаз» (зирек), «Нәфисә», «Гөлсинә», «Бергә — гомергә», өч гөбе — «Шүрәле» вазалары кебек могҗизалар килеп чыкты. Бу вакытта «Сагыш» (груша), «Язгы моңнар» (чинар), «Тулпар», «Галимҗан Ибраһимов» кебек фәлсәфи-гомумиләштерелгән эшләр (агач) инде музей подвалларында һич реставрация күрмичә яргалана, күгәрә дә башлаганнар иде.

Ә бит шулар белән бергә, бу өйдә аның 78 яшеннән алып 93 кә хәтле (1975—1990) сынлы сәнгатьнең нәгъшь төрендә яңа сүз булырлык «Истәлекләр» циклы иҗат ителде. «Уралтау эргәсендә», «Салтык болыны», «Сабантуй», «Печән базары», «Сак-Сок», «Ибн-Фазланның Болгарга килүе»,

«Библиофил», «Замандаш», «Абай тирмәдә», «Тукай һәм Әмирхан», «Кама Тамагы», «Лобач», «Түбән Ослан» кебек картиналары, «Фәридә», «Төмән кызы», «Фәридә Кудашева», «Диләрә Тумашева», «Камил Вәлиев», «Флора Әхмәтова» кебек дистәләрчә майлы буяу портретлары, йөзләрчә костюм эскизлары, меңнәрчә этюд, пейзаж, тын табигать (натюрмортны ул шулай атады), майлы һәм сулы буяулар белән ясады.

Ул кояш чыкканчы сәгать ярым элек тора, иртәнге намаз белән өйлә арасында гына да (8 сәгать!) эһ тә итмичә, җырлап агач кисә, рәсем ясый, шигырь яза. Кич китап укый, музыка тыңлый. Ашавы таза. 50 ел сызлап, 4 сантиметрга кыскарган аягы авыртуына ул, әйтерсең, игътибар да итми. «Мәңге яшим, дип мал җыю (иҗат), иртәгә үләм, дип гыйбадәт кылу» принцибы белән гомер сөрә ул.

Менә кояш яктысы үзгәрүгә ул майлы буяуларын җыя, палитрасын типтигез итеп кырып чистарта, буягычларын юып, пөхтәләп тәрә дә, мольберт яныннан китә. Барыбер да бетми калган «Намаз» (Нияз), «Бергә — гомергә»ләрен (агач) әз-мәз булса да тукылдатып ала, аннан дәү бер өстәле янына килеп, яткан «Торшон» кәгазен чылатып җәя, кышкы, җәйге, көзге, язгы пейзаж, чәчәк акварельләрен эшли...

Әнә шундый эшләре арасында, сирәк-мирәк сәяхәтләрендә, үзен кай яклары беләндер кызыксындырган шәхесләрнең график портретларын бер-ике генә сызгандай итеп, карандаш йә күмер белән ясап куя. Ул портретлар 1982 елгы зур күргәзмәсендә (250 эш) кеше иң күп йөргән махсус бер галерея сыман булды. Шул вакыттан бирле аларны аерым альбом итеп чыгарырга да хыялланды, музейларга да тәкъдим итте. Әмма моның артыннан йөрергә үзе иҗат эшеннән аерыла алмый, ә портретлар һаман ишәя, берсе өстенә берсе өелеп, кибеп, ышкылып ята. Аларның бер йөзләбен сайлап, рәссамның 100 еллыгына чыгару өчен Татарстан китап нәшриятына тәкъдим иттек. Анда бастырырга алындылар, кереш сүз һәм портрет ияләре турындагы мәгълүматларны да үземә язарга әйткәч, мин рәхәтләнеп риза булдым. Әлбәттә, Бакый Урманченың нәгыйшь (живопись дигәнне ул шулай атады) һәм скульптура эшләрен, графикасын һәм архитектура эшләрен, костюм шәкелләрен, шамаилләрен, шулай ук җырларын, шигырьләрен, мәкаләләрен — һәммәсен махсус галимнәр — сәнгать белгечләре, әдәбиятчылар җыярга, тикшерергә, альбомнар, китаплар чыгарырга тиеш. Ә мин исә рәссамның җәмәгате, варисы буларак кына, фольклорчы башым белән хәлемнән килгәнне эшли торырга булдым: китап әлегә истәлекләр һәм портретлар рәвешендә чыгачак.

103 портретны эченә алган ул китапка казакъ һәм татар типлары, язучылар һәм композиторлар, рәссамнар һәм архитекторлар, педагоглар һәм галимнәр, сөргендәш дуслары сымасын кәгазьдә мәңгеләштергән, карандаш, күмер, тушь белән ясалган әсәрләре тупланачак. Кайда саклануы атап күрсәтелмәгән һәрбер портет өйдә, остаханәдә тора.

Әйдәгез әле, исән рәссам белән 1982 елда Казан күргәзмәләр залының Комлев урамы ягына карап тезелгән бу портретлар илен тагы бер гизгәндәй булыйк.

— Тапшырдык! — дияр иде рәхмәтлебез — шушы әсәрләр авторы Бакый Идрис улы Урманче.

## I. Татар типлары.

1. **Сөембикә.** 1976. кәг., тушь. Татар халкының сөекле ханбикәсе Сөембикә (1518—1537 (?) — нугай морзасы Йосыф кызы, Казан ханы Җангали (1519—1535) хатыны. Җангали үтерелгәч, Казан ханы, Кырым ханнары Гәрәйләр династиясеннән булган Сафагәрәй ханга (1509—1549) чыга. Ул да үлгәч, ике яшьлек уллары Үтәмешгәрәй урынына ханлык кыла (регент). Мәскәү һәм Кырым яклы Казан морзалары ярдәмен таба алмыйча, Явыз Иванга әсир төшкән Сөембикә язмышы хакында улы чукындырылып, 20 яшендә патша мазарында күмелүеннән башка әлегәчә бернәрсә билгеле түгел. Б. Ур-

манче иҗат фантазиясе белән ханбикәнең 4 график, бер скульптура (юкә) портреты эшләнгән (1976, Татарстан Республикасы сынлы сәнгать музее — ТРССМ)

2. **Татар кызы.** 1987. кәг., күм.

3. **Татар кызы.** 1987. кәг., тушь.

4. **Наилә Моратова.** 1984, кәг., күм. (1961 елда туган) Француз теле укытучысы. «Төмән кызы» дигән портретын Б. Урманче майлы буяу белән дә язды (1984).

5. **Чулпан Зиятдинова.** 1986. кәг., күм. Балтач районы Карадуган авылында укытучылар Бакый һәм Мәдинә Зиятдиновлар гаиләсендә туган. Математика укытучысы.

6. **Шәмсия Апакай.** 1986. кәг., санг. Шәмсия ханым Апакай Пенза татарларыннан. 1914 елда Ерак Көнчыгышта туган. Сан-Францискода (АКШ) яши, татар балаларына дин сабаклары, тел, әдәбият дәресләре бирә, җырлар җыеп, аларны кассеталарга язып, татарлар арасында тарата. Коллекциясендә меңнән артык татар җыры бар. Үзе дә матур җырлый, оркестрда уйнаган. 1935 елда Харбинда Кытайның рус колониясендә чибәрләр конкурсында җиңүче булган — «ханбикә күтәрелгән» Казанга Тукай 100 еллыгын, ислам дине 1100 еллыгын бәйрәм итүгә, Бөтентатар Конгрессына катнашырга килде. «Ак калфак» Татар хатын-кызлары Ассоциациясенең идарә әгъзасы. Дүрт-биш ел дуслык шартларында Б. Урманче аның ике график (берсен үзенә бүләк итте), бер нәгышь портретын язды (1988).

7. **Дания Ханкирмән.** 1947. кәг., кар. Касыйм татары. 1947 елда Алма-Атада ике график портретын ясаган. Кем икәне язылмаган — әсәрләр турында мәгълүматларны, һичшиксез, рәссамның көндәлекләреннән табу мөмкин булыр киләчәктә.

8. **Кадрия Корбанова.** 1984. кәг., кар. Себер кызы. Педагог Газиз Әхмәтов гаиләсендә 1959 елда Төмән өлкәсе Тобол районы Күкрәнде авылында туган. Б. Урманче аның өч график, бер нәгышь портретын (1984) эшләде.

9. **Татар хатыны.** 1942, кәг., кар. Алма-Атада ясалган. Кем икәне язылмаган.

10. **Татар кызы.** 1965. кәг., флом. Казанда Соцгород остаханәсенә килеп йөргән студентлардан берсе.

11. **Татар кызы.** 1967. кәг., күм. Казанда Соцгород остаханәсенә килеп йөргән кызлардан берсе.

12. **Татар кызы.** 1971. кәг, күм. Хәлимә исемле бу кызның берничә график портреты ясалган.

13. **Казан татары.** 1963. кәг., күм. Кем икәне язылмаган. «Кызыл Байрак»ка пароход белән барганда ясап кайткан булуы ихтимал.

14. **Каспий татары.** 1956. кәг., кар. Кем икәне язылмаган. 1956 елда улы Илдар белән Каспий дингезе күренешләрен язарга барганнарында эшләнгән.

15. **Донбасс шахтеры.** 1935. кәг., күм. 1935 елда Мәскәүдән Донбасска барып, татарлар тормышыннан күп кенә картиналар язып кайткан, күргәзмәләргә куйган, алар төрле урыннарга сатып алынганнар.

16. **Лампа йөртүче шахтер хатын.** 1935, кәг., күм. «Татарка-лампоноска» исеме белән күп күргәзмәләрдә катнашты.

17. **Почтальон Нина.** 1966. кәг., күм. Исеме ялгыш куелмады микән, бездә ул вакыт керәшен хатыны Аня йөртә иде почтаны.

18. **Шәрифә.** 1935. кәг., санг. (акв.?) Уфада «1 Май» исемле шырпы фабрикасында алдынгы эшче портретын ясаган. Нестеров исемендәге музейда саклана (Уфа).

19. **Пионер кыз.** 1938. кәг., кар. Мәскәүдә бер танышлары кызы портретын ясаган.

20. **Мөхсинә Урманче.** 1956. кәг., кар. Сәмәркандда яшәүче апасының (1893—1989) өч график портретын ясаган.

21. **Дутарчы Шәрифҗан Нәбиев.** 1978. кәг., кар. Мөхсинә апасының кияве. Аның кызы Мәүҗүдә Нәбиева — Ташкентта танылган музыкант. Шәриф ага кызының музыкаль сәләтен Бакый абзаларыннан, дип йөри иде. 1978 елда без Сәмәркандка баргач, көннәр буе дутарда татар, таҗик, үзбәк көйләрен уйнап, Б. Урманчены хәйран калдырды. Шул вакыт рәссам аның ике график портретын ясады.

22. **Сара Баишева-Урманче.** 1942. кәг., кар. Сара Хәсән кызы Баишева-Урманче (1896—1988) Пензаның 1 гильдияле сәүдәгәре кызы, Б. Урманченың беренче никахындагы җәмәгате. Ике график, ике нәгышь портреты язылган («Сара», «Сара һәм Илдар») Казан сынлы сәнгать музеенда сакланалар.

23. **Фирая Закирова.** 1985. кәг., кар. Рәссам белән бер тәтәнкәле (әбиле) кыз туганы. Майлы буяу белән язган портреты Ф. Закировада саклана.

24. **Айдар Урманче.** 1981, кәг., күм. Рәссамның кече улы. 1967 елда Казанда туган. Биш график, бер нәгышь портреты ясалган.

## II. Казахстан.

1. **Куанышбаев.** 1943. кәг., санг. Казахстанның халык артисты. Нәгышь портреты Алма-Ата музейларының берсендә.
2. **Оспанов Танибек.** 1943. кәг., санг. «Пахта-Арал» колхозчысы.
3. **Молдабеков.** 1943. кәг., санг. «Актюбинск» колхозы ат караучысы.
4. **Олугбәк.** 1951. кәг., паст. Олугбәк Мөхәммәд Тарагай (1394—1449). Сәмәрканд хакиме, Аксак Тимер оныгы, галим, мәгърифәтче. Обсерватория ачкан. Б. Урманченың архитектура проекты Олугбәккә Ташкентта куеласы һәйкәл конкурсында икенче урынны алган, әмма куелмаган.
5. **Абай.** 1942. кәг., санг. Абай Кунанбаев (1845—1904)—казах язма әдәбиятына нигез салучы шагыйрь, мәгърифәтче. Б. Урманченың «Абай тирмә эчендә» исемле нәгыщь әсәре дә бар (1982). Аның 1945 елгы нәгыщь эскизы Татарстан Президенты М. Шәймиев тарафыннан 1995 елда Абай 150 еллыгына багышланган бәйрәм вакытында Казахстанга бүләк итеп бирелде. Рәссамның Абайга һәйкәл проекты да Алма-Атада конкурс аша узган (1956), әмма куелмый калган.
6. **Академик Д. Митрохин.** 1943. кәг., санг. Бу графика остасы белән Алма-Атада эвакуациядә булганда аралашып яшиләр. Портрет шул вакытта ясалган.
7. **Ат караучы.** 1949, кәг., санг. Социалистик Хезмәт Батыры Картабай Атшабаров портретын ясаганда Б. Урманче аннан тирмә төзелешен өйрәнә, күп картиналарын язып кала.
8. **Колхозчы Зейналов.** 1942. кәг., кар.
9. **Бригадир Мамут Сасыков.** 1943. кәг., кар. 76 яшьлек колхозчы.
10. **Металл коючы Тасбергенов.** 1943. кәг., күм. Карсакпай эшчесе.
11. **Колхозчы Мамед Газизов.** 1943, кәг., кар. 78 яшьлек колхозчы.
12. **Ләил Бабысов.** 1956. кәг., кар. Каспий дингезе.
13. **Казакъ кызы.** 1943. кәг., кар. Алма-Ата.
14. **Кинорежиссер Дәрига.** 1947. кәг., кар. Мәскәү.
15. **Артистка Александровская.** 1942. кәг., кар. Алма-Ата.

## III. Язучылар.

1. **Әхмәт Фәйзи.** 1948. кәг., кар. Бу портрет Мәскәүдә яшәгән татар язучысы, күп шигырьләр, поэмалар, драма, комедияләр, либретто, сценарийлар авторы, «Тукай» романын гына 61 вариантта эшләгән, язучылардан беренче буларак Тукай бүләге алган (1958) Әхмәт Фәйзи (1903—1958) белән озак еллык дуслык истәлеге булып тора. Якташлары С. Эрьзя (Нефедов) Көньяк Америкадан кайтып, авыр хәлдә калгач, бергәләп аның янына барып йөриләр.
2. **Хәсән Туфан.** 1968. кәг., кар.
3. **Хәсән Туфан.** 1970. кәг., санг. Татар халкының классик шагыйре, Тукай бүләге лауреаты (1966), егерме еллап репрессиядә булган Хәсән Туфан (1900—1981) лирикасын Б. Урманче бик ярата, әмма үзен тиешенчә аңлап бетерә алмавы турында «Хәсән Туфан турында истәлекләр» китабында да язды.
4. **Сибгат Хәким.** 1967. кәг., күм. Күренекле шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе Сибгат Хәким (1911—1986), Татарстанның Г. Тукай, РСФСРның М. Горький исемендәге дәүләт бүләкләре лауреаты, Тукай якташы, Кырлайда аның мемориаль музеен булдыру эшләрендә катнашып йөргән заманнарда өч график портреты ясалды. Берсе Дәүләт музеенда.
5. **Гомәр Бәширов.** 1980. кәг., күм. Татарстанның халык язучысы (1901 елда туган), СССРның Дәүләт бүләге (1951), Татарстанның Г. Тукай (1996) һәм Гаяз Исхакый (1994) бүләкләре иясе Гомәр ага Бәширов белән Б. Урманче гомеренең соңгы чирек гасыры мәгънәви дуслыкта үтте. «Туган ягым яшел бишек», «Җидегән чишмә» әсәрләрен яратып укый, аларга рецензияләр дә язып чыга, «Мең дә бер мәзәк» китабына иллюстрацияләр ясарга, шулай ук нәгыщь портретын язарга да җыена иде, өлгермәде.



*Хәсән Туфан*

6. **Әмирхан Еники.** 1980. кәг., кар. Татарстанның халык язучысы, республиканың Г. Тукай һәм Г. Исхакый исемендәге бүләкләр иясе Әмирхан ага Еникиның (1909 елда туган) рәссам белән самими мөнәсәбәтләре 1935 еллардан башлана һәм иң якын дуслыкка әйләнә. Нәгышь портретын һәм скульптурасын иҗат итәргә әзерләнеп, берничә график портретын ясаган иде. Тегеләре шулай җыену белән калды.

7. **Фатыйх Хөсни.** 1982. кәг., күм. Татарстанның халык язучысы (1908—1996). Г. Тукай бүләге лауреаты (1972), 1—2 сеанс өйдә булды.

8. **Мирсәй Әмир.** 1980. кәг., күм. Б. Урманченың Казан сынлы сәнгать училищесында укыткан елларында килгән беренче шәкертләреннән. Бу еллар турында язучы Мирсәй Әмир (1907—1980), Г. Тукай бүләге лауреаты (1972), «Хатирәләр урманы» (1982) дигән китабында матур истәлекләрен язып калдырды.

9. **Шәйхи Маннур.** 1974. кәг., күм. Шагыйрь һәм прозаик Шәйхи Маннурның (1905—1980) бу портретыннан башка гипс һәм металлдан ярымфигура скульптураларын да эшләде (өйдә һәм Мамадыш районында торалар).

10. **Равил Фәйзуллин.** 1983. кәг., кар. Шагыйрь (1943 елда туган), М. Җәлил (1970) һәм Г. Тукай (1978) исемендәге бүләкләр лауреаты Р. Фәйзуллинның шигырьләрен автор үзе укыганны ярата, Илдар Юзеев, Гамил Афзал, Гәрәй Рәхим, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, башка яшь шагыйрьләр әсәрләрен карандаш тотып, билгеләр ясап, рәссам үзе укый, Сибгат Хәкимне радиодан тыңларга ярата иде.

11. **Мәдинә Маликова.** 1983. кәг., күм. Прозаик (1936 елда туган). 15 ләп китап авторы, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның Х. Ямашев исемендәге бүләге лауреаты, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният эшлеклесе. «Узма, гомер» китабын (1982) китереп бүләк иткәндә ясалган портрет.

12. **Эльмира Шәрифуллина.** 1986. кәг., күм. (1950 елда туган). «Яңгыр җиле», «Гөлләр иле», «Мизгел» дигән китапларын бүләк итте. Шул вакытларда ясалган портрет.

13. **Сәйфи Кудаш.** 1984. кәг., күм. Башкортстанның халык шагыйре, 100 яшенә 100 китабы чыккан Сәйфи ага Кудашның (1894—1993) 90 яшен бәйрәм итәргә барганда ясап калдырган портреты әдип гаиләсендә Уфада саклана. Күп еллык дуслык багланышлары хакында «Тере хатирә» дигән истәлекләр китабында (Уфа, 1994) язылды.

14. **Сәгыйть Агиш.** 1961. кәг., кар. Башкорт язучысы Сәгыйть Агиш (1905—1976?). Казандамы, Уфадамы ясалган портрет икәнен ачыклый алмадым.

15. **Нури Арслан.** 1982. кәг., санг. Шагыйрь Нури Арслан (1912—1990), Г. Тукай бүләге лауреаты (1985), Б. Урманченың Сәнгать училищесында укыткан беренче шәкертләреннән булса да, аның шагыйрь дип танылып китүеннән рәссам канәгать, шигырьләрен бик ярата иде.

16. **Атилла Расих.** 1987. кәг., санг. Троицк каласында 1916 елда туган язучы Атилла Расихтан тәрҗемәи хәле, Яманкала (Троицк) хәлләре һәм бабасы Зәйнулла ишан турында сөйләтеп ясады бу портретны.

## IV. Композиторлар, музыкантлар, артистлар.

1. **Нәҗип Җиһанов.** 1980. кәг., күм.
2. **Нәҗип Җиһанов.** 1980. кәг., күм. Композитор. Күп санлы опера, балет, җыр, симфонияләр авторы, СССРның һәм ТАССРның халык артисты, В. И. Ленин һәм Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләкләре лауреаты, Социалистик Хезмәт



*Нәҗип Җиһанов*

Батыры Нәҗип Җиһановның (1911—1988) 70 яшь тулуына өч график портретын ясады, 1956 елда Руза шәһәрендә ясаган скульптурасы рәссамның беренче сыннарыннан иде, тонлы гипс көенчә өйдә һәм Җиһановларда тора.

3. **Ренат Еникеев.** 1984. кәг., санг. Композитор Ренат Әхмәт углы Еникиев (1937 елда туган), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай бүләге лауреаты (1983). Рәссам аның өч график портретын ясады. «Урманчелы дәвер истәлеге» дип язып китергән «Скрипка өчен романс»ын бик яратып тыңлый иде Б. Урманче. Соңрак композитор рәссамның:

Күңел багладым эшем уңасына,
Тәвәккәл иттем Кодрәт иясенә.
Өметем камил, ышанычым нык
Бу фәкыйрьгә бәхет иңәсенә,

— дигән шигыренә гимник бер әсәр дә иҗат итте. Аны Г. Ильясов җырлавы радиода язулы.

4. **Фуад Мансуров.** 1987. кәг., санг. Танылган дирижер Фуад Шакир углы Мансуров (1928 елда туган), Казахстанның һәм Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге бүләк лауреаты, Мәскәүнең Зур театры, Казан Опера һәм балет театрлары баш дирижеры. Рәссам аның Казандагы концертларын калдырмый, өйдә әңгәмәләре кызу була иде.

5. **Нияз Даутов.** 1985. кәг., санг. Нияз Курамша углы Даутов (1917—1986) — танылган җырчы һәм режиссер, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г. Тукай бүләге лауреаты. Аларның әтиләре дә таныш булып, Идрис хәзрәт углы Бакыйны Курамша дустына малайлыкка Мәкәрҗә ярминкәсенә җибәрә икән. Булачак рәссам шунда татарның бөеге Гаяз Исхакыйның (1876—1954) кулын үбеп күрешү бәхетенә ирешкән. (Кая да булса язылгандыр ул заманнар турында да.)

6. **Мөнирә Булатова.** 1980. кәг., кар. Татарстанның һәм РСФСРның халык артисты, опера җырчысы Мөнирә Закир кызы Булатованың (1914 елда туган) нәгыше портретын 1942 елда Алма-Атада язганнан соң скульптурасын да ясарга керешкән иде. Мин инде ак мәрмәр эченнән Роден Камилласы кебек килеп чыга язган, скифка охшаш мәгърур профилен дә күрә башлаган идем Мөнирә ханымның. Әмма 22-завод поликлиникасы кору татар сәнгате өчен күп нәрсәне хыялда гына калдырды: квартирада мәрмәр чабып булмый.

7. **Фәридә Кудашева.** 1987. кәг., күм. Башкортстан һәм Татарстанның халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты, җырчы, Г. Тукай бүләге лауреаты (1996) Фәридә ханым Кудашеваның (1920 елда туган) нәгыше портретын язганда (1987) иҗат ителгән бу графика әсәре җырчыга 75 яше тулган көнне бүләк итеп бирелде. 1995 елдан ул Фәридә ханым Кудашевада саклана.

8. **Галина Казанцева.** 1980. кәг., күм. Татарстанның атказанган артисты, Опера һәм балет театры солисты, (1953 елда туган) яшел күлмәк, җирән чәч белән язылган матур нәгыше портреты бетмичәрәк калды ахыры, чөнки җырчыбыз кияүгә чыгу сәбәпле сеансларга йөрми башлады. Ике график портретына кулын куйган Б. Урманче, димәк, аларны тәмамланган дип санаган.

9. **Гали Ильясов.** 1986. кәг., күм. Җырчы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Бөтенроссия җырчылар конкурсы лауреаты (1972) Гали Ильясовны (1936 елда туган) беренче мәртәбә Актерлар өендә Нияз Даутов җеназасына килгәндә күреп, күзләренә игътибар итте, килеп ясалырга тәкъдим итте. Артистның көчле тавышын, матур тембрын һәм үзен тотышын ярата иде. Галинең үзе язган һәм итальян җырларын тыңлап рәхәтләнә, Хәлбуки, үзен һәвәскәр дип санап, рәссам артистлар алдында һич җырламый иде. Г. Ильясов юбилеенда кемдер соравы белән җырлап җибәргәч, юбилярның ачык зәңгәр

күзләре яшелгә әйләнде: «Минем тавыш белән — 90 яшьтә?!» дип, хәйран калган иде баритональ тенор иясе.

9. **Рафаэль Ильясов.** 1986. кәг., күм. Татарстанның халык артисты һәм атказанган сәнгать эшлеклесе (1939 елда туган). «Сандугач»ын радиодан ишетеп, үзен күрмәс борын портретын ясарга теләде. Җырчы килде, әмма портрет төгәлләнмичәрәк калганнар исәбендә.

10. **Ания Туишева.** 1985. кәг., кар. Татарстанның халык артисты, җырчы Ания Туишева (1946 елда туган) портретын язу өчен дә этәргеч аның радиодан «Гөлҗамал»ын ишетү булган. Чакырып, ике график портретын ясады, берсен җырчының үзенә бүләк итте.

11. **Лима Кустабаева.** 1987. кәг., кар. Татарстанның һәм Россия Федерациясенең халык артисты, данлыклы Татар җыр һәм бию Ансамбле җитәкчесенең (1945 елда туган) бу портреты япон сәнгатькәрләренә бик ошаган.

12. **Люция Җәлилова.** 1961. кәг., кар. Кинорежиссер Люция Муса кызы Җәлилованы (1936 елда туган) Б. Урманче 1961 елда 26 мәктәп ишек алдында Муса Җәлил һәйкәлен ачу вакытында очраткан һәм ике график портретын ясаган. (Бу турыда: «Сөембикә», № 2, № 5, 1996).

13. **Скрипкачы Халидә Әхтәмова.** 1980. кәг., күм. Мәскәү консерваториясе профессоры Халидә ханым Әхтәмова (1930 елда туган) еш кына Казан консерваториясендә дәресләр бирә, имтихан алырга дәүләт комиссиясенә килә. Шулай бер килгәнендә 20 минутта ясалды бу портрет.

14. **Зариус Шихмурзаева.** 1982. кәг., күм. Мәскәү консерваториясе профессоры, күп халыкара конкурсларда үзе һәм улы лауреат булган бу скрипкачыны (1936 елда туган) Б. Урманче Ташкентта ук белгән икән. Казанга концерт белән килгәнендә ясап, тәмамларга өлгерми калды.



*Шамил Монасыйпов*

15. **Шамил Монасыйпов.** 1985. кәг., күм. Скрипкачы, галим, сәнгать фәннәре кандидаты, Казан консерваториясе доценты һәм халык музыкасы кафедрасы мөдире, шул уку йорты квартетын 15 ел җитәкләп дан казандыручы оста, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Җәлил бүләге лауреаты Шамил Монасыйповны (1945 елда туган) Б. Урманче улы кебек яратты, үз итә иде. Әтисе Хәмит ага, әнисе Разия ханым затлы нәселдән булып, сәләтле дүрт балаларын зур читенлекләр белән гаҗәеп эшчән һәм миһербанлы итеп тәрбияләгәннәрен тәкъдир итә. Үзе дә бала чагыннан яраткан «каз муенын» Шамил һаман асып килер, дөнья классикасы һәм татар музыкасын көне-төне тыңлатыр, дип уйлагандыр, скрипкасы белән нәгыйшь портретын язу һаман чигерелә килде, бу ике график портретына да кул куелмый калды. (Ш. Монасыйповның тәэсирле, җанлы нәгыйшь портретын Урманченың икенче дусты, төсләр остасы Хәнәфи Нафиков язганын да искәртеп үтик). Шамил Монасыйпов үзе дә Б. Урманче иҗатын тирәнтен аңлый, үзен ихтирам итүен «Урманче һәм татар музыкасы» дигән мәкаләсендә язды.— Искусство, рожденное Октябрем. 1989, 55—67 битләр.

16. **Лариса Маслова.** 1985. кәг., күм. Татарстанның халык артисты, виолончельдә уйнаучы Л. Маслованы (1951 елда туган) инструментын күтәртеп тә чакыра, концертларында да еш була, уйнавын рәхәтләнеп тыңлый иде. Әмма Лариса портреты иң әз ясалган эскиз булып калган. «Олы рәссамнарның бетмәгән эше булмый» гыйбарәсен бик сак файдаланып булса да, китапка кертәсе килде. (Аның турында: Р. Гурьянова. Мелодия судьбы. Татарстан, № 11, 1993).

17. **Фатих Бәкер.** 1967. кәг., күм. Элек Казанда — артист, соңыннан Ташкентта юридик фәннәр докторы, профессор Фатих Бәкер (1899—1979) портретын Казанга килгәнендә ясады.

18. **Гөлсем Болгарская.** 1968. кәг., кар. Татарстанның халык артисты Гөлсем Болгарскаяның (1891—1968) үлгәч ясалган рәсеме.

19. **Ширъяздан Сарымсаков.** 1982. кәг., күм. Режиссер, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор Ш. Сарымсаков (1911 елда туган), Г. Тукай бүләге лауреаты, Б. Урманченың үзен дә, сәнгатен дә мөкиббән китеп ярата, ихтирам итә. Кая гына булмасын, рәссамны олылау, мактау — аның үзенең иң мөһим рольләреннән берсе кебек тоела. Б. Урманчены горбәттән кайтару эшен башлап йөрүчеләрдән берсе булганына, әлеге портретны без аның 80 еллык юбилеенда үзенә бүләк итеп бирергә булдык. 1991 елдан ул портрет Ш. Сарымсаковта саклана.

20. **Габдулла Шамуков.** 1980. кәг., күм. СССРның һәм Татарстанның халык, Башкортстанның атказанган артисты (1909—1981) белән самими дуслыкта иде. Ике график портретын ясады.

21. **Шәүкәт Биктимеров.** 1981. кәг., күм. СССРның һәм Татарстанның халык артисты, Г. Тукай бүләге лауреаты Ш. Биктимеров (1928 елда туган) рәссам сөргеннән кайтуга ук декорацияләгән «Беренче чәчәкләр» спектаклендә (К. Тинчурин) Хәмит ролен уйнаган һәм олы шәхесләр сәнгать күгеннән халык тормышына ничек якты нур сибүен үз күзе белән күргәндәй булуын яза. (Ш. Биктимеров. Урманче и театр.— Искусство, рожд. Октябрем. с. 107—108).

22. **Һидият Солтанов.** 1981. кәг., күм. Татарстанның халык артисты Һ. Солтанов (1915 елда туган) белән сеанс вакытындагы әңгәмәләре театр, милләт, Баку турында (артист шунда озак еллар эшләгән) була иде. «Күренеше импозант» дип, ап-ак куе чәчләрен майлы буяу белән бирүгә кызыкты. Әмма бу портретка да «бер генә киләсе, кул куясы бар», дисә дә, ул очрашу ничектер булмый калды.

## V. Рәссамнар, архитекторлар.

1. **Автопортрет.** 1922. кәг., кар. Портрет читенә «Галәм эчендә син мәк орлыгының ничәнче өлеше икәнеңне уйла да елмаюыңны мыек астына яшер» мәгънәсендәге фарсы шигырен язып куйган. 25 яшьлек егет бу вакытта патша армиясендә хезмәт итеп кайткан, ике революция күргән (февраль һәм октябрь), Тамбовта балалар укыткан, Казан сәнгать училищесының авыр имән ишекләрен ачып баккан һәм ашкынып Мәскәүдә укып йөргән.

2. **Автопортрет.** 1946. кәг., кар. Бу автопортрет Мәскәүдә яшәү хокукыннан мәхрүм ителгән елны ясалган. Шушы гаделсезлекне ул Соловкига сөрелүдән дә авыррак кичергән. Мәскәүдән кире Алма-Атага очканда «Самолет Урал тауларына бәрелеп егылса идем», дия икән. Үз-үзе белән көзгә аша сөйләшүдә исә дөньясына нәләт, нишләрмен, дип аптырау да күренми сыман. Инде Алма-Атада 1947 елда ясалган нәгышь автопортретында драматизм да, батыр рухы да кәгазьдәгедән күпкә көчлерәк кебек сизелә миңа (ТРССМ).



*Бакый Урманче*

3. **Илдар Урманче.** 1962. кәг., кар. Илдар Бакый угылы Урманче (1937 елда туган) Мәскәүдә ВГИК бетергән күчле графиклардан. Л. Толстой, Ч. Айтматов, һ. б. әсәрләренә иллюстрацияләре, «Баранкин, кеше бул!», «Утлы еллар җырлары», «Кояш кызы» һ. б. мультфильмнары халыкара конкурсларда югары бәя алдылар. Улы Илдарның график һәм нәгышь портретларын Б. Урманче шактый күп ясады, алар Мәскәүдә И. Урманчеда саклана.

4. **Рәгънә Хәбиб.** 1957. кәг., кар. Рәгънә Хәбиб (1937 елда туган) Ташкент Сәнгать институтында Б. Урманченың сәләтле шәкертләреннән берсе. Кияүгә чыгып, Һиндстанга китә, аннан «Азатлык» радиосына эшкә урнашып, Америкага күчә. 1990 елда мин аны

Мэдисонга (АКШ) фәнни конференциягә барганымда күреп сөйләштем, әмма сынлы сәнгате белән танышып булмады.

5. **Чыңгыз Әхмәров.** 1973. кәг., күм. Татарстанның һәм Үзбәкстанның халык рәссамы, Үзбәкстанның Хәмзә исемендәге дәүләт бүләге лауреаты (1968) Чыңгыз Габдрахман улы Әхмәров (1907—1995) Троицк каласында туып, Пермь һәм Мәскәүдә укып, үзбәк монументаль сәнгатен үстерүгә күп өлеш керткән рәссам. Мәскәүдә 1957 елгы сәнгать Декадасын, Казанда Опера һәм балет театрын бизәгән, татар Милли Үзгенә күп эшләрен бүләк итеп биргән. Б. Урманчены «—39» тырнагыннан азат итеп, 1950 елларда Ташкентка Театр-Сәнгать институтына чакыруны нәкъ Ч. Әхмәров, аның рәфикасы Әшрәф ханым һәм мәшһүр рәссам Урал Тансыкбаев кайгыртып йөргәннәр. Ике график портреты рәссам 1973 елда Казанга килгәнендә ясалды.

6. **Мөхәммәтша Кәримов.** 1982. кәг., күм. Мәскәүдә яшәгән бу рәссам (1915—1985) Казан Сәнгать училищесында (1926) Б. Урманченың беренче шәкертләреннән була. Остазы кулга алынып, аның училищеда калган әсәрләре өстенә башкалар рәсем ясый башлаган яисә чыгарып атканнарында Б. Урманченың 5 мәшһүр әсәрен («Сепаратор янында», «Кичү», «Татар кызы», «Татар егете», «Бикбулатов портреты») музейда яшереп кала, шуның белән татар сынлы сәнгатенең нәгышь төре 1920 еллардан да соң башланмаганын раслау мөмкинлеген ачты. Үзенең персональ күргәзмәсе Татар Сынлы сәнгать музеенда ясалып, 1982 елда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелде.

7. **Абрек Абзгильдин.** 1980. кәг., күм. Татарстанның халык рәссамы һәм атказанган сәнгать эшлеклесе, Рәссамнар Берлеге рәисе А. Абзгильдинның (1940 елда туган) нәгыш портретын язганда (1980) Б. Урманче аның ике график портретын да ясады.

8. **Скульптор Адель Абдрахимов.** 1977. кәг., кар. Красноярскида яшәүче скульптор Габделхак Хәким улы Габдрәхимов 1915 елда Енисейск шәһәрендә туган чын Себер рәссамы. Аны Б. Урманче 1971 елда минем белән Читага халык иҗаты җыю экспедициясенә барганда Красноярскида туктап эзләп тапкан, аның Салчак Тока, Бегичев, А. А. Ванеев, С. Лазо, һ. б. һәйкәлләрен ошатып кайткан иде. Соңыннан А. Абдрәхимов Урманче скульптурасын да ясаганы турында хатта язды, әмма әлегә ул эшнең фотосын да җибәрә алганы юк. А. Абдрәхимов портреты 1977 елда ул Казанга кунакка килгәч ясалды. (Аның турында: Ф. Әхмәтова. Себердә татар рәссамнары.— А. Х., № 1, 1981).

9. **Архитектор Исмәгыйль Гайнетдинов.** 1975. кәг., күм. Казанда Опера һәм балет театрын, Елга вокзалы һ. б. биналар проектын иҗат итте. Мәскәү профессоры Исмәгыйль Гайнетдинов (1899—1976) белән алар 1935 елларда ВСХВда, 1957 елда Татар сәнгать Декадасын бизәү һ. б. эшләрдә бергә булып, бу архитектор даһилыгын аеруча югары бәяли иде рәссам. (Кара: Б. Урманче. Татарстанның сынлы сәнгате.— К. У. № 10, 1960. 138—142 битләр. Һәм И. Гайнетдинов турында — К. У.?)

## VI. Галимнәр, педагоглар, журналистлар.

1. **Академик Камил Вәлиев.** 1989. кәг., күм. Россия һәм Татарстан Фәннәр академиясе хәкыйкый әгъзасы, Мәскәүдә яшәүче академик-физик К. Вәлиевнең (1930 елда туган) нәгыш портреты Б. Урманченың соңгы эшләреннән иде (ул аны «Сездә кеше күбрәк күрер», дип галимнең үзенә бүләк итте). Шул көннәрдә бу график әсәр дә иҗат ителде. (Бу турыда: Ф. Әхмәтова-Урманче. Галим илдә туа.— Соц. Татарстан. 31 январь 1992 ел).

2. **Академик Әбрар Кәримуллин.** 1982, кәг., күм. Татарстан Фәннәр академиясе хәкыйкый әгъзасы, китапчы-галим, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Г. Тукай бүләге лауреаты Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин (1925 елда туган) — 600ләп фәнни хезмәт авторы. Б. Урманче аның ике график портретын ясады, кызып фәнни бәхәсләргә кереп китүләре аркасында (рәссамга галимнең «без татар түгел, болгар» дигән концепциясе ошамый, галим үз карашын яклауга күп дәлилләр китерә) әсәрләр тәмамланып та бетмәде.

3. **Академик Мирза Мәхмүтов.** 1986. кәг., кар. Татарстан Фәннәр академиясе һәм Россия мәгариф академиясе хакыйкый әгъзасы, педагогия фәннәре докторы, профессор, (1926 елда туган), аның берничә график портретын ясады, кайберәүләре тәмамланмаган.

4. **Академик Диләрә Тумашева.** 1985. кәг., кар. Татарстан Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы, филология фәннәре докторы, Татарстаның атказанган фән эшлеклесе һәм Дәүләт бүләге лауреаты Диләрә Гариф кызы Тумашеваның (1926 елда туган) бер график портретын ясады.

5. **Альфред Халиков.** 1981. кәг., кар. Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, тарих фәннәре докторы, археолог, профессор Альфред Хәсән угылы Халиков (1928—1994) портреты шулай ук тәмамланып җитмәгән.

6. **Сәет Рафиков.** 1973. кәг., кар. Россия Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, Башкортстан Фәннәр академиясе президенты, химик Сәет Рәүф угылы Рафиков (1919—1989?) белән дуслык мөнәсәбәтләре бик тирән иде, шигърият, фән, сәнгать турындагы әңгәмәләре, кызганыч, язып калынмаган. 1980 елда озаграк, иркенрәк күрешү, сөхбәтләшү өчен үз машинасы белән Уфадан Янгантау санаториена озатып куйган иде.

7. **Әнвәр Әмирханов.** 1980. кәг., кар. Уфада яшәүче химик Ә. Әмирханов (1914—1984?) җир астындагы торбаларны эчтән һәм тышкы ягыннан саклар өчен төрле катнашмалар уйлап таба иде. Гыйлем Камай шәкерте, Урта Азиядә САГУда укыган заманнарын сөйләвен ихлас тыңлап, Б. Урманче аның шушы график портретын ясады.

8. **Хәйрулла Мәхмутов.** 1956. кәг., кар. Тел галиме, профессор (1914—1978), аның белән Алма-Атада танышып дуслашканнар. Профессор — казах теле турында күп фәнни хезмәтләр язган, төрле сүзлекләр төзегән. 1975 елда шәкерте Олжас Сөләймановның «Аз и Я» китабын җибәртеп, «Өнчы Фәхри»еннe бер тыңлар өчен нилэр бирмәс идем», дип язган иде.



*Шамил Мөхәммәдьяров*

9. **Шамил Мөхәммәдьяров.** 1986. кәг., күм. Тарихчы, Мәскәү галиме (1926 елда туган) татар тарихын иң борынгы заманнарыннан алып тикшерүче. Әтисе медицина профессоры, нарком Фатих Мөхәммәдьяров исеме Б. Урманче яшәгән урамга бирелгәч, шул урамны һәм рәссамны күрергә килүендә ясалды бу портрет.

10. **Хатип Госман.** 1981. кәг., күм. Әдәбият галиме, татар шигъре һәм шигърияте турында күп хезмәтләр язган, Казан университеты профессоры Хатип ага Госман (1908—1992) студентларын гарәп язмасы стильләре (сөлс, тәгълик, нәхү) өйрәнер өчен Б. Урманчега дәрес бирү мөмкинлекләре тапты (шул яшьләрнең берсе, әдәбият галиме Нәҗип Исмәгыйль-Нәкъкаш — хәзер үзен Б. Урманче шәкерте дип саный). Табигатьтән куелган көчле тавышы, моңлы җырлары белән дә профессионал җырчылар алдында авыз ачмаган рәссам дүрт папка шыплап тутырылган шигырьләреннән бер папка сайлап, профессорга биреп карады, әмма аннан бер кәлимә сүз ишетә алмады. «Минем шигырьләрне син генә яратасыңдыр», — дия иде миңа. Юк икән, радиодан Айрат Арсланов укыгач та күп кешегә ошаган алар. Вакыты җитеп, тулы бер китапка җыелып басылса, алар, минемчә, Гали Рәхим, Назыйм Хикмәт һ. б. язган заманны хәтерләтер иде.

Шулай да мисал өчен укучыга бер шигырен язып куясым килде:

Кышкы кич, карлы юлдан йөргән идек,
Матур айны күк йөзендә күргән идек.
Күк йөзендә җемелдәр йолдызларны
«Нинди матур! Нинди матур!» — дигән идек.
Син моңланып күктәге айга бактың.
Мин сокланып синең күзләреңә бактым.
Күңелемдә ай нуры күк моңлы, серле,
Ай нуры күк күгелҗем нурлар якты.

Мин һич сайламыйча, беренче очраган бу шигыренә күз салсам, шул ук кәгазьдә «Васыятем» дигән шигыренә юлыктым.

Газиз дустым,
Әгәр үлсәм,
Каберемә бер матур таш
Син куярсың,
Матур тәгъликъ
Язуыңдан
Таш өстендә
Моңлы-моңлы сүз уярсың. (1935)

Мин моны элек мең кат укысам да, аның мин туган елны язылганына игътибар итмәгәнмен. Ул «матур таш» — кара гранитны болгар ташларына охшатып кистерү, фото-барельеф куйдырмыйча, мәшһүр имзасын ерактан күренерлек итеп яздырып кую миңа насыйп булды. «Матур тәгъликъ» белән Нәҗип Нәкъкаш язды (ташка Альфред дигән егет уйды). «Моңлы сүзләр» өчен ихтимал үзе ризалыгын да бирмәс иде, чөнки алар Аллага хәмд — «Сәйфелмөлек» дастаныннан алынды:

«Гаҗәп кадыйр торур, кодрәтләрен күр,
Гаҗәп санигъ торур, сәнгатьләрен күр»нең соңгы юлы.
Ярлыкагыл, Раббем!
Дога кылып үтегез рәссамга да, аннан ерак ятмаган профессорга да.

11. **Мөхәммәт Гайнуллин.** 1982. кәг., кар. Татарстан һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, әдәбият галиме, профессор Мөхәммәт ага Гайнуллин (1903—1985) татар әдәдбиятын өйрәнү һәм өйрәтү эшендә гаҗәеп күп хезмәт куйган галим һәм педагог. «Татарская литература и публицистика» дигән китабын (1983, Казан) матур автограф язып, бүләк итеп китергәнендә ясалып калды ул портрет. Бу фәкыйрь ул китапның җаваплы редакторы иде, Б. Урманче минем һәрбер эшем белән кызыксынып торганга, ул китап белән дә таныш. Әлбәттә, аның әтисе Идрис хәзрәт белән очрашып йөргән, соңыннан Соловкида үзе белән бергә булган Һади Атласыйны «буржуаз милләтче», дип, легендар йөремсәк, милләтен агарту, ислам динен тарату юлында күп эшләр башкарып, Японияда үлеп калган Рәшит казый Ибраһимовны «ата пантюркист» дип язуы йөрәгенә май булып ятмады рәссамның. «Пантюркизм», «панисламизм»нарның «солтангалиевчелек», хәзерге «фундаментализм» кебек уйлап чыгарылган нәрсә икәнен аңлау гына түгел, үз җилкәсендә татыган кеше бит ул. Башка хезмәтләрен, күп эшләвен тәкъдир итә иде галимнең.

12. **Мидхәт Мөхәррәмов.** 1980 (81). кәг., күм. Тарих галиме, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты директоры (1962—1981), профессор Мидхәт Кәрим угылы Мөхәррәмовның (1922—1994) тирән ихтирамын тоеп яшәде рәссам. Портретын ясар алдыннан аның танкта янган, зур җиңүләр яулаган батыр командир булганы турында җизнәсе Мирсәй Әмир очеркын укыдык. Сеанслар вакытында «Идегәй» турында да сүз була иде. Олы кунаклар булганда мәҗлесләребезгә чакырулы. Үзенең 60 яшен билгеләгәндә бер ягына Бакый, икенче ягына Нәкый агаларны утыртып, «Ончы Фәхри»ен җырлатты мәрхүм.

Җегет тә чакларым әй бар иде,
Киң урамлар гына лай тар иде.
Җегет тә булып лай йөргән чакларымда
Шәһәрләр саен ярларым бар иде ләй.

13. **Әделмә Мирбадалева.** 1988. кәг., күм. Мәскәү галимәсе, фольклорда төрки халыкларының эпик мирасын барлап, тикшереп, русчага тәрҗемә итеп, тугыз том хезмәт язган, филология фәннәре докторы Әделмә Сабир кызы Мирбадалева (1934 елда туган). «Евразия халыклары эпик мирасы» дигән сериягә безнең «Бәетләр»не әзерләшергә килеп йөргән заманнарында ясалды бу портрет. Ул күренекле татар галимнәре Мәдинә Богданова кызы, Әмир Нәҗип сеңлесе, әтисе үзбәк зыялыларыннан.

14. **Флора Әхмәтова-Урманче.** 1979. кәг., күм. Бу юллар авторы, (1935 елда туган), рәссамның икенче никахындагы хатыны, фольклорда татар дастаннары, бәетләре кебек эпик жанрларны барлаучы, туплаучы һәм тикшеренүче, филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать белеме институты өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге бүләгенә

халык иҗаты 12 томлыгын әзерләүдәкатнашуы өчен лаекбулды (1989), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Рәссам аның унлап график, алты нәгышь портретын язды («Филолог», «Ф. Әхмәтова», «Флора», «Айгөл», «Себер кызы», «Кама буенда» (ТРССМ).

15. **Фәүзи Йосыпов.** 1981. кәг., күм. Профессор Фәүзи Садри углы Йосыпов (1927—1982), әнисе Хәдичә ханым ягыннан Хәлфин, хирург, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, төп ачышы (оча сөяге сынганда түгәрәк буынны металл белән алмаштыру) турындагы хезмәте Парижда укылып, дөнья медицинасында кулланыла. Бакчасында өч йөз төрле роза гөле үстерә, дөньяда иң байлардан булырак билгеле күбәләк коллекциясе бар иде, тимераякта фигуралы шуу буенча дөнья чемпионы А. Фадеев тренеры Воробьевның тренеры да булган. Каты авыруга дучар булуын белгәч, Казан телестудиясендә аның турында фильм ясап чыгардылар.

16. **Гыйниятулла Терегулов.** 1974. кәг., кар. Уфа галиме. Күренекле терапевт, профессор Гыйниятулла Терегулов (1892—1986). Башкортстанның җылы парлар өстендә утырган «Янгантау» санаторие шифаларын ачкан, тикшеренү эшләре алып барган. Рәссамның авыру аякларын дәвалауда шактый ярдәм итте. Аның Урманче ясаган ак мәрмәр бюсты (1974) Янгантауда тора, Нестеров музеена куелуын тели иде рәссам.

## VII. Сөргендәшләр, якын дуслар.

1. **Микъдат Брундуков.** 1964. кәг., санг. Микъдат Юныс углы Брундуков (1896—1965) 1918 елдан коммунист, заманында Сталинның шәхси секретаре, Үзәк Мөселман Хәрби коллегиясенең хәрби җитәкчесе, Татарстан АССР мәгариф наркомы, Банк һәм Кожсиндикат башлыгы булган. Аның турында М. Мөлековның мәкаләсе «Возвращенные имена» дигән китапта (Казан, 1922). Соловки лагеренда алар 1930—1934 елларда М. Бөдәйли, С. Сүнчәләй, С. Солтангалиев, Кашшаф Мохтар, Һади Атласый һ. б. белән бергә булалар. М. Брундуков кайткач, 1938 елда яңадан 8 елга сөрелгән. Б. Урманче Казанга кайткач М. Бөдәйли белән бергә аралашалар иде. Портрет шул вакытта ясала. (Шагыйрь, галим, юстиция наркомы, үзе белән озаграк аралашкан М. Бөдәйли рәсеме исә, дәһри булганынамыдыр, ясап калынмаган).

2. **Исмәгыйль Хантимер.** 1976. кәг., күм. Мәскәүдә Тимирязев академиясендә укыган хвалын татарларыннан (1898—1992). Б. Урманче ВХУТЕМАСТА укыганда танышканнар, Бутыркада да, Соловкида да бергә булалар. Исән-сау кайткач, И. Хантимер Сыктывкарда үз белгечлеге буенча фәнни-тикшеренү институтында эшли, 81 яшендә кандидатлык диссертациясен яклый, тундрада терлек азыклары үстерү турында фәнни хезмәтләрен бер кулы белән икенчесен тотып, бер бармак белән машинкада басып иҗат итә: урман бете тешләп, кулы калтыранып калган була (энцефалит). 1969 елда өч соловчан Әстерханда очрашканнан соң өченчеләре — СССР Фәннәр академиясе Балыкчылык институтында эшләгән юрист Борһан Бадамшин һәм И. Хантимер Казанга килделәр, соңгысының портреты шунда ясалды. Б. Бадамшинныкын ясап үзенә бүләк иткәндерме, бездә андый әсәр юк.

3. **Али Юнусов.** 1978. кәг., кар. 1952 елда Ташкентка ТТХИда укытырга чакырылганчы, Б. Урманчега Сәмәркандда апасы Мөхсинә янында торгалап китәргә туры килә. Шул вакытта үзбәк Социалистик хезмәт батырлары портретларын язар өчен Сачәк-Болак дигән авылга баргач, шулай ук сөрелүләрдән качыбрак яшәгән Казан татары мәшһүр Юнысовлар нәселеннән бер табиб белән очраша. «Сельский эскулап», дип тыйнак кына таныштыра ул үзен, һәм утыз елларга сузылган дуслык, утызар битле хатлар, шигырьләр йөри ике арада. 1978 елда яңадан Сәмәркандка барып күрешкәч, ике график портретын ясады. Али Юнысов (1896—1986) — патша армиясе офицеры, Колчак белән киткән, Зәки Вәлиди янында хезмәттә булган. Япония аша Төркиягә килеп, Ататөрк хөкүмәтендә җаваплы хезмәттә була. Иленә кайту мөмкинлеге чыгуга ук Әстерханда кулга алына, аннан кайтып, гомерен Сачәктә тәмамлый. Истәлекләре Мәскәүдә улы табиб Морад Али углы Юнысовта булырга тиеш.

Карандаш һәм кәгазьдәге портрет, гади тарихи фактлар янына Али Юнысовка багышланган күп шигырьләреннән берсен китереп үтәсем килә. Аның бәлкем

сәнгатьчә әлләни кыйммәте дә булмас, анда саналган урыннар да аларны күн саен күреп йөрүчеләр өчен яңалык түгел. Әмма сөрелеш ике сәргәрдан күңеле сулкылдавын сиздереп, татарның дөнья бәясе ике гылым газиз илләреннән аерып, сагынып яшәүгә дучар итүчеләр өчен нәләт булып яңгырар бу сүзләр:

Казан, Кабан, мәшһүр Болак елгасы.
Уртасында Печән базары...
Үсмер чакларыбыз узган Казанда,
Укыган мәдрәсәң — Беренче гимназия.
Толстойлар шунда укыган.
Минем альма-матер — мәдрәсәи «Мөхәммәдия»,
Барудилар шунда укыткан.
Син бер якка киткән, мин — башкага.
Очраштык, гомер байтак узгач инде,
Илебездән ерак калада,
Калада да түгел, бер авылда,
Данлы кала Сәмәрканд янында.
Таныштык.
Күңелләрдә урын табыштык.
Авыз итеп яшь йөзем шәрабыннан,
Хатирәләр белән кавыштык.
Таңнар атты, пылау янарды.
Истәлекләр һаман кабарды:
Озын урам тау башында.
Бер очында Сөембикә, хан мәсҗеде,
Бер очында ак колоннада —
Мәшһүр Казан университеты.
Болакны үтеп, киттек төрле якка.
Җиттек шулай Идел буена...
Күтәрелде кояш...

4. **Шакир Мөхәммәдьяров.** 1956. кәг., кар. Бу «чын татар зыялысын» (Ә. Еники) Б. Урманче «Шакир азый Мөхәммәдьяров» дип, бик еш телгә ала иде. Мәсәлән, «күпме очрашулар, әңгәмәләр булмый калган» дигән сүзен кабатлаганын мәҗлестәш-утырдашлары әле хәтерлиләрдер дә. Гаяз Исхакый белән бергә Казанда Учительская школада, Петербур университетында юристлыкка укып, дипломын Мәскәү университетында имтихан тотып алган Ш. Мөхәммәдьяров (1883—1967) — IV Думаның мөселман фракциясе сәркатибе, 1912 елда Петербурга килгән Г. Тукайны каршы алып, урнаштырып, озатып йөрүчеләрдән булган. Репрессияләрдән азат булгач (әмма кайберәүләр күз карашы астында), Ташкент каласында яшәп, Ташкент һәм Казанда очрашканнар, портрет Казанга кайтканынчы ясалган. Моннан башка майлы буяу белән язылган портреты да булганын мин Әмирхан ага Еники тарафыннан Ш. Мөхәммәдьяровның Т. Ченәкәйгә язган бер хатын бастыруы аркылы гына белдем («Мирас», № 9, 1992, 23—30 битләр). Кайда хәзер ул портрет, миңа билгеле түгел.

5. **Рушад Хисаметдинов.** 1976. кәг., кар. Кыргызстанның Ош каласында яшәп калган җәлилче (музыкаль ансамбль җитәкчесе булган), ветеринар Рушад Билал улы Хисаметдинов (1911—1992) Казанга бер туган апасы Кәшифә ханым, энеләре, сеңелләре янына еш килә иде. Килү белән Бакый Урманче янына омтыла, сөйләшеп сүзләре бетми, җырлашып моңнары сүрелми торган затлар иде. Икесе дә мәрхүм инде, Аллаһеның рәхмәтендә булсыннар. Һәм табигатьләре, һәм йөз-кыяфәтләре, һәм фикер-хисләре белән туганнардай охшаш, татарның типик уллары иде алар. Күңелгә түгелергә торган саф зәңгәр күзләре төсен үлгәнче үзгәртмәде бугай бу ГУЛАГ кичергән батырлар. И. Хантимер һәм Б. Урманченың 90ны узгач та күзләрен картлык элпәсе, дым капламады.

Ишектән керә-керешкә Рушад абый күзләрен йомшак төбәп карый, исәнләшеп, дога кылып утырышуга, кичә тукталган әңгәмәсен дәвам иткәндәй, матур итеп сөйләргә керешә иде. Алар һич лагерь дәһшәтләрен, шәхесне изә торган кансызлыкларны сөйләмәделәр, мәгърурлар! Рушад абый бик ансат үлеп кала торган чакта да «их бин арцт» (мин табиб!) «их бин мослем» (мин мөселман!) дип кычкырып өлгерүенә «Ходай

рәхмәте беләндер, әнкәм догалары беләндер», ди, ничә мәртәбә автомат читкә борылган. Ул килеп керүгә мин өстәлгә магнитофон куям, шулай 4—5 табаклык истәлекләре язылып калды. Алар кыскача «Казан утлары» журналында басылып чыкты (1995, № 9). Кызганыч, ул аларны үзекый алмады.

Менә бу һәм тарих, һәм сәнгать ягыннан гаҗәеп кыйммәтле график портретлар күргәзмәсе буенча сәяхәтебез тәмамланды. Аларның кайс нинди сәнгать алымы белән башкарылганы, нинди ысул белән рәссам теге яки бу шәхеснең иң отышлы ягын күрсәтә алганы хакында сәнгать белгечләре сөйләр. Мин исә гади юлдаш ролендә сезнең белән татлы хатирәләр дәрьясында гиздем. Дастаннар ахырында әйтелгәнчә:

> Доганыздан фәрәмуш итмәнезләр (онытмагыз),
> Хата йирен төзәтмәй китмәнезләр.


## МИЛЛИ ГАЗЕТАБЫЗНЫ — һӘР ГАИЛӘГӘ!

«Шәһри Казан» — Татарстан башкаласында чыга торган иң яшь, иң дәртле, вөҗданиятле вә илһамиятле, иҗтимагый вә сәяси чын милли газета!

Бүген һәм якын киләчәктә газета битләрендә Сез:

— татар халкы һәм аның данлы мәркәзе — Казан тарихы, милли мәгърифәте, мәдәнияте, әдәбияте вә сәнгате,

— чын мөстәкыйльлек, икътисади бәйсезлек өчен барган көрәше,

— башкалабызның көндәлек чуар вә күптөрле хәяте,

— дөньяда барган мөһим вакыйгалар, «кайнар нокталар»дан язмалар,

— халык авыз иҗаты энҗеләре, яңа вә борынгы гореф-гадәтләре, яңа «йолдыз»лар, яңа җырлар, яңа исемнәр, яңа китаплар,

— үтемле реклама, спорт, сәүдә, тамаша яңалыклары, телерадиопрограмма,

— дин вә мәгыйшәт, татар халкының данын үстергән шанлы зат вә шәхесләр турында

тулы вә тәфсилле мәгълүмат алачаксыз!

**Язылу бәясе:**

**Казанда** — 54208 индексы белән: бер айга — 3800 сум,
ярты елга — 22800,
бер елга — 45600 сум.

**Район вә авылда** — 54126 индексы белән: бер айга — 6600 сум,
ярты елга — 39600,
бер елга — 79200 сум.

Яшәп яткан чакта бер көйгә —
«Шәһри Казан» булсын һәр өйдә!

# Маннур Саттаров

## «Бергә-бер» уены

Утырдым экранга каршы,
Узып бүлмә түренә.
«Бергә бер» дигән тапшыру
Тартты мине үзенә.

Рингыда ике демократ:
Берсе ялган, берсе чын.
«Чын» вә «Ялган» дип исемлик
Ике як сугышчысын.

Башымда тик бер генә уй:
Кем өстен чыгар хәзер?
Әлбәттә, Ялган батырны
Чын батыр егар хәзер!

Таныштыргач алар белән,
Көрәш китте башланып.
Бу ни хәл? Ялган батырга
Кул чаба зал шатланып.

Чын батырның сукканыннан
Чәчрәгәндә чаткылар,
Дәшми берни, су капкандай,
Ялган батыр яклылар.

Зал тулы Ялган кавеме —
Йөзләрен яшермәгән.
Күрәм ки: Чынны сөйгәннәр
Бу залга дәшелмәгән.

Ялган үз мәкерлекләрен
«Фаш иткәч» Чынга ябып,
Зал белән бергә судья да
Кул чапты «Ура!» ярып.

Микрофон аның кулында,
Сөйли гел Чынны каклап.
Ә Чынга бирми секунд та
Әйтергә үзен яклап.

Чын батыр чыдасын гына
Парлашып тукмауларга.
Күз кыса Ялган елмаеп
Залдагы куштаннарга.

Суктылар билдән түбән дә,
Заманы башка, имеш!
Алкышлар — Ялган батырга,
Чын батыр аста, имеш!

Хакның җиңү тантанасын
Күзәтү иде уем.
Юкка мин үзәк каналдан
Көткәнмен гадел уен!

Чынны хур итәргә дәшкән
Миллионнарның каршына,
Биреп мыскыллау сабагы
Мескен Рәсәй халкына.

## Матбугат «сакчысы»

Ул шагыйрь дә түгел үзе,
Иҗат итми көйләр дә,
Юк сокланырлык эшләре
Үлгәч сагынып сөйләргә.

Хезмәте шул: «хәтәр» сүздән
Саклый гәҗит капкасын,
Ягъни дөреслек авазы
Халыкка юл тапмасын.

Ат казанды бу эштә ул
Ал байракка юл биреп,
Инде «персональный» көтә
Каракошка буй бөгеп.

Бер ул эшсез кала язды
Хакны сөйләү хут алгач,
Тик янә кирәге чыкты
Ак йорт эчен ут алгач.

Яңа дәрт, гайрәт белән ул
Керде эш калыбына:
Өйрәтә иҗат кешесен
Сәнгать осталыгына.

Былбылга, мәсәлдәгечә,
Бирә Ишәк киңәшен:
«Сайрарга Әтәчтән үрән,
Килсә концерт бирәсең!»

Халык әйткән күздә тотып,
Шәт, аның ишеләрне:
«Белгән эшли, белмәгәне
Өйрәтә кешеләрне».

«Абзыйлар сөймәс»,— дип әйтми,
«Җыр түгел,— ди,— җырларың!»
Куша мәкалә язарга
Сүтеп шигырь юлларын.

Мәкалә китерсә бераү,
«Яз,— ди,— шигырь иттереп».
Куркуын хаклык сүзеннән
Әйтми нигә кистереп?

Булды бездә кол түрәләр
Һавалы, мәртәбәле.
Әмма халык берсенә дә
Куймады һәйкәл әле!

Цензураны бетте диләр,
Юктыр аның бетәсе.
Ялган патшалык иткәндә
Хаклыкка ни көтәсе?

## ХӘТЕР КӨНЕ

15 октябрьдә, елдагыча, башкалабыз Казанда һәм башка күп кенә шәһәр-авылларда Хәтер көне, дистә меңләгән милләттәшләребез катнашында, оешканлык белән үтте. Билгеле булганча, моннан 444 ел элек, Явыз Иван гаскәрләре Казан ханлыгының баш шәһәренә җимергеч һөҗүм ясыйлар — яндыралар, талыйлар, үтерәләр...

Менә шушы фаҗигале көнне хәтердә яңарту, илбасарларга каршы изге көрәштә шәһит киткәннәрне искә алу өчен Казанның Ирек мәйданына Чаллы, Әлмәт, Мамадыш, Әстерхан, Уфа, Чита, Чабаксар, Ижау һ. б. шәһәрләрдән дә күп милләттәшләребез килгән иде. Әзербайҗан, чечен туганнарыбызның да әйтер сүзләре яңгырады.

Матәм митингысын милли хәрәкәт лидерларының берсе — күренекле язучы, отставкадагы полковник З. Зәйнуллин ачып җибәрде. Харис хәзрәт 1552 елдан алып бүгенге көнгәчә барган сугышларда шәһит киткән мөэмин-мөселманнар рухына дога индерде. БТИҮ президенты М. Мөлеков, Татар иҗтимагый үзәге рәистәше Р. Сафин, Татарстан мөфтие Габдулла хәзрәт, Мәрҗани мәчете имамы Госман хәзрәт, галим Г. Фәйзрахманов, җырчылардан В. Гыйззәтуллина, М. Галиев һ. б. дистәләгән милләтпәрвәрләребез үз чыгышларында милли азатлык көрәшендә бер сафта барырга, бердәм булырга, үзара дус-тату яшәргә өндәделәр.

Митингтан соң җыелган халык, тигез сафларга басып, Казан Кремлендәге Сөембикә манарасына юнәлде. Биредә, шәһитләр рухына багышлап, янәдән дога кылынды.

## МАЛАЙЗИЯ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — КАЗАНДА

6 октябрьдә мәркәзебез Казанга Галиҗәнап Король Принц Тунку Нәкыеддин ибн Туанку Җафар житәкчелегендә Малайзия делегациясе килде. Югары дәрәҗәле кунакларны Кремльдәге резиденциясендә ТР Президенты М. Шәймиев, Хөкүмәт йортында Премьер-министр Ф. Мөхәммәтшин, Татарстан Парламентында Дәүләт Советы Рәисе урынбасары З. Вәлиева кабул итте. Җылы шартларда узган әлеге очрашулар барышында һәр ике ил өчен дә файдалы хезмәттәшлек турында сөйләшүләр булды. 9 октябрьгә хәтле дәвам иткән визит барышында Малайзия делегациясе вәкилләре Татарстан Республикасының сәүдә-промышленность палатасында, Зеленолдагы судно-лар төзү заводында, Казандагы оптика-механика, вертолет заводларында, авиация берләшмәсендә һ. б. урыннарда булдылар.

## ПОЛЬША ТАТАРСТАНГА ЯКЫНАЯ

19—21 октябрь көннәрендә Президент М. Шәймиев житәкчелегендәге Татарстан делегациясе Польшада булып кайтты. Аның барышында ике дәүләт арасында үзара файдалы хезмәттәшлек турында эшлекле сөйләшүләр, күпсанлы очрашулар булды. Татарстан кунакларын Лодзь шәһәрендә бик җылы каршыладылар. Биредә Татарстан Икътисад министрлыгы һәм Лодзь воеводалыгы арасында сәүдә-икътисад, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү төзелде.

Польша Республикасы Президенты А. Квасьневский Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевны, зур хөрмәт күрсәтеп, үз резиденциясендә кабул итте. Сөйләшүләр вакытында Польша һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлегенең аерым мәсьәләләре тикшерелде.

## АКШ ВӘКИЛЕ — КАЗАНДА

17 октябрьдә АКШ Президентының милли иминлек мәсьәләләре буенча элеккеге махсус ярдәмчесе, Россия, Украина һәм Евразия дәүләтләренең милли иминлеге Советының баш белгече, хәзерге вакытта АКШның Дәүләт секретаре Кристоферның мәгълүмат-тикшеренү мәсьәләләре буенча ярдәмчесе Тоби Тристер Гати ханым беренче тапкыр Казанга килде. Американың олы кунагы Татарстан Президенты М. Шәймиев, ТР Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин, Казан шәһәре мэры К. Исхаков һ. б. рәсми кешеләр белән очрашты. Сәясәт һәм икътисадтан тыш, аны Татарстанның Россия Федераль хакимиятләре белән үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсе дә кызыксындырды.

## ТАТАРСТАН — МӘСКӘҮ КҮПЕРЕ

14 октябрьдә Казанда Татарстан Дәүләт Советы белән Мәскәү шәһәре Думасы арасында хезмәттәшлек турындагы беркетмәгә кул куелды. Ул илнең регионнары арасында горизонталь элемтәләре ныгытуга юнәлдерелгән. Документка ТР Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев һәм Мәскәү Думасы Рәисе В. Платонов кул куйдылар.

## КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМӘНЕ ОЛЫЛАУ

15 октябрьдә ТР Президенты М. Шәймиев күренекле тюрколог, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Диләрә ханым Тумашеваны кабул итте.

Президент, 70 яшьлек юбилярны кайнар котлап, татар телен үстерүгә юнәлдерелгән биниһая зур хезмәтләре өчен, аңа ихлас рәхмәтен белдерде, сәламәтлек, бәхет һәм иҗат уңышлары теләде.

## «АЗАТЛЫК» РАДИОСЫ РӘХМӘТЕ

16 октябрьдә Прагадан — «Азатлык» радиосының Татар-башкорт редакциясе мөдире Фәрит Иделледән ТР Президенты М. Шәймиев исеменә телеграмма алынды. Анда болай диелә: «Казанда «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе корпунктын ачуда һәм моның өчен бина табуда ярдәм күрсәткәнегез өчен ихлас күңелдән рәхмәт белдерәм. Бәйсез Дәүләтләр Берлеге башкалаларында гына эшләп килгән мондый хәбәрчеләр үзәгенең Татарстан башкаласында да ачылуы демократия үсешенә һәм республиканың мөстәкыйльлеген ныгытуга уңай йогынты ясар дип уйлыйм»...

## УРАМНАР ИСЕМНӘРЕН ҮЗГӘРТӘ

Казан шәһәр хакимиятенең топонимика комиссиясе башкалабыздагы кайбер урамнарны үзгәртү турында тәкъдим кертте. Ленин урамы — Кремль урамы, Куйбышев — Александр Пушкин, Городецкий — Карл Фукс, Комлев — Хәмит Мөштәри урамнары дип аталып йөртеләчәк. Ульяновлар урамы да исемен бераз «үзгәртте» — Ульянов-Ленин урамына әверелде. Әле күптән түгел генә тууына 70 ел тулган мәрхүмә шагыйрәбез Сажидә Сөләймpraнованың да якты истәлеге мәңгеләштерелде — Казанның Киров районындагы бер урамына аның исеме бирелде.

## ҮТКӘНЕН БАРЛЫЙ ХАЛЫК

Аксубай районының Шәрбән авылында әлегәчә татар авылларында сирәк очрый торган зур бәйрәм булды. Ул борынгы Болгар заманындагы Шәһре Бану — Шәрбән каласының нигезләнүенә 1100 ел тулуга һәм биредә яңа мәчет ачуга багышланган иде. Әлеге бәйрәмгә Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләреннән һәм башка төбәкләрдән күпсанлы кунаклар кайткан иде. Тантанада тарихчы-галимнәрдән С. Алишев, Ф. Хуҗин, Ә. Хәйри, язучылардан Т. Миңнуллин, Н. Гыйматдинова, Р. Миңнуллин, К. Фәсәхов, Ш. Мостафин, «Биләр» фонды җитәкчесе Р. Кормашев, Мәрҗани мәчете имам-хатыйбы Г. Саматов, ТР Мәдәният министры урынбасары М. Низамиев, Аксубай районы хакимияте башлыгы М. Халитов, «Әл-зәкят» хәйрия фонды вәкилләре, Татарстан радиосының «Балкыш» программасы мөхәррире Г. Нургали, җырчылардан И. Биктаһиров, Н. Мусина, А. Хәйри, баянчы-композитор Ф. Хатыйпов, нәфис сүз остасы И. Сафин һ. б. чыгыш ясады.

## ЧУВАШСТАНДА — «КАЗАН УТЛАРЫ» КӨННӘРЕ

Октябрь аеның икенче ункөнлегендә Чувашстан Республикасының Батыр районында, Татарстаннан килгән бер төркем язучылар катнашында, «Казан утлары» журналы көннәре булып үтте. Анда журналның баш мөхәррире — шагыйрь Равил Фәйзуллин, журналның бүлек мөхәррирләре — Шамил Маннапов һәм Шаһинур Мостафин, Татарстан радиосының баш мөхәррире Җәүдәт Дәрзаман, Казан дәүләт университетында эшләүче галим-язучылардан Ринат Якуш һәм Җәүдәт Сөләйман (аларның соңгы икесе — шушы төбәктән) катнаштылар. Алар районның Шыгырдан, Татар Согыты, Кызыл Чишмә авылларында булып, хезмәт ияләре, мөгаллимнәр һәм мәктәп укучылары белән очраштылар, «Казан утлары»ның үткәне, бүгенгесе һәм алданиләр башкарачагы турында сөйләделәр, тыңлаучыларны үзләренең иҗатлары белән дә таныштырдылар. Мәктәпләрдә һәм мәдәният йортларында зур җанлылык белән үткән әлеге очрашуларда Чувашстанда татар телендә чыгучы «Вакыт» республика газетасының баш мөхәррире — шагыйрь Ринас Гайфин, җирле авторлардан Кәлиф Вәлитов, Минназыйм Ибраһимов, Әсрар Халитов һ. б. да чыгыш ясады.

Татарстаннан килгән кунакларны Батыр районы хакимияте башлыгы вазифаларын башкаручы Анатолий Бабаев һәм хакимнең беренче урынбасары Миннегали Хафизов кабул итте. Чувашстан мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти Альбир хәзрәт Крганов белән очрашу да булды.

Районда «Казан утлары» көннәрен оештыруда Шыгырдан, Татар Согыты авыл Советларының җирле үзидарәләре башлыклары Наил Вәлитов, Миннәтулла Вәлиуллов, «Байрак» күмәк хуҗалыгы рәисе Ринат Сираев, Шыгырдан, Кызыл Чишмә урта мәктәпләре директорлары Наилә Алиева, Сәет Гаязов һ. б. үзләреннән зур өлеш керттеләр.

## ЯҢА КИТАПЛАР КӨНЕ

Китап язмышы турында кайгыртып, Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, Татарстан китап нәшрияты белән берлектә, мәркәзебезнең Бауман урамында беренче мәртәбә «Яңа китаплар көне» үткәрде. Анда Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире, шагыйрь Харрас Әюп, татар әдәбияты аксакалы Әмирхан Еники, язучы-галимнәребездән Әбрар Кәримуллин, Тәлгат Галиуллин һ. б. чыгыш ясады. Татар китабы бәйрәменә килүчеләр язучыларның култамгалары салынган яңа җыентыкларын алу бәхетенә дә ирештеләр.

## ЗӘКИ ЗӘЙНУЛЛИНГА — АКМУЛЛА ИСЕМЕНДӘГЕ БҮЛӘК

Башкортстанның Эстәрлебаш районы хакимияте язучы Зәки Зәйнуллинга, үз әсәрләрендә бу төбәк халкының язмышын-тормышын киң чагылдырганы өчен, Акмулла исемендәге бүләкне тапшырды. 8 октябрьдә Эстәрлебашта узган шушы тантанада З. Зәйнуллин әлеге бүләкнең акчасын тулысынча үз авылы мәчете төзелешенә тапшыруын белдерде.

## АВЫЛДА — ЯЗУЧЫ ЮБИЛЕЕ

26 октябрьдә Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Түбән Шөн урта мәктәбендә шушы авылда яшәп иҗат итүче шагыйрь һәм прозаик, әдәби тәнкыйтьче һәм журналист, Киров өлкәсендә татарча чыгучы «Дуслык» газетасының үз хәбәрчесе Рафаэль Сибат (Хуҗин)ның 50 яшьлек юбилеена багышланган әдәби очрашу булды. Язучыны түгәрәк бәйрәме белән котларга Казаннан һәм Кукмарадан, Малмыждан һәм Нократ Аланыннан бер төркем каләмдәшләре, дуслары килгән иде. Очрашуда катнашучылар Казан кунакларыннан Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатлары — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, юбилярның яшьтәше-сабакташы Мөдәррис Әгъләмов чыгышларын аеруча зур кызыксыну белән тыңладылар. Тантанада Р. Сибат та сүз алып, заманында үзе укыган, мөгаллимлек һәм директорлык иткән туган мәктәбе коллективына, авылдашларына яңа гына басылып чыккан әсәрләрен бүләк итте.

## ТАТАР ЗЫЯЛЫЛАРЫ КЛУБЫНДА

Мәскәүдә яшәүче татар зыялылары клубы (җитәкчесе — «Азатлык» радиосының үз хәбәрчесе, язучы Нәзифә Кәримова) үзенең дүртенче сезонын ачып җибәрде. Аның беренче утырышы танылган композитор Алмаз Монасыйпов иҗатына багышланды. Нур өстенә нур өстәп, әлеге очрашуда Клара Хәйретдинова (Казан), Идрис Газиев (Уфа), Наилә Фатыйхова (Мәскәү) кебек танылган артистлар маэстроның әсәрләрен башкардылар.

## КОМПОЗИТОРНЫҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Казан дәүләт университетының «УНИКС» тамаша залында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, танылган композитор Вадим Усмановның тууына — 50, иҗат эшчәнлегенә 30 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе зур уңыш белән үтте. Татарстан Мәдәният министры урынбасары М. Низамиев, шагыйрә Г. Зәйнашева, ТР телерадиокомпаниясе оркестры җитәкчесе Р. Үтәй, радионың музыкаль тапшырулар редакциясе хезмәткәре С. Латыйпова, җырчы В. Ганиева, композитор Л. Батыр-Болгари, нәфис сүз остасы һәм җырчы А. Хәмзин һ. б. Вадимның иҗатына югары бәя бирделәр. Кичәдә Вадимның әтисе — Татарстанның халык рәссамы Мәхмүт ага Усманов та чыгыш ясап, улына үзенең яңа картинасын бүләк итте.

## АНЫ ШВЕЦИЯДӘ ДӘ БЕЛӘЛӘР

Композитор Мәсгүдә Шәмсетдинова музыка сөючеләргә үзенең үзенчәлекле әсәрләре белән күптәннән таныш. Халык моңына, татар фольклорына бөтен барлыгы белән гашыйк бу зур белгечне, маһир башкаручыны Швеция короленең музыка колледжы Стокгольмга бер елга үзләрендә стажировка үтәргә чакырды. Шулай итеп, М. Шәмсетдинова шведларны татар музыкасы, әдәбияты-сәнгате белән тагын да якынрак таныштырачак.

## АКШ АЛКЫШЛЫЙ

Татарстанның танылган җыр осталары Рафаэль Ильясов, Гөлзада һәм һәртөрле уен коралларын сандугачтай сайрата белүче Рөстәм Вәлиев, шәхси чакыру буенча, Америка Кушма Штатларында булдылар. Бирелә аларның концертлары милләттәшләребезнең күңелләренә бик хуш килде.

## «КУРАЙ» РАДИОДУЛКЫНЫ

Казанда «Курай» исемле яңа радиодулкын эшли башлады. Ул татарча тапшыруларны тәүлек дәвамында 73,37 дулкыннарында һәм 4,05 УКВ дулкынында алып бара. «Курай» тыңлаучыларны иң яңа кассеталар, компакт-дисклар белән таныштыра, кабатланмас моңнар белән кавыштыра.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия Федерациясе Президенты Указы белән, сәнгать өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты **Гайнуллина Алсу Әскәр кызына** «Россия Федерациясенең халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Сынлы сәнгать өлкәсендәге уңышлары өчен, Казан каласында яшәүче сынчы-рәссам **Фәсхетдинов Фәһим Нуретдин улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

---

### *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Ибн Фазлан портреты — рәссам Рушан Шәмсетдинов эше.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрә, «Идел» журналының баш мөхәррире урынбасары Роза Кожевникова.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ. **«Иман тәрәз шакый»:** *шигырьләр, балладалар, поэмалар.*— Казан. Татар. кит. нәшр., 1996—336 бит. Тиражы — 2000 данә.

Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты М. Әгъләмовның бу сайланма томлыгында аның төрле елларда чыккан «Кыңгырау», «Учак урыннары», «Исәнме, йөрәк!», «Киләчәккә кайту», «Мин әйттем» китапларыннан иң яхшы шигырь үрнәкләре тупланып бирелгән. Кереш сүзне шагыйрь Ркаил Зәйдулла язган. Китап «Шигырь китапханәсе» сериясендә нәшер ителгән. Мөхәррире — шагыйрь Харрас Әюп. Шигырь сөючеләргә яхшы бүләк булырлык бу китап шагыйрьнең 50 еллыгы уңае белән чыгарылган.

Лукман ЗАКИРОВ. **«Мустафа».** Издательство «Таң-Заря». Казан, 1995 ел. 224 бит. Повесть һәм хикәяләр җыентыгы.




Бу китапка авторның 4 повесте һәм 6 хикәясе кертелгән. Андагы әсәрләр, моннан егерме еллар элегрәк язылган булса да, хәзер генә дөнья күргән. Үз вакытында басылмауның сәбәбе шул: ул чактагы уяу цензура авторны социализм чынбарлыгын «бозып» күрсәтүдә гаепли, фетнәле язмалар дип бәяли. Асылда автор тормышның күпләребез күрмәмешкә салышкан четрекле якларына игътибар итәргә, җәмгыятькә әхлакый чистару кирәклеген аңлатырга тырышкан.

Үзгәртеп кору елларында Локман Закиров көндәлек матбугатта чыккан үткен публицистик мәкаләләре белән танылды. «Казан утлары» журналында исә аның «Инша» һәм «Бүреләр» дигән ике әсәре дөнья күрде.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)